
# Казан утлары

2. 1994



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ

# УКАЗЫ

**«Татарстан Республикасының халык язучысы»,**
**«Татарстан Республикасының халык шагыйре»**
дигән мактаулы исемнәр бирү турында




Г. Ахунов



А. Гыйләҗев



И. Юзеев



М. Мәһдиев

Татар әдәбиятын үстерүдә зур өлеш керткән өчен: язучы **Гарифҗан Ахунҗан улы Ахуновка**, язучы **Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевка**, язучы **Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиевкә «Татарстан Республикасының халык язучысы»** дигән мактаулы исем бирергә.

Татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен шагыйрь **Илдар Гафур улы Юзеевка «Татарстан Республикасының халык шагыйре»** дигән мактаулы исем бирергә.

Казан, Кремль
1993 ел, 24 декабрь

Татарстан Республикасы Президенты
**М. Ш. Шәймиев**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(856)**

**1994**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. РӘШИТ. Аккан суларга карап. *Шигырьләр* . . . 3
Г. ТАВЛИН. Афәт *(Роман-трилогиянең өченче китабы)* . . . 8
Ф. ЯРУЛЛИН. Косна каләм — яктылыкта. *Шигырьләр* . . . 118
К. СИБГАТ. Киләчәкне уйлап. *Шигырьләр* . . . 123
Ф. ЯХИН. Соңарган дастан. *Хикәя* . . . 129
С. ЗАРИПОВ. Юл чатында кабер. *Парча-истәлек* 132

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕННӘН

М. ЖОМАБАЕВ. Ут. *Шигырьләр* . . . 135

ПУБЛИЦИСТИКА

Х. ХӘКИМОВ. Чехлар заманында . . . 139

ӘДӘБИ МИРАС

Т. ӘЙДИ. Үлемсез исем . . . 147
С. РӘМИЕВ, Г. ХӨСӘЕНЕВ. Мөхәммәтгаяз әфәнде . . . 148
Г. АКЫШ. Гаяз Исхакый: Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы . . . 152
В. ГОРДЛЕВСКИЙ. Мөхәммәт Гаяз Исхаков . . . 162

Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан . . . 163

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. ӘМИРХАН. Фаҗигале еллар авазы . . . 168

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Ш. КАМАЛ. Депутат. *Хикәя* . . . 177

СӘНГАТЬ

Г. ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА. Бәхет кошы кая куна? . . . 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман Г. ТАВЛИНА «Бедствие», рассказы Ф. ЯХИНА, С. ЗАРИПОВА, стихи А. РАШИДА, Ф. ЯРУЛЛИНА, К. СИБГАТА.
«Из поэзии тюркских народов»: стихи М. ДЖУМАБАЕВА.
«Публицистика»: очерк Х. ХАКИМОВА «Времена белочехов».
«Литературное наследие»: статьи Т. АЙДИ «Бессмертное имя», С. РАМИЕВА, Г. ХУСАИНОВА «Господин Мухаммедгаяз»; Г. АКЫШ «Гаяз Исхаки»; В. ГОРДЛЕВСКИЙ «Мухаммед Гаяз Исхаков».
«Перед XII съездом писателей Татарстана».
«Из истории народа»: статья Р. АМИРХАНА «Эхо трагического прошлого».
«Навыки чтения на основе латинской графики».
«Дневник общественно-культурной жизни».
На наших обложках «Открытые ворота» — картина художника Р. Насырова; известный поэт А. Рашид.

## IN OUR ISSUE.

«Prose and Poetry»: G. Tavlin's novel» «Galamity»; verses of A. Rashid, F. Yaroullin, K. Sibgat.
« From the Poetry of Turkic Peoples»: M. Dgombaiev's verses.
«Publicism»: essay of H. Nakimov «Times of White Czechs»
«Literary Heritage»: articles of T. Aydi «Immortal Name»; S. Ramiev, G. Housainov «Mr. Mouhammedgayas», A. Akish «Gayas Ishaki», V. Gordlevsky «Mouhammed Gayas Ishakov»
«Before the XII Congress of Tatar writers»
«From the History of Nation»: the article of R. Amirhan «Echo of the Tragic Past»
«Reading Skills on the Basis of Latin Script»
«Diary of the Social and Cultural Life»

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 11.01.94 ел. Басарга кул куелды 9.02.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 020. Заказ А-4. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Әхмәт Рәшит

АККАН СУЛАРГА КАРАП

### 1993 ел — җәй башы

Сибәләп ява яңгырлар —
Чылата җир күкрәген,
Никтер яшеннәр яшьнәми,
Никтер күкләр күкрәми.

Тетрәтеп бар җаннарымны,
Давыллап, җилләп килеп,
Хет коеп яусын иде дә
Әүвәлге чакта кебек,

Күкрәккә пыскан тынлыкның
Котларын алсын иде,
Җандагы сагыш юшкынын
Суларга салсын иде...

Ә ул, үч иткән шикелле,
Сибәли, пыскый бары,
Балкымый күкләр түрендә
Салават күперләре.

Ничә көн инде тоташтан...
Әрни җан, кибә җилек,
Билгесез халәт күңелдә —
Илдәге хәлләр кебек...

* * *

Шигырьсез яши замана —
Җыр-бию, «буги-вуги»...
Мәҗнүндәй гашыйк шагыйрьләр
Дөньяга кабат үги.

---

Әхмәт Рәшит (1936) — *шагыйрь, публицист; «Хатирә», «Сәяхәтнамә», «Давыллар кайтавазы» һ. б. татар, урыс телләрендә басылган унлап китап авторы. Ул — Г. Исхакый исемендәге бүләк лауреаты. Казанда яши.*

Илаһи сүзләр кирәкми,
Күңелләр ашмый күккә.
Спидтан хәтәр чир йоккан,
Әйтерсең, кешелеккә.

Ыштансыз марҗага карап,
Мөкиббән киткән дөнья.
Нигә игътибар итсең ул,
Шагыйрь, дип, сиңа, миңа.

Күр, әнә, татар баласын —
Өнәми милләт җырын,
Коръәнне ятлар урында...
Ул укый «Декамерон».

Рәсемнән карый даһилар
Таң калып мондый эшкә,
Көнләшеп «Анжелика»лар
Ирешкән казанышка.

Язалар такмак-реклама,
Искесен җырның сипләп —
Пушкиннар сүзен беркем дә
Утырмый бүген җөпләп.

Үпкәләп безнең заманга,
Ләгънәтләр ора-ора,
Китап киштәсе артыннан
Тукайлар карап тора.

* * *

Үзгәрә дөнья, диләр дә...
Үзгәрми әле бик үк...
Бүгенге кичә кебек тә,
Иртәсе — бүген кебек.

Сукрана-сукрана кеше
Гел дөнья куа тора.
Бер патша үлсә, урнына
Яңасы туа тора.

* * *

Яманлыкны борын заманнардан
Һаман җиңә килгән яхшылык.
Дөнья күптән камил булмакчы да,
Тик камиллек кенә... юк та юк.

* * *

Кай тарафтан соң бу сихри аваз?
Ни тели ул адәм затына?
Хәбәр булып ерак дөньялардан,
Йолдыз арты йолдыз атыла.

## Юату сүзе

Шул кадәр дә якын булган икән —
Ансыз күңел ничек түзәр инде?!
«Сенелем,— дип әйттең өзгәләнеп,—
Унган иде бигрәк, гүзәл иде...»

Ул синнән дә гүзәл идемени?
Ул да сине шулай сөйдемени?
Аһ, бу дөнья, язмыш кыраулары,
Сезгә дә соң, килеп тидемени?

Ник каныга дөнья матурлыкка?—
Гомер буе шуны аңлый алмыйм.
И Йәнбикә, мондый халәтеңдә
Ничек итеп тыныч кына калыйм?!

Чибәрләргә бәхет күп тәтеми,—
Көнләшмәсен кеше — булмаганга,
Такмасыннар юкка нахак бәла,
Гөнаһлы, дип, гөнаһ кылмаганга.

Аларда да йөрәк бер генә бит —
Яралана торган, сызлый торган;
Бушанасы килгән чакларында
Битарафлар китеп торсын юлдан...

Ул көн миңа гаҗәп мизгел иде.
Күңелеңдә болыт йөзә иде:
Сенелеңне сагынып сөйләдең син —
Елавың да синең гүзәл иде...

## Әле кичә генә

Таңнар аткан чакта гөлләр тирбәләләр,
Гөлләр тирбәләләр, җилләр иссә генә;
Күңел күкләремдә кояш көлә иде,
Кояш көлә иде әле кичә генә.

Нәрсә булды бүген, нәрсә булды болай —
Нигә каплый болыт күңел кояшымны;
Яра салдың җанга, авыр сүзләр әйтеп,
Авырлыгын ләкин үзең тоясыңмы?!

Әле кичә генә, әле кичә генә
Сөям диден бит син, гомерлеккә дидең;
Күзең карашлары үпкә тулы нигә,
Нәрсә булды бүген, нигә башың идең?!

Әйтче, бәгърем, миңа, әйтче ачык кына,
Нигә моң эленде шаян күзләреңә?
Кояш көлә иде әле кичә генә,
Әле кичә генә, әле кичә генә.[1]

[1] Әнвәр Бакиров музыкасы

## Аккан суларга карап

Ага сулар, үтә гомер,
Үтәр дә китәр инде;
Яшәмәдем түгел җирдә,
Яшәдем — җитәр инде.

Арылды ыгы-зыгыдан,
Көнкүреш ваклыгыннан.
Ирештемме, тик, хыялга,
Теләгән чаклы гына?

Мин сөйдем дә, сөелдем дә —
Ят күрмәде чибәрләр;
Мин үлгәч, кемнәрдер мине
Әле сагынып сөйләрләр.

Гөнаһлар, әйе, булгандыр,
Савап та аздан түгел —
Фәрештә кебекмен, димим,
Тик юлдан язган түгел.

Мин яшәдем ходай биргән
Нигъмәтне татый-татый...
Булганы булды, ә алда —
Аерылган юл чаты.
Тәмугкамы, җәннәткәме —
Анысы инде... «тегендә»
Нәкир белән Мөнкир әйтер
Сорау алу көнендә.

...Кызарып кояш батканда,
Дулкыннар чәчен тарап,
Гомерем уйлап утырам,
Аккан суларга карап.

* * *

Мин — финишка якынайган саен,
Гомер чытырманы арасыннан
Соңгы адымнарын саный-саный
Йөгерүче марафончы сыман...

Юкса мин — стайер.
Маршрутым озын —
Чабам... чабам... түзсен генә йөрәк.
Яшәлгән ел ни ул? — минем яшьне
Берничәгә тапкырларга кирәк.

Мин инде карт, яшем йөздән ашкан,
«Картлач» диләр миңа, кем дәшмәсен...
Гомер юлын җилеп кенә үткән
Сирәк бәхетлеләр көнләшмәсен.

Мин дустыма түгел, дошманыма
Һич теләмәс идем мондый язмыш;

Һәр адымым саен — югалтулар,
Һәр адымым саен — хата, ялгыш.

Иң таяныр затлар кирәк чакта
Атам-анам үлгән, сеңлем үлгән...
Һәм дусларым китә берәм-берәм,
Ә аларны табып булмый җилдән.

Җил каршыга исә, ә мин чабам...
Туктап калсам, нидер булыр кебек.
Бу дөньяның бөтен аһ-зарлары
Күкрәгемә кереп тулыр кебек.

Арыдым мин марафончы сыман...
Ни яшәтә мине сүгеп-кыйнап?
Каршымда бит алдап, ымсындырып
Рәшә уйнап торган офык кына...

## Төшләремдә... очам

Төннәр буе очам төшләремдә...
Очам... очам... очып туялмыйм...
Бу гөнаһлы җирдән чиксезлеккә
Алып менә мине хыялым.

Нәрсә соң бу —
Бер яралган җанның
Җирдә черер тәннән ваз кичеп,
Башка дөньяларга ашуымы?
Ә кирегә кайтам мин ничек?

Яшьлегемдә очыйм, дигән идем,
Очалмадым —
Сынды канатлар.
Төшемдәге сәер очуларым —
Шул хыялны мәллә кабатлау?

Сәгать суга — гомер чикле, димә...
Суксын... Аныс мине борчымый;
Чикләнмәгән гомер көтә алда —
Артта калыр Җирнең чыр-чуы.

Артта калыр, үткәннәрдә калыр,
Бөтен рухны Ходай яңартыр:
Җан бирү ул — әле азак түгел —
Алда, бәлки, бүтән таң атыр?

Һәм онытып Җирнең газапларын
Йөрәгемә уйган яраны,
Яшәештән тәмам югалганчы
Кош буласым минем бар әле.



## Гурий Тавлин

# АФӘТ

РОМАН-ТРИЛОГИЯНЕҢ ӨЧЕНЧЕ КИСӘГЕ

## Кара болыт таралгач

Беренче бүлек

### 1

Тәкъдирне алдап булмый. Ул синә түгел, син аңа буйсынасың. Тормышта капыл үзгәрешкә күнегү кыен. Гомер юлында бар нәрсә буталган, чәбәләнеп чуалган, чияләнеп төйнәлгән...

Идел, ару-талуны, кыска мизгелгә генә дә туктатып ял итүне белми торган чал Идел, синең өстеңнән мин янә билгесезлеккә юл ярам. Тәүге кат без, сугыштан соң, мин Кизләүгә Моталлап абыйларга кайтканда очрашкан идек. Үзгәрмәгәнсең, һаман шул ук син, Идел. Әмма күренешең никтер моңсу, басынкы синең. Ярларыңда юан арканнарга җигелеп таудай баржаларны агымга каршы сөйрәүче йончыган бурлаклар күптән җәфаланмыйлар бит, югыйсә. Хәсрәтле чыраең уңъяк ярындагы урманнарны ярым шәрәләп, яфрак ясагы җыйган көз шәфкатьсезлегеннәндер, бәлки? Аңарга микән? Юктыр. Тик миңа гына син шулай тоеласыңдыр? Моңа мин үзем, нахакка рәнҗетелүемнең кан саркыткан авыр ярасы сәбәпчедер, мөгаен...

Пароход түбәнгә, агым уңаена, җай гына йөзә. Мин аның коерыгында борт читенә таянып, күбекләнеп як-якка йөгерешкән соры дулкыннарны күзәтәм...

Тоткынлыктан котылуым инде бәхәссез, шулай да иректә икәнемә һаман ышанып җитмим әле. Кемнәрдер искәрмәстән яныма килерләр дә аркама корулы пистолет терәп тагын төрмәгәме, колониягәме алып китәрләр кебек. Дөрес, инде кесәмдә минем дә узганнары тапсыз кешеләрнеке кебек үк паспортым бар. Ләкин хикмәт паспортта гынамы? Киләчәгем билгесезлек эчендә минем. Беренче чиратта үземне асрар өчен акча эшләргә ниндидер эш табасым бар, ә белгечлегем урам себерүче яки каравылчы булудан узарлык түгел. Берничә көн Казан урамнарында белдерү такталарын карап йөрдем, тик минем кебек дипломсыз сукбайларны эшкә чакырган бер генә өндәмәгә дә юлыкмадым. Кайда да инженер-

---

Гурий ТАВЛИН (1925) — *әдип, «Йолдызлар безгә янәшә», «Сары яфраклар коела» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

лар, конструкторлар, бухгалтерлар, токарьлар, фрезерчылар, шоферлар, төзүчеләр, монтажчылар, кранчылар, тәҗрибәле бетончылар гына кирәк.

Ирекка чыгуымның беренче көнендә үк, кулга алынганчы тулай торакта бер бүлмәдә яшәгән элекке курсташым Салих Хәкимов мине үзенә сыендырды. Ул хәзер китап нәшриятында өлкән мөхәррир, гаилә корган, улы бар. Чемоданымны Карл Маркс урамындагы милиция бүлегендә калдырып, Матбугат йортына баргач, бәхетемә, анда, ул очрады. «Син — төрмә җене»,— дип миннән йөз чөермәде, очрашуыбызга балаларча шатланды Салих. Ул аз гына да үзгәрмәгән, шул ук гади, эчкерсез холыклы. Узган төнне тимер юл вокзалында үткәрүемне ишеткәч:

— Мин, бүлек мөдиренә кереп, китәргә рөхсәт алам да, безгә кайтабыз. Гүрнәчә күк фатирым барда син дустымны теләсә кайда кундырып йөртсәм, кем диярләр мине,— диде.

Салихның фатиры эше урыныннан ерак түгел икән, тиз кайтып җиттек. Юл уаенда дустым, кибеткә кагылып, аракы һәм тагын нәрсәләрдер алып чыкты. Ул:

— Синең котылуны бүген әйбәтләп юабыз, Ирек. Яңадан очрашуыбызны хәтердә калырлык итеп билгелибез, боерган булса,— диде, инемә кулын салып.

Дустымның хатыны Рәйсә ханым да ачык йөз белән каршылады мине. Салих аңа хәлемне кыскача гына аңлаткач:

— Тартынмагыз, күпме кирәк, шул кадәр торырсыз бездә. Үзегезне өегездәге кебек хис итегез,— диде.

Аларда атна буе кунак булдым. Дустым үзе дә, хатыны да мине туганнары күк күрделәр. Кунак өч көнгә кадәр генә кунак, аннары имгәк, дигән борынгылар. Алда күңелем яткан берәр эшкә керергә өметем, ышанычым булса икән, юк бит...

Менә мин, ирекка чыгарга булышканы өчен рәхмәт әйтергә, Оля янына барам. Эчкерсез Рәйсә ханым бу сәфәремне хупламады хуплавын.

— Очрашкач, ул сезгә сагыз күк сыланачак, аңардан аерыла алмаячаксыз, Ирек. Ул кызга җылы гына хат язгыз да, шул җиткән. Сезгә анда барып вакыт үткәрмәскә, киләчәгегезне кайгыртырга кирәк. Сөйләвегезгә караганда, ул кызны сез рәтләп белмисез дә, яратмыйсыз да бит. Һаман электәгечә үк беркатлы кыздыр дисезме аны? Шикләнәм моңа. Кеше яшәү юлында яхшыдан бигрәк яманга үзгәрә. Сезне тозактан коткаруны Олягыз үз файдасын күздә тотып эшләгәндер, минемчә. Сугыштан соң хатын-кызларга ирле булу кыенлашты. Ирләргә кытлык хәзер. Хатын-кызларның омтылышларын, физик һәм рухи таләпләрен кешедән сорыйсы түгел миңа, үзем хатын-кыз,— диде Рәйсә алардан киткәндә.

Юк, ул хаклы түгел. Оляны белмәстән үлчәп ялгышадыр Салихның җәмәгате.

Пароход артында ургылып кайнаган су уйларымны ерак Себергә, берничә ел гомеремнең каһәрле кабере булган колониягә илтеп тоташтыра. Йөрәгем авыртып кысыла, күзләремне яшь пәрдәсе томалый...

Чынында нинди соң ул — мин «халык дошманы»на хыянәтсез калган чая да, тәвәккәл дә кыз? Оляны мин күз алдыма китереп бастырырга тырышам, ләкин булдыра алмыйм. Аның тере төсмере куе томан эчендәге шикелле тонык ланып, күңелемнән эзсез юылган, онытылган. Күзләре, иреннәре, кашлары, карашы, елмаюы нинди иде соң әле аның? Оля урынына, ни гаҗәптер, күз алдыма Рәйсә ханым килә. Аны ничек бар, шулай күрәм: каратут йөз, юан кара толымнар, килешле юка борын, калын иреннәр, сөйкемле елмаю... Оля исә капма-каршысы — ак чырайлы, аксыл чәчле, җитди карашлы иде бугай.

Ирекка чыкканнан бирле мин үземне кая куярга белмим, нәрсәмнеңдер табалмаслык югалттым шикелле. Кешеләр арасында үземне артык, кирәксез итеп сизәм. Бәлки, бу янымда якыннарым юкка, бербашым гына булганга шулайдыр? Ялгызлык — яман чиргә бәрабәр, дигәне бар

иде колониядә чакта элекке мөһажир Арон Маневичның. Ул аны Ерак Көнчыгыштагы төрле илләрдә, Ватаныбызга әйләнеп кайтырга форсат эзләп ялгызы каңгырып йөргәндә, башыннан кичергәнгә әйткән булгандыр, мөгаен. Минем дә менә бәхет тәрәзәсенең эчкә түгел, тышка ачылуына иманым камил инде хәзер...

Идел өстендәге кичке эңгер куера башлагач пароход эченә кердем. Пассажирлар, кара көз башлангангамыдыр, күп түгел, берән-сәрән генә иде. Дүртенче классның машина бүлеге белән янәшә өлешендә көрәк сакаллы бер агай янында аулак урын бар иде, шунда барып утырдым. Агай миңа сагаюлы караш ташлады, әмма сүз катмады. Бәлки, ул өстемдәге койты киемнәремне һәм кулымда берниндн дә йөгем юклыктан шөбһәләнгәндер, кем белә. Каракмы мин, җүнле бәндәме, маңгаема язылмаган бит. Агай бераздан янындагы капчыгыннан ипи, казылык, суган чыгарып ашарга әзерләнә башлады. Мин юлга берни дә алмаган идем, күршемнең тәмләп ризыклануын күрмәс өчен читкә борылып утырдым. Озак та үтмәде, хәлемне аңлаптыр, агай миңа сүз кушты.

—Энем, борыл әле бу якка, сөйләшик.

Борылдым.

— Минем белән бергә тамак ялгарсың, бәлки? — Сакаллы агай без утырган эскәмия-ятакка икебезнең арага газета җәеп, табын әзерләгән иде. — Әйдә, житеш.

— Рәхмәт, үзегез генә ашагыз, мин тук.

— Карышма, күрәм туклыгыңны, аша, тартынма. Ризык монда миңа да, сиңа да җитәрлек.

Артык кыстатмадым, кулыма бер телем ипи һәм суган алдым.

— Казылык ал, чучка ите ашаудан курыкмыйсыңдыр бит?

— Курыкмыйм, өлгерермен.

— Кайдан син, энем? Кая барышың?

— Казаннан. Алексеевскига барам.

Агай миңа текәлеп карады.

— Төрмәдән күптән чыктыңмы?

— Бер атна элек.

— Ни өчен утыртканнар иде?

Әйттем. Үзем турында аны кызыксындырган башка сорауларга да җавап бирдем.

— Гафу ит, мин сине каракты бу дип уйлаган идем, — диде агай ахырда...

Мин үземә һич көтмәгәндә гел сәер, үзенчәлекле кешеләр очрауга гаҗәпләнәм. Күптәнме әле столыпин вагонында Казанга кайтканда «башындагы шөрепләре тиешле юнәлештә әйләнмәгән» юлдаш туры килгән иде. Ул үзенең «фикерләүләрен» алла барлыкка ышанмаучы кешегә төшенүе кыен дип кисәткән иде, ә бу сакаллы агай аны-моны әйтеп тормады, бүленгән сөйләмен дәвам иткәндәй:

— Кеше — катлаулы һәм аңлаешсыз зат, — диде, яңалык ачкан һәм башкача уйларга урын калдырмаслык итеп. — Галимнәр аксымнар һәм углеводлар кушылмалары структурасы дип кенә санап, аңардагы гаҗәеп энергетикага күз йомалар. Алар аксымнарның кодка салынган энергия дәрәҗәсенә тәңгәллекләрен исәпкә алуны да кирәк тапмыйлар. Ә бит кеше әнисе карынында чакта ук анык энергия билгеләмәсе ала. Аны ул тормышында кулланамы, юкмы — бу икенче мәсьәлә. Туганда игелекле, миһербанлы булып туган бәндәнең ахырда усал, явыз адәмгә әверелүе мөмкин. Кешенең тууы белән үлеме генә үзенә бәйләнмәгән, калган бөтен нәрсәләрне ул үзендә яшәгән мохите факторлары йогынтысында формалаштыра. Кеше тормышында барлык нәрсәләр алдан билгеләнеп куела, аның үзеннән гомер юлында очраган хәлләрдән дөрес һәм тиешенчә файдалана белү генә таләп ителә. Рухын кеше матди байлыклар туплауга һәм тормыштагы төрле рәхәтлекләргә алмаштыруга, йә үз асылын саф килеш саклап калу өчен тормышын кызганмый фида кылып,

утта янып, катыйль балтасы астына ятып, хачка кадакланып, үлеме белән Изге фикерне мәңгеләштерүгә бирә. Кешеләр нәкъ менә шуңа күрә йә тиңдәшсез фидакарьлекләр, йә чирканыч җинаятьләр эшлиләр. Сөйләгәнем сезгә аңлашыламы?— дип агай миңа текәлде.— Бәлки, юкка акыл сатамдыр, ничек уйлыйсыз?

— Аңлашыла. Бүленмәгез, дәвам итегез, сезне мин кызыксынып тыңлыйм,— дидем.

— Әйе, берәүләр тормышта рәхәт чигүне генә хуп күрәләр, икенчеләр гомерләрен Изге фикерне мәңгеләштерүгә багышлыйлар. Акыл ияләре арасында, кеше мәңгелекме, түгелме, дигән бәхәс бара. Берәүләре кеше мизгел җимеше генә, ул атомнарның бер-берләренә тоташулары нәтиҗәсе, ә кешелек дөньясы үзе эволюцияләр сөземтәсе, диләр. Икенчеләре, кеше мәңгелек, тәңре аны үзенә, үзенең төс-кыяфәтенә охшатып яраткан, ул үлгәннән соң материаль дөньяда ниләр кылуы турында, үзен барлыкка китергән тәңре алдына, хисап бирергә баса һәм аның тарафыннан йә мәңгелек рәхәткә, йә мәңгелек газапка дучар ителә, диләр. Бу бәхәскә хәтта төрле җәбер-золымнар, ирексезләүләр дәлил итеп файдаланыла, әмма аңа карап хакыйкатькә ирешелми. Фән казанышлары, кешеләрнең гыйлем ягы чикле булганга күрә, тегесен дә, бусын да исбатлый алмый. Дин, мәңгелек хакыйкатьне үзенә кирәккәнчә аңлатып, ахыр чиктә үзгәрмәүче кануннарда тәмам буталып, үзен фәнгә каршы куя. Хакимият вәкилләре исә тегe яки бу фәлсәфәне үз мәнфәгатьләренә яраштырып, мәгълүм бер дәвердә рәсми хакыйкать дип игълан итәләр. Бу электр тогындагы «плюс» бер үк вакытта хакыйкатькә исәпләнеп, «минус» каһәрләнүгә, яки, киресенчә, «минус» хакыйкатькә исәпләнеп «плюс» каһәрләнүгә ошар иде. Ә бит «плюс» белән «минус»тан башка электр юк һәм була да алмый.

Фәндә, философиядә, идеологиядә ниләр эшләнүгә күз салыйк. Гаять көчле фикерләү спектрыннан ниндидер бер тармак сайлап алына да калганнары кире кагыла. Ләкин кире кагылып спектрда калган тармаклар да ятим-ябага түгел, сайланылган тармак кебек үк тулы канлылар. Алардан да шул ук хакыйкать нурлары бөркелә, алар тик бераз башкачарак кына. Гыйлем ияләре нинди генә басым астында да үз хакыйкатьләреннән баш тартырга тиеш түгелләр. Бу аларның үзләре хакыйкатькә санаган нәрсәләргә инанганнары өчен генә түгел, ә инанган хакыйкатьләрен кешеләргә җиткерүләре өчен зарур. Бу аларның Җирдә изге вәкаләтләре. Өлешенә мул тигән заттан күп таләп тә ителә. Кешелек дөньясы гыйлемлекләрне үзенә ничек кирәк, шулай квалификацияләп, берәүләрне — бүгенгенең көрәшчеләре, икенчеләрне кичәге һәм туасы көннәрнең йә каһарманнары, йә җәфа чигүләре итә. Безнең көннәрнең хакыйкате — ялганнар һәм ялгышлар җыелмасы...

Сакаллы агай, үзен дикъкать белән тыңлавымны күреп, таңга кадәр сөйләүдән туктамады. Иртәнге сигезләр тирәсендә мин аның белән саубуллашып, Мурзиха пристанендә пароходтан төшеп калдым, ул ары китте. Аның кая баруын, кем икәнлеген сорашмадым. Ничек очрашсак, шулай аерылыштык та.

Болын өсләп салынган такыр сукмактан Алексеевск поселогы ягына атлаганда пароходта агай сөйләгәннәрне күңелемнән янә үткәрдем һәм, һәртөрле ышану-инанулар кичкенә бер төркем фән һәм сәнгать әһелләре яки белдекле түрә-чиновниклар тарафыннан расланырга да, кире кагылырга да тиеш түгелләр булып чыга, дигән нәтиҗәгә килдем.

Кеше тормышының мәгънәсе, яшәү рәвеше хакында уйланырга, аңын йокыдан уятырга, уй-фикерләренә алга талпынырга булышырга, шәхси юлын кеше компасына иярөп салудан баш тартырга һәм, иң мөһиме, үз асылын тәшкил итәрдәй сыйфатларын калкуландыра барырга тиеш. Максатка ирешү чарабыз төрле, әмма юлыбыз барыбызның да уртак бит, уртак, дидем мин үз-үземә.

Мурзиха белән Алексеевск арасы ун чакрым. Тәҗел адымнар белән байтак юл узгач, сукмак читендә кешеләргә хаҗәте калмаган иске җил тегермәненә юлыктым. Мине ул: кая ашыгасың, билгесезлеккә кабаланып бармыйлар, дип озатып калды кебек...

Алексеевск — Кама буендагы тигез уйсулыкта ярыйсы ук зур мәйданны биләп утырган чибәр генә поселок икән. Һава сүрән, салкын, якшәмбе көн булгангамыдыр, аның урамнарында миңа бер генә кеше дә очрамады. Оляның адресын яхшы белсәм дә, ул яшәгән урамны һәм йортны табуы авырлашты. Сорашыр кеше юк. Нишләргә белми аптырап калдым. Берәр йортка кермичә булмас. Чү, алда әнә теге карсак таш бина — кибет бугай бит. Әйе, кибет. Ишеге дә ачык, кердем. Сатучы хатын түрдә ике ир-ат белән нәрсә турындадыр сөйләшә иде, мине күргәч, әңгәмәләрс өзелде. Исәнләштем. Сатучы хатын җавап кайтарды. Ирләр күзләре белән үземне, хәрти өс-башымны капшадылар.

— Әйтегезче, Фрунзе урамы кай җирдә монда? Аны ничек табарга?

Өстенә мех якалы җылы куртка кигән урта яшьләрдәге ир:

— Сул якта бу урамга параллель өченче урам — Фрунзе урамы,— дип, кулын сул якка изәде...

## 2

Ниһаять, мин Оля яшәгән фатирның ишеген шакыдым. Эчтән хатын-кыз тавышы:

— Керегез,— диде.

Кердем. Анда, кысан коридорда, чәче малайларныкыча кыска калдырып кыркылган яшүсмер кыз кер юа иде.

— Исәнмесез.

— Исәнмесез.— Кер юучы шакшы сулы таз өстеннән башын күтәрде.

— Миңа Ольга Викторовна Пенькина кирәк иде. Өйдәме ул?

— Ирек, син бит бу, син!.. Танымадыңмыни мине, бәгырькәем?..— Кер юучы кыз, сабын күбекле куллары белән муеныма сарылып, мине шашынып үбәргә кереште.

Ул моннан дүрт ел элек ике көннең берендә Казандагы Вахитов лагерена килеп мине бимазалаган Оля түгел, бөтенләй башка кеше булып тоелды миңа. Нигә аның кыяфәте шулай үзгәргән? Чәчен кыска калдырып кыркыткангамы? Башы йодрык кадәр генә кебек. Муены нечкә генә, гәүдәсе такта сыман, күкрәкләре юк. Яшүсмер дә яшүсмер, ул да. Электәгедән күп үзгәргән, урамда очраса, аны танымый да узар идем...

Кочагыннан ычкындырмыйча:

— Мин шат, чиксез шат синең ireккә чыгуыңа,— диде Оля, әсәрләнеп. Аннары, миннән аерылып, артка чигенде.— Һич ышана алмыйм, син түгелдер бу, Ирек, синең урыныңа башка кешедер. Үзгәргәнсең, нык үзгәргәнсең. Йөзең кырыс, чәчләреңә чал керә башлаган...

— Төрмә курорт түгел бит. Тышкы үзгәрүем мине борчымый. Ул табигый. Җәфа-михнәтләрдән инде арындым, алардан син коткардың. Мин сиңа миңа ирек яуларга булышканың өчен чиксез зур рәхмәтемне әйтергә килдем. Рәхмәт сиңа, Оля, барысы өчен дә зур рәхмәт. Эшләгән яхшылыкларыңны, кешелеклегеңне, олы җанлылыгыңны гомерем буена онытмам, үземне сиңа һәрвакыт бурычлы итеп тоярмын.

— Ул турыда оныт, бәгырем, булды, бетте. Иң мөһиме — хәзер без бергә. Әйдә, түт бүлмәгә. Утыр, ял ит. Мин тиз генә кибеткә барып киләм, аннары бу яңадан очрашуыбызны әйбәтләп билгеләрбез. Бу көнне ничек көткәнемне үзем генә беләм. Син китаплар караштыра тор, мин озак йөрмәм, тиз әйләнеп кайтырмын.

Оля кер юган күлмәге өстенә плащын киде дә каядыр чыгып йөгерде.

Бүлмәдә ялгызым гына калгач, тирә-ягыма күз салдым. Оляның фатиры — авыл өендә берданбер тәрәзәсе урамга караган, зур сандыкка охшаган кечкенә генә аралык икән. Ул олы яктан фанера белән бүлеп алынган. Бүлмәнең яртысыннан күбрәген карават һәм мич почмагы били. Түрдә бәләкәй генә өстәл белән ике урындык. Өстәлнең сул ягындагы стенада Максим Горькийның утыз томлык әсәрләр җыелмасы һәм төрле дәреслекләр тезелгән китаплар шүрлеге. Ишек катында берничә чөйле агач элгечкә ниндидер киемнәр эленгән. Алар өске өлеше бөгелеп бау үткәрелгән ак җәймә белән капланганнар. Өстәлдә тәртипсез рәвештә кәгазьләр, газеталар, китаплар чәчелеп ята. Мин урындыкларның берсенә утырып, өстәлдәге бер калын китапны кулыма алдым. «Лобачевский». Титул битен ачкач: «Хөрмәтле Ольга Викторовна, сез улым Алешага өлгергәнлек аттестаты алуда зур булышлык күрсәттегез. Алдыгызда баш иеп сезгә олы рәхмәтемне белдерәм. Ихтирам белән Иван Заботин. 17 август 1953 ел. Казан» дигән язуны укыдым.

Институтта чакта Оля, киез итек-фетр фабрикасында эшләү өстенә, кемнәргәдер дәресләр дә биргән, димәк... Миңа ярдәм итәр, булышыр өчен эшләгән ул аларны... «Иң мөһиме — хәзер без бергә... Бу көнне ничек көткәнемне үзем генә беләм»... Аның бу сүзләрен ничек аңларга? Ул мине үз янына әллә өйләнергә килде дип уйладымы?.. Миңа бүген үк Казанга кайтып китәргә кирәк. Ирektәге яңа тормышымны мин кемнеңдер булышлыгыннан башка ялгызым башларга тиеш...

Оля озак йөрмәде, тиз әйләнеп кайтты.

— Бераз капкалап алыйк та, минем элекке фатир хуҗабикәм Поля түти мунча яккан, мунчага барырбыз.

— Мунча кереп юанмам мин, Оля, берничә сәгатьтән Казанга кайтып китәрмен. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

Оляның кашлары маңгаена менде.

— Минем яннан бүген үк тыракларлык булгач, ни өчен генә кайттың соң син монда?

— Миңа ирекке чыгарга булышканың, иткән яхшылыкларың өчен рәхмәт әйтергә.

— Тик шуңа гына кайттыңмы?

— Шуңа гына, Оля.

— Тиз котылмакчы буласың миннән, тиз, җанкисәгем. Белмәсәң бел, мин сине ирекке рәхмәт ишетер өчен генә чыгармадым бит. Сине гомер юлдашым итәр өчен чыгардым.

Бу сүзләре белән Оля башыма, гүя, таш белән орды.

— Мин синнән үземә ирек юллашуыңны сорамадым, Оля. Һәр хатымда диярлек, үзеңә иптәш тап, дип әйтә килдем. Өйләнү, кияүгә чыгу уен эш түгел. Минемчә, никахлашучылар бер-берләрен яхшы белергә, яратырга тиешләр.

— Безнең бер-беребезне биш елга якын белүебез азмыни сиңа? Минем кемлегемне, турылыклы тормыш иптәшең булырымны аңлагансың, шөт. Мин тоткынлыктан сине кемгәдер бирергә, кемнедер бәхетле итәргә араламадым. Син — минеке!..

Очрашуыбызның мондый юнәлеш алырын көтмәгән идем, югалып калдым.

— Икебезнең дә әле тормыш итәрлек рәтебез юк бит, Оля. Мин институтны тәмамлап эшли башлыйм хет, ашыкмыйк,— дидем, үртәлеп.

Оля исә үзенекен сукалады.

— Институтны да бетерерсең, эшкә дә урнашырсың, алар алда. Хәзергә мин тапкан да җитәр безгә. Яшең инде олыгаеп бара, мин дә өченче дистәнең соңгы яртысын үтеп барам, уртак гаиләбез, балаларыбыз булуын телим. Бөтен курсташларымның гаиләләре, балалары бар, мин алардан кимме?

— Миңа гаилә корырга иртә, аңла шуны. Төрмә, колония мәхшәрләрен онытасым, ирекtәге тормышка күнегәсем бар. Моңа, аз дигәндә,

бернечә ел китәчәк. Сиңа мин бурычлы, әлбәттә, әмма янадан бәйсезлегемне югалту бәрабәренә түгел, үпкәләмә. Иң авыр вакытларымда тәмгысыз (бескорыстно) булышуыңны мәңге онытмам. Без бер-беребезнең холык-фигылен, мәнфәгать-омтылышларын чыпчык борыны кадәр дә белмибез, ашыгып ялгышлык эшләмик.

Оля сүзләремне колагына да элмәде.

— Бер-беребезне бергә тора башлагач өйрәнербез,— диде, кырт кисеп.

— Бергә тора башлагач кына өйрәнергә калдыру җүләрлек бит ул.

— Син мине яратмыйсың, Ирек.

— Ярату — изге хис. Ул нәрсә миңа әле таныш түгел бугай, Оля.

— Ә мин сине өзелеп яратам. Сиңа шул җитмимени?

— Җитми, Оля. Мин — кеше, курчак түгел. Үзенә мәгълүмдер, сабый курчагын башта чиксез ярата, аның белән мавыгып уйный, чишендерә, киендерә, ашата, йоклата, үзе белән урамга алып чыга, хәтта мунчага да алып бара. Аннары акрынлап курчагыннан туя һәм бер дә бер көнне аны каядыр ташлап оныта да соңыннан ялгышып та исенә төшерми. Минем киләчәктә шундый хәлгә каласым килми.

— Биш ел буена сине онытмадым, кулымнан килгәнчә булышырга тырыштым. Моннан соң да читкә тибәрмәм, курыкма. Ярату, яратмау буш нәрсә ул, минемчә. Яратуны кемдер — гадәтләнү, дигән. Без дә иртәме-соңмы бер-беребезгә күнегербез дип уйлыйм. Әле күптәнме егет белән кызны әти-әниләре кушылдырганнар. Өйләнешүчеләрнең күбесе булачак хәләл җефетләрен, тәүге кат, никахлашканда гына күргәннәр. Аңа кадәр бер-берләренең хәтта дөньяда барлыкларын да белмәгәннәр. Кушылгач яратышканнар, гөрләтеп гомер сөргәннәр, балалар үстергәннәр.

— Ләкин алар минем күк тоткынлык газапларын татыган, үз күләгәләреннән дә курка торган бичара бәндәләр булмаганнар бит.

Оляның мине күндерә алмавына түземе төкәнде, күрәсең, ул:

— Бер дә харап, син бүтәннәргә охшамаган үзеңә бер төр аерым зат инде,— диде, җене чыгып.— Күрерсең, мин барыбер үз дигәнемне итми калмам, Ирек, хәтереңә уй моны.

### 3

Аннан-моннан гына ашап алгач, Оля мине мунчага алып китте. Юлда барганда ул:

— Мин хәзер синең тәнеңә тоткынлыкта сеңгән бөтен керләреңне юып чыгарам,— диде, серле елмаеп.

— Әллә син мунчага минем белән бергә кермәкче буласыңмы?— дидем, тукталып.

— Нәрсә, мунчага парлап керүебезгә каршымыни син?

— Оятыңны син бөтенләй үк югалтмагансыңдыр әле, шәт!

— Бәлки күпләрне чиркандыра торган оят дигән нәрсә булмагандыр да миндә...

— Ярар, мунчага үзең генә кер, мин Казанга кайтам, хуш...

Оля шаркылдап көлде. Ләкин аның көлүе ничектер ясалма чыкты.

— Шаярттым мин, тынычлан. Мунчага син минем белән түгел, Поля түтинең ире Ваня дәдәй белән керерсең. Казаныңа иртәгә китәрсең, тотмам сине.

Бу миңа бүтән бәйләнмәскә теле икән, дип, эчемә җылы керде. Оля мине үзенең элекке фатир хуҗалары белән таныштыргач, каядыр китте. Ваня дәдәй белән без мунчада бер-беребезнең аркаларыбызны юышып, ләүкәгә кат-кат менеп чабына-чабына рәхәтләнеп юындык.

Мунчадан соң Оляның фатирына кайтмадым. Ваня дәдәй, Поля түти һәм Оля минем тоткынлык газапларыннан арынуымны әйбәтләп «юдылар». Минем табында авызыма бер генә грамм да аракы уртламавым аларның берсенә дә ошамады.

— Кыланасың булыр син, Иркуша, дөньяда эчмәгән ир юк ул,— диде мина кинаялэп Поля түти.

Ваня дәдәй исә:

— Эчмәсен лә, безгә күбрәк тияр,— диде.

— Ул, мин аны агулар, дип курка, шуңа эчми,— диде Оля, миңа каш астыннан карап.

Тустаганнар тутырыла һәм бушатыла тордылар. Хуҗабикә белән аның ире Оляның уңганлыгын, булганлыгын, юмартлыгын мактадылар. Аларның өчесенең дә ярыйсы ук башларына китте.

— Оля, укучыларыңның сине ничек атаганнарын беләсеңме?— диде Поля түти, бераздан.— Шөпшә диләр алар сине.

— Нигә шөпшә?

— Зәһәр булганга.

— Юк, шөпшә кебек бернәрсәсез саран түгел, киресенчә юмарт, киң күңелле кыз Ольга. Яшь чагым булса, мин аңа гашыйк булып, башкаларны аңа якын да җибәрмәс идем. Шөпшә булса, болай сыйлар идеме ул безне? Юк. Әйдәгез, сөйләшүне калдырып, җырлыйк әле. Мин башлыйм, сез кушылыгыз.

Шумел камыш, деревья гнулись,
А ночка темная была.
Одна возлюбленная пара
Всю ночь гуляла до утра...

Мәҗлес озакка сузылды. Тагын байтак башка җырларны да җырладылар. Мин таң алдыннан гына йокларга яттым.

Оля тәки үз дигәнен итте. Мин Ваня дәдәй белән мунча кергән арада ул, район ЗАГС бюросы мөдирен очратып, безнең никахлашуыбызны хәл итеп куйган булып чыкты. Иртәгесен, ашап-эчкәч, сәгать тугызлар тирәсендә ул минем янга Поля түтиләргә килде.

— Ирексезләп сөйдереп булмый, ди халык. Әгәр син мине аз гына хөрмәт итсәң, тыңла сүземне, язылышыйк. Аннары китәрсең Казаныңа, тоткарламам сине. Минем ир хатыны исәпләнәсем, шуны паспортта билгеләтәсем килә.

— Моны син ихлас күңелдән әйтәсеңме?

— Әйе, ихлас күңелдән.

— Аңа гына мин риза. Әйт, язылышкач бу сүзләреңнән кире кайтмассыңмы?

— Кайтмам.— Оляның күзләреннән яшь бәреп чыкты. Ул миңа кызганыч булып китте. Ләкин ни хәл итим, тамчы да яратмыйм бит аны.

ЗАГС бюросы мөдире никахлашучылар кенәгәсенә башт. миннән кул куйдырды, аннары Оля, минем алдыма чыгып, кенәгәне үзенәрәк тартты. Мин аңа комачауламас өчен арткарак чигендем. Оля, ручканы кулына алгач, миңа борылып:

— Ник өркәсең, кил янәшәмә. Без бүгеннән бер бөтен булабыз, хәзер үк бөтен тәшкил итик,— диде, боерулы тавыш белән.

«Кәләшем»нең дорфалыгы, кимсетүле әрсез мөнәсәбәте кәефемне кырды. Гүя, аның өчен мин мин түгел, дәресләренә ни җитте генә әзерләнеп килгән бер аңгыра укучы идем.

Язылышуыбызга шаһит булырга килгән укытучы кызлардан унайсызланып, янадан өстәл янынарак килдем. Оля мине, җиңемнән тартып, үзенә якын ук китерде дә үкчәләре белән аякларыма басып, кенәгәгә минем имзам янәшәсенә кулын куйды. Аннары миңа:

— Йә, котла мине үбеп, шушы минуттан безнең чәчләребез чәчкә бәйләнде,— диде, мәкерле елмаеп.

Мин иреннәремне аның битенә тидереп алдым.

— Юк, юк, мин мондый кысыр үбүгә риза түгел, җаныкаем, син мине иреннәремнән, озаклап, суырып үп.

— Сабыр ит, анысын без синең белән икәүдән-икәү генә калгач эшләрмен.

— Тимерне кызуында сук диләр, хәзер үп!..

Ачуым чыкты.

— Аякларымнан төш башта. Кенәгәгә минем аякларыма басып кул кую нигә хаҗәт булды сиңа?

— Гаиләбездә өстенлек һәрвакыт минем якта булсын өчен.

— Бүгеннән башлап син — патрицианка, мин — кол, димәк?

Оляның чырае чытылды.

— Калдыр, ул турыда кайткач сөйләшербез,— диде ул, кашларын җыерып.

Район ЗАГС бюросы мөдире безне законлы никах белән тәбрикләгәч, икебезгә дә бәхетле, куанычлы озын гомер теләп кулларыбызны кысты. Язылышуыбыз вакытында шаһитлар сыйфатында катнашкан Оляның иптәш кызлары да безне кайнар котлады.

Кайтырга чыктык. Район ЗАГС бюросы урнашкан бинадан Оляның фатирына кадәр ара шактый җир. «Кәләшем», кулымнан тотып, миннән үзен култыклатты. Язылышканда ул оештырган кәмиткә җенем чыкканга мин, янәшәмдә беркем дә юк чактагыча, үз уйларыма бирелеп атладым. Артык бер генә минут та монда тормаска, тизрәк китәргә кирәк миңа Алексеевскидан...

Бераздан Оля, кулымны ычкындырып, алдыма чыкты.

— Син нәрсә, кушылуыбызга шатланмыйсыңмы әллә?

— Миңа шатланыр сәбәп юк, син шатлан.

Укытучы кызлар йөзләрен читкә бордылар.

— Йәле алайса, күтәр мине кулларыңа. Җүнле ир хатынын кулларында күтәреп кенә йөртергә тиеш.— Оля муеныма сарылды.— Фатирыбызга кадәр җиргә бастырмый күтәреп кайт.

— Акылыңа кил, Оля, кеше көлдермә. Тузга язмаганны таләп итмә миннән.

— Шулаймы? Кайтма алайса безгә иярep, олак теләсәң кая!..

— Паспортымны бир.

— Мә! — «Кәләшем» паспортымны плащ кесәсеннән чыгарып йөземә бәрде.— Моннан ары күземә күренәсе булма. Син мине белмисең, мин сине белмим.

— Барысы өчен дә зур рәхмәт сиңа, Оля. Хуш.

— Яхшы чакта югал күземнән, кире уйлавым бар. Йә!..

Мин борылып китеп бардым.

## Икенче бүлек

### 1

«Нәрсә булды бу? Нигә Рәйсәне тыңлап, хат кына язмадым Оляга, ә янына килдем?» — дип уйладым, болын аша салынган сукмактан пристаньга атлаганда. Ни өчен түбәнсетергә, мыскылларга, мәсхәрәләргә тырышты мине Оля? Иптәш кызлары алдында ул мине түгел, үзен уңайсыз хәлгә куйды бит. Ничек аңларга аны, ничек?..

Көн сүрән, күңелсез. Кама ягыннан салкын җил исә. Кыш инде үзенең якын икәнен, кешеләрнең ишек төпләренә үк килгәнен хәбәр итә. Көтмәгәндә өстемнән, ямьсез каркылдап, ялгыз карга очып үтте. Кешеләр өсләреннән карга кычкырып узуны яхшы хәбәр алачакларына юрыйлар. Миңа исә карга миннән көлә кебек тоелды. Бәлки бу — карганың ялгызлыгына зарлануы, инде борын төбендәге кышның аңа михнәтләр китерәсен уйлап сагышлануы булгандыр?.. Мин соңгы биш елда тик үз

шәхесем белән генә булышканга, уйларым үз тирәмдә генә буталганга, башкача фикер йөртерлек һәм әйләнә-тирәмдәге күренешләргә тәңгәл аек бәя бирерлек хәлдә түгел идем. Хәтта сукмак читендә утырып калган теге иске җил тегермәне дә минем бәхетсезлегемә сөенә кебек күренде миңа...

Җил оясындагы ышыксыз пристаньга баргач та җан тынычлыгы тапмадым, анда да очсыз-кырыйсыз уйларым бимазалады. Өстемдәге киемнәрем койтыга күрә, пристань эчендә хуҗасы әшәке көнне өеннән сөреп чыгарган бүлмә этенә охшап, бөрешеп, калтырандым. Казан ягына пароход килергә дүрт сәгать вакыт бар иде әле, дебаркадер читеннән Каманың болганчык дулкыннарының түбәнгә ялкау гына агуларын күзәтеп бераз басып торгач, яр читендә янган зур учакны һәм аның тирәсендә утырган дүрт-биш кешене күреп, җылынырга шунда ашыктым.

— Исәнмесез, бәхетле бәндәләр! Мине дә арагызга алыгыз әле, туңдым, тешләрем тешләремә тими,— дидем учак тирәсендәгеләргә.

— Күңелебез киң, рәхим ит,— диде учак кырыена башкаларыннан аерым утырган, уң күзенә ак төшкән утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге берсе.— Тик башта ягарга нәрсә булса да алып кил. Озак янарлык коры әйбер тап.

Пристань тирәсеннән утта янардай нәрсә эзләп як-ягыма карандым. Әмма утын булырдай берни дә күзләремә чалынмады. Шуннан соң, кая баруыма хисап биреп тормастан, пристань янәшәсендәге авыл ягына юнәлдем. Бераз баргач юл читендәге казылмада тәгәрмәчсез ватык агач тачка ятканын күрдем. Булды, бәхеттән бик үк мәхрүм түгел икәнмен әле, шуны алып барам, дидем үз-үземә, ягардай нәрсәгә тиз юлыгуыма шатланып.

Ватык тачканы өстерәп учак янына кайткач, мине утын юнәтергә җибәргән кеше:

— Ягар әйберне тиз таптың, егет икәнсең,— диде, мактап.— Болай җиңел генә киенеп кая барышың?

— Бәхет эзләргә.

Кая баруым белән кызыксынучы миңа сынаулы караш ташлап, үз янәшәсендә утырырга урын күрсәтте.

— Әйдә, шушында кунаклап җылын. Туңуың инде чиктән ашкан бугай, иреннәрең күм-күк, төсең дә мәетнеке белән бер.

— Булыр,— дидем, киң күңелле бәндә янәшәсенә урнашып.— Ташкентның нәкъ үзе монда, рәхмәт сезгә.

— Ялгышмасам, син казна йорты белән әле бик күптән саубуллашмаганга охшыйсың?..

— Ялгышмыйсың, нәкъ өстенә бастың.

— Күпме утырдың?

Мин уң кулымның бармакларын җәеп күрсәттем.

— Аз түгел. Нәрсә өчен абындырганнар иде?

— Гел гаепсезгә,— дип елмайдым, ачылып сөйләшергә теләмәвемне сиздереп. «Урка»лар булырга охшыйлар учак тирәсендәгеләр, алар белән уртаклыгым юк ич минем.

— Анык җавап бирергә теләмисең, ихтыярың. Мин үзем дә такыр юлдан гына йөрүче түгел. Сталин бабайның «Макар бозауларын да көтәргә уңай булмаган» кәттә санаторийларында инде өч тапкыр хәл «җыйдым». Менә синең шикелле үк бәхет эзләргә чыктым әле. Бәлки аны бергәләп эзләрбез, ничек уйлыйсың?

— Туңдым, башымның уйлар рәте юк әле, гафу ит, яхшы бәндә,— дидем, туры җаваптан качып.

— Джентльмен син, күрәм, хәйләкәр джентльмен,— диде күршем.— Бүген ашамаган да бугай бит әле үзең?

— Хәтерләмим, бәлки шулайдыр...

— Миндә ашарга бар, биримме?

Нәрсә кирәк аңа миннән, ник бәйләнә?

— Син мине, бәлки «Маша» итәргә ниятлисеңдер? Ниятең эшкә ашмас, кирюха, темиең сузма...

— Шөлләмә, агаңның андый түбәнлеккә төшкәне юк әле.

Шулчак пристань күршесендәге авыл урамын, әйләнә-тирәсен иләмсез тавышына күмеп, бишекле мотоцикл килгәне күренде. Аның руле артына милиционер, бишегенә — башына җылы шәл бәйләгән хатын-кыз утырган, җилдереп киләләр. Чү, Оля бугай бит хатын-кызы!.. Курыккан-га куш — койрыгы белән биш, диләр, күңелемә шом керде. Олядан, миһербанлылыгы белән бергә үк, теләсә нинди этлекне дә көтәргә мөмкин икән бит, юкка килүе түгелдер...

Мотоцикл, яр белән дебаркадерны тоташтырган күпергә җитеп кире борылгач, туктады. Бишектә утырган хатын, чыннан да, Оля булып чыкты. Ул аннан төшеп, ашыгып дебаркадерга үтте. Мине юллап килгән ул, һич бүтән түгел, дигән борчулы уй миемне көйдерде. Алда үземне ниндидер күңелсезлек көткәнен сизеп сагайдым. Ике-өч минут үтүгә Оля, дебаркадердан чыгып, без утырган учак ягына күз ташлады. Аннары моторы сүндерелмәгән мотоциклының руле артында утырган милиционер янына килеп нәрсәдер әйтте. Милиционер, мотоциклыннан төшеп, ялкау адымнар белән учак янына килде. Аңа күршем:

— Гражданин начальник, бүген җил, суык, тырылдыгыңда өшегәнсең, әйдә җылын безнең белән,— диде.

Милиционер сүз катмады, учак тирәсендә утырган һәммәбезне дә каш астыннан берәм-берәм күздән кичерде. Ул пошмас кыяфәтле, таза бәдәнле ир уртасы кеше иде. Бераздан карлыккан тавыш белән:

— Монда сезнең кайсыгыз Кадыйров? — диде.

— Кадыйров — мин. Нәрсә булды?

— Нәрсә булганын миннән түгел, сездән сорарга кирәк. Киттек, миңа сезне район милиция бүлегенә алып кайтырга куштылар, анда ачыкларлар.

— Мин беркая да бармыйм.

— Урлаган әйберләрегез үзегез беләнме? Кайда алар?

— Кем урлаган? Нинди әйберләр?

— Әнә мотоцикл янындагы гражданканың әйберләрен урлагансыз, алар кайда?

— Сезнең ул корчаңгы гражданкагызны да, аның ниндидер әйберләрен дә белмим һәм белергә дә теләмим. Минем гомеремдә инә дә урлаганым юк. Гражданкагыз саташа булыр...

— Саташамы, саташмыймы, милиция бүлегендә ачыкларбыз. Әйдәгез!..

— Мин беркая да бармыйм.

— Барырсың!..— Милиционер, килеп, мине җиңемнән тотты.

— Кара әле, начальник, җылынырга комачаулама безгә. Ник гаепсез кешегә бәйләнәсең? Минем гомеремдә инә дә урлаганым юк, дип чатнатып әйтте ич ул сиңа. Җибәр аны! — дип, күршем миңа ярдәмгә килде.

Милиционерның яңак мускуллары биеп алды.

— Сез бер шайкамыни? Теләсәгез, сезне дә монда калдырмам, үземә ияртермен.

— Хакыгыз юк, начальник, кулыгыз кыска. Кешене кулга алыр өчен прокурор рөхсәте кирәк. Шундый рөхсәт кәгазегезне күрсәтегез, аннары сезгә ияртербез. Безне артык бимазаламыйча, таегыз яхшы чакта бу тирәдән. Юлыгызга ак җәймә, начальник, үтенәм, нервыда уйнамагыз. Без монда алты кеше, сез бер үзегез, эшнең үтә күңелсез бетүе бар. Бәлки, сез чибәр бичәгез, мотоциклыгыз белән бергә балыкларга азык булырга, Камага чумарга телисездер? Без, начальник, ярдәмчел бәндәләр, сезгә ике дә уйламый булышырбыз. Йә, ничек килешәбез, ризамы? Дәшмисең? Яхшы чакта күзебездән югал, эт токымы!..

— Чамалап ач авызың, йолкыш, төкерәм янауларыңа...

Күршем урыныннан сикереп торды.

— Төкерәсең, фиргавен? Яхшы. Егетләр, кулларыгызга кисәү башлары алып, күрсәтегез мильтонга күрмәгәнен!..

Күршемнең иптәшләре кулларына шундук утлы кисәү башлары эләктерделәр. Милиционер, кырт борылып, мотоциклына йөгерде. Аның артыннан, һавада зәңгәр төтен дугалары ясап, кисәү башлары очты. Оля, килгәндәгечә үк, тырылдыкның уңай бишегенә кереп оялаган иде, милиционер, йөгереп килгән шәпкә рульгә ябышып газ бирде дә, мотоциклын чак кына әйләндереп капламыйча, җәлт кузгалып китте.

— Нашатыр кыстырдык мильтонның койрык астына, көләргә кеше генә юк. Күрегез, артына борылып та карарга куркып элдерә, җанын табанына төшердек кабахәтнең. Сарыклар арасында арыслан, арысланнар арасында сарык шушыдыр инде...

Оля, нишләвең бу? Әллә нахак бәла тагып, мине яңадан рәшәткә артына тыгарга уйладыңмы? Ничек аңларга сине? Ирекка чыгарга миңа үзең булышкан идең бит. Инде менә гаделлеккә булган актык ышанычымны аяк астына салып таптадың. Ирекка чыккач, сине мин фәрештәгә тиңли башлаган идем. Сукырлык күрсәткәнмен... Өстенә сарык тиресе ябынган бүре түгелсең ич син?..

Күршемнең:

— Нәрсәләрен чәлдең соң син ул чәчбинең? — дигән соравына сискәнеп киттем. — Фамилияңне белә, нинди танышың ул синең?

— Лагерьдагы бер фраерның сеңлесе ул. Фраер миңа аңа тапшырырга хат бирде. Мин аның әманәтен үтәдем. Чәчби белән танышлыгым шул.

Ялганым үзеннән-үзе килеп чыкты. Милиция мотоциклына утырып артымнан юллап килгән «чәчби» белән без моннан әле берничә сәгать элек кенә язылышкан идек, ул минем кәләшем димәм бит инде. Учак янындагы күршем һәм аның иптәшләре мине үзләре күк блатнойга санныйлар икән, санасыннар, ни югалтам?..

— Мильтон ияртеп артыннан чыгарлык нәрсәләрен эләктердең аның?

— Хатын-кыз елтыр-былтырлары инде.

— Кая соң ул елтыр-былтырлар? Үзең беләнме?

— Юк, үзем белән түгел. Мин аларны монда килгәндә юл буендагы иске җил тегермененә кереп күмеп калдырдым.

— Балдак, алка, беләзек ише нәрсәләр генәме анда?

— Алар гына түгел, алтын тәңкәләр, кашык-чәнечкеләр, чиркәү әйберләре дә бар.

— Ярыйсы ук икән.

— Күбрәк булды шул. Ялтыраулары кызыктырды. Чәчби сизмәсен өчен беразын калдырасы булган да, соң иде. Рәхмәт сезгә, мент кулына бирмәдегез.

— Тапла, бүген сиңа без ярдәмгә килдек, бәлки кайчан да булса син дә безгә булышырсың, дөнья бу. Кайда юл тотышың?

— Әлегә Казанга дим.

— Безгә монда калырга ярамый, тизрәк табан ялтыратырга кирәк. Фиргавен озакка сузмас, монда иптәшләрен ияртеп килеп җитәр. Алардан кисәү башлары атып котылып булмас. Түбәнгә йөзүче пароход килергә шактый әле. Бәлки көймәдә аргы якка элдерербез, ничек уйлыйсыз, бөркетләр?

— Үзең хәл ит, Карчыга. Ни әйтсәң дә, каршы килмәбез.

— Булды алайса. Ишкәкләр эзләгез.

«Карчыга»ның бөркетләре ишкәкләр табарга авыл ягына йөгерделәр. Учак янында күзенә ак төшкән күршем белән икәү генә калдык.

— Төнлә бу якка чыгып, синең «хәзинәңне» алырга барырбыз. Аны яшерелгән җирендә озакка калдыру гөнаһ булыр дим мин.

— Син хаклы, Карчыга, тик безгә уяулыгыбызны икеләтә арттырырга кирәк булыр.

Кинәт тирә-юньне яңгыратып сузып, пароход кычкыртты. Без, берберебезгә карашып, тавыш килгән якка борылдык. Түбәннән пароход күтәрелә икән. Миңа «бөркетләр» ишкәкләр табып килүләрен көтмәскә, килгән пароходка утырып таярга кирәк. Казангамы, бүтән җиргә барам-мы, барыбер ич. Кайда да зарыгып көтеп торучым юк. «Карчыга»ны «бөркетләр»е белән жил тегермәненә җибәрергә кирәк...

Мина Карчыга үзе ярдәмгә килде.

— Син ычкын бу пароход белән, агайне. Хәзинәңне кайда, ничек яшергәнеңне тәфсилләп сөйлә. Әйт, нәрсәләр бар анда? Теләсәң, мин сиңа аларның хакын хәзер үк түлим.

— Нигә сез дә минем белән китмисез? Хәзинәне аннары килеп алыр идек.

— Безгә түбәнгә төшергә кирәк. Анда очратасы кешеләребез, майтарасы эшләребез бар.

— Аңлашылды.

— Хәзинәң тегермәндә кайда яшерелгән?

— Мөшкәгә менә торган баскыч астына күмеп калдырдым.

— Анда нәрсәләр бар дидең әле?

— Ике калын алтын балдак, өч пар алтын алка, асыл ташлар белән бизәлгән беләзәк, алтын һәм көмеш кашыклар, чәнечкеләр, патша сурәте төшерелгән алтын тәңкәләр, хачлар һәм ниндидер чиркәү әйберләре. Монда артымнан бастырып килгән хатынның әтисеме, бүтән берәр кардәшеме чиркәү әһеле булган. Мин «аякландырган» әйберләр ул хатынның үз әйберләре түгел, элек чиркәүдә эшләгән кешенеке булырга тиеш.

Карчыга мин әйткәннәрне чынга алды: аның күзләре ялкынлана иде. Оля монда милиционер ияртеп килмәсә, «Карчыга»ның «бөркетләре» тәртип сакчысын углы кисәү башлары атып пристаньнан табан ялтыраттырмаган булсалар, төшемә дә кермәслек уйдырмаларны сөйләр идемме мин? Сөйләмәс идем, әлбәттә.«Хәзинә» чәлү башымда ничектер үзеннәнүзе туды. Ул минем батканда саламга ябышуым кебегрәк булды. Беренчедән, тоткынлыкта ни өчен булуымны яшердем,икенчедән, Оляның үземә кем булуын әйтүдән котылдым, өченчедән, ничек шуңа башым житкәндер, яңа «әшнәләрем»нән арыну юлын таптым.

Карчыга куен кесәсеннән бер төргәк акча чыгаргач, аптырап калдым.

— Күпмегә сатасың хәзинәңне, мә, күпме кирәк ал.

— Үзең күпме бирсәң, мин шуңа риза. Көймәмнең комга терәлгән чагы, гаепләмә. Өс-башым да, күрәсең, иң ялкау җилне дә тоткарларлык түгел. Миңа бу пароход белән Молотовка элдерергә кирәк. Анда Дима Угрюмыйны тапсам, диңгез тубыктан миңа. Аның катына буш кул белән бару уңайсыз уңайсызын, эшнең мондый юнәлеш алырын кем белгән. Әҗәлең якаңнан тотса, чүмечтәге суга батасың, дип юкка әйтмәгәннәр...

— Ярар, мин сиңа бер тулы калҗа (полный кусок) бирәм, бәхиллә. Димага сәлам тапшыр, аны мин ишетеп беләм, ул бөтен Уралны йодрыгында тота, синең янга килергә миңа Кылый булышты, диярсең. Мин законниклар арасында, Карчыгадан бигрәк, Кылый буларак мәшһүрмен. Жил тегермәне мотоциклы мильтон киткән яктамы? Моннан еракмы аңа?

— Шул якта. Биредән бер жиде чакрым чамасы жир аңа. Бу авылны чыгу белән кукраеп күренеп тора, аны озак эзлисе түгел.

Карчыга миңа, санап, ун йөзлек тоттырды.

— Мә. Әнә пароход дебаркадерга якынлаша, син, аңа утырып, шыл. Киләчәктә әле күрешербез дип ышанам.

Мин «Карчыга»ның хатын-кызларныкы кебек йомшак кулын кыстым.

— Мә, ал минем сырманы. Пароходта барганда хет җәеп ятарга ярар.

— Кирәкми, үзең киемсез каласың бит.

— Кирәк икән, кореш, мондый сырманы бу авылда мин унны табармын. Хәерле юл сиңа. Синдәй мут егеткә берни кызганыч түгел.

— Син — Кеше, Карчыга. Рәхмәт.

Мин, инемә яңа «әшнәм» бүләк иткән сырманы элеп, дебаркадерга юнәлдем. Һич көтмәгәндә мондый сукыр бәхет каян килде миңа: кесәмдә акча, өстемдә начар гына булса да киемем бар. Тукта, ата каракның биргән акчасын, кияргә сырмасын алып дөрес эшләдемме мин? Биргән акчасын алмасам, анарда шик туачак, минс мәнсез фраерга санаячак иде ул. Ә фраерлар белән ул «суык аяк»лар исәпләшмиләр: алдашса янтыгына йә пычак төртәләр, йә бүтән җәза табалар. Бүген мин йокымнан сул аягым белән тордым, күрәсең, әнә нинди хәлләргә тап булдым, аларны искә төшерү генә дә чәчләрне үрә торгызырлык. Бәлки төшләнәмдер мин?..

## 2

Дебаркадерга керүемә, аны иләмсез чайкалдырып, пароход килеп туктады. Кассага чират юк иде, Молотовка кадәр дүртенче класска билет алдым һәм күпергә чыгып, учак янында ялгызы калган Карчыгага кул болгадым. Эшем кәттә, минем өчен борчылырлык түгел, янәсе. Карчыга исә кул болгавымны әллә күреп юри күрмәмешкә салышты, әллә чыннан да күрмәде, тыныч кына утыра бирде. Аның өчен, әйтерсең, мин инде дөньяда юк идем. Башыма, белешим әле, пароход монда озак торыр микән, дигән уй килде. Бәлки шома егетләрнең берәрсе Карчыга белән калырга теләмәс, миңа иярер...

Йөк ташучылар пароход эченнән, тәжелләнеп, өч зур сыра мичкәсе тәгәрәтеп чыгардылар. Аннары үтә кабаланып ниндидер зур тартмалар ташырга тотындылар. Мин янә касса тәрәзәсенә барып:

— «Вера Фигнер» озак торырмы? — дип сорадым.

Кассадагы агай:

— Менә-менә кузгалырга тиеш. Ул болай да инде өч сәгатькә соңарып килде. Сез Молотовыгызга вакытында барып җитәрсез, борчылмагыз, — диде.

— Рәхмәт яхшы сүзегезгә.

Озакламый пароход бер-бер артлы өч гудок бирде. Мин кулымдагы билетымны алга сузып трапка йөгердем. Пароход эченә үткәч, як-ягыма карандым, дулкынланудан йөрәгем еш-еш типте, тыным кысылды. Хуш, Оля, гаеп итмә, сине минем бу актыккы күрүем булсын. Изге җанга саный идем үзеңне, ялгыштым. Чын йөзеңне күрсәткәнең өчен рәхмәт сиңа. Кемлегеңне озакка сузмый вакытында ачтым. Эшләгән яхшылыкларың белән бергә, сәер кыргыйлыкларыңны да гомерем буена онытмам. Сиңа ир була алмадым, бәгайбә. Паспортым пычраңды пычрануын — өйләнгән исәпләнәчәкмен, әмма аны зыянга санарлык түгел, бүтән пычраклар да түбәмнән ашкан ич әле, иш янына куш кына ул паспортым тапланну, аны үземнән бүтән кем белә? Белсәләр соң, өйләнгән саналырмын, «халык дошманы» булдым бит әле — аңа карап маңгаема мөгез үсмәде, буйдак килеш «өйләнгән» исемен күтәрүдән дә берни дә булмас...

Пароход кузгалып киткәч койрыкка чыктым. Әнә мин Алексеевскидан пристаньга килгән болын юлы. Әнә аның читендә хәзинә «яшерелгән» иске җил тегермәне. Бичара Картлач, шома егетләрне «хәзинә» алырга сиңа юнәлткәнем өчен кичер, орышма мине. Гаделлек белән гомер сөрү кыен бу дөньяда. Хәйләсез дөнья файдасыз, диләр бит. Чү, Мурзиха ягына машина җилдерә ич анда! Ул бәлки милиция машинасыдыр?.. Минс каптырырга ашыксагыз, соңардыгыз, мент иптәшләр, мин инде сезнең тирәдән табан ялтыратып Молотовка юл тотам. Тукта, чыннан да, кая барам соң әле мин? Бәлки, алдагы беренче пристаньда ук төшеп калыргадыр. Расписаниене карадым, алда Балык Бистәсе, Чистай,

Берсут пристаньнары... Шуларның кайсында төшсәм уңармын? Оляга, «Карчыга»га һәм шома егетләргә аю төбәгендәге ниндидер караңгы авылда яшеренсәм генә мине эзләп табу кыенлашыр. Алар исә, һичшиксез, эзләячәкләр мине. Кама буенда туктасам, уңмаячакмын. Студент чагымда бер җәйне Иделдәге Маркиз утравына барганда бер хатынның күзләренә чәч пәкесе белән сызган кесә карагы әнә һич истә-санда юкта Вахитов колониясендә очрады бит. Дөнья — уңмаганнар өчен иркен түгел, кысан, үтә кысан ул. Хәтта үз күләгәмнән дә куркып яшәүдән хикмәт чыкмас, ни булса шул, пароходтан Балык Бистәсендә төшеп калам. Аннан Казанга да ерак түгел, җәяү дә тәпиләрлек. Миңа, беренче чиратта, читтән торыпмы, яңадан керепме, институтны тәмамлап, диплом алырга кирәк. Һич югы кесәмдә, институтта дүрт ел чамасы укыды, дигән кәгазь булдыру һәм фиркалегемне кире кайтару. Төрмәдән чыкканда бирелгән белешмә миңа иң хөрти колхозда дуңгыз көтәргә ялланырга да ярарлык түгел.

Пароход эченә кергәч бик нык аруымны тойдым. Ятып ял итәсе иде хәзер, юкка билетны каютага алмадым, дөньяда ике яшәргә килмәдем бит, дип уйладым. «Карчыга» биргән акчаны саклап тотсам, бер айга җитәр, шәт. Әмма өстемә кием-салым аласым бар, киң күнелле «суык аяк» сырмасы белән генә кышка кереп булмас. Болай эш сорап кайда гына барсам да, йолкышка санап, ышаныч күрсәтмәячәкләр. Урыслар юкка гына «встречают по одежде» димиләр...

Уйга чумып, аркамны машина бүлегенең кайнар стенасына терәп, йокыга талуымны сизми дә калганмын. Күпме йоклаганмын, белмим, кинәт сузып пароход кычкыртуга сискәнеп, күзләремне ачтым. Башта, йокы аралаш, кайда икәнемне шәйләми тордым. Берәм-берәм янымнан кулларына йә капчык, йә төенчек, йә чемодан тоткан кешеләр уза башлагач кына пароходта икәнем исемә төште. Кайсыдыр пристаньга җиттек ахры. Тордым. Тышта караңгы, берни күренми. Кешеләргә ияреп ярга чыктым. Кай җир бу? Һәй, кай җир булса да барыбер түгелмени! Шушында калам, утырмыйм пароходка бүтән...

Мин сөзәк ярдан өскә күтәрелүче берничә кешегә ияреп пристань янәшәсендәге авылга юнәлдем. Янәшәмдә кулына калын портфель тотып атлаган берәүдән:

— Алдыбыздагы авыл ничек атала? — дип сорадым.

— Балык Бистәсе.

— Кунып чыгар җир бармы анда?

— Колхозчы йорты бар. Балык Бистәсе район үзәге бит.

Бу җавап миңа, «һәр ләкләк үз сазлыгына мөкиббән» әйтемен хәтеремдә яңартты. Янәшәмдә атлаган портфельле адәм әйтмәсә, Кама буендагы өтек кенә авылның район үзәге икәнен белер идемме?.. Юк, әлбәттә.

## 3

Колхозчы йортын, төн булса да, озак эзләмәдем, тиз таптым. Бәхетемә, анда кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге бер хатыннан башка кеше юк иде. Ул колхозчы йортының хуҗасы булып чыкты. Паспортымны бик җентекләп тикшергәннән соң, ул миңа:

— Паспортыңда прописканң юк, мин сине кундыра алмыйм, — диде.

— Мин халык дошманы саналып нахакка утырдым, апа. Күрегез, башымда әле адәм рәтле чәч тә юк, зинһар, сез дә кыерсытмагыз инде, — дип үтенгәч, ул:

— Милициягә барып рөхсәт алып кил, болай үз өстемә алмыйм, бәлагә тарыйсым килми, — диде.

— Ярар, кертмәсәгез кертмәссез кунак йортыгызга, авылыгызда бар кеше дә сезнең шикелле таш йөрәкле түгелдер әле, өй борынча эзләсәм, кундырып чыгаручы табылыр, шәт, — дип, ишеккә юнәлдем.

— Утырганлыгына язуын бармы?

— Бар. Анда «биш елга якын КГБның эчке төрмәсендә утырды» диелгән. Мәгез, карагыз.

— Ул төрмә Казанның кай төшендә?

— Сезнең Казанда булганыгыз бармы соң, апа?

— Ник булмасын, сугышка кадәр тордым мин анда.

— Ул төрмә Черек күл буенда.

— Утыз җиденче елны кешеләрне нахакка ташыган җир инде ул, алайса. Аннан да исән чыгамыни кеше?

— Башкаларны белмим, мин чыктым менә.

Директор апа эчке төрмәдән бирелгән белешмәне миңа кире кайтарды.

— Паспортыңны миңа бир дә, әнә стена буендагы аулак урынга ятып йокла.

Колхозчы йортында күзләремә төне буе йокы кермәде, уйланып яттым. Оляның кыланышларын ничек бәяләргә, нигә юрарга белмәдем. Бәлки арабызда туган күңелсезлекләргә ул түгел, үзем гаепледер? Никахлашып янында калырга ризалашмыйча аның хатын-кыз горурлыгын кимсеттем бит. Миннән ул үзен Алексеевск урамы буйлап фатирына кадәр күтәртеп кайтырга теләде. Аның теләген үтәсәм, укам коелыр идеме? Ул өтек киемле кичәге ристан — минем белән ЗАГСка язылышырга барырга хурланмады. Таләбенең үтәлмәвен урынсызга кимсетелү, көтмәгәндә янагына чалтырату итеп күрде һәм шуның өчен үч алды. Әйе, гаеп аңарда түгел. Ул аш атканда мин тинтәк аңа таш аттым. Оляның таләбенә ризалашсам, бу аның кубызына бию, үз-үземә хыянәт итү булыр иде...

## Өченче бүлек

### I

Мин яңадан Казанга, киң күңелле дустым Салих фатирына кайттым. Ул үзе эштә, өйдә тик Рәйсә ханым гына иде.

— Сүзегездә торасыз икән, тиз йөрдегез, Ирек, юлыгыз уңганга охшый, — дип каршылады ул мине.

— Уңды, Рәйсә ханым, уңмаган кая, хәтта хатынлы да булдым инде мин, — дидем.

— Котлыйм, егет икәнсез, тиз тоткансыз. Олягызга өйләнгәнсездер инде?

— Шуңа Тинтәккә акыл кирәкми, Рәйсә ханым, качтым мин хатыннан.

— Ник бик тиз?

— Озакка сузсам, кызыгы калмас дидем.

— Чәй куям, ачыккансыздыр. Чәй эчкәндә башыгыздан кичкән хәлләрне сөйләрсез, теләсәгез.

— Сөйләрмен, Рәйсә ханым. Тик Салихны көтик. Чәй куеп мәшәкатьләнмәгез. Бераз урамда йөреп керим әле мин.

Урамнарда кичкә кадәр киләп сардым. Юрганыңа карап аягың суз, ди халык. Минем юрганым хәзергә аякларымны капларлык түгел, кыска. Яшәр өчен эш табасым бар. Институтка яңадан алсалар, эшләп читтән торып укыйсы булыр. Газеталарда әнә Куйбышев ГЭСы төзелү уңае белән Казанны судан саклау буенча инженерлык корылмалары төзелеше баруы турында язалар. Шул төзелешкә эшкә керсәм, эшчеләр тулай торагына урнашырмын. «Карчыга»ның мең сумын түздырмаска тырышырга кирәк. Аның шома егетләре белән һич көтмәгәндә очрашып куюым да бар, дип уйлана-уйлана Салихларга кайттым.

Дустым эштән кайткан иде инде. Ишектән керүем белән янымa килеп кул бирде. Рәйсә ханым:

— Әйдәгез, кулларыгызны юыгыз да өстәл янына узыгыз. Эштән кайткач Салих ашамады әле, Ирек, сезне көтте,— диде.

Өчәүләп табын тирәсенә урнаштык. Өстәлдә аш тәлинкәләре, кашык-чәнечкеләр, тәбәнәк матур кәрзингә телемнәргә кисеп өеп куелган ипи белән бергә махсус савытларда серкә, борыч, аракылы графин һәм өч чәркә дә бар иде. Салих графиннан чәркәләргә аракы агызды.

— Әйдә, Ирек дус, синең гаилә бәхетең, киләчәк уңышларың өчен каплыйк әле бу хәерче малайларын.

Чәркәләрне чәкештек. Салих белән Рәйсә ханым эчтеләр.

— Әйдә, назланма, капла син дә, илле граммны кеше түгел тавык та эчә,— дип кыстады мине Салих.

— Рәхмәт, дус, эчмәвемне беләсең, кыстама.

— Уңайсыз бит, без хуҗалар эчәбез, син карап утырасың. Болай бер дә килешми инде.

Рәйсә ханым миңа ярдәмгә килде.

— Ирексезләмә, Салих, үзенә карасын. Күңелсезгә күлмәк кидермиләр, дия иде безнең әти. Ашыгыз, Ирек, ашыгыз суына.

Табыннан торгач хуҗаларыма Алексеевскига баргач үзем кичергән күңелсезлекләр турында сөйләдем.

— Гаиләбездә өстенлек миндә булсын дип, никах кенәгәсенә имзасын аякларыгызга басып салды, дисез. Адәм көлкесе, шул кеше укытучы — яшь буын тәрбиячесе саналсын инде. Коточкыч бит бу!..

— Анысы бер хәл, загстан чыккач фатирына кадәр күтәртеп кайтармакчы булган ич әле. Аның яныннан күпкә сузмый таеп дөрес эшләгәнсең, дус. Анда калсаң, ышанып әйтәм, ике дә уйламый башыңа да җитәр иде ул.

— Сезне Олягыз тынычлыкта калдырмаячак, монда эзләп киләчәк әле.

— Килсен, мин аның белән барыбер бүтән аралашмаячакмын.

— Алла диегез,— диде бу сүземә Рәйсә ханым, тирән сулап.— Халыкта иң әйбәт хатын да ирен суярга төнгә җиде тапкыр тора, дигән гыйбарә бар. Сез, Салих әйткәнчә, Олягыз яныннан китеп дөрес эшләгәнсез. Ләкин ул сезне бимазаламый калмаячак әле. Без, хатын-кызлар, бик гарьчел бит. Үзебезне кыерсыткан, рәнҗеткән, хәтеребезне сакламаган кешеләрдән үч алуны изге эшебез саныйбыз. Ачуын Олягыз сездән бише белән кайтарачак.

— Сез әллә нинди коточкыч нәрсәләр сөйлисез, Рәйсә ханым. Бу үзегезгә дә кагыламы?

— Нәрсә сез, мине хатын-кызга санамыйсызмы әллә?

— Саныйм, ник санамыйм. Сез акыллы, күркәм, ачык йөзле, кешелекле хатын. Шуңа күрә үзегезне яңа гына сурәтләнгән дию кыяфәтендә күзаллый алмыйм.

Рәйсә ханым күзләремә туры карап хәйләкәр елмайды.

— Аз беләсез әле сез мине, аз, Ирек.

— Димәк сездән дә теләсә нинди явызлык көтәргә мөмкин?

— Әйе, миннән дә сакланыгыз, Ирек. Юкка гына, сыер дуласа аттан уздыра, димиләр. Салкын самавырдан болайрак кайныйм мин дә...

— Үзенә эчкерсез мөнәсәбәттәге хатын-кызлардан да мәкер, ниндидер усаллык көтәрлек булгач, дөньяда яшәвең корсын.

— Күңелегезне юкка төшермәгез, Ирек, шаярттым мин. Азрак салсам, гел шулай кемгәдер бәйләнә, кемнедер ирештерә башлыйм. Курыкмагыз, тормышта яман хатын-кызлар яхшыларының йөздән бере дә юк. Теләсәгез сезне мин бер дигән хатын булырлык кыз белән таныштырам.

— Зинһар, кирәкми, Рәйсә ханым. Минем инде хатыным бар, күп хатынлыкта гаепләтәсегез киләме әллә мине?

— Юкка әркемәгез, сезне кем беләндер таныштыру өйләндерү дигән сүз түгел әле ул.

— Бу вәсвәсәле уегызны онытыгыз, Рәйсә ханым. Тормышта чишәсе табышмакларым түбәмнән ашкан, үтенәм, аларга яңаларын да өстәмәгез, зинһар. Миңа, беренче чиратта, эш, фатир табуымны, алда ничек көн итәремне кайгыртырга кирәк. Кеше түгел бит әле мин — ноль. Ә ноль,— сез — математик, беләсез,— берәмлек түгел.

— Сезгә әйттек ич инде, менә фатир, торыгыз, безгә комачауламассыз, дидек. Эш тә табарсыз. Кем әйткәндәй, муеныгыз бар, камыт табылыр. Башта сезгә институтка кайтырга, диплом алырга кирәк. Дипломсыз сез чыннан да ноль. Бездә дипломы булса ишәк тә шәхес. Дипломлы ишәкләрне күп беләм мин. Үзем эшләгән мәктәптә дә алар дүрт-биш баш. Шулар әле балалар «тәрбиялиләр». Үзләрендә юк белемне укучыларга «бирәләр».

Рәйсә ханым белән без кич буе сөйләштек. Салих теле белән тегермән тарта белми, аз сүзле кеше, безнең әңгәмәгә катнашмады, тыңлап кына утырды. Ул, гомумән, корыны бушка аударуны өнәми, әйткәнең бер алтын булса, дәшмәвең ун алтын, диптер, бүтәннәр сөйләгәнне тыныч кына тыңлауны яхшырак күрә. Рәйсәсе аның капма-каршысы. Бәлки, ул укытучы булганга, укыткан фәнен укучыларына чәйнәп каптырырга өйрәнгәнгә шулайдыр? Аның белән теләсә нинди темага җәелеп әңгәмә куертасың. Ул игътибарлылыгы, ягымлылыгы, эчкерсезлеге белән магнит күк үзенә тарта. Ләкин шунысы бар, үзе берәүгә дә ярарга, җайлашырга тырышмый, ул сыйфатлар аңа чит, кемгә дә ни уйласа шуны әйтә.

Мин Алексеевскидан кайтуымның өченче көнендә Салихларның фотоальбомнарын карап утырдым. Анда язучыларның, шагыйрьләрнең, артистларның, галимнәрнең, рәссамнарның Салих белән Рәйсә ханымга истәлеккә бүләк иткән фотоларына юлыктым. Минем гаҗәпләнүемә Рәйсә ханым:

— Безнең фатирыбыз — дусларыбыз өчен бер-берләре белән риясыз очрашу, аралашу урыны кебегрәк җир. Безгә бер тапкыр аяк баскан кеше яңадан килми калмый,— диде горурлык белән.— Сез дә безгә фотогызны бирерсез дип ышанам. Иртәгә үк фото ательега барып төшеп кайтыгыз, ядкарьгә шушы кыяфәтегез калсын. Еллар үткәч, Ирекнең менә нинди вакытлары бар иде, дип искә алырлык булсын...

Ничек итеп мин аларның альбомнарына Гали Хуҗи, Бари Рәхмәт, Сәхаб Урайский, Ибраһим Нуруллин, Салих Сәйдашев, Гамир Насрый, Әнәс Камал, Рәфкать Бикчәнтәев, Мәхмүт Хәсәнов, Харис Якупов, Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Зәет Мәҗитов, Шамил Бикчурин кебек мәдәният әһелләре арасына килеп керим? Кем мин? Нахакка кулга алынып, инде тулысынча акланган «халык дошманы» титулы хокук бирәме миңа шундый кешеләр арасына керергә? Юк, бирмидер...

## 2

Казанны судан саклау буенча инженерлык корылмалары төзелеше идарәсенә эш белешергә баргач, үзем элек укыган педагогия институтының төп бинасына да кагылдым. Аның ишеген ачып, бусагасын атлавыма дулкынланудан тыным кысылды. Анда бөтен нәрсә элеккечә, бернинди үзгәреш тә булмаган төсле күренде миңа. Гүя, ул мөкатдәс йортка соңгы керүемә әле тик берничә көн генә үткән иде. Диварларында соңгы кат кергәнемдәгечә үк төрле плакатлар, лозунглар, расписаниеләр, портретлар, эреле-ваклы белдерүләр эленеп тора. Вестибюльдә гамьсез студентлар арлы-бирле йөри...

Канцеляриягә кереп, Йосып Әхмәтҗановичның урынындамы икәнен сорадым.

— Институт директоры өйдә юк, Кавказда ялда,— диде машинистка кыз.

Элек монда машинистка булып бик җитди карчык эшли иде, ул инде мин юкта пенсиягә киткән, күрәсең, дигән уй узды башымнан.

— Аны кем алыштыра хәзер?

— Урынбасары Илья Иванович Мельников.

— Аңа керергә буламы миңа?

— Йомышыгыз нинди? Ашыгычмы?

— Ашыгыч. Миңа яңадан институтта укырга кайтырга кирәк.

Машинистка кыз гаҗәпләнде.

— Нигә сентябрь башында килмәдегез? Кайсы курстан киткән идегез?

— Тарих-филология факультетының дүртенче курсыннан. Мин сентябрь башында монда килә алмадым, ул чакта төрмәдә утыра идем әле.

Кызның күзләре шар ачылды.

— Төрмәдә идегез?..

— Әйе. Черек күл буендагы эчке төрмәдә. Анда илленче елның кышкы сессиясеннән соң утыртылдым.

Кыз директор кабинетына кереп китте һәм, аннан шундук әйләнеп чыгып:

— Үтегез,— диде.

Ишекне ачып эчкә уздым. Директор кабинеты да үзгәрмәгән, элеккечә үк. Тик анда Йосып Әхмәтҗанович кына юк, аның урындыгында бүтән кеше. Исәнләшүемә ул салкын гына җавап кайтарды.

— Илья Иванович, миңа укуыма кайтып институтны тәмамларга кирәк. Йосып Әхмәтҗанович ялда икән, эшемне бәлки сез ансыз да хәл итәрсез?

— Фамилиягез ничек әле сезнең?

— Кадыйров.

— Сезгә бәйләнешле матавыкларны хәтерлим мин, яхшы хәтерлим. Кайчан азат ителдегез?

Мин кесәмнән мәгълүм белешмәне чыгарып директор урынбасарына бирдем. Ул аңа озак кына карап утырды, андагы саран юлларны кат-кат укыды булса кирәк.

— Сез гел эчке төрмәдә генә утырдыгызмыни, Кадыйров?

— Юк, Себерне дә күрсәтеп кайтардылар. Ангара буенда яңа шәһәр салдык, шул шәһәр янәшәсендә үк химия гиганты төзүдә катнаштым. Быелның июль аенда эшемне яңадан тикшерергә Казанга кайтардылар һәм җинаятьче түгеллегемә инангач, ирекка чыгардылар.

— Белешмәгездә нигә аларның берсе дә күрсәтелмәгән соң? Ул нәкъ ребус кебек.

— Аны мин язмадым бит, Илья Иванович, нинди бирделәр, шуны күрсәтәм. Гомумән, серле ул дәүләт иминлеге комитеты исемен йөрткән оешма. Төшегездә генә дә күрергә язмасын аны сезгә.

— Бик куркынычмыни?

— Куркыныч түгел, чиркаңыч.

— Ишетеп бераз беләм ул оешманы, Кадыйров. Сезне ирек алуыгыз белән чын күңелемнән котлыйм. Ә институтта яңадан торгызылу мәсьәләсен мин безнең спецчасть аша белешермен һәм уңай якка хәл итәргә тырышырмын. Монда тагын бер өч көннән керә алырсызмы?

— Керермен. КПСС өлкә комитетына барып партиягә кайтарылуымны да хәл итәсем бар әле минем.

— Башта сез безнең райкомга керегез. Райком секретаребез кыю һәм яхшы иптәш. Ул сезгә ихластан булышыр дип ышанам.

— Фамилиясе ничек аның?

— Габдерәшитов.

— Рәхмәт сезгә, Илья Иванович.

## 3

Бездә житәкче постларда бюрократлар гына түгел, игелекле, миһербанлы бәндәләр дә барлыкка мин Казан шәһәрендәге Дзержинский райкомының беренче секретаре Нәҗип ага Габдерәшитов янына кергәч ышандым. Нәҗип ага мине бик җылы кабул итте. Ишектән керүемә өстәл артыннан чыгып яныма килде, кул биреп исәнләште. Аннары йомшак диванынннан урын күрсәтте.

— Әйдәгез, утырып сөйләшик.

Мин, һаман ристан киемле кеше, үземне бу оешмада болай каршылауны көтмәгәнгә, югалып калдым.

— Кем дип белик сезне? — дип йөземә текәлде бүлмә хуҗасы.

Аңа мин кесәмнән эчке төрмәдән бирелгән белешмәне чыгарып бирдем. Райком секретаре, аны укыгач, аякларына калыкты.

— Төрмәдән чыгарганда тик шушы өтек кәгазьне генә бирделәрмени сезгә?

— Әйе.

— Кулга ни өчен алынган идегез? Миңа йомышыгыз нинди? Ярдәм кирәкме?

— Кулга алынганчы мин партия әгъзасы идем. Утырыр алдыннан, нахак бәла тагып, партиядән чыгардылар. Миңа яңадан партиямә һәм институтка кайтырга кирәк.

— Партиядән кайчан чыгарылдыгыз? Райком бюросы аны раславымы?

— Партиядән — педагогия институтында кырык тугызынчы елның декабрь аенда куылдым. Җыелыш карары расланганлырмы, юктырмы, белмим.

— Хәзер беләбез аны. Сез утырып торыгыз, мин илленче ел башында үткән райком бюросы утырышлары беркетмәләрен таптырыйм.

Райком секретаре җиңел адымнар белән бүлмәсеннән чыкты һәм берничә минуттан ике бармак калынлык соры папка тотып кире керде.

— Хәзер тикшерәбез. — Райком секретаре, алып кергән папкасын ачып, актарырга кереште. — Январь аенда эшегез бюрога куелмаган. Февраль беркетмәләрендә дә фамилиягез күренми. Инде мартны карыйк. Һе, март беркетмәләрендә дә сез юк. Әһә, райком бюросы илленче елның унберенче апрелендә педагогия институты партия җыелышының сезне партиядән чыгарырга дигән карарын раслаган. Сез курсташ иптәшләрегезне «репрессияләнгән буржуаз милләтче әдип» Галимҗан Ибраһимовның реакцион әсәрләрен өйрәнергә чакыргансыз, имеш. Шуның өчен сезгә партия җәзасы өстенә төрмә шәрәфләрен дә татытканнар булып чыга. — Райком секретаре папканы шапылдатып япты. — Шайтан да аңламас заманда яшибез. Татар мәдәниятенең иң якты йолдызларының берсен, контрреволюцион милләтчелектә гаепләп, таш капчыкта гомерен чиклиләр, ул шәхеснең кемлеген дә анык итеп күз алдына китермәүче икенче берәүне, аның «зарарлы» әсәрләрен өйрәнергә чакыруда гаепләп, башта партиядән сөрәләр, аннары төрмәгә тыгалар. Белешмәгездә язылганча, сез гел эчке төрмәдә генә утырдыгызмы?

Мин райком секретарена да башымнан кичкәннәрне кыскача гына сөйләп бирдем.

— Ирекка чыгарганда КГБда сездән гафу үтенүче булдымы?

— Юк.

— Күпме матди ярдәм бирделәр?

— Андый нәрсәне анда берәү дә искә алмады. Хәтта кулга алынгач, тентү вакытында кесәмдә табылган ун сумны да кире кайтармадылар.

— Хәзер нәрсә хисабына яшисез соң?

— Фатирына сыйдырган сабакташым җилкәсендә утырам. Якын көннәрдә эшкә урнашырга уйлыйм. Илдә чыпчык үлми...

— Рәхәт тә күрми, — диде каттый итеп райком секретаре. — Болай килешик, мин бүген үк КГБга да, партия өлкә комитетына да шал-

тыратырмын. Ышанып әйтәм, партиягә дә кайтачаксыз, институтта да укырсыз. Минем янга тагын ике көннән керегез.

— Зур рәхмәт сезгә, Габдерәшитов абый...

— Чыкмый торыгыз, мин оештыру бүлегенә шалтыратам, анда сезгә бераз акча бирерләр.

Миңа уңайсыз булып китте.

— Кирәкми, Габдерәшитов абый, мин сезгә материаль ярдәм өметләнеп кермәдем.

— Җүләр сатмагыз. Сез коммунист, райком сезнең төп йортыгыз. Ярдәм итү — безнең кешелек вазыйфабыз.— Ул телефон аша кем беләндер миңа акча бирү турында сөйләште.— Сез, иптәш Кадыйров, миңа тагын ике көннән керегез. Хәзер оештыру бүлегенә кагылыгыз.

Райком секретаре мине бүлмәсенең ишеге төбенә кадәр озатып:

— Яңадан күрешкәнгә кадәр, иптәш Кадыйров,— дип кулымны кысып калды.

## Дүртенче бүлек

### 1

Райкомга керүемнең икенче көнендә Рәйсә ханым, эштән кайткач, Салих белән миңа:

— Егетләр, апагызны бүген, зур илтифат күрсәтеп, джентельменнарча, икегез ике ягымнан култыклап, театр каратып кайтыгыз әле,— диде.

Салих, борчылып:

— Нигә алданрак әйтмәдең соң аны? Рәтле урын калгандыр дисеңме инде партерда? — дип, кашларын җыерды.

— Анысы инде сезнең эш, җаныкаем. Театрга көн дә бармыйбыз, мине хөрмәт итсәгез, табарсыз җүнле билет. Сез — икәү...

Кичке аштан соң җыенып өйдән чыктык. Минем театр карарга бернинди дә теләгем юк иде, хуҗаларымның хәтерен саклап кына аларга иярдем.

Инде октябрь урталары җитсә дә шәһәрдә көз әле кырыслыгын сиздерми. Һава тын, урамнарда фонарьлар яна. Без өчебез дә һәркайсыбыз үз уйларыбызга бирелеп тигез тротуардан атлыйбыз. Шактый җир үткәч, Рәйсә ханым, канәгатьсез тавыш белән:

— Нигә сез икегез дә авызларыгызга су каптыгыз? Бүгенге кичегезне әллә бүтәнчә үткәрергә планлаштырган идегезме? — диде.

Аңа ире:

— Мин кичке урам карап хозурланып барам, гел генә такылдарга димәгәндер,— дип җавап кайтарды.

— Әйттең сүз, башка вакытта күп сөйлисең инде син, бер дә харап. Сез дә, Ирек, шушы тын кичтән башыгызны югалттыгызмы?

— Мин нинди спектакльгә тап булырбыз икән дип уйланып барам.

— «Идел буенда» диелгән афишада. Аны «Алтын көз» музыкаль комедиясе дә диләр.

— Шәп, көзне урамда гына түгел, театрда да карыйм икән әле,— диде Салих, көлеп.

— Театрга барасы булсам, мин Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ын исемә төшерәм,— дип сөйләп китте Рәйсә ханым, уйчан гына.— Мин сәхнәдә беренче кат караган спектакль ул. Авылыбыз яшьләре куйган иде аны. Исмәгыйль булып уйнаган егет Хәлил булып уйнаган егетне сәхнәдә чын-чынлап атып үтерде. Хәлил ролен башкарган гармунчы егет ядрәләр урынына кадаклар турап корган үзе ясаган наганыннан атты аны Исмәгыйль булып уйнаучы, диделәр соңыннан. Шул фаҗига

гомерем буе китми күз алдымнан. Хәлил ролен башкарып һәлак булган егет Гали исемле иде һәм ул бездән бер генә өй аша яши иде. Кечкенә сабый идем әле ул чакта. Караңгы төшкәч, сәхнәдә җан биргән Гали абый килеп тотар дип, өйдән бусаганы атлап чыгарга курка идем. Чыксам, баскыч төбендә генә Гали абзый көтеп торадыр, ул мин өйалды болдырына эз басу белән эләктереп алыр кебек иде...

Рәйсә ханымның тәүге кат караган спектакле калдырган күңелсез истәлеген тыңлап, театрга барып җитүебезне сизми дә калдык. Тышкы ишектән кергәч, Салих билетлар алырга кассага юнәлде. Анда егермеләп кеше чиратка баскан иде.

— Салих, син бездән аерыласыңмыни? — дип гаҗәпләнгән булды Рәйсә ханым. — Өйдә безнең белән, ялгыз калсаң адашырсың, өйгә кайта белмәссең бит... — Ул редикюленнән билетлар чыгарып, миңа бирде. — Мә, Ирек, джентельмен бул, уздыр безне алдан.

Театр фойесы инде халык белән шыгрым иде. Мин бәйрәмчел, ваемсыз кешеләр арасында күптәннән булмаганча үземне уңайсыз хәлдә сиздем. Күз алдымда өстемдәге кебек үк «шайтан тиресе»ннән тегелгән тупас ристан «костюмнары» кигән зэклар яңарды. Тормышта шуларның кайсы чын — бередәге үз-үзләреннән канәгать, иртәгәсе көннәре кирәгенчә тәэмин ителгән шушы ваемсызлармы, әллә тамак хакына эшләп, ачлы-туклы гомер сөрүче иректән мәхрүм зэк-колларммы?..

Тамаша залына керергә чакырып кыңгырау шалтырады. Фойедагы кешеләр киң мәрмәр баскычтан ашыкмый гына күтәрелеп, тамаша залына керү ишекләренә юнәлделәр. Без дә аларга иярдек. Урыныбыз партерның бишенче рәтендә иде. Рәйсә ханым башта Салихны урынына үткәрде, аннары — аның артыннан үзе... Миңа:

— Ә сезнең урыныгыз миңа бер кеше аша, — диде. — Әнә ул үзе дә килә инде.

Безнең рәткә эре дулкынлы коңгырт чәчле, мөлаем йөзле, уртадан бераз калкурак буйлы егерме биш-егерме сигез яшьләр тирәсендәге туташның килгәне күренде. Мин аны Рәйсә ханым янәшәсенә үткәрдем.

— Таныштырыйм сезне, Ирек, бу — медицина фәннәре кандидаты Мөнирә иптәш. Ә бу, Мөнирә, Салихның элекке сабакташы, безнең кунагыбыз, күптән түгел генә Себердә сират күперләрен кичеп кайткан Ирек.

Без, яңа танышлар, бер-беребезгә баш кактык.

Спектакльне барыбыз да тын гына карадык. Ул, артык шау-шулы булгангадыр, миңа ошамады. Анда гәүдәләндерелгән вакыйгалар тормыштан ерак, ясалма һәм примитив иде.

Дүртәүләшеп кайтырга чыккач, Рәйсә ханым миңа:

— Сез егет кеше, Ирек, Мөнирә туташны өенә кадәр озатып куярсыз, бәлки? — диде.

— Туташ үзе каршы килмәсә, мин әзер, рәхәтләнеп озатам, — дигән булдым. Үзем исә: миңа шул гына җитми иде, — дип уйладым, уртәлеп.

Мөнирә, назланып:

— Мин бик еракта торам бит, укенмәссезме соң? — диде.

— Фатирыгыз Столбище районында ук түгелдер бит?

— Анда ук түгел, мин Кабан күленең аргы ягында торам.

— Килештек. Кабан күлләре өчәү, аларның иң аргысы читендә яшәсәгез дә курыкмыйм, барам. Вакытым санаулы түгел.

— Ярый алайса, үзегезгә карагыз...

Салих белән Рәйсә ханым, Пушкин урамында Мөнирә туташ белән саубуллашып, өйләренә юнәлделәр. Алардан аерылгач, мин:

— Култыкласам, үпкәләтмәмме сезне, Мөнирә туташ? — дидем.

— Кодрәтегез җитсә, култыклагыз, — диде ул, көлеп.

— Нигә аңа кодрәт? Мин кемнән куркырга тиеш?

— Минем танышларым очраудан.

— Зарар юк, сез үзегез курыкмасагыз, мин курыкмыйм. Рәйсә ханым безне таныштырганда, бу — Себердә сират күперләрен кичеп кайткан Ирек, диде бит. Ә сират күперләре Казан урамы гына түгел, күпкә хәтәррәк.

— Нәрсәне аңлата соң ул сират күперләрен кичү? Бәлки, төшендерерсез?

— Рәйсә ханым сезгә минем турында берни дә сөйләмәдемени? Яшермәгез, турысын әйтегез. Безнең бу очрашуны ул махсус оештырды, шулаймы?

Туташ боргаланып торуны кирәк тапмады.

— Сөйләде. Шулай,— диде гади генә итеп.

— Мин куркыныч кеше, Мөнирә. Сез фәннәр кандидаты, врач. Мин — дипломсыз сукбай. Черек күлдәге төрмәнең ялгыз камераларында каңгырап, Гулаг колонияләрендә кандалалар, черкиләр симерткән, җәһәннәмнең түрен күреп кайткан йолкыш. Эшем дә, торыр урыным да, сыенырга якыннарым да юк. Иртәгәм нәрсә алып килер, бу бер аллага гына мәгълүм. Тормышымда миңа бөтен нәрсәне нольдән башларга кирәк. Менә без бүген спектакль карадык. Минем күзләрем сәхнәгә төбәлгән булсалар да, башымдагы уйларым әллә кайларда буталдылар. Сәхнәдәге корама сюжет та, артистларның тамашачыларны көчәнә-көчәнә көлдерергә тырышулары да, башкарган тозсыз җырлары да күңелемә үтмәделәр. Мин, гомумән, тормышыбызны аңламыйм. Ул, миңа калса, сәләтсез рәссам эшләгән корама декорация кебек...

Мөнирә сүземне бүлми тыңлап кайтты. Болак күперенә җитәрәк:

— Төрмәне мин күз алдыма китерә алмыйм, нәрсәгә охшаган ул? — диде.

Менә ишетмәсәң ишет! Дөньяда төрмәнең нәрсә икәнен дә белмәүче бәндә дә бар икән ләбаса. Гаҗәп...

— Пушкинның «Мәхбүс»ен исегезгә төшерегез. Мәктәптә укыганда ятлаганыгыз хәтерегездәдер, «сижу за решеткой в темнице сырой»... Төрмә — безнең иң койты демократиядән дә мәхрүм илебездә кеше шәхесен түбәнсетү, кимсетү, җәберләү, газаплау, деградацияләү урыны. Сез аны белмисез икән, шатланыгыз гына, белмәвегез хәерле. Сез, минемчә, тормышта мин очраткан иң бәхетле кеше. Әйдәгез, бу күңелсез теманы калдырып, башка нәрсә турында гәпләшик.

— Үзегез турында сөйләгез әле, кайдан сез, кемнәрегез бар?

Бу туташ миннән сорау ала башлады түгелме соң? Кызыксынуына чик куйыйм булмаса.

— Кемнәрем бар дисез? Хатыным бар.

Туташ кинәт тукталды.

— Арттырасыз булыр?

— Нигә арттырыйм, паспортымны күрсәтә алам.

— Кайчан өйләнгән идегез, кулга алынганчымы?

— Төрмәдән чыгуыма атна тулганда язылыштык.

— Тормыш иптәшегез хәзер кайда? Әле генә сыенырга хәтта якыннарым да юк, дидегез бит. Хатыныгыз ул исәпкә кермимени?

— Керми, Мөнирә, керми. Чөнки хатыным минем тик кәгазьдә генә. Бар да ул, юк та...

Пушкин урамыннан ук башланган әңгәмәбез шунда өзелде. Минем күз алдымда кинәт Мурзиха пристане, анда яр буенда янган учак, «Карчыга», аның «бөркетләр»е һәм бишекле милиция мотоциклына утырып килгән Оля яңарды...

— Менә без кайтып җиттек,— дигән сүзләр уйларымны бүлде.

Без революциягә кадәр үк салынган ике катлы иске агач йортның алгы подъезды алдында туктадык.

— Сез мине кешеләр ачыктан-ачык сөйләү түгел, хәтта уйларга да өнәми торган нәрсәләр турында такылдап килгәнем өчен кичерегез, Мөнирә туташ. Замандашларым белән бер калыпта фикер йөртә бел-

мәгәнем, аларча эзгә-эз басып якты киләчәгебезгә атламаганым өчен зиндан «рәхәтләрен» татыдым инде татуын. Әмма ул, күрәсез, файдага китмәде. Бу кичегезне миңа багышлаганыгыз һәм минем «фәтнәчел» лыгырдавымны түземегезне төкәндерми тыңлаганыгыз өчен рәхмәт. Инде кайтыйм. Тыныч, тәмле йокы телим сезгә. Хушыгыз.

Мөнирә мине җибәрмәде, җиңемнән тотты.

— Ишегем төбенә кадәр озаткач, фатирыма керми китмәгез. Әйдәгез, керик, мин сезне чәй белән сыйлармын.

— Вакыт соң инде, Мөнирә. Истә-санда юкта, төн уртасында, сезгә ияреп кайткан ят кеше өегездәгеләрне өркетер, кермим.

— Минем өемдә сез кергәнгә өркерлек беркемем дә юк. Мин бербашым торам. Әйдәгез, назланмагыз, керик.

Икеләнә калдым. Әмма яңа танышымның фатирына керергә ихлас күңелдән чакыруы мине җиңде. Кереп чыгыйм соң, ни югалтам, дип дәртләндердем үземне.

Фатирына кереп ут алгач, Мөнирә:

— Үзегезне өегездәгечә хис итегез, тартынмагыз. Мин хәзер чәй куям, сез әнә китаплар караштыра торыгыз. Тартасыгыз килсә, тартыгыз. Төпчек савыты шунда өстәлдәдер,— диде.

— Рәхмәт, мин тартмыйм.

— Ә мин, гонаһлы бәндә, хатын-кыз булсам да, оялмый тәмәке пыскытам. Алай берәзлексез тартмыйм тартуын, көнгә дүрт-биш сигарет кына, әмма тартам. Врач әсәре бит. Тартмаган медицина хезмәткәрләрен медиклар үз араларында «ак карга»га исәплиләр. Бу да сәбәп түгел, әлбәттә. Тартырга институтта укыганда, моргка мәетләр анатомировать итәргә йөргәндә өйрәнелде. Ташларга вакыт тими, ташла, сиңа тарту килешми, дип тыючы да юк, өстәвенә ихтыяр көчем дә өчле-тугызлы гына.

Мөнирә боларны кухнясында пидер кайнаша-кайнаша сөйләде. Мин аны тыңлап, фатирына сокланып утырдым. Бер кешегә болын күк зур бүлмә. Дүрт стенаның берсен китаплар стеллажы биләгән. Анда Пушкин, Лермонтов, Толстой, Достоевский, Гоголь, Тургенев, Горький әсәрләре, күп томлы Эфрон һәм Брокгауз энциклопедиясе, төрле медицина китаплары. Әдәби китапларның күбесе революциягә кадәр нәшер ителгәннәр. Стеллаж алдына ук барып, кайбер китапларны кулыма алып карый башладым һәм көтмәгәндә Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Риза Фәхретдинов әсәрләренә дә юлыктым. Алар ничек сакланганнар һәм кем саклаган ул гарәп имлясындагы тыелган китапларны?..

Мөнирә кухнясы белән бүлмәсе арасында тыз-быз йөреп өстәл хәзерләде.

— Сез бу тәмәкече чәчбигә мондый фатир ничек эләккән икән, дип уйлыйсыз булыр. Сере юк аның. Монда элек бабам белән әбием яшиләр иде. Бөтен гомерләрен балалар укытуга, мәктәпкә багышлаган кешеләр иде алар. Кемнең дә гомере, үзегез беләсез, мәңге түгел, өзелә. Бабам, моннан дүрт ел элек, көтмәгәндә дөнья куйды. Әбием, бабамнан калгач, монда елга якын ялгызы каңгырады да, бер көнне безгә килеп, үлсәмнитсәм фатирым юкка чыгар, дип мине бу бүлмәгә күчәргә кодалады. Мондагы барлык китаплар, җиһазлар, савыт-саба барысы да әбием белән бабамныкы. Өемдәге үз әйберләрем әнә теге төпчек савыты белән аякларымдагы үкчәсез чүәкләрем генә. Әйдәгез, кухняда кулларыгызны юып чыгыгыз да, табынга утырыйк. Күрүегез әйбәт булды әле, мин бүлмәмә аяк басу белән сигарет кабызыр идем. Ялгызлык чир белән бер, үзеңне кая куярга белмисең, күп вакыт нәрсә эшләргә, кулларына нинди шөгыль табарга аптырыйсың.

Мин кулларымны юган арада Мөнирә ике бәллүр чәркәгә мөлдерәтеп коньяк салган иде. Өстәл артына утыргач, чәркәләрне кулларыбызга алып чәкештердек һәм хуҗа тоташ:

— Танышуыбыз хөрмәтенә! — дип, чәркәсен төбенәчә бушатты. Мин иренемне генә чылаттым.

— Әллә эчмисездәме сез, алла бәндәсе? — дип гаҗәпләнде туташ.— Кыланмагыз, зинһар. Бусы бетсә, икенче шешәне ачарбыз. Исерсәгез, әнә диван, ятып йокларсыз.— Ул үз чәркәсенә тагын коньяк салды.— Сез, бу нинди инсафсыз чәчби, тарта, эчә, ди торгансыз. Сез әнә монда кайткан-да ялгыз камерада утыруыгызны сөйләдегез. Ялгыз камераның нинди икәнен мин күз алдыма китерә алмыйм, кош ябарга махсус эшләнгән читлек кебегрәк нәрсәдер инде ул. Һич арттырмыйм, мин дә үземне тар читлектә итеп тоям. Өемнән кая да булса чыгып китсәм, яңадан кайтып керәсем килми.

— Шуның өчен тәмәкедән, аракыдан юаныч эзлисезме?

— Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума. Бу — шул гына. Ул «бозыклык»ларым миңа, дөя үркәчләре кебек, инде гомерем буена аерылмаслык ябышканнардыр, дип уйламыйм.

— Тормышка чыгарга кирәк сезгә,— дидем мин аңа турыдан-туры.

— Һәй, кемгә хаҗәтем бар минем? Ирләргә пар табуы җиңел, хатын-кызга алай түгел. Кеше белән танышасың, сиңа аның йә бер ягы, йә икенче ягы ошамый, йә ул сине ошатмый.

— Сезнең ошамас җирегез юк, минемчә. Буегыз-сыныгыз, төсегез-битегез сокланырлык, белгечлегегез бер дигән, баш өстегездә түбәгез бар, фикерләвегез төпле, аек...

— Һәй, күкләргә күтәрмәгез мине, җиргә төшерегез. Мине бөтенләй белмисез сез, мактамагыз, зинһар. Үземнең кем икәнемне мин яхшы беләм, кешедән сорыйсым юк. Турыдан-туры биргән соравыма шулай ук туры җавап бирегез. Әйтегез әле, минә сез миңа өйләнер идегезме?

Кызык сорау бирде туташ. Бер сүз белән «әйе» дисәң дә, «юк» дисәң дә, ул аңлатып бируемне көтәчәк. Җавабымны бераз уратып бирим, булмаса...

— Минемчә, кешеләр уртак тормыш төзер алдыннан бер-берсен күпмедер өйрәнергә, белергә тиештер. Өйләнешү ир кешегә дә , хатын-кызга да базарданмы, кибеттәнме нәрсәдер сатып алу гына түгел бит. Әйбер сатып алганда да кеше күрү белән күзләренә чалынган нәрсәне түгел, күңеленә хуш килгән нәрсәне сатып ала. Мин сезнең холкыгызны, интересларыгызны, кешелек сыйфатларыгызны бөтенләй белмим. Чагыштыруым урынсыз тоелса, гаепләмәгез: елан, беренче карашка, бик матур, әмма тотсаң, ул сиңа агулы тешләрен батыра. Кешеләр арасында да андый хәл юк түгел. Күрер күзгә берәү коеп куйган, ә эчендә агу. Бәлки, мин дә шундыйдыр? Тормышта чын йөзләрен яшерергә тырышып артистланучылар аз түгел. Аннары, өйләнешер өчен минем сезне ошатуым гына аз, сезнең дә мине ошатуыгыз, ризалыгыгыз кирәк бит әле.

— Мин язмышымны сезнеке белән бәйләргә риза, Ирек.

— Без пар түгел, Мөнирә. Аннары мин буйдак түгел ич инде, хатыным бар.

— Кәгазьдә генә дидегез түгелме соң ул хатыныгызны?

— Ул кәгазь рәсми документ бит.

— Хатыным бар дип юкны сөйләмәгез, мин сезне инде бераз беләм, Ирек. Рәйсә ничек өйләнүегез турында да, каһәрле тормышыгыз турында да төкми-чәчми сөйләде. Менә үзегезне күрдем. Яшермим, ошадыгыз миңа. Сезгә мин аякка басарга, узгәнегездәге күңелсезлекләрне онытырга, сез инде ятсынырга өлгергән ирекле тормышка борчу-мәшәкатьләрсез яңадан чумарга булышырга телим. Сезнең дә үземә арка таянычым була алырыгызга шикләнмим.

Кара, киләчәгем инде ничек хәл ителгән!.. Кемнәр өчендер пешка хезмәтен үтәүдән кайчан туктармын мин?

— Рәйсә ханым мине бик аз белә, Мөнирә. Аның сүзләрен чын хакыйкатькә санап ялгышкансыз сез. Миңа ышаныч күрсәтүегез, язмышыгызны икеләнүсез минеке белән бәйләргә, үзегезне күрелмәгән авырлыкларга дучар итәргә әзер торуыгыз өчен баш иям алдыгызда. Җиде кат үлчә — бер кат кис, дигән борынгылар. Ашыкмыйк, өйрәник бер-

беребезне. Мин партбилетымны кире алыйм, эшкә урнашыйм, институтка кайтып, аны бетереп чыгыйм. Аларны мин кемгәдер ышыкланып түгел, ялгызым эшләргә тиеш. Хәләл көчем куеп тапкан акча урынына кемнеңдер хәер-сәдакасы исәбенә көн итә башласам, мин үз-үземнән җирәнәчәкмен.

— Минем хәлемә керергә теләмисез, димәк?

— Хәзергә үз хәлем хәл әле, Мөнирә, үпкәләмәгез.

— Мондый катгый җавап көтмәгән идем сездән, Ирек, гафу итегез.

— Түбәнсетмәгез үзегезне, кирәкми. Горур булыгыз, имәгез башыгызны.

— Һәй, горур булудан, башны югары тотудан ни отам? Минем хатын-кыз бәхетен татыйсым — бала табасым, бала үстерәсем килә. Иптәш кызларымның, сабакташларымның һәммәсенең балалары — дәвамчылары бар. Мин генә төнге ябалак күк бербашым, үртәләм.

Гаҗәп, Мөнирә дә Оля әйткәннәрне үк сүзгә-сүз диярлек кабатлады. Алар нәкъ сүз куешканнар диярсең, ә бер-берләрен бөтенләй белмиләр үзләре...

— Мин китим, Мөнирә, йоклагыз.

— Куныгыз монда гына. Кайтуыгызны дүрт күз белән көтеп торучыгыз юк бит. Минем өчен борчылмагыз, йокларга өлгерермен, иртәгә лекцияләрем төштән соң гына.

— Рәхмәт, мин китим.

— Җансыздыр сез, Ирек, валлаһи, ялгызым калсам, төне буе керфек тә какмаячакмын бит мин...

— Тагын бер кат тыныч төн, тәмле йокы телим сезгә. Хушыгыз.

— Хушыгыз.

## 2

Фатир хуҗаларым инде йоклаганнар иде, әмма ишекне үземдәге ачкыч белән сак кына ачып, бусаганы атлавыма Рәйсә ханымның:

— Өйгә кем керде, сезме, Ирек? — дигән соравы ишетелде.

— Әйе, мин кайттым, борчылмагыз, йоклагыз, — дидем. — Мин дә менә чишенәм дә ятам.

— Сезне без Мөнирәдә кунасыздыр дип уйлаган идек инде. Нәрсә, бер-берегезне ошатышмадыгызмы әллә?

Менә сиңа мә!.. Мине Рәйсә ханым үземнән сорамыйча өйләндергән булган, димәк. Ачуым чыкты. Мине кемгә саный ул? Аларга комачаулыйм икән, ачыктан-ачык әйтсен, фатир табыгыз, Ирек, без үзебезне кысрыклап сезне асрый алмыйбыз, дисен.

— Бу сезнең, безгә күз көеге булмагыз, сездән тарсынабыз, диюегезме?

Рәйсә ханымга җавабым ошамады, ул аны күкерт күк кабызды.

— Акылыгыздамы сез, кем тарсына, кем куа сезне? Бездә күпме теләсәгез, шулкадәр торыгыз, дидек бит инде, нигә һәр сүздән гаеп эзлисез?

— Мине Мөнирә белән таныштыру, аны озаттырып куюу нигә кирәкте соң сезгә? Кем өчендер уенчык хезмәтен үтәргә теләмим мин.

Сүзләремне тавышымны кысмый әйттем, Салих караватларыннан торып яныма килде.

— Ярар, дус, шаулама, аңлыйм хәлеңне, ир бул. Чишенеп ят, йоклыйк. Рәйсә белән иртәгә тел чарларсыз, — диде ул, иңемнән кагып.

Хуҗабикә аклануны кирәк тапты.

— Гафу итегез, Ирек, сез ике ялгызакны таныштыруым хәлегезгә керергә тырышуым иде. Бер-берегезгә, бәлки, таяныч булырсыз дигән идем. Мөнирә бер дигән кыз, ә парсыз. Мин аның бәхетен тизрәк табуын

телим. Сезне дә бәхетле дия алмыйм. Бәлки уртак тел табырсыз дигән идем...

— Мөнирәгә мин пар түгел, Рәйсә ханым. Без аның белән икебез ике дөнья кешеләре. Ул буй җитмәс югарыда, мин исә тирән упкын төбендә. Язмышын минеке белән бәйләгән кеше бәхетле булмас дим мин.

— Мөнирә ошадымы соң сезгә?

— Сезнең һаман үз туксаныгыз, Рәйсә ханым. Мин инде хатынлы кеше, миндә кызлар кайгысымы?

— Ярар, бүгенгә җитсен, вакыт соң инде, йоклыйк,— дип тыйды безне Салих.

Рәйсә ханым:

— Сез ашап алыгыз, Ирек. Кухняда әнә үзегезгә кирәк нәрсәләрне табарсыз. Зинһар, миңа үпкәләмәгез, яман уй белән очраштырмадым мин сезне,— дип, бүлмәләрендәге утны сүндерде.

— Ашап тормыйм, рәхмәт, Мөнирәдә сыйланып кайттым,— дип, өстемне чишенергә керештем.

Ничек кенә тырышсам да таңга кадәр йокыга китә алмадым. Башымны төрле уйлар тинтерәтте. Ирекле тормышка җиңел генә кереп китә алмавыма үртәлдем. Үземне көткән билгесезлекләрдән тизрәк арынасым килде. Көннәр үтә тора, мин исә, үрмәкүч пәрәвезенә элегеп бәргәләнгән чебен күк, үткәннәрем тозагыннан котыла алмыйм. Ирекка чыкканнан бирле кыл да кыймылдатмый яшәвемә чик куеп, нинди дер эш майтара башларга кирәк. Райком секретаре берсекөнгә керергә кушты, эзләп кулай эш тапмасам, бәлки, аңа мөрәҗәгать итәрмен. Юк, эш мәсьәләсендә дә аны бимазаларга ярамас. Ул миңа бер булышты — партия кассасыннан ике йөз илле сум акча бирдертте бит инде. Аңа эшкә урнашырга булышуын да сорап мөрәҗәгать итсәм, ул мине, якты йөз күрсәткәч, ямаулык теләнгән саилчегә охшатыр. Эшне мин, кемнеңдер булышлыгыннан башка, үзем табарга тиеш... Мөнирә йоклый торгандыр инде, бәлки йокламыйдыр, үзем генә калсам, күзләремә йокы кермәячәк, диде бит. Оля белән һич чагыштырырлык түгел аны. Оля дуамал, ә Мөнирә сабыр. Аларның икесенең дә табигать биргән ана булу вазифасын үтиселәре килә. Фәннәр кандидатлыгын, абруйлы белгечлеген, эшен Мөнирә чүпкә дә санамый кебек...

## 3

Ниһаять, эшкә урнаштым. Балалар бакчасын төнлә саклау дәрәҗәле эш түгел түгелен, әмма, бездә начар хезмәт юк, һәр эш күркәм һәм мактаулы, дигән атаклы гыйбарәгә турылыклы калсаң, ул хурланырлык түгел. Мин үзем саклаган бакчаның кечкенә генә бер караңгы бүлмәсендә торам да. Вазифам төнге каравыл гына түгел, бакча бинасы һәм аның янындагы хуҗалык корылмалары тирәләрен себерү—җыештыру, машинада балалар өчен китерелгән азык-төлекне ашханәгә яки складка ташырга булышу, уеннар мәйданчыгындагы җиһазларны тәртиптә тоту да. Бу эшкә урнашырга миңа райком секретаре Габдерәшитов абый булышты.

— Сез анда үзегезгә үзегез хуҗа булырсыз, фатир да эзләргә туры килмәс. Мин балалар бакчасы мөдире иптәш Ишалина белән сөйләштем, ул каршы түгел. Аның сезгә төп таләбе — төннәрен янызгыза хатын-кызлар йөртмәү. Андый катгый таләпне үти алырсызмы?

— Үтәрмен, Габдерәшитов абый.

— Чокырны сикереп үткәнче үк һоп димәгез. Хәзер хатын-кызлар ирләрне үзләре аулыйлар, үзләре азындыралар, имеш. Сумкаларына ярты кыстырып, курчак кебек ясанып, күзләрен хәйләкәр майландырып килгән чибәрдән баш тарта алырсызмы икән? — дип елмайды райком секретаре.

— Эчмим дә, тартмыйм да бит мин. Намусыма хыянәт итмәм, Габдерәшитов абый.

— Шаярттым мин, барыгыз, уныш телим сезгә. Партиягә кайтуыгыз мәсьәләсе тиздән хәл ителәр, көтегез,— дип озатып калды ул мине.

Хатын-кызларның бәйләнчекләкләрен белә икән Габдерәшитов абый. Моңа мин бик тиз инандым. Эшли башлавымның өченче төнендә сәгать унберләр тирәсендә кемдер балалар бакчасы бинасының ишеген шакыды. Милиционерлар килгәндер, хуҗаларча шакыйлар, дип барып ишек артында кем барын сорамый келәне күтәрдем. Тыштан ярым караңгы вестибюльгә балалар бакчасы пешекчесе — калын гәүдәле, йөзе һәрвакыт елмаюлы Роза керде.

— Хәерле кич, матурым.

— Хәерле кич,— дип җавап кайтардым, аптырап.— Нәрсә булды, ник килдегез?

— Сине сагындым. Әллә бүтән кешене көтә идеңме?

— Ни сөйлисез, мин берәүне дә көтмим.

— Сиңа монда ялгызыңа гына күңелсездер, сөйләшеп утырырбыз иркенләп, дип килдем менә. Әйдә, тормыйк монда, ишегеңне бикләдә бүлмәңә үтик. Гомер бер генә килә кешегә, аның кадерен белергә кирәк. Кухняда минем яшереп куйган яртым бар, салырбыз, сөйләшербез. Син дә ялгыз, мин дә ялгыз...

— Кермибез минем бүлмәмә, сөйләшмибез дә. Кайтып китегез өегезгә.

— Кума, матурым. Ир кеше ич син. Мин синең яныңнан тиз генә чыгарга килмәдем.

— Чыгыгыз, Роза, үтенәм сездән.

— Чыкмыйм.

— Чыкмасагыз, мин милициягә шалтыратам.

— Чынлап әйтәсеңме? Ахмак түгелсең бит син?

— Чынлап әйтәм, чыгыгыз моннан.

— Мин менә, көчли, коткарыгыз, дип разбой салсам нишләрсең?

— Кычкырып карагыз, нишләвемне күрерсез.

Роза шул сүзләремне генә көткән кебек кинәт бар тавышына:

— Каравыл!.. Ярдәм итегез, үтерә!..— дип сөрән салды.

— Тыңламадыгыз, үзегезгә үпкәләгез!— Мин төнге кунакны кулларын артка каерып тиз генә ишектән чыгарып җибәрдем.

Ул ишегалдыннан миңа:

— Дурак син, потың бер тиен! Нишләр икән бу дип кенә кергән идем яныңа, алаша,— дип кычкырды.

Әллә инде дөньяда җүнле-башлы ояла, тартына белүче бер генә хатын-кыз да калмады микән, дип уйладым мин, ачынып. Иреккә чыкканнан бирле ник гел тап булам шундыйларга? Эзләмим дә бит үзләрен. Оля, Мөнирә, Роза. Бишь ел эчендә тормыштан бик нык артта калганмын, күрәсең...

Пешекчебез Розаның төнлә балалар бакчасына килүен берәүгә дә әйтмәдем. Аның үзенең дә төнлә яныма керүен, икебез генә очрашканда да, бүтән искә алганы булмады, үткән эшкә салават дип, ул турыда искә төшерүне мин дә кирәксенмәдем.

Балалар бакчасына төн уртасында «адашып» килүче хатын-кызлар Розадан соң да булгалады. Ләкин мин аларның берсен дә бина эченә кертмәдем, ләчтит сатарга яннарына да чыкмадым. Шуның өчен әллә нинди мыскыллаулар ишетергә туры килде. Араларыннан берсе, үтенечемә колак салмавыма җенләнеп, хәтта балаларның көндез йоклый торган бүлмәләре тәрәзәсен таш атып челпәрәмә китерде. Иртәгесен колхоз базарында пыялачы табып аны үз хисабыма куйдырдым. Габдерәшитов абый алдында уңайсыз хәлгә калмас өчен, эшемне төгәл һәм җиренә житкереп башкарырга тырыштым. Шуңа күрәдер, балалар бакчасы мө-

дире — үзенә буйсынган һәр хезмәткәрнең эшеннән гаеп эзләүче Суфия Ишалинадан да бер тапкыр да тәнбиһ ишетмәдем.

Суфия Ишалина инде кырыкка якынлашып килгән, фронт юлларын үткән ике балалы тол хатын иде. Ул эшен һәркөнне, барлык бүлмәләрне тикшерүдән, бакчадагы җиһазларны барлаудан һәм миннән төннең ничек үтүен сорашудан башлый иде. Башта ул миңа ничектер шикләнеп, шөбһәләнеп карый иде кебек. Аннары көндезләрен институтка лекцияләр тыңларга йөрүемне, төннәрен баш күтәрми китаплар өстендә утыруымны белгәч, карашын үзгәртте. Хатын-кызлар көне 8 Мартта миң мөдирем турында «Кызыл Татарстан» газетасында «Фронтовик әле дә алгы сызыкта» дигән җылы гына мәкалә бастырдым. Мәкалә белән бергә газетада Суфия Илдархановнаның рәсемен дә чыгардылар. Бу аның күңеленә бик хуш килде. Шуннан соң берничә көн үткәч, ул:

— Мин сезне эшкә кабул иткәндә, иптәш Габдерәшитов сезнең өчен җаваплылыкны үз өстенә алса да, ышанмаган, икеләнгән идем. Сынауны сез лаеклы үттегез. Розаны төнлә яныгызга «кәеф-сафа кылырга» мин җибәргән идем, гафу итегез,— диде.

— Әйтегезче, төннәрен мине бимазалаган бүтән төнге кошларны да сез яллыйсызмы?— дип кызыксындым мин.

— Яныгызга Розадан бүтән кешене җибәргәнем юк...

Кеше намусын мәкерле, кабәхәт юллар белән тикшерүгә бирәр вакыт чик куелырмы икән бездә?

Шушы тәкәллефле аңлашудан соң мөдиребез миңа үзенең тормышы, балалары, башыннан кичергәннәре, фронтта күргәннәре, белемен тирәнәйтәсе килүе, әмма көндәлек ыгы-зыгыда моңа вакыты җитмәве, көннәре анда чабып, монда чабып, йә тегене, йә моны юнәтеп үтүе һәм шуларга охшаш бүтән нәрсәләр турында сөйли торган булды.

— Мин кичергәннәр зур бер китап язарлык,— дия иде ул, серле итеп.

Бер сөйләшкәндә аңардан:

— Сезнең ирегез кайда?— дип кызыксындым.

— Ирем минем төгәллегемне, таләпчәнлегемне ошатмый качты,— диде ул, яшермичә.

Балалар бакчасына эшкә урнашкач, мин чәбәләнгән тормыш йомгагымны тәртипкә китерергә, аның үзәк җебен табып яңа йомгак урарга керештем, алда үтәсе юлым өстеннән томан тарала башлады диясем килә. Инде кабат партиягә дә, институтка да кайттым. Өс-башым да бераз рәтләнде. Күпмедер кеше кимәленә кердем. Ләкин яңа курсташларыма күнегә алмыйм әле. Мин алардан инде сигез-ун яшькә өлкән. Бу үзен нык сиздерә. Элекке курсташларым арасында да, мин берничә ел сугыш зилзиләсен үткәнгә, алар исә институтка тик әле мәктәп бусагасын гына атлап кергәнгә, ярыйсы ук олы идем. Инде менә казна исәбенә, ашыгу-кабаланусыз, ерак Себерне гизеп кайткач, яңа буын яшьләре арасында бөтенләй ак карганы хәтерләтәм булыр. Җитмәсә тагын уку программасына кертелгән логика, психология кебек элек безнең төшебезгә дә кермәгән фәннәрне укыта башлаганнар. Яңа курсташларым аларны инде күптән өйрәнеп, имтиханнар тапшырганнар. Мин әле ул фәннәрне өйрәнергә, алардан имтиханнар бирергә тиеш. Юкса «койрыклар» белән дәүләт имтиханнарына кертелмәячәкмен. «Койрыклы» студент булу күңелле нәрсә түгел. Мин — «бабай» студентка ул икеләтә хурлык.

Тау белән тау очрашмый, кеше белән кеше очраша, диләр. Ахмак тәгъбир бу, бер уйласаң. Ничек инде мәңге урыннарыннан кузгалмаган таулар очрашсыннар да, бер урында яткан ташка мүк үсә дип, хәрәкәтне бәрәкәткә исәпләүче кешеләр очрашмасыннар. Очрашалар, әлбәттә. Күп очракларда аны бөтенләй теләмәсәләр дә, очрашалар. Очрашып кына калмыйлар, үзара аңлашалар да әле. Нигә бу юк кына нәрсә турында мин гәп кузгаттым диярсез. Аның сәбәбе бар. Бүген без институт бинасы вестибюлендә теге вакытта мине репрессияләнгән буржуаз милләтче Галимҗан Ибраһимовның зарарлы кадими (реакцион) әсәрләрен өй-

рәнергә чакырды, дип партиядән кудырган һәм Татарстан югары суды хөкем иткәндә авызыннан күбекләр чәчеп шуны ук чатнатып әйткән укытучыбыз Җамал Гыйбатовна белән йөзгә йөз килдек. Ул, үткәнебездә һич нәрсә булмагандай:

— Кадыйров бәгырем, исәнме! Сине яңадан студентлар арасында күрүемә мин бик шат. Син аз гына да үзгәрмәгәнсең, гелләр элекке кебек,— диде, юхаланып.

Бу сүзләрдән минем күз алларым караңгыланды, гасабилануымнан сулышым кысылды. Үземне ачудан көчкә тыеп:

— Исәнмесез, Хамелеон Гыйбатовна,— дидем.— Сез мине, бу, һичшиксез, дөмегер, без бүтән беркайчан да очрашмабыз, дигәнсез. Ялгыштыгыз. Әйе, үзгәрмәдем, һаман шул ук калдым. Мин, аллага шөкер, сезнең кебек җил кайсы якка бөксә, шул якка ава торганнар токымыннан түгел.

Укытучым, эшләгән этлеге өчен, миннән гафу үтенде дисезме? Юк, уйламады да. Ул, таш чыраенда бер генә мускулын да калтыратмыйча:

— Төрмә сиңа бераз акыл кертәндер дигән идем, юк икән,— диде...

Институтыбыз директоры Туишев белән очрашуым тагын да әкәмәтрәк булды. Ул:

— Кадыйров, теге чакны сез кинәт кенә кая югалдыгыз?— диде, кул кысышып исәнләшкәч.

— Курортка киттем ич. Үзегез путевка юллашкан идегез, оныттыгызмыни?— дидем.

— Хәтеремнән чыккан инде. Институтта сез меңләгән бит, бөтенегезне дә истә тотуы авыр...

Арабызда сүз бүтән үрчемәде, кемдер яныбызга килеп әңгәмәбезне бүлде. Директорның игътибары шундук миннән ул кешегә күчте. Мин, саубуллашып, китеп бардым.

Теге чакта кая китүемне бик яхшы белә бит Йосып Әхмәтҗанович, әнә хәтта фамилияне да онытмаган. Ә нигә белмәмешкә салыша, нигә дип икейөзләнәнә?.. Аны бит, утыз җиденче елда үзен дә кулга алып, берничә ай төрмә шулпасы чөмерткәннәр, диләр. Нигә безнең илебездә бар нәрсә ясалма, өч кешенең берсе алдакчы, бөтен нәрсә тик ялганга, шапырынуга гына корылган икән? Әйтерсең, тормышыбыз — тоташ сәхнә, ә кешеләр барысы да артистлар. Нигә без бер-беребезгә тамаша күрсәтүдән оялмыйбыз икән?..

## Бишенче бүлек

### 1

Матбугат йортының беренче катындагы китап кибетендә Рәйсә ханым белән очраштык. Ул:

— Эшли башлагач күзгә-башка күренгәнегез юк, безне бөтенләй оныттыгыз,— диде, мине шелтәләп.— Хәлләрегез ничек?

— Хәлләрем ярыйсы, Рәйсә ханым. Сезгә бара алмавыма үзем дә уңайсызланам. Беренче җәй чыгу белән мотлак барырмын. Институт белән арамны өзим инде,— дидем.

— Килүегезне озак көтәсе икән әле. Ял көннәрегездә нишлисез? Якшәмбе көннәрендә дә укымыйсыздыр бит?

— Укыйм, Рәйсә ханым. Күп нәрсә хәтеремнән чыккан. Бөтен буш вакытым шул онытылганнарны искә төшерүгә, хәтеремне яңартуга китә. Имтиханнарда миңа, син институттан мәгълүм сәбәпләр аркасында аерылып тордың, дип ташлама ясаучы булмаячак.

— Әмма тишек хәтерегезне ямаганда безне исегездән чыгаруыгызны гафу итеп булмый, Ирек. Дусларыгызны, эшем муеннан дип, чит күрү әйбәт түгел.

— Гаеп миндә, сез хаклы, Рәйсә ханым. Хатамны төзәтергә тырышырмын. Сездә нинди яңалыклар бар? Салих ничек?

— Телгә алырдай яңалыкларыбыз юк. Салих әүвәлгечә баш күтәрми эшли. Ул да, минем кебек үк, Ирек безне онытты, дип сезгә үпкәли. Кичә безгә Мөнирә килгән иде, ул, Ирек хәзер кайда, укыймы, әллә эшлиме, дип кызыксынды. Ошаткан ул сезне. Ирекне күргәннән соң тартуымны ташладым, исерткеч эчемлекләрне дә авызыма якын да китермәячәкмен, ди. Сезгә күп итеп сәлам әйтте. Очраса әйтегез, фатирымны белә, килеп чыксын әле, аның белән сөйләшәсем килә, диде.

Кинәт, идәннән тылсым көче белән калыккан төсле, искәрмәстән алдыбызга Оля килеп басты! Күзләре усал ялтырый, гасабилануы йөзенә чыккан.

— Исәнмесез, сөекле хәләл җефетем Ирек, исәнмесез аның сөяркәсе димме, өстерәлчеге димме, минем өчен кеме булсагыз да барыбер. Сүзегезне бүләм, ачуланмагыз. Ирек җаным, сагындым сине, әле син мине бу юбкалы пәригә алыштырырга өлгермәгәнсең, шәт? Китик моннан, сул инең аша төкер дә аңа...

Рәйсә ханым Оляның мәсхәрә сүзләреннән бер агарды, бер күгәрде. Әмма ләм-мим сүз катмады. Миңа:

— Ярый, комачауламыйм сезгә, Ирек. Онытма безне, вакыт табу белән кил,— диде, һәм китәргә борылды. Оля аны җиңеннән тотып туктатты.

— Ашыкма, кәнтәй, ирем мине синең белән таныштырмады бит әле, таныштырсын башта.

— Җибәрегез җиңемне! Мин сезне белмим һәм белергә дә теләмим. Сезнең шикелле акылга туймас адәм актыгы белән танышуны түбәнлек саныйм,— диде Рәйсә ханым, ярсып.

— Минме адәм актыгы?..— Оля Рәйсә ханымның чәчләрен элэктерергә теләп кулын сузуга, араларына кердем.

— Рәйсә ханым, бу ахмакның провокациясенә бирелмәгез, юлыгызда булыгыз...

Оля лач итеп битемә төкерде.

— Мине, законлы хатыныңны, күпме кеше алдында мәсхәрәләтәсең, җир бит! Мә сиңа!..— дип, «хәләл җефетем» яңагыма да чалтыратты.

— Шөкәтсезләнүеңне ташла!— дип, мин аның кулын борып артка каердым. Ул бөтен кибеткә:

— Ярдәм итегез, үтерә, үтерә кабахәт!— дип кычкырып җибәрде.

Безнең янга шундук кешеләр җыйналды. Ниндидер бер ир-ат мине якамнан эләктереп алды.

— Хәзер юк итәм сине, оятсыз!..

— Тимәгез аңа, гражданка үзе гаепле. Башта ул иренең битенә төкерде, аннары яңагына чалтыратты,— диде мине яклап, бездән берничә адым читтә касса аппараты артында утырган хатын.

— Сиңа да кирәкме, син дә аның өстерәлчегеме әллә?— дип, Оля кассир хатынга борылды.

— Син тинтәкне кешеләр арасында йөртмәскә, акыл җыярга тилеләр йортына ябарга кирәк,— диде аңа кассирша хатын.

— Ишеттегезме, ул мине тинтәк дип мәсхәрәләде, шаһит булыгыз, мин аны судка бирәм,— дип кычкырды Оля тирәбезгә җыйналган кешеләргә.

— Дөрес әйтте кассирша сиңа, чыннан да, акылың тулы түгелдер синең, кызым. Акылы камил кеше җәмәгать урынында тавыш-гауга чыгарамы? Чыгармый. Үзара мөнәсәбәтегезне монда түгел, өегезгә кайткач ачыкларсыз, кешеләрдән оялыгыз,— диде аңа йөзен җыерчыклар телгәләгән чал чәчле бер әби.

— Мин аны монда сөяркәсе белән тоттым,— дип акланды Оля.

— Димәк, син үзең гаепле. Бер генә ир дә әйбәт хатынын начар сөяркәгә алыштырмый.

— Ул төрмәдә черергә тиешле кеше, мин аны барыбер утыртам.

— Сүземә көферлек кылмәсен диген. Бу заманда төрмә белән саилче капчыгы беребездән дә ерак йөрми... Ирenә баз казып, анда үзен төшә күрмә...

Китап кибетеннән Оля мина ияреп чыкты.

— Колониядә чагында кирәк идем сина, ирекка чыккач, хаҗәтем калмадымыни?

— Зинһар, саруымны кайнатма, кит янымнан, калдыр ялгызымны, Оля.

— Көтмә, калдырмыйм. Хәзер син кая барсаң, сина тагылып шунда барам.

Тигәнәк белән бер бу, ничек арынырга анардан, дидем үз-үземә. Аның уенда мина нинди дә булса этлек эшләү хәзер. Шуның өчен анардан мөмкин кадәр ераграк булырга кирәк...

Матбугат йорты алдындагы тукталышта Ленин районына йөрүче троллейбус тора иде, тиз генә шуна утырдым. Оля да миннән калмады. Без утыру белән троллейбус иңләп кенә кузгалып китте. Озакламый Кремль, Казансу елгасы аша салынган агач күпер, юлның ике ягындагы су баса торган болын артта калды. Гривки дамбасы турындагы тукталышта мин троллейбустан төштем. Оля да калмады, мина ияреп. Мин, юлны аркылы чыгып, дамба буйлап Киров районы ягына юнәлдем. Оля, эзгә-эз басып, мина тагылды.

— Без кая барабыз?— диде Оля, сагаеп.

— Син кая барасыңдыр, мин фатирыма кайтам.

Дамбада бездән башка кеше юк иде, мин, иелеп, аяк астымнан йодрык зурлык таш алып, Оляга борылдым.

— Иманың укы тизрәк, күгәрченкәй, син мина барыбер көн күрсәтмәячәксең, дөнья белән бәхилләштерәм үзеңне,— дидем, ташым белән аңа сугарга әзерләнгән шикелле як-ягыма каранып.

Оля, күзләрен шар ачып, мина текәлде, йөзе агарынды, гәүдәсе кызганыч бөрешге.

— Ирек, җаныем, зинһар гафу ит мине,— диде ул, калтыранып.

— Итмим. Өчкә кадәр саныйм, йә яхшылык белән китәсең моннан, йә дөмегәсең. Бе-ер... И-и-и-ке...

Оля өч дигәнне көтмәде, башын иңнәренә җыерып кырт борылды да кире троллейбус тукталышына элдерде. Мин, кулымдагы ташны читкә атып, куаклар арасына кереп киттем.

Тоткынлыктан мине ул аралады бит, нигә аның белән кешечә сөйләшмәдем, тыныч кына аңлашасы урында үтерү белән янадым, дип битәрләдем үземне. Шундук күз алдымнан ничек язылышуыбыз, загстан чыккач ятышсыз аерылышуыбыз, Мурзиха пристане, бүген китап кибетендә булган күңелсезлекләр бер-бер артлы кабатланып узды. Алар барсы да төшемә генә кермәделәр, өнемдә булдылар бит, дип уйладым, ачынып. Бүген ярады, анардан җиңел котылдым, әмма ул миннән моның үчен алмый калмаячак. Сине мин төрмәдә черетәм, диюе юкка түгел аның. Казанга ул ник килгән? Уенда мина тагын нинди этлекләр эшләү икән аның? Чыннан да, акылы камил түгелдер Оляның... Мәктәптә укыганда ук әнисе белән уртак тел тапмавы, алагаем үҗәтлеге юкка түгелдер... Алай дисәң, ничек мәктәптә эшли дә, ничек мине аклата алды?.. Мин бу сорауларга җавап таба алмадым. Беләсе иде, тагын ниләр кичерәсем бар икән алда. Бәлки, яшәүгә караганда үлү хәерлерәктер мина? Тормышымның һәр адымында интегер, газапланыр өчен исән калдыммыни мин сугышта?.. Инде кырыс кыш узып артта калды, әнә табигать җанлана башлады, тиздән җылы яклардан кошлар әйләнеп кайтыр, җир яшеллеккә күмелер... Мина яз үзгәреш алып килерме, әллә ул килгәч тә бөтенесе хәзерге кебек буталчык, коточкыч чәбәләнгән көе калырмы? Азга гына булса да онытыласы иде. Юк, онытылу мөмкин түгел. Әнә төннәрен балалар бакчасында китапларга, конспектларга

күмелеп тә онытыла алмыйм. Үткәнемдәге бөтен мәхшәрләр, вәхшәтләр, чәнечкеле тимерчыбык киртәләре төшләремә кереп борчыйлар. Йокымнан шабыр салкын тиргә батып уянам. Уянгач, үземне тулы канлы, нормаль кеше итеп тою җитми!

## 2

Ниһаять, максатыма ирештем: дәүләт имтиханнарын тапшыргач, педагогия институтын тәмамлавым турында диплом алдым.

Ирекле диплом. Әлегә кайда эшләячәгем билгесез. Муеным бар, аңа ничек тә камыт табылыр әле... Казанның үзендә генә дә мәктәпләр әнә йөздән артык. Аларда урын табылмаса, берәр редакциядә эшли башлармын. Илебез Америка түгел, социализм төзибез, эшсез калу куркынычы юк.

Хәерчегә җил каршы, дигәннәре дөрес икән, көткәнем акланмады, эш эзләргә керешкәч, аны табу җиңел түгел икәнен үз җилкәмдә татыдым. Инде август аеның икенче яртысы башланды, мин әле эшсез. Мәгариф министрлыгында, беркайда да вакант урыннар безгә билгеле түгел, үзегез эзләп карагыз, бәлки, табарсыз, диделәр. Министрлык булып министрлык таба алмаганны ничек мин табыйм инде? Ә эшсез яшәп булмый. Кулымда дипломым була торып, балалар бакчасында һаман каравылчы вазифасын үтәргәме?

Казан районнарының мәгариф бүлекләрен янә бер кат әйләнеп чыгуым нәтиҗә бирмәгәч, бәлки, булышырлар, дип республика дәүләт иминлеге комитетына кагылдым. Ишек төбендә кизү торучы старшина мине бина эченә үткәрмәде, пропуск таләп итте. Пропусклар бүлегендә кем янына керергә теләвемне төпченделәр. Озак уйламый, кадрлар бүлегенә, дидем. Пропусклар бирүче офицер, телефоннан кемгәдер шалтыратып, миңа:

— Йомышыгыз?— диде.

— Шәхси йомыш,— дидем.

Тырнак астыннан кер эзләмәсәләр, үзләрен иминлек сакчылары исәпләмиләрдер алар, валлаһи!..

Озак та үтмәде, ыспай киемле, чытык чырайлы утыз ике-утыз биш яшьләр тирәсендәге берәү пропусклар бүлеге алдына чыгып мине бүлмәсенә алып керде һәм, өстәле янындагы урынына үтеп, төксе генә:

— Тыңлыйм сезне,— диде.

— Эшкә урнашырга булышыгыз миңа. Мин моннан ун ай элек сезнең учреждениенең эчке төрмәсеннән азат ителгән кеше.

— Документларыгыз бармы?

Дипломымны, паспортымны, партия билетымны, төрмәдән чыкканда бирелгән белешмәне бүлмә хуҗасына суздым.

— Дөрес, бездән үткәнсез икән. Эшегезне кем алып барды?

Әйттем. Бүлмә хуҗасы шундук телефонында номер җыйды.

— Семен Андреевич, исәнмесез. Кадрлар бүлеге борчый сезне. Минем янга үзен эшкә урнаштыруны сорап сездә тикшерү үткән Кадыйров килде. Ирек Сабирович Кадыйров. Ул инде яңадан партиягә кайткан, институт тәмамлаган... Әйе... Аңа Раифага барырга тәкъдим итегез, дисезме?.. Яхшы, әйтермен.

Телефон трубкасын урынына куйгач, бүлмә хуҗасы, башын бер яккарак салып, миңа текәлде.

— Тикшерүчегез сәлам әйтте сезгә,— дип дәвам итте ул сүзен,— институт бетерүегез белән котларга кушты. Сезгә кулай урын да тапты, Раифага барырга тәкъдим итте. Анда эчке эшләр министрлыгына караган кече яшьтәге җинаятьчеләр колониясе бар. Шунда укытучы-тәрбияче кирәк. Кием-салым, фатир, ашау-эчү мәсьәләләрен анда үзегезгә кайгыртасы булмас, эшегезгә керешү белән дәүләт тәэминатенә күчәрсез. Безнең

тәкъдимне хуп күрсәгез, республика эчке эшләр министрлыгына шалтыратып, мин бөтенесен җайлармын. Теләсәгез, бүген үк эш урыныгызга барып карап та кайтырсыз. Казаннан Раифа ерак җир түгел.

— Рәхмәт. Сез миңа үз иркем белән яңадан төрмәгә керергә тәкъдим итәсез. Бирердәге эчке төрмәгез дә әле көн аралаш төшемә керә. Раифада эшләргә сез дөньяга тик кызыл күзлек аша гына карауны ике аяклы ишәкне эзләгез. Борчыганым өчен гафу итегез. Хушыгыз, мин чыгам...

Бүлмә хуҗасы мәсхәрәле елмайды.

— Сабыр. Чыкканчы пропускыгызга кул куйыйм. Биш ел чамасы бирердә булып, тәртипкә өйрәнмәгәнсез, кызганыч...

Нәрсәмне кызганды КГБ күсесе, аңламадым.

Раифа... Раифа... Нинди рәк җир икән ул Раифа? Элек анда монастырь булганын беләм. Революциядән соң андагы монахларның шул төбәк крестьяннары фетнәсен оештырулары да, фетнә вакытында Раифада берничә милиционерның үтерелгәне дә миңа мәгълүм. Анда хәзер кече яшьтәге җинаятьчеләр колониясе бар икән. Утыз җиденче елның ахырында мине шунда алып барганнар идеме әллә?.. Алай дисәң, ул чакта анда мәктәп юк иде кебек. Бәлки, хәзер дә юктыр, мәктәптә укыту турында сүз булмады бит, укытучы-тәрбияче, диде теге күсе. Хәзер кече яшьтәге җинаятьчеләрне укыта да башладылар микәнни инде? Ләгънәтләнгән комитетка кермәсәм, кече яшьтәге җинаятьчеләрне укыта-укыта тәрбияләүне белми яшисе икәнмен... Инде тагын эш эзләп кая керергә? Казан тирәсендәге районнарга барып белешсәм, ничек булыр икән? Якын тирәдә нинди районнар бар әле? Арча, Биектау, Питрәч, Столбище, Лаеш, Зеленодольск, Дөбъяз... Аларның кайсына баруы җиңелрәк икән? Тукта, Питрәч, кем әйтмешли, борын төбендә генә бугай, тәвәккәлләп башта шунда юл тотыйм...

## 3

Питрәч Мишә елгасы буена урнашкан шактый ук зур авыл булып чыкты. Казаннан килгәндә, сыртлык итәгендә утырганга күрә, ул үзенә тәмам барып җитмичә күзгә ташланмый. Йортлары җыйнак, күбесенең түбәләре салам белән ябылган. Таш яки кирпечтән салынган йортлар бармак белән генә санарлык. Питрәчнең Казаннан килгән юл өстендәге ягы яшеллеккә ярлы — агачлар бер-сәрән генә. Алары да йә Америка өрәңгесе, йә сәрби яки канәфер куаклары. Мишәгә якын өлешендә карт тупыллар, юкәләр, таллар; бакчаларда җимеш агачлары...

Як-ягыма карана-карана урам буйлап атлаганда каршыма очраган урта яшьләрдәге бер ир кешедән:

— Район мәгариф бүлеге кайда монда? — дип белештем.

— Райком бинасында.

Шәп, төгәл һәм кыска җавап. Ул бина кайда соң монда, дип төпченеп тормадым, райком, гадәттә, район үзәгендә иң күркәм йортта була, аңа ничек тә юлыгырмын, шәт, дип, юлымны дәвам иттем. Бара-бара карсак ашханә бинасын, икмәк кибетен, хуҗалык өчен төрле кирәк-яраклар сата торган эреле-ваклы берничә ларекны, гөмбәзе сүтелеп түбәсе тигезләп ябылган зур таш чиркәүне, алалы-колалы «Союзпечать» киоскысын, рәшәткә койма белән әйләндереп алынган кызыл кирпечтән салынган кечкенә генә мәктәпне узып киткәч, өстенә кызыл байрак кадалган ике катлы зур йорт күренде. Башыма, әһә, Питрәчнең «кремле» менә кайда икән, дигән уй килде.

Район мәгариф бүлегендә, көн ярыйсы ук эссе булса да, өстенә җил-яңгырларда агарып, таушалып беткән кожан, башына янчек салам эшләпә кигән берәү, мин кергәндә, телефоннан каядыр шалтырата иде.

— Исәнмесез. Миңа роно мөдире кирәк иде,— дидем.
Салам эшләпәле, телефонынннан аерылмый гына:
— Ни йомыш? Мин — роно мөдире,— диде.
— Сезгә мин эш юллап килдем.
— Белемегез, партиялегегез?
— Быел Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамладым. КПСС әгъзасы.
— Документларыгыз үзегез беләнме?
— Рәхим итегез, менә алар.
Салам эшләпә, документларыма өстән-өстән генә күз йөртеп чыккач:
— Безнең мәктәпләребез барсы да комплектлаштырылды инде. Аркатово мәктәбенә директор табасыбыз гына калды, теләсәгез билгелибез сезне шунда.
— Нинди мәктәп ул? Еракмы район үзәгеннән?
— Җидееллык мәктәп. Моннан егерме чакрымда. Аркатово — чиркәүле урыс авылы. Анда барсагыз, поп атакайның көндәше булырсыз. Директорлыкны өстегезгә алырга тәвәккәлләсәгез, хәзер райкомның пропаганда бүлегенә кереп мәслихәтләшәбез.
— Ашыктырмагыз, башта миңа ул мәктәпне барып карарга кирәк.
— Мәйлегез. Сез миннән эш сорадыгыз, мин тәкъдим иттем. Сез анда барганчы ул урынга безнең башка берәүне җибәрү ихтималыбыз бар, йә, ничек, керәбезме пропаганда бүлегенә?..
Район мәгариф бүлеге мөдиренең тимерне кызмас борын ук сугарга омтылуы мине сагайтты. Монда нәрсәнеңдер очы-очка ялганмый шикелле. Яңа уку елы инде борын төбендә, ә нигә моңарчы ул мәктәпкә директор итеп куярга район кадәр районнан кеше тапмаганнар? Мәктәптә эшләү тәҗрибәм булу-булмау белән бөтенләй кызыксынмыйча, нигә мине мәктәп һәм андагы коллектив белән җитәкчелек итәргә кодалый роно мөдире?
Мин документларымны, өстәлдән җыеп алып, кесәмә салдым.
— Ул мәктәпне, анда үз кул астымда эшләячәк укытучыларны күреп сөйләшми торып тәкъдимегезне кабул итә алмыйм, гафу итегез,— дидем.
— Җаваплылыктан куркасыз, димәк?
— Нәрсәгә таянып андый нәтиҗәгә килдегез, аңламыйм.
Салам эшләпә минем белән бүтән сүз куертуны артык санады, күрәсең, җавап кайтармады, телефон трубкасын яңадан кулына алып, каядыр шалтыратырга кереште. Мин, аның яныннан чыгып, ашханәгә юнәлдем.
Аркатово... Аркатово... Чиркәүле авыл... Поп атакайга көндәш... Хәерле булсын, нәрсәнедер әйтеп бетермәде, яшерде мәгариф әһеле.
Юл уңаенда мәктәпкә кагылдым. Анда бер җыештыручы ападан бүтән кеше юк иде.
— Укытучылар, мәктәп җитәкчеләре кайда?— дигән соравыма ул:
— Белмим, алар кайда барасыларын миңа әйтеп йөрмиләр,— диде, коры гына.
Түбәсе тигезләп ябылган таш чиркәү яныннан үткәндә аның түр ишегенең уң ягында: «Җиңү байрагы» газетасы редакциясе» дигән язуга күзем төште. Менә кайда Аркатово турында мәгълүмат алып булыр дип уйлап, ишектән эчкә үттем. Анда редакция белән типография бергә булып чыкты, хәреф җыючы кызлар янында тукталмый, эчкә уздым. Урта буйлы кеше үрелсә буе җитәрлек биеклектә фанера белән генә бер-берләреннән аерылган кысан бүлмәләрдә кемнәрдер үзара сөйләшәләр, түрдәге ачык ишекле бүлмәдән машинка тавышы ишетелә иде, кая керергә белми югалып калдым. Шулчак машинка шакылдаган бүлмәдән аксыл сары чәчле бер чандыр егет чыгып, миңа эндәште:
— Исәнмесез. Сез безнең хәбәрче бит, фамилиягез ничек әле?..
— Ялгыштыгыз, мин Казан кешесе,— дидем аңа.— Кемгә мөрәҗәгать итим икән: миңа Аркатово авылы һәм андагы мәктәп турында мәгълүматлар кирәк иде.

— Әнә теге ишеге ачык бүлмәгә керегез, мин менә бу материалны җыярга бирәм дә сөйләшербез,— диде егет.

Берничә минуттан ул минем янга әйләнеп керде.

— Әдәпсез сорау бирәм, гафу итегез. Аркатово авылы сезне нигә кызыксындыра? Сез кем, корреспондентмы әллә?

— Мин педагог,— дидем һәм роно мөдире белән булган әңгәмәбезне егеткә бәян иттем.

— Башта танышыйк,— дип кулын сузды ул.— Алексей Евстигнеев, «Җиңү байрагы»ның җаваплы секретаре.— Бик койты авыл ул Аркатово, бармагыз анда,— диде секретарь, кисеп.— Мәктәбе иске, җимерек, тәртсез авырга тора. Аның элекке директоры бер эчкече иде, партиядән чыгарылып хөкемгә тартылды, хәзер төрмәдә. Мәктәпкә капиталь ремонт үткәрү, аны кыш буена житәрлек утын белән тәэмин итү авыл советының гәмендә дә керми. Укытучылар берсе өстеннән берсе төрле оешмаларга шикаять язудан бушамыйлар. Боларны мин кая беләм, дисезме? Күптән түгел райком мине аннан килгән әләк-шикаятьләрне тикшерергә җибәргән иде. Аркатоволылардан редакциябезгә килгән кайбер зар-интизарларны сезгә күрсәтә дә алам, теләсәгез. Чәчегез үрә торырлык...

— Күрсәтмәгез, кирәкми, болай да ышанам. Сезне очратуым яхшы булды әле, мин анда әллә барып кайтыйммы дигән идем.

— Инде нишлисез?

— Кире Казанга кайтам.

— Бәлки, безгә эшкә керерсез?

— Кем булып?

— Редакция эшен күз алдыгызга китерә аласызмы сез?

— Алам. Минем район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшләгәнем бар.

— Безгә урысчаны татарчага, татарчаны урысчага аудара алган тәрҗемәче кирәк...

Куян артыннан чапканда, көтмәгәндә, мин әнә шулай «төлке» тоттым.

## Алтынчы бүлек

### 1

Эшемә, редакция коллективына тиз күнектем. Хезмәттәшләремне әйбәт кешеләр дия алам. Алар мине ят итмиләр, мөнәсәбәтләре дустанә, эчкерсез. Сугыш зилзиләсендә исән калып, төрмә, колонияләрне үтеп, эчәргә дә, тартырга да өйрәнмәвемә генә гаҗәпләнәләр. Үзләре җай чыккан саен берәр аулаграк җирдә ике-өч яки күбрәк кеше берләшеп, «котырган сыер сөте»ннән авыз итүне чит күрмиләр.

Мин, эштән соң фатирыма кайтып, йә хуҗабикәм Марийша түти белән тәп куертам, йә Мишә яры буйлап салынган сукмакка чыгып арлы-бирле килеп сарам. Фатирдан уңдым дия алам. Марийша түти ачык йөзле сүзчән карчык. Ул миңа кадәр болын кадәр өйдә бербашы гомер сөргән. Аны, инде алтмышның өске ягына чыкса да, карчык диярлек түгел әле — үтә тере, эшчән, тиктормас. Ялгызы гына яшәсә дә, сыер асрый. Көннәрен шул сыеры — сөекле Зойкасына кышка житәрлек азык әзерләүгә сарыф итә. Чокыр-чакырлардан, ташландык җирләрдән үлән чабып ташый. Кыяфәте сөйкемле генә. Бер күзенә ак төшкән булса да, ул аның мөлаемлыгын бозмый. Хуҗабикәмнең тормышы ал да гөл — җинел генә булмаган. Ул ялгызы өч бала үстергән. Балалары күптән инде үз көннәрен үзләре күрәләр. Улы Питрәчтә үк, үз өе белән тора. Шофер булып эшли, хатыны, ике баласы бар. Ул әнисен эчәргә акча

кирәк булганда гына искә ала. Кызларының берсе шушы ук районның Ходяш авылында кияүдә, ди. Икенче кызы төрмәдә. Анысы фронтта да булган. «Ксениям үтә чая, башсыз минем. Шул чаялыгы рәшәткә артына кертте дә аны»,— ди Марийша түти, ул кызы турында. «Ирем дә исән әле, тик аның Питрәчкә инде күптән эз басканы юк. Карелиядә яши бугай. Куып чыгардым да алимент-фәлән алмадым ул эттән. Күзем акны, бер эчеп кайткач, холыксызланып, икмәк кыерчыгы белән сугып, шул мәнсез төшерде. Салырга ярата, тик үзен генә кешегә саный, кулына ни эләксә, шуның белән уйламый ора иде, шуңа түзәлмәдем, дөбердәтеп куып чыгардым. Сыер дуласа аттан хәтәррәк, диләр бит. Мин дә шул дулаган сыер күк булдым. Балаларым өчесе дә холыклары белән шул мәлгуньгә охшадылар, өчесе дә базарлы көндә дә бер тиен торырлык түгел, тугач та һәркайсын, авызына мендәр каплап, дөмектерәсем калган. Кем белгән ул чакта аларның бу көнгә калдырасыларын...»

Ничек кенә булмасын, начар кеше дип белмим мин хуҗабикәмне, мине ул ничектер үз итә: «Син тора башлагач өемә ямь керде, торагым яктырып, киңәеп киткән төсле булды, гүя, аңа тагын бер яңа тәрәзә уелды»,— ди.

## 2

Йокымнан уянгач, бүген ял көне, эшкә барасы юк, дип, урынымда шактый вакыт Тукай шигырьләрен укып яткач, торып ашадым да, Мишә буена балык каптырырга киттем. Балык белән сыйланасым килгәнгә түгел,— теләсәм, аны монда күпме кирәк сатып та ала алам,— талгын гына аккан су агымына карап утырасым килде. Бала чагымнан ук мин үз җаена гына дөрләп янган учакларны һәм салмак кына аккан инеш суын онытылып күзәтергә яратам.

Яр буена уңайлап урнашкач, кармагымны селәүчән кидереп тугайга аттым да, балык чиртүен көтеп, калкавычка текәлдем. Уйларым, иренеп кенә аккан су агымына ияреп, еракта Чуал буйларында адашып калган гамьсез бала чагыма кайтты. Күз алдымнан, кино экранындагы сыман, бер-бер артлы мәктәп дусларым, Чүлмәк тау, Миләүшә белән көтү кууларым, Хәйрүш абыйның курайда уйнаулары, Кәримнәрнең өе януы, Ярулла абзыйга бәйләнешле хәлләр, мәчет манарасын кисү һәм башка бик күп вакыйгалар кабатланып үтте.

— Сезгә минем тугаемда кармак салырга кем рөхсәт итте?— дигән сораудан сискәнеп киттем. Башымны күтәреп каршы як ярга карадым. Анда яшь кенә хатын-кыз басып тора иде.

— Сез кем?— диде ул, өстендәге күлмәген җәһәт кенә салып.— Хәер, шәһәр кунагыдыр инде, авыл кешесе җәйге чилләдә көн уртасында кармак салмый. Кемгә кайттыгыз?

Мин җавап бирергә өлгергәнче, туташ суга кереп, минем якка йөзеп тә чыкты. Ул бюстгалтерсыз, тәне төсендәге җыйнак трусиктан гына иде.

— Мин — Зәйнәп,— диде ул, минем янга ярга күтәрелеп.— Әйдә, чишенегез, су керик. Балыкка иртәгә таңнан төшәрсез. Кем диим сезне?

Мин исемемне, кайда эшләвемне, кемдә торуымны әйттем.

— Туры сүземә үпкәләмәгез, сүзләр белән сабын куыгы өрүче, кәгазь пычратучы икәнсез. Шәһәрдә җүнлерәк эш табалмадыгызмыни, безнең район газетасына килмәсәгез?

— Чамам шундый гына бит, туташ. Юрганыма карап аягымны суздым.

— Юрганыгыз шундый печтекмени сезнең?

— Әйе, дәү түгел.

— Әйдә, чишенегез, су керик.

— Рәхмәт, мин көндез түгел, кичке якта коенам.

Туташ, үҗәтләнеп, һаман үзенекен куды.

— Әллә батырыр дип куркасызмы? Бәлки, йөзә белмисездер? Белмәсәгез, өйрәтәм.

— Бүген түгел, башка вакытта, Зәйнәп. Мин кайтыйм, хушыгыз.

— Кунакка керсәм, ачуланмассызмы?

— Шат булырмын, рәхим итегез.

— Ярты чыгарырсызмы?

— Карарбыз.

Бу нинди сагыз? Кем ул? Бәлки, оятын югалтып, теләсә кемгә сыланучы бер сөмсез заттыр. Андыйга охшамаган. Күзләрендәниндидер сагыш бар аның. Үзен артык иркен тотуы — кемгәдер үч итептер, бәлки?

## 3

Атна уртасында редакторыбыз Николай Ильич Малов, иртән эшкә килгәч, мине үз бүлмәсенә чакырып алды.

— Каршы килмәсәгез, мин сездән районыбыздагы берәр хуҗалыктан умартачылыкка, бал җитештерүгә карата кеше кызыксынып укырлык материал әзерләвегезне сорар идем. Кортчылык тармагы сезгә таныш булмаса, аны белгән иптәшләргә мөрәҗәгать итәрсез, казынырсыз, эзләнерсез. Умартачы турында очерк язасызмы, чүнниктән репортажмы, гади мәкалә генәме,— бу үз иркегездә. Турысын әйтәм, мин сезгә бу йомышымны йөкләп иҗади потенциалыгызны, журналистлык эшендә нәрсәгә сәләтле икәнегезне сынамакчы булам. Сез моңа ризамы?

Мин хуҗабыз йөкләгән эштән, «чүлмәкне аллалар яндырмый» дигән әйтемне хәтерләп, умартачылык турында тик ишетеп кенә белсәм дә, баш тартуны кирәксенмәдем.

— Материалны кайчанга өлгертергә? Аның күләме нинди булырга тиеш?— дидем.

— Материал ашыгыч түгел, сезгә атна-ун көн вакыт бирәм. Күләме — ничек язуыгызга карап.

— Сезгә берничә сорау бирергә мөмкинме, Николай Ильич?

— Мөмкин, сорагыз,— дип елмайды редактор.

— Умартачылык белән бу районда кайларда шөгыльләнәләр? Бу мәсьәләдә кемнәргә мөрәҗәгать итәргә булыр?

— Район үзәгенә янәшәдә үк «Колай» совхозында гына да ике йөз баш умарта бар. Совхозның чүнниге Мишә аръягында, күп булса моннан чакрым-чакрым ярымда гынадыр. Аны сез бүген үк барып карап кайта аласыз. Газетабызның иртәгә чыгасы санына керердәй ашыгыч материаллар килеп чыкса, аларны кулдашыгыз Кәтибә Бариевна тәрҗемә итәр. Беренче коймагыгыз төерле булмасын, уңыш телим сезгә.

Редактор бүлмәсеннән чыккач, башта кай якка юл тотыйм икән дип, берничә минут уйланып тордым. Беренче чиратта, миңа умартачылык турында азмы-күпме белергә кирәк. Район советы башкарма комитетының авыл хуҗалыгы бүлегендә кортчылык турында китаплар бардыр, булмый калмас. Нишләргә, башта умартачылыкка кагылышлы китаплар табаргамы, әллә чүнникне күреп кайтыргамы?..

Әүвәл чүнниккә киттем. Мишә аша салынган агач күперне чыгып, болын юлына борылгач, шаулашып урманнан кайтып килүче бер төркем малайлар очрады. Алардан:

— Егетләр, совхоз чүннигe кайдарак монда, аны ничек табарга?—, дип сорадым.

— Чүнникне бик тиз табарсыз, абый. Әнә теге печән кибәннәрен үткәч, урманга бер юл кереп китә. Шул сезне кирәк җирегезгә илтә дә куя,— диде миңа малайларның берсе.

Рәхмәт әйтеп юлымны дәвам иттем.

Көн аяз. Бөркү. Төрле бөҗәкләр тавышыннан, һавада тирбәлешеп очкан тәкәрлекләр чыелдавыннан әйләнә-тирә ниндидер илаһи музыкага

төрелгән кебек. Урман ягыннан искән талгын җил печәне инде чабылып алынган болын өстенә нарат чәересе исен тарата. Саф һавага җан рәхәтләнә, үпкәләргә шифалы һава үзе бәреп керә кебек... Кара, шәп икән Мишәнең бу ягында. Питрәчкә килгәннән бирле тәүге кат аяк басуым ич әле монда.

Уйларым редактор йөкләмәсе тирәсендә буталды. Мин балның бик затлы ризык икәнен, аның бик күп авыруларны дәваларга яраганын, инә күзе кадәр генә тамчылардан җыелуын, юкә, карабодай, тукранбаш чәчәкләреннән җыйналган төрле баллар барлыгын беләм. Язмамда миңа умартачылыкның икътисадый файдалыгына, әллә ни күп чыгымнар таләп итми торган табышлы тармак икәненә күбрәк басым ясаргадыр, бәлки? Материалны, бәлки, кортчылыкның тамырлары бик борынгы заманнарга барып тоташуыннан башларгадыр? Ничек булса да миңа белгечләр белән сөйләшми торып эшкә тотынырга ярамас. Бөтен районда ничә умарта исәпләнә һәм һәр умартадан күпме бал алына икән?..

Уйларга бирелеп, чүнниккә аяк басуымны сизми дә калдым. Мине анда, калын тавыш белән һау-һаулап, бозау кадәрле эт каршылады. Кулымда аңардан сакланырга таягым-фәләнем булмаса да, шөлләмәдем,— колониядә чакта овчаркалар бу авыл этеннән күпкә явызраклар да, аяусызраклар да иде,— карашымны этнең ачу белән көмер күк янган күзләренә төбәп, юлымны ашыкмый гына дәвам иттем. Этләрнең кеше карашын күтәрә алмауларын, нинди генә ярсу, усал булсалар да, үз күзләренә кыю төбәлгән кешегә ташланырга җөрьәт итмәүләрен белә идем. Чүнник эте белән дә шулай булды. Ул башта, өрүеннән туктамыйча, башын читкә борып күзләрен миннән яшерде, аннары ул саклаган чүнник эченә минем аңардан курыкмый керүемне күреп, бераз читкәрәк китеп һау-һаулады.

Кинәт:

— Абрик, җитәр, тукта!.. Кил монда!..— дигән боерулы хатын-кыз тавышы ишетелде. Эт тавыш килгән якка чапты. Мин агачлар арасыннан чүнник читендә күренеп торган җыйнак кына өйгә таба атладым. Өй болдырында этне үз янына чакырган хатын-кызны күргәч, аптырап калдым. Ул моннан бернечә генә көн элек миңа кармак салырга комачаулаган Зәйнәп иде. Эт аның янәшәсендә тыныч кына басып тора, аны, әйтерсең, алыштырганнар, ярсуының эзе дә калмаган.

— Исәнмесез, Зәйнәп. Сез вәгъдә итеп тә миңа кунакка килмәгәч, түзмәдем, сезнең янга менә үзем килдем. Кабул итәсезме?

— Исәнмесез, Ирек. Рәхим итегез. Әйдә, өйгә үтегез.

— Абрик өстемә ташланмасмы соң?

— Алдында җебеп төшмәгән кешегә ташланмый ул.

— Зур да, чибәр дә хуҗалыгыгыз. Чын җәннәт сезнең монда. Урман һавасы үзе генә дә ни тора...

— Бу җәннәтнең хуҗасы да ярыйсы гына, шулай бит,— дип көлде Зәйнәп.

Нәрсәгә әйтте ул моны, гади хатын-кыз чытлыклануы гына булдымы, башкамы, аңламадым. Шулай да:

— Әлбәттә,— дидем.

Зәйнәп җитдиләнде.

— Дөрес, кортчылыкның нечкәлекләрен белмәүче, сәбәп юкта сәбәп табып, бал белән сыйланырга килүчеләргә җәннәт монда...

— Минем ишеләргә, димәк?

— Әйе, сезнең ишеләргә.

— Бетте, балыгыздан баш тартам, ул юктан сәбәп чыгаручыларга калсын.

— Юк инде, килгәч сыйланмый китмәссез, сыйлармын.

— Үзегезне сез чүнникнең хуҗасы кебек тотасыз, кемегез — әтиегезме, абыегызмы, иптәшегезме эшли монда?

Зәйнәп мәсхәрәле көлде.

— Мин үзем эшлим монда, чүнник хуҗасы — үзем. Сез санаган беркемем дә юк минем. Әтием сугыштан кайтмады, абыемны әтием белән әниемә алла бирмәгән, иптәшем юк — ул холкыма түзә алмый мине ташлап качты. Умарталыкта хатын-кыз эшләми дип сезгә кем әйтте?

— Гафу итегез, сезне умартачы итеп күз алдыма китермәгән идем мин.

— Кем дип уйлаган идегез мине? Җиңел акыллы җилбәзәк хатын дипме?

— Әйе, теге көнне сез миндә шундыйрак тәэсир калдырдыгыз.

Зәйнәп туры сүземә үпкәләмәде, шаркылдап көлде.

— Мин дә сезне ул көнне, бу хатын-кызларга өркеп караучы дивана икән, дигән идем.

— Өстенә анадан тума диярлек чибәр туташ давылдай килсә, диванага әйләнми хәлең юк. Хатын-кызлардан куркам мин, Зәйнәп. Бер авызы пешкән салкын суны да өреп каба...

— Минем кебек чәчбиләрнең авызыгызны пешергәннәре бар, димәк?

— Бар, Зәйнәп, бар. Дөнья бит. Әйдәгез, ул турыда гәп куертмыйк, калдырыйк әле. Мине монда балга хирыслыгым түгел, редакция йомышы китерде. Редакторыбызга, газетага умартачылык турында материал кирәк, сез тиз генә «Колай» совхозы чүннигенә барып, аны карап кайтыгыз әле, дип җибәрде ул мине монда.

— Һәй, шыр ялганчы икәнсез, кунакка килдем, дип күземә карап алдадыгыз. Чыпчык борыны кадәр генә дә ышаныч юк икән сезгә.

— Чыпчык томшыгы кадәр дә диегез, Зәйнәп, кошларның борыннары томшыкларында. Сүзне нәрсәдәндер башларга кирәк иде бит. Шатланыгыз, газета кортын сыйлап маташмассыз, миннән чыгымсыз гына арынырсыз. Кунак шайтан суы өмет итә, ә газетчыны сүз белән сыйласагыз да, башы күккә тия.

Зәйнәп янадан җитдиләнде.

— Умартачылыкта нәрсәләр кызыксындыра сезне? Сорагыз, белгәннәремне сөйләрмен.

— Сездә кортчылык турында китаплар бардыр, миңа шуларның эчегездә иң кирәклеләрен берничә көнгә биреп торсагыз, дим. Бу — бер. Совхоз эшегезгә ничек булыша, совхоз җитәкчеләренә нинди таләпләрегез, нинди үпкәләрегез бар? Кортчылык хуҗалыгыгызның киләчәген ничек күзаллыйсыз, нинди үзгәрешләр көтәсез? Бу — ике. Шушы сорауларыма җавап бирсәгез, хәзергә миңа шул җитә.

— Бик гади сораулар болар. Сез, журналист буларак, безнең тармак белән тирәнрәк кызыксынырсыз дигән идем. Зарар юк, аңгәмә куертырга әлегә болары да җитеп торыр. Умартачылык турында китапларым бар, «Кортчылык» дигән журнал да алам, танышырга аларны сезгә бирермен, ул зур мәсьәлә түгел. Совхозның кортчылыкка булышуына, аның җитәкчеләренең миңа мөнәсәбәтләренә килсәк, уңай сүз әйтә алмыйм. Дөрес, совхоз җитәкчеләре бал яраталар, әмма алар кортларның бөтен табышны тик юкә чәчәгеннән генә җыюларын өмет итәләр. Чүнниккә якын җирләрдә карабодай, көнбагыш, ак һәм ал тукранбаш чәчүлекләре булдыру, баллы башка төр үсемлекләр дә чәчү турында гамьнәренә дә кертмиләр. Чүннигебездә умарталар санын ишәйтү мәсьәләсе дә проблемага әйләнде. Умарталарыбызның күбесе тузган, иске. Аларны яңаларга алыштыруга да совхоз җитәкчеләре каршы торалар. Кортларга зиннәтле сарайлар нигә, торыр урыннары бар, шул җиткән, дип карыйлар. Аларның ул тораклары күксегән яки җил үйнарлык тишек-тошыклы, ярыклы булуларын ишетергә дә теләмиләр. Үзләре исә бал җитештерүне елданел арттыруны таләп итәләр. Алар өчен иң мөһиме табыш, кортларга кыш чыгарлык бал калмаса да, ике ятып бер төшләренә дә керми.

Бу пырдымсыз хатын чүнниктә ничек эшли башлаган икән, умарталык өлкән яшьтәге кешеләр урыны бит диясездер инде сез. Башыңа төшсә башмакчы буласың икән. Бал кортлары белән шөгыльләнергә

түгел, мәктәптә эшләргә, балаларга белем, тәрбия бирергә тиеш кеше мин. Университетны тәмамлагач, өч ел укыттым да мәктәптән куылдым. Элекке коллегаларым хәзер хәтта очрашырга куркалар. Мәктәптән сөрелгәч, иремә дә кирәгем калмады — ташлап китте. Шуннан соң эшсезлектән, ялгызлыктан качу өчен монда умарталыкка килдем. Заманыбыз өчен, гомумән, типик зат түгел мин...

Чүнник тирәсе бал кортлары безелдәвеннән гөжләп тора. Ул тырыш, эш сөючән бөҗәкләрнең аяз, матур, җилсез көнне заяга уздырасылары килми, форсаттан тулысынча файдаланып калырга тырышалар. Кортларның Зәйнәптә дә, миндә дә гамьнәре юк, үз эшләре эш.

— Сер булмаса, бәлки, әйтерсез, укыту эшеннән ни өчен җибәрделәр сезне?

Зәйнәп миңа сынаулы текәлде.

— Үзе укытучы түгел кеше бүгенге мәктәп хәлләрен белми. Мәктәптә хәзер, балаларга белем бирүдән бигрәк, югары күрсәткечләр турында кайгыру өстенлек итә. Мәктәп бусагасын яңа атлап кергән сабый беренче адымнарыннан ук алдашырга өйрәтелә башлый. Укытучының бөтен буш вакытын төрле җәмәгать эшләре үтәү, дәрес планнары төзү, ведомостьлар тутыру, укучыларның өйләренә бару, дәфтәрләр тикшерү, ата-аналар белән очрашулар ала. Аңа белемен арттырырга, дәресләргә әзерләнергә вакыт та калмый. Хезмәт хакы түбән. Авыл укытучылары мәктәп турында түгел, үз шәхси хуҗалыклары турында кайгырталар. Аларның күпчелегенә мәктәп әллә бар, әллә юк. Шуларга — торгынлыкка каршы чыкканым өчен миңа бүре билеты тоттырдылар.

— Нинди факультет бетердегез сез?

— Биология факультеты. Алдаша дисезме әллә?

— Аллам сакласын, алай димим. Мин үзем быел гына педны бетердем. Тарих-филология факультетын. Әллә сез дә филологмы дигән идем.

— Ә сез нигә мәктәптә эшләмисез, редакциягә урнаштыгыз? Нигә бушкуык, шалтыравык язмалар белән тулган ялган, берәүгә дә кирәге юк газетаны чыгаруда катнашасыз?

Мин тирән көрсендем.

— Язмышым шулай кушты.

— Ничек алай, чүпрәк түгелсездер бит сез?

— Бәлки чүпрәкмендер дә, кем белә?.. Сөйли китсәм, тормышым адәм ышанмаслык минем, Зәйнәп. Сөйләшмик ул турыда. Вакытыгыз кысан булмаса, бераз хуҗалыгыгыз белән таныштырыгыз мине.

— Әйдәгез, тик битлек киегез. Кортлар ят кешене яратмый. Бигрәк тә исерекләрне, тәмәке тартучыларны. Тагын тәннәреннән тир исе аңкыган шапшак кешеләрне.

— Битлек киеп тормыйм. Абригыгыз тешләмәде бит, бәлки, кортларыгыз да аяп чакмас.

— Кортлар, Абрик күк, әйткәнне тыңламаслар, алар миңа буйсынмыйлар.

— Ни булса ул, битлек кимим, корт чагуны тәнгә сихәт диләр...

— Мәйлçгез. Чаксалар, мин кисәттем сезне, үзегезгә үпкәләрсез.

Зәйнәп мине умарталары арасында шактый йөртте. Кортлар безгә игътибар итмәделәр, үз эшләрендә булдылар.

— Кара, кортлар сезне үз иттеләр бит, ник берсе шикләнеп яныгызга килсен. Монда аяк баскан начальникларның берсе дә алардан өлешсез китмиләр! Шуңа алар чүнниккә көн сүрелгәч, кортлар эшләп аргач, кичке якта гына күз салалар.

— Кортлар минем монда бал өмет итеп килмәвемне беләләр булыр, шуңа тимиләрдер. Ярар, кортчылык турында берәр китабыгызны бирегез дә, эшегездә бүтән комачауламам, китәрмен.

Без тыштан чүнник өенә кердек. Зәйнәп миңа тышлыгына «Кортчылык» дип язылган бер калын китап тоттырды. Аннары тиз генә идән астына төшеп, аннан ниндидер бер чүлмәк алып чыкты.

— Көн бик бөркү, эчәсе килде, сусынны басыйк әле.

Ул ян стенага беркетелгән ябылмалы шкафтан ике стакан алып, аларга чүлмәктәп шаулап күбекләнеп торган саргылт сыекча агызды.

— Ачы балмы бу?— дип кызыксындым мин, стаканнарга күрсәтеп.

— Шул, төчесен аның эчмиләр, ашыйлар. Йөгез, күтәрик.

— Мин күтәрмим, Зәйнәп, рәхмәт. Балның бик мәкерле эчемлек икәнен ишеткәнем бар, болай да акыл өләшкәндә йоклап калганмын, шуңа шәрәб, аракы, бал, сыра ише эчемлекләрне үземә дошман санап авызыма алмыйм.

— Күңелсезгә күлмәк кидермиләр, мәйлегез. Ә мин, гөнаһлы бәндә, сусадым,— дип, балын бик тәмләп эчте Зәйнәп.

Чүнниктән кайткач, Зәйнәп биргән китапны актарып утырганда, аның эченнән ике ягы да тутырып язылган бер дәфтәр бите килеп чыкты. Анда эре йөгерек хәрефләр белән: «Юкә агачы 20 яшьтә чәчәк ата, 300—400 ел яши. Бер гектарда үскән 30—40 яшьлек юкәләрдән 1000 килограммга хәтле бал алып була. Андый кишәрлектән корт иле көнгә 10—15 килограмм бал җыя. Умарталыкта, гадәттә, 120 умарта була. Бер гектар өрәңгедән бал кортлары 200 килограммага кадәр бал җыялар. Районда ике мең ярымнан артык корт иле исәпләнә. Шулар 1956 елда 284 центнер бал җитештерсәләр, 1957 елга ул 183 центнерга калды. Шәмәхә чәчәкле Иван-чай үсемлеге гектардан 350 килограмм, кура җиләге 100 килограмм, фацелия 200 килограмм, карабодай 70 килограмм, люцерна 35 килограмм бал бирә. Ак һәм алсу тукранбаштан бал кортлары 100 килограммга хәтле татлы сыекча җыялар. Көнбагыш, горчица, шепкән кебек культуралардан һәм кандала үләненнән дә шактый күләмдә бал алырга мөмкин. Кортлар бал гына түгел, бик кыйммәтле дару чималы — корт икмәге чырышына да җитештерәләр»,— дип язылган иде.

Бу язуны мин, бәлки материалымны эшләгәндә ярап куяр, дип, күчереп алдым.

## Җиденче бүлек

### 1

Редакторыбызның йомышын йөземә кызыллык килмәслек итеп башкарырга тырыштым. Башта умартачылык турында мәгълүматлар җыйдым, аннары район үзәгенә якындагы өч колхоз чүннигенә барып кайттым. Чүнникләр бер-берләренә охшамаганнар иде. Аларның барысы турында да гомуми мәкалә язаргамы, әллә тик берсе турында гына сөйләргәме дип, шактый вакыт бер карарга килә алмый уйландым. Ахырда Зәйнәп эшләгән чүнник һәм аның үзе турында җитди мәкалә язарга булдым. Моның өчен Зәйнәпне шәхес буларак та белергә тиеш идем. Мәктәпкә барып, аның андагы эше турында сораштым. Элекке коллегаларның барысы да Зәйнәпне дорфалыкта, тискәрелектә, үзсүзлелектә гаепләделәр. Бездә эшләгәндә аның төп хәсрәте коллективыбызда низаг арты низаг тудыру иде, ул мәктәптән киткәч, без иркен сулый, тынычлап эшли башладык, чебеннән фил ясарга, тырнак астыннан кер эзләргә ярата иде ул, диделәр. Ә аның укытуы ничек иде, бәлки эшен дә аннан-моннан гына үтәгәндер ул, диюемә, ул яктан аңа сүз әйтерлек, гөнаһына керерлек түгел, дәресләрен Зәйнәп бер дигән итеп үткәрә, балалар аны яраталар иде, үтә таләпчәнлеге, һәрвакыт тик үзен генә хаклы санавы, бүрәнә аркылы бүре күрүе абындырды аны, диделәр. Хәзер очрашканда беребез белән дә исәнләшми, мыскыллы елмаеп читкә карап уза. Педсоветларда ул яшь, аз тәҗрибәле укытучыларга гына түгел, карт, тәҗрибәле укытучыларга да: «Сезгә педагог исемен йөртү харам, сез балаларда әхлаксызлык тәрбиялисез, дәресләрегә әзерләнеп

килгән укучыларга да, әзерләнмәгәннәренә дә бер үк төрле билгеләр куеп, укучыларыбыздагы тырышлыкка, кызыксынучанлыкка балта чабасыз. Укучыларыбызның кайберләре чирек буена фәннәрне «икеле»гә генә үзләштерәләр, ә чирек ахырында күз йомып шуларга «өчле» чыгарабыз. Без кемне алдыйбыз шулай? Күрсәткечләребез гел туксан тугыз процентган түбән төшми. Аны түбәнәйтсәк, мәктәбебезне төрле җыелышларда, киңәшмәләрдә начар дип чәйнәлүдән куркабыз»,— дип, директорыбыз Сафуан Галимовичның канына күп тоз салды. Хәзер инде, ялган күрсәткечләр белән мавыгасыз, эшемә аяк чаласыз, дип, совхоз җитәкчеләренең теңкәләренә тия, диләр. Акылы нормаль түгел аның. Җүнле булса, аны ире ташламас иде. Бөтен коллективыбызны тик үз кубызына гына биетмәкче иде дә Зәйнәбебез, юл куймадылар, сөртенделәр. Райкомдагы иптәшләргә рәхмәт, безгә аңардан котылырга алар булышты...

Нигә без башкаларныкыннан үзгә фикерле кешеләрне өнәмибез, арабыздагы андый «ак каргалар»ны нишләп сөймибез, күрәлмибез— аңлашылмый.

Совхоз җитәкчеләреннән дә миңа Зәйнәпкә уңай бәя ишетергә туры килмәде.

— Гомәрова — үз дигәненә генә табынучы кире беткән зат, чөнники тән аны күптән тыраклатасы иде дә, тик анда Сирай бабайга ялгызына гына эшләве авыр булыр, дип, теш кысып түзәбез,— диде совхозның партоешма секретаре Григорий Леушин, Зәйнәпкә характеристика бирүен үтенгәч.— Кырларыбызга нәрсә чәчәсен игенчелектә бернинди мәгълүматы булмаган, бодайны арпадан аера алмаучы ул тилчә телме, махсус югары уку йортында укып кайткан тәҗрибәле агрономны яхшырак беләме? Гомәровага пеште дә төште булсын: карабодай да чәч син аңа, фацелия дә чәч, горчица да, көнбагыш та, ак һәм алсу тукранбаш та... Югарыдан төшерелгән планны без җиренә җиткерергә, аны бер генә карыш та читкә тайпылмый үтәргә тиешбез. Оялмый, чөннигегездә мин эшли башлаганчы күпме бал ала идегез дә, мин килгәч күпме бал аласыз, дип, күзләрен дә йоммый масая. Тыйнаклык, әдәп, башкалар сүзенә колак салу кебек сыйфатлар читләтеп узган аны.

Совхоз бухгалтериясендә һәр умартадан былтыр балны өченче елгыга караганда утыз җиде килограммга артыграк алынганын әйттеләр. Сирай бабай, чүнникнең бөтен тоткасы Зәйнәп икәнгә, үзенең инде бөтен сәләтен җигеп кортлар белән эшләү хәленнән килмәүгә ышандырды.

— Зәйнәп сеңлем булмаса, чөннигебез быел кыш бетә иде. Кортларыбызны ул саклап калды. Совхоз директоры көз кергәч, бал суыртырга кирәк, умарта хуҗалыгыбыз районда алдынгылыкка чыксын, дип теңкәбезгә тиде. Юк, диде аңа Зәйнәп сеңлем кисеп, кортлар да безнең күк үк җан ияләре, ашамый яши алмыйлар. Сыерларга совхоз кыш чыгарга күпмешәр центнер азык әзерләде? Һәр сыерга берничә тоннамы? Бездә терлекләр өчен әзерләнгән азыкның яртысыннан күбрәге чери, черми калганы әрәм-шәрәм ителә. Бал кортлары да үзләренә кыш чыгарлык азык тупладылар, без аларның җыйган балларын суыртып алдык инде. Кортларның үзләренә әзерләгән запасларына кагылсак, аларны һәлакәткә дучар итәчәкбез. Әйт, Сирай бабай, хаклымы мин, әллә ялгышаммы, диде. Мин дә чөннигебездә суыртырга мыскал да бал калмады, булганы күптән суыртылды инде, дидем. Быел яз көне Мишә ташыганда омшанникка су керә башлады. Зәйнәп сеңлем булмаса, умарталарыбызның байтагыннан колак кага идек. Ул, совхоз ирләрен бөтенесен аякка бастырып, кортларыбызны һәлакәттән коткарды. Ут хатын ул Зәйнәп сеңлем, ут, теле борыч белән бер, әйтәсе сүзен, ике уйлап тормый, кемнең дә йөзенә бәреп әйтә...

Умартачылык турындагы мәкаләмне мин редакторга күрсәткәнче башта Зәйнәпкә укытырга булдым. Мәкаләмдә ул кортчылык тармагында югары күрсәткечләргә ирешү өчен җан атучы булудан бигрәк хаклык

эзләүче, торгынлыкка, сулпәнлеккә каршы көрәшүче Дон-Кихот сымаграк килеп чыкты.

Мин язмамны укытырга дип чүнниккә килгәндә Сирай бабай белән Зәйнәп икәүләп умарта карыйлар иде. Чүнниктә озак тукталуны кирәк санамадым.

— Зәйнәп ханым, бу көннәрдә гел тирәгездә буталганым өчен, зинһар, орышмагыз мине. Чүннигегез турындагы язмам әзер. Шуны укып чыгып, фикерегезне әйтмәссезме дип килгән идем, күрәм, сез һаман эштә...

— Язмагызны калдырыгыз, эштән бушагач карап чыгармын,— дип җавап кайтарды Зәйнәп.

— Озакка сузмасагыз иде...

— Сузмам. Укып чыгармын да кич эштән кайтышлый керермен сезгә.

Кич үтеп, карангы да төште. Мин Зәйнәпне Мишә яры өстендәге сукмакта арлы-бирле йөренә-йөренә көттем. Әмма ул нигәдер озаклады, күренмәде.

Димәк, язганым ошамады аңа. Мәктәптә гаделлек өчен көрәшендә теләктәшлек тапмавын, укытучылар коллективын ничек үзенә каршы куюын, нәтиҗәдә укытудан китәргә мәҗбүр ителүен, совхоз умарталыгында эшли башлагач та хуҗалык җитәкчеләре белән тыныша, уртак тел таба алмавын язуым хәтерен калдырды, күрәсең...

## 2

Марийша түтинең печәнлегендә әле яңа гына йокыга киткән идем бугай, кемнеңдер кулыма кагылуына уянып, башымны күтәрдем.

— Кем бар монда?

— Бу мин — Зәйнәп. Куркыттым, ахры? — дигән җавап ишеттем.

— Зарар юк,— дидем.— Килерегезгә өметемне өзгәч, йокларга яткан идем инде. Килдегез, рәхмәт. Инде фикерегезне әйтегез, язма барырлыкмы?

— Ашыкмагыз, атны җиккәнче үк чыбыркылый башламыйлар, Ирек. Бераз сулу алырга бирегез. Совхозда гомуми җыелыш булды, сезнең яңа яктыда килергә шуңа тоткарландым. Укыдым әйберегезне. Сезгә бер-ике сүз белән, әйбәт яки начар язгансыз дип, кенә җавап бирәсем килми. Башта әйтегез, бүген мине печәнлегегездә кундырасызмы?

Кызык, нигә кирәк аңа минем янымда куну?

— Печәнлек минеке түгел, Марийша түтинеке. Гайбәттән курыкмасагыз, кунызыз.

— Гайбәт тотен түгел, күзгә кермәс. Марийша түти миңа монда йокларга рөхсәт итте инде. Бәлки, сез куркасыздыр гайбәттән?

— Намусымнан бүтән беркем алдында да хисап бирәсем юк минем.

— Янгызда кундырасыз, кумыйсыз, димәк?

— Үзегезгә карагыз.

Зәйнәп янәшәмә ятты. Күңелемдә, нәрсә кирәк аңа, кемгә саный ул мине, дигән вәсвәсә борынлады.

— Үзегез турында сөйләгез әле, мин сезне бөтенләй белмим бит. Сез мине әнә биш бармагыгыз кебек өйрәнгәнсез, кунак ашы кара-каршы булсын,— диде тоңге «кунак», миңа сыена төшеп.

— Тормышым күңелсез минем, Зәйнәп, аның кешегә сөйләрлеге юк,— дидем мин теләр-теләмәс кенә.— Белүегез кирәк микән аны?..

— Кирәк, Ирек. Язмагызны укыгач, сезне якыннан беләсем килде.

— Язмам ничек, барырлыкмы? Ул нинди тәэсир калдырды?

— Әйбәт тәэсир, бернинди ялган да күрмәгән анда. Ләкин аны газетагызда бастырсагыз, районыбыз җитәкчеләре сезне башыгыздан

сыйпамаячаклар. Хакыйкатькә көн юк Питрәчтә, бөтен нәрсә ялганга, кода-кодагыйлыкка корылган. Бу язмагыз өчен, фиркале булсагыз, кызыл билетыгыз белән дә саубуллашуыгыз бар.

— Куркытасыз булыр? — дидем, көлеп.

— Куркытмыйм, уемдагыны әйтәм.

— Сез моннан бер ел чамасы элек кенә халык дошманы саналган кеше янәшәсендә ятуыгызны беләсезме?

— Шаяртасыздыр?

— Шаяртмыйм. Халык дошманы исәпләнеп, чәнечкеле тимерчыбык киртәләре артында, биш елга якын каты сак астында, казна исәбенә тереклек иткән мәхлук мин.

— Нәрсә өчен утыруыгызны сөйләгез әле.

— Аның өчен бөтен үткәнемне янә бер кат сөреп чыгарга кирәк миңа. Утыз җиденче елда кешеләрнең эзсез юкка чыгуларын, бәлки, ишеткәнегез бардыр? Минем дә кимсетелү-түбәнсетелүләрем шул елдан башланды.

— Ничек алай, сез малай гына булгансыз ич әле ул вакытта?

— Минем әтием белән әниемне кулга алдылар, мин берүзем калдым.

— Гафу итегез, язмышы берәүнең дә маңгаена язылмаган. Әтиегез белән әниегез хәзер кайда, Казандамы?

— Белмим, алар шул утыз җиденче елны кулга алынгач, юкка чыктылар.

— Якыннарыгыздан хәзер кемнәрегез бар?

— Мин дуадак каз кебек бербашым, беркемем дә юк. Тормышым — тәкъдир иркендә. Киләчәккә бернинди планнарым да юк, иртәгәм булса ни дә, булмаса ни. Йоклыйк, Зәйнәп ханым, иртәгә миңа да, сезгә дә эшкә барасы.

Мин төнге кунагыма аркам белән борылдым. Ул йоклыйк та, йокламыйк та димәде. Үз-үземне сүктем. Нигә дип очраган бер кеше алдында мескенләнәм, теләсә кемгә отчет бирәм мин? Юк, мескенләнмим, күрегез, абзагыз утны, суны кичкән бәндә, дип кукраям, шапырынып күкрәк кагам. Йә, ахмак дими кем дисең мине?.. Нигә бу хатын янымда ята? Нигә ул монда кунарга калды? Нәрсә кирәк аңа миннән?.. Бәлки, язмамны редакторга күрсәтмәскәдер, аңа, эшем барып чыкмады, кушкан йомышыгызны үти алмаганым өчен мин җебегәнне гафу итегез, дияргәдер? Алай эшләсәм, мәктәпләрдәге һәм совхоздагы үземә мәгълүм башбаштаклыкларга күз йомам, яшереп калам булыр...

Кинәт лапасның печәнлек янәшәсеннән Марийша түтинең әтәче карлыккан ямьсез тавыш белән:

— Ки-и-кри-и-кү-ү-ук!.. — дип бөтен Питрәчкә сөрән салды.

Печәнлектә йоклый башлавымның беренче төненнән үк мин ул әтәч белән көрәш башлаган идем. Мине ул печәнлеккә тәүге кат йокларга менгәч әлеге күк үк, искәрмәстән шыран ярып, уятты. Шуңа күрә моңарчы аны һәр төнне кичтән үк кетәктән алып чыгып лапасның бер почмагына бастырылган иске буш мичкә эченә иртәнгә кадәр утырта торган булдым. Бүген исә кич буе Зәйнәпнең язмамны китерүен көтеп, йокымны бүлүче кушбугазны кисмәгенә утыртырга оныткан идем.

— Күңелле икән сезнең монда. Колак төбегездә үк төннәрен дөнья ярып, разбой акыруга ничек түзәсез? — диде Зәйнәп, иңемә кагылып.

— Әтәч белән без бер-беребезгә комачауламау, үзара тыныч, үпкәләшсез яшәү турында килешендек, игътибар итмәгез, — дидем мин, урынымнан торып.

Әтәч мине мыскыллаган төсле яңадан бар тавышына сузып сөрән салды. Аңа төрле тавышлар белән Питрәчнең башка әтәчләре кушылды. Мин печәнлектән төшә торган баскычка үрмәләдем.

— Кая китәсез сез, ятыгыз, булмаса мин китим.

— Китмәгез, мин әтәч белән сөйләшәм дә менәм, азына ул явыз.

Әтәчне кетәгеннән алып чыгып, кисмәккә яптым. Аннары печәнлеккә менеп:

— Тынычлап йоклагыз, Зәйнәп ханым, сезне бүтән борчучы булмас,— дидем.

— Минем йокым качты инде, Ирек. Сезнең турыда уйлап ятам менә. Сәер кеше сез. Яныгызда әллә мин бар, әллә юк, аркагызны борып яттыгыз да, шундук борыныгызны сызгырта башладыгыз. Ярый әтәч уятты әле сезне, аңа рәхмәт. Безнең печәнлектә икәүдән-икәү генә гөнаһсыз кунуыбызга берәү дә ышанмаячак бит...

— Сез әллә безнең бергә кунганны Питрәч буйлап сөйләп йөрмәкче буласызмы?

— Аны мин сөйләп йөрмәсәм дә беләчәкләр. Авыл — авыз, кыр — күз, урман — колак дигәнне ишеткәнегез бардыр, шөт.

— Сөйләсеннәр, намусыбыз пакь булса, аңа бернинди кер дә кунмас.

— Әдәпсез соравым өчен үпкәләмәгез, сезнең яратканыгыз, моңарчы хатын-кыз куенында булганыгыз бармы?

— Андый нәрсәләргә миңа вакыт тигәне юк әле, Зәйнәп ханым. Башта әти-әниемнән калгач ятимлек ачысын татыдым, аннары авыр фронт юллары үтелде, сугыштан кайткач, ачлы-туклы студентлык еллары, аннары төрмә, колонияләр. Сезне кызыксындырган гыйшык-гайшрәткә вакыт тимәде.

— Моңарчы хәтта үбешкәнегез дә юкмы әллә?

— Бар дисәм дә ялган булыр, юк дисәм дә алдармын. Хакыйкать шуларның икесе арасында, теләсәгез ничек аңлагыз.

Төнге кунагыма мин Оля турында сөйләүне кирәк тапмадым.

Әтәчне кисмәккә утырткач, без йокламадык, гәп куерттык. Зәйнәп үзенең бала чагы, мәктәптә укыганда бөтен буш вакытын рәсем ясауга багышлавы, хәзер, бик теләсә дә, буяулар белән кәгазь яки киндер пычратырга вакыты юклыктан зарланды.

— Чүнниктә ураткан шөгылем белән мавыгырга вакыт юк. Анда мин бәйдәге эт төсле. Йә теге, йә бу эш кичектерүне көтми алдыма баса...

Сүз барышында ул язмамның, аның чүннигеннән бигрәк, үзенә багышлануына уңайсызлануын әйтте.

— Ничек уйлыйсыз, бәлки, аның мәктәпкә кагылышлы өлешен алып ташларгадыр? — дидем.

— Кирәкми, язмагызның бөтен тозы да шунда,— дип, каршы килде Зәйнәп. Аннары ул моннан өч ел элек Питрәчтән сигез километр читтәге Починок исемле инде бетүгә йөз тоткан урыс авылында бер укытучының классында чирек процент та өлгереш бирмичә бөтен республикага мәсхәрәгә калуын офтанып сөйләде.

— Починок зур авыл түгел. Нибары җиде-сигез хуҗалык анда. Кешеләренең күбесе картлар, карчыклар. Яшь гаиләләр ике-өч кенә. Бөтен авылларына биш-алты бала бар. Аларны надан калдырмас өчен Починок мәктәбендә әле дә бер укытучы асрала. Һәр класста бер йә ике укучы исәпләнә. Укытучы барлык классларын аерым-аерым түгел, берьюлы укыта. Өченче ел, аның бәхетсезлегенә, беренче класста акылы камил түгел бала укый башлый. Ел буе тырышса да, укытучы аны санарга да, хәрефләр танырга да өйрәтә алмый. Шуңа күрә район мәгариф бүлегенә ул, Починок мәктәбенең беренче классында укыган берләнбер бала Фәлән Фәләнов ел буена бер генә фәннән дә өлгермәде, шул сәбәпле ул классында икенче елга калдырылды, дип отчет бирә. Бу көлке һәм бер үк вакытта аяныч та. Укытучы үз намусына тап төшерергә теләмәгәне өчен телгә керде. Шаккатыргыч хәбәрләр эзләүче җилкуар бер журналист бу хәлне хәтта өлкә газетасында да язып чыкты. Ул укытучыны булдыксызлыкта, пешмәганлектә гаепләде, класста берләнбер баланы да санарга, хәрефләр танытырга өйрәтә алмау хурлык, циркта әнә этләр булып этләр дә санарга өйрәтелә, дип язды. Дебил баланы нәрсәгә өйрәтеп булсын, ул уйлый белү сәләтеннән тулысынча мәхрүм иң. Исеме — бала, җисеме — тере бүкән.

Зәйнәп белән без төне буена күп нәрсәләр турында сөйләштек. Иртән аерылганда, ул, мине үбеп:

— Бу сиңа башка комагай ирләргә охшамаганың, янәшәмдә хатын кеше ята дип, миңа нәфесләнмәгәнең, кешегә исәпләгәнең өчен,— диде.

3

Редакторым язмамны минем алда ук укып чыкты да:

— Материалыгыз ошады миңа. Тәрҗемә итегез, газеталарыбызның икесендә дә киләсе санда бирербез,— диде.

Өстемнән, гүя, тау төште, иркен сулап куйдым. Әмма иртә тынычланганмын булып чыкты. Язмам газетабызда басылу белән редакторыбызны райкомга дәшеп алдылар. Аннан ул шактый озак торып, сөмсере коелып кайтты. Шуннан соң озак та үтмәде, газетабызның җаваплы секретаре Алексей Евстигнеев минем янга кереп:

— Сезне райкомның беренче секретаре иптәш Филиппов әңгәмәгә чакыра,— диде...

Райком секретаре — таза бәдәнле, керпе инәләре сыман тырпаеп торган кыска кызгылт чәчле урыс — мине өстәле янына баскан килеш, чыраен чытып каршылады.

— Син яздыңмы бу саташуны? — диде ул, өстәлдә яткан газетага ымлап.

— Нинди саташуны? — дидем, нәрсә турында сүз барганны аңламаганга сабышып.

— Ангыра сарык булып кыланма, җавап бир!..

Ачуым чыкты, иң шәп саклану чарасы — үзең һөҗүмгә күчү, дигән тәгъбир хәтеремә килде.

— Җикермәгез миңа. Сез түрә, мин хезмәтче түгел. Сез дә, мин дә коммунистлар, тавышыгызны күтәрмәгез, мин чукрак түгел.

Райком секретареның күзләре акайды, яңак мускуллары биеп алды, йодрыклары төйнәлде. Ул тешләрен шыгырдатып өстемә килде.

— Син мине ничек сөйләшергә өйрәтмә, җавап бир, хәсис!

— Нинди җавап?

— Менә моны син яздыңмы?

— Әйе, мин яздым.

— Ничек килеп эләктең син безнең редакциягә?

— Мине монда партия өлкә комитеты җибәрде.

— Ә районыбыз мәктәпләренә яла ягарга сиңа кем кушты?

— Кешечә сорашмасагыз, җикеренсәгез, мин сезнең белән сөйләшүне артык санийм, чыгып китәм.

— Куркыттың!.. Чык, дүрт ягың кыйбла, көчек. Башка күземә күренәсе булма. Олак бу районнан, монда бүтән эзең булмасын!..

«Әгәр сине түбәнсетсәләр, бу — син күпмедер дәрәҗәдә хаклы дигән сүз»,— дия иде колониядә инженер Арон Маневич.

— Яхшы, мин чыгам, әмма синең тәнкыйтьне кысуың, районны бөлгенлеккә алып баруың, бөтен башбаштаклыкларга үзеңнең дә күз йомуың һәм башкаларны да шуңа ук өндәвең турында бүген чыккан шушы газета белән бергә кичекмәстән иптәш Хрущев исеменә Үзәк Комитетка язам. Иптәш Хрущев синең ише икейөзле бушбугазларны гына түгел, ҮКны озак еллар эчтән таркаткан Молотов, Каганович, Маленков шикелле муртайган түрәләрнең дә, партия эшенә аяк чалганнары өчен, артларына типте. Сине дә шул көтә. Хуш!..

Беренче секретарь, үз өстеннән Үзәк Комитетка хат юлласымны ишеткәч, күзгә күренеп шиңде. Нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты, ләкин сүзе чыкмады. Мин, әңгәмәбезне тәгәлләнгәнгә санап, ишеккә юнәлдем.

— Чыкмагыз, утырыгыз әле, сөйләшик,— диде беренче секретарь, артымнан килеп, үтенгән тавыш белән.

— Сөйләштек ич инде, житәр. Мине эшем көтә,— дип, мин ишекне шап итеп ябып чыгып киттем.

Редакторыбыз, аның урынбасары, газетабызның җаваплы секретаре мине редакциябезнең ишеге төбендә каршыладылар.

— Сезгә иптәш Филиппов райкомга янадан килергә куша.

— Мин әле генә аның янындан чыктым. Кирәк булса, ул монда үзе килсен. Аның белән бүтән сөйләшер сүзем юк.

Коллегаларымны киреләнүем гаҗәпләндерде. Чебен дулап тәрәзә ватамы?.. Райком секретаре теләсә сине җир белән тигезли бит, җүләр, дигән кызгану күрдем мин иптәшләремнең күзләрендә.

— Райкомга барудан баш тартуыңны телефоннан иптәш Филипповка үзең әйт алайса.

— Шалтыратыгыз аңа...

Николай Ильич үз бүлмәсеннән беренче секретарьга шалтыратты. Мин, трубканы үземә алып:

— Сезгә миннән тагын нәрсә кирәк, иптәш Филиппов?— дидем.— Мәкаләдә телгә алынган мактап администрациясен һәм умарта хуҗалыгының эшенә аяк чалучы совхоз җитәкчеләрен райком бюросында җәзага тартмыйча торып мин сезнең белән сөйләшмәячәкмен. Үтенәм, мине бүтән борчымагыз.— Һәм трубканы куйдым.

Телефоннан беренче секретарьга әйткән сүзләремне тыңлап торган коллегаларымның күзләре маңгайларына менде.

— Ут белән шаярасың, агайне. Филиппов кем дә, син кем?— диде редакторыбыз, тирән борчылып.

— Кешелек сыйфатларын югалтмаган булса, ул әле бүгенгә тәкәллефсезлеге өчен килеп бездән гафу үтенер, Николай Ильич. Юкка борчылмагыз,— дип тынычландырдым аны.

Кич, эштән кайтканда, урамда Зәйнәпне очраттым. Ул мине язмамның дөнья күрүе белән котлады. Аңа мин редакторыбызның һәм үземнең мәкаләм басылып чыгу уңае белән райкомга чакырылуыбызны әйттем. Иптәш Филиппов белән булган ятышсыз сөйләшүебезне телгә алуны кирәк тапмадым, райкомда язмам өчен бераз гына шелтәләделәр дидем.

— Районыбыз хуҗасы үз биләмәләрендәге җитешсезлекләр, чатаклыклар турында тел тибрәтергә базучыларны өнәми. Ул өеннән чүпне читкә чыгарган кешеләрдән тиз арына, күрерсез, сезне дә эшләтмәячәк монда,— диде Зәйнәп, хафаланып.

— Таяк ике башлы,— дип каршы төштем аңа.— Бәлки, миңа түгел, ул түрәнең үзенә районнан табан ялтыратырга туры килер әле, белеп булмый...

— Оптимист сез, оптимист,— диде әңгәмәдәшем, исе китеп.

Газетабызда язмам чыккан атнада ук райком бюросы җыйналып, анда Зәйнәп эшләгән мәктәпнең директорына, мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдиренә, совхоз директорына, совхозның баш агрономына һәм партоешма секретарена шәхси карточкаларына язып каты шелтә бирергә, дигән карар кабул ителде. Ул карарны газетабыз «Безнең материаллар эзеннән» дигән баш астында урыс һәм татар телләрендә басып чыгарды. Иптәш Филиппов Николай Ильичтан да, миннән дә мәкалә чыккач урынсызга кызганы өчен телефон аша гафу үтенде.

Мин, үзем дә сизмәстән, иптәшләрем арасында каһарманга әверелдем. Алар, иптәш Филипповны ничек игә китерә алдың син, дип гаҗәпләнделәр. Минем турыда, югарыда берәр таянычы бардыр аның, шунсыз безнең беренче секретарьны игә китерә алмас иде, диючеләр дә табылды.

Бер көнне Зәйнәп, истә-санда юкта, редакциягә кереп, миңа:

— Райкомнан кайтып килешем. Анда мине янадан мәктәпкә әйләнеп кайтырга димләделәр, мин каршы килдем,— диде, озатырга чыккач.— Печәнлегебезне онытa алмыйм, яныгызга бүген төнлә тагын киләм, көтегез...

Мин кырт кисеп:

— Килмәгез, кирәкми,— дидем.

## Сигезенче бүлек

### 1

Район бюросы, башка бик күп коммунистлар белән беррәттән, мине дә район колхозларының берсенә Бөек Октябрь социалистик революциясенең 40 еллыгына багышланган тантанада чыгыш ясарга җибәрергә карар чыгарганы мәгълүм булды. Чыгыш ясарга кайсы авылны сайлау һәр коммунистның үз ихтыярына куелган иде. Мин Питрәчтән егерме биш километр читтә урнашкан «Коммунизм» колхозына барырга булдым. Анда баруымның төп сәбәбе — ул колхозның газетабызда бик аз телгә алынуы иде.

«Коммунизм» колхозына барырга транспорт көтеп тормадым, җәяү киттем. «Коммунизм» колхозына юл сазлы болыннар аша үтә икән. Юлдашка миңа Казаннан әнисе янына кунакка кайтучы, аркасына дәү биштәр аскан, яше инде утыз тирәләренә якынлашкан, таза гәүдәле, чиртсәң кан чыгардай тулы түгәрәк йөзле, юл буе черт-черт сагыз чәйнәп кайткан сүзчән Әкълимә очрамаса, «Коммунизм» колхозына ул көнне, бәлки, барып та җитә алмас идем. Аңа рәхмәт.

— Казанда мин инде дүртенче елымны торам. Башта ипилек-тозлык та урысча белмәгәч читен иде, урысчаны әзрәк пупалый башлагач күнектем тагы. Авылыбыздан элек тә туйган идем, инде шәһәргә күнеккәч, анда кайтып күренәсем дә килми,— дип зарланудан башлады ул сүзен.

— Алайса ник соң, тездән саз ерып, үлә-бата кайтасыз анда?

— Әни бар авылда. Янына үзем бара алмыйм, җаең чыкканда айга бер-кайда бер кайтып күренеп кит, дип хаты саен ялвара. Сәламәтлеккә туймый әнием, бүген бар ул, иртәгә юк. Үлеп-нитеп китсә, сүзен тыңламавыма ахырда үкенермен, дип, теләмәсәм дә юлга чыгам.

— Авылыгыздан җаныгыз нигә бизгәнне сөйләрсез, бәлки?

— Һәй, котырган этне бәйләп куйсаң, ул да бәен өзеп качарлык хәзер Салтышта. Колхозына «Коммунизм» исемен мыскыл итеп биргәннәр кебек аның. Аннан бер чыгып киткән кеше кабат әйләнеп кайтмый. Салтыш, шүрәле каргаган авыл күк, елдан-ел бетә бара. Кешеләр генә түгел, зиратына оялаган каргалар да башка авылларга күчеп бетте инде аннан.

— Авылдашларыгыз туган нигезләреннән берәм-берәм тайгач, хәзер кем эшли соң колхозыгызда?

— Җирләрне, МТСтан килеп, сөреп чәчәләр. Игеннәрне урып-җыю да шул ук МТС өстендә. Терлекчелектә авылдан китми калган гарип-горәбә дә, карт-коры, малай-шалай һәм кыз-кыркын селкенә. Ышанасызмы, язын-көзен яңгырлардан, кыш көне салкыннардан ышыкланырлык кечкенә генә клуб әсәре дә юк Салтышта. Мәктәбебез дә җүнле кешенең мунчасы кадәр генә. Анда да укыр кеше санаулы гына — бөтен авылга унбиш-егерме бала бар.

— Районыгыздагы бүтән авылларда хәл сез сөйләгәнчә үк мөшкел түгел бит, туган авылыгызны сез ачудан хурлыйсыз булыр?..

— Менә барасыз анда, арттыраммы, киметәмме, үз күзләрегез белән күрерсез баргач,— диде юлдашым, үпкәләп.— Алдашырга, туган авылыма күрәләтә яла ягарга мин тилебәрән орлыгы ашамаган ла...

— Гафу итегез, шигемне сезне рәнҗетим дип әйтмәдем.

— Сез нәчәлник кешедер әле, шуңа дөресне сөйләгәнгә ышанмыйсыздыр?

— Начальниклар минем күк җәяү йөрмиләр, сеңлем. Мин дә сезнең кебек үк язмышым кыерсыткан гап-гади бәндә.

Юлдашым моңа ышаныргамы, ышанмаскамы дигән төсле мине башымнан аягыма кадәр күздән кичерде.

— Сез Салтышка кемгә барасыз?

— Фатирга кемгә кертерләр, шуларга. Мине кабул итү колхоз житәкчеләре эше.

— Үзегез, мин нәчәлник түгел, дисез. Йомышыгыз колхоз башлыкларында булгач, нәчәлник инде, яшерәсез генәдер...

— Ярар, сезнеңчә булсын.

Салтышка барып житкәч, колхоз идарәсенә юнәлдем. Ул йозакта булып чыкты. Авыл кибете идарә янәшәсендә икән, анда кердем. Кибеткә килгән кешеләр миңа колхоз рәисенең Чыты авылына кайтып киткәнен әйттеләр. Ул Чыты кешесе икән. Аның гомеренең дүрттән өч өлеше Салтыш белән үз авылы арасында үтә, кайчагында рәисебезне атналар буе күрә алмый зар-интизар булабыз, сезнең аны бүген монда очрата алуыгыз икеле, диделәр. Колхоз партоешмасы секретаренең биле кузгалган, авырып урында ята булып чыкты. Хисапчының лаякыл исерек икәнен белдем. Алдыма кемгәдер фатирга урнашу, киченниндидер бинага кешеләрне жыю бурычы килеп басты.

Салтышта эшемне нәрсәдәндер башларга кирәк иде, райком йөкләмәсен үтәми Питрәчкә тәпиләү турында уема да кертмәдем. Авылдагы мәктәпнең ике укытучысының берсен эзләп табып, аның белән партоешма секретаренең өенә бардым. Без килгәндә секретарьны хатыны кызган үтүк белән дәвалап азаплана иде.

Мин, исәнләшкәч:

— Вакытсыз чирләгәнсез, иптәш секретарь, бик вакытсыз. Һич югында бәйрәм үткәнне күтәргә иде. Болай авылдашларыгыз Бөек Октябрь социалистик революциясенең кырык еллыгы тантанасын тиешенчә билгеләп үтүдән мәхрүм калалар бит,— дидем.

Секретарь миңа:

— Көнендә генә билгеләргә димәгән бит аны,— дип каршы төште.— Мин аякка баскач, шаулатып үткәрәбез без ул тантананы.

— Ә мин нишлим? Мин монда райкомнан ул тантанада чыгыш ясарга махсус жибәрелдем бит.

— Докладыгызны калдырыгыз миңа, халыкны жыеп аны үзем укырмын,— диде секретарь, исе китмичә.

— Докладым язылмаган, ул башымда минем, халыкны бүген жыярга кирәк. Чәчәкнең иң күркәм чагы — аткан көнендә. Аннары аның нәфислеге кайтыша. Бәйрәм дә шулай.

— Сез минем хәлемә керегез инде, иптәш, күрәсез, чирлим.

— Урынбасарыгыз, партбюро әгъзаларыгыз юкмыни соң сезнең?

— Исәпкә урынбасарым да, бюро әгъзалары да бар, тик эш майтарырга гына кеше юк.

— Ә жыелышларны кайда үткәрәсез?

— Колхоз идарәсендә.

— Ул бикле икән бит...

— Аның миндә ачкычы бар. Хатын, кесәдән алып бир әле аны Гаптеригә, ул ачар идарәне. Жыелышка кешеләр жыюны да Гаптери эшләр. Минем урынбасарым — асылда уң кулым ул.

Монда килгәндә үзенең партоешма секретаренең урынбасары икәнен әйтмәде, астыртын, дип уйладым, инде чыгарга ишеккә борылган укытучыга карап.

— Мине фатирга кемгә урнаштырырсыз икән?

— Жыелыштан соң Гаптери әнә үзенә алып кайтыр сезне. Кунакка ничек тә урын табар. Бер кичкә кер мичкә, диләр.

Кичен колхоз идарәсенә егермеләп кеше килде. Жыелышка кадәр мин алардан көндәлек тормышлары, эшләре турында сорашып утырдым. Күбесе инде олы яшьтәге кешеләр жыйналган, араларында дүрт хатын да бар иде.

— Тормышыбыз, дөресен әйтергә кирәк, мактанырлык түгел, иптәшкәй,— диде арадан шәрә баш түбәсенә каешланып беткән кара кәләпүш чәпәгән ямьшек борынлы агай, кайнарланып.— Авылда яшибез,

үзебез иген-тура үстерәбез, ә авыз тутырып ашарга ипи заты күрмибез. Колхозыбызда тегермән юк, авылыбызга он кыш көне юл төшкәч кенә кайткалый. Анда да кибетчебезнең дус-ишләре, таныш-белешләре, туган-тумачалары гына тәэмин ителә. Безгә он кайткач, кибеткә килеп өлгерсәк, он тия, өлгермәсәк, сакал сыпырып калабыз. Башка төр ашамлыклар белән дә шул хәл. Сугышка хәтле гөрләп торган авыл иде Салтыш, сугыш аны, үзе монда килеп житмәсә дә, чүплек башына әйләндерде. Хәзер, бөтен бәлаләрне сугышка сылтавым көферлектер, елның елында авылыбызны район житәкчеләре жибәргән әрәмтамак председательләр хәерчегә чагырдылар дисәм, расрак булыр...

— Безгә гел, фәләнне эшләгез, тегәнне үтәгез, арышны фәлән вакытта, сабан ашлыкларын кар китү белән чәчә башлагыз, дип күрсәтмә бирмәсәләр, без нишләргә белмибез кебек. Елның елында безгә вәкил булып район финанс бүлеге мөдире Гата Фәйрушин килә. Сәламны печәннән аера алмый үзе. Авылыбыздагы тол хатыннарның итәк асларын капшарга гына мачтыр. Бер кызы, ике малае үсә инде Салтышта. Бүтән нәрсә кулыннан килмәсә дә, анысын булдыра, дуңгыз!..

Сәгать кичке жиде тулгач, укытучы Гаптери, жыелышны ачып, миңа сүз бирде.

— Мин сезгә, иптәшләр, нотык сөйләмәм, ул эчегезне пошырыр, йокыгызны китерер дип куркам. Бөек Октябрь социалистик революциясе турында сезнең кайберләрегез белән жыелыш алдыннан гәпләшкәндәге кебек, гади генә итеп сөйләргә тырышырмын,— дип башладым чыгышымны.— Иске тормышка тирән кабер казып аны ләхеткә иңдергән Бөек Октябрь социалистик революциясе булуга иртәгә тәгәл кырык ел тула. Берәүләргә кырык ел тик бер мизгел генә төсле тоела, икенчеләргә ул гаять озын-озак дәвер булып күз алдына баса. Без революциядән соң тарихта күрелмәгән уңышларга ирештек. Электәге ач-ялангач Рәсәй иркен тормышта яши башлады. Илебездә социализм төзелә. Сезгә, менә монда утырган иптәшләргә ул файда бирдеме, зыян китердеме? Әлбәттә, файда китерде. Без киң хокукларга ирештек, колхозлар төзедек, кулакны сыйныф буларак юк иттек... Бөек революция капиталистлар өчен аяз көнне яшьнәгән яшен кебек булды. Алар үз аяк асларындагы жирнең иртәме, соңмы аяктан егасын, Октябрь жиленең үзләренә дә үтеп керәсен сизенеп, революция казанышларын юк итәргә омтылып үндүрт ил бергә берләшеп, илебез өстенә ташландылар...

Чыгышымны кызыксыну белән тыңладылар, бүлмәдә чебен очкан тавыш та ишетелерлек иде. Ахырда ярыйсы ук четрекле сораулар да бирделәр. Мин һәр сорауга мөмкин кадәр тулы җавап бирергә тырыштым. Жыелышка килүчеләр арасында миңа бу авылга килгәндә юлдаш булган Әкълимә дә бар иде...

## 2

«Коммунизм» колхозына Бөек Октябрь социалистик революциясенең 40 еллыгы тантанасына багышланган жыелышта чыгыш ясарга баруым эзсез үтмәде. Кайткач, газетабызга Салтыштагы хәлләр турында зур мәкалә яздым.

Мәкаләм басылып чыккач, райкомның беренче секретаре Антон Егорович Филиппов мине, гадәтенчә, райкомга чакыртты. Бусында ул мине, түрәләрчә түгел, кабинетының ишеге төбендә, бүлмәсенә кергәч тә, кул биреп, якты йөз белән каршылады. Аннары, диванда утырырга урын күрсәтеп, үзе дә янәшәмә кунаклады. Башта, тормышым, эшем турында сорашты, Салтышка ничек барып чыгуым, андагы колхоз председателе белән райком вәкиле Фәйрушин турындагы мәгълүматларны кайдан алуым белән кызыксынды. Мин аңа Бөек Октябрьның 40 еллыгын билгеләп үтү тантанасында чыгыш ясарга райкомның пропаганда һәм аги-

тация бүлеге тарафыннан җибәрелүем, ул колхозга баргач хуҗалык җитәкчеләреннән берәүне дә очрата алмавым, партоешма секретареның авыру булганын, ахырда андагы мәктәп укытучысы Гәрәйшин белән бәйрәм тантанасын билгеләргә колхоз идарәсенә тик егермеләп кешене генә җыя алуыбыз, мәкаләдә язылган хәлләрне шунда җыелган кешеләрнең сөйләгәнен, үземнең анда хәтта фатирга да урнаштырылмавым турында әйттем.

— Авыл, андагы колхоз ошадымы соң сезгә? — диде миңа райком секретаре.

— Салтышның үзенең дә, андагы колхозның да инде кешегә ошарлыгы калмаган, Антон Егорович, — дип җавап кайтардым, аның үземә мәкерле сорау бирүен абайламыйча.

— Шулай дисезме? Ничек уйлыйсыз, ул колхозны рәткә кертеп юлга сала алыр идегезме сез?

— Эшче көчләр юк дәрәҗәдә ул колхозда, Антон Егорович. Аны рәткә кертү асылда инде мөмкин түгел, миңа калса.

— Дөньяда җинел эш тик майлы ботка ашау гына, иптәш Кадыйров. Көч, тырышлык куймыйча берни дә майтарылмый. Менә без җитәкче иптәшләр белән җыйналып киңәштек тә «Коммунизм» колхозына председатель итеп сезне җибәрергә кирәк дигән карарга килдек. Моңа сез үзегез нәрсә әйтерсез?

— Нәрсә әйтим, Питрәч районы җитәкчеләренең, башлары белән түгел, утыра торган йомшак җирләре белән уйлаулары шөбһәсез икән, диярмен. Мин авыл хуҗалыгында профан бит. Үзегез үк белеп торасыз, минем кулымнан килердәй эш түгел колхоз председателе булу. Оештыру сәләте юк дәрәҗәсендә миндә.

— Без беребез дә туганда ук һәр нәрсәгә сәләтле булып тумыйбыз. Безне эшкә тормыш, зарурыйлык өйрәтә. Райком секретаре булганчы әллә мин, шәһәрдә туып үскән кеше, авыл хуҗалыгын белә идемме? Белми идем. Оештыру сәләтем дә чикле иде. Эшли башлагач өйрәндем. Без — партия солдатлары. Партия кайда җибәрсә, шунда барабыз. Ул нинди эш йөкләсә, карышмый шуны үтибез. Менә райком сезгә дә, коммунист буларак, койрыкта сөйрәлгән колхозны аякка бастыру бурычын йөкли.

— Моны сез һәръяклап уйладыгызмы, Антон Егорович? — дип, мин секретарьның йөзенә текәлдем. — Тәнкыйть мәкаләсе язган өчен миннән арынырга маташуыгыз түгелме бу? Нигә анда ул колхоздагы хәлләрне биш бармагыдай белгән райком вәкиле иптәш Фәйрушин түгел, ул колхозга очраклы рәвештә генә барып чыккан мин килергә тиеш? Сез миннән шулай котылырга, шулай үч алырга булдыгызмы? Ул хуҗалыкның көенечле хәле өчен кайгыргач, аны рәткә кертергә нигә үзегез алынмыйсыз? Авыл хуҗалыгын әйбәт белүегез белән дә әле генә шапырындыгыз, күрсәтегез район коммунистларына үрнәк. Салтышта, райкомның беренче секретаре иптәш Филипповның безнең колхозга аяк басканы юк әле, без аның нурлы йөзен күрергә зар-интизар, диләр. Ул авылга сез нинди юл алып барганын да белмисез булыр. Моны районлагы чүпләрне читкә чыгарганым өчен сөргенгә җибәрергә омтылуыгыз дип аңладым мин. Җитәкче кешегә үчлекле булу килешми, Антон Егорович. Мин сезне әллә бераз акыллыракмы икән дигән идем, ялгыштым, күрәсең. Сез каршы килмәсәгез, мин «Коммунизм» колхозы турындагы мәкаләмне өлкә газетасына җибәрәм, аны анда бик теләп басарлар, дип уйлыйм. Теләсәгез, анда сезнең үземне ул мәкалә өчен шул колхозга председатель итеп җибәрергә ниятләвегезне дә теркәрмен. Нинди киңәш бирәсез, җибәримме мәкаләмне өлкә газетасына, әллә аны Мәскәүгә үк олактырыйммы? Күрсеннәр югарыдагы иптәшләр районыбыздагы уңышларны...

Райком секретаре йөзен чытып читкә борылды.

— Җибәрмәгез. Безнең арада бүген бернинди гәпләшү дә булмады дип санагыз. Беркая да бармыйча, үз эшегездә тыныч кына эшләгез. Хушыгыз.

— Хушыгыз, Антон Егорович.

Мин беренче секретарьның йомшак диванынннан торып ишеккә юнәлдем, ул башын иеп утырып калды.

Гаҗәеп чикләнгәнлек, үчлелек, фикерләү кытлыгы каян килгән бу кешегә? Нигә ул үзен районда иң югары һәм шул ук вакытта иң актык инстанция исәпли? Нигә нинди генә очракта да аның сүзе генә сүз булырга тиеш? Ник ул тик үзен генә хаклы һәм хөкемдар саный? Ни өчен аңардан бөтен кеше уттан курыккандай курка, аңа берәүнең дә, сез хаклы түгел, ялгышасыз, дияргә кыюлыгы җитми? Түрәләрчә кыланыш аңа каян килгән, нигә аның сүзләре, кем әйткәндәй, бөеренннән генә чыга? «Сезне без үзегез хурлаган «Коммунизм» колхозын рәткә кертергә, юлга салырга анда председатель итеп җибәрергә булдык», имеш. Кемнәр ул — без? Нигә башта ул турыда минем үзем белән сөйләшмәскә, әүвәл председатель булырга минем ризамы, түгелме икәнем белән кызыксынмаска? Партия бурычы, ди. Кесәләрендә кызыл кенәгә йөрткән, һәйт диюгә шундук вәйт дияргә йоклаганда да әзер торучылар кайчандыр гөрләп чәчәк атып утырган соклангыч авылларны хәрәбә хәленә китерделәр. Шуларның берәрсе кылган җинаятьләре, эшләгән башбаштаклыклары өчен вөҗдан газабы кичерәме, йокларга яткач төннәр буе бер ягыннан икенче ягына әйләнә-әйләнә уйлар, газаплар, үкенү, хәсрәт-офтанулар диңгезендә йөзәме? Юк, билгеле. Аның өчен җебен тартып хәрәкәткә китерелә торган тере курчак түгел, кеше булырга кирәк шул...

## 3

Кайчандыр студент Володя Ульянов сөргендә булган Кокушкино авылы янәшәсендәге Үшнә балык хуҗалыгы Татарстанда һәм аңа күрше республикаларда балык үстерү белән шөгыльләнүче колхоз һәм совхозларны ел саен миллионлаган маймычлар белән тәэмин итә. Анда бер үк зурлыктагы ясалма күлләрдә табан, сазан, киң маңгай балыкларының маймычлары үрчетелә. Ул маймычларны сату балык хуҗалыгына ел саен мул акча кереме бирә. Нәселгә калдырылган табан һәм сазан балыкларының кайберләре ундүртәр килограмм тарта. Аларны хуҗалыкта эшләүче ихтиологлар даими барлап-тикшереп торалар. Ана һәм ата балыклар бер-берләреннән аерым асрала. Аларның җенесләре саңакларының шома яки кытыршылыгына карап, яшьләре тәңкәләрдәге сырлар буенча билгеләнә. Үзенә бер аерым сихри экзотик дөнья ул Үшнә балык хуҗалыгы. Мин анда, җәйгә кергәч, яңгырсыз көннәрдә атна саен бармый калмыйм. Эшем чабуымнан тотмаганда, редакциябезгә Питрәчнең күршесендәге Күн авылыннан көн дә килеп эшләүче корректорыбыз Тажи Галимовның велосипедына атланып, Үшнәгә элдерәм. Мин анда җилләп кайтырга, балыкларның ясалма күл ярына синең килеп басуыңны күреп, җим теләнепме, кызыксынышмы, ябырылып мыжгуларын күзәтергә барам. Кулымны суга тыгуым була, балыклар шундук йомшак иреннәре белән бармакларымны кытыклый башлыйлар. Бу, бәлки, аларның: табигатькә, тереклек ияләренә ваемсыз булмагыз, саклагыз безне, Җир шарына янаган экологик һәлакәткә юл куймаска өлешегезне кертегез, дип ялваруларыдыр, кем белә?..

Бүген, шактый вакыт Үшнәдә булып, редакциягә кайтуыма, велосипед хуҗасы, хәйләкәр елмаеп:

— Сөенчегә бер ярты синнән, агайне,— диде.

Гаҗәпләндем.

— Нәрсәгә сөенергә тиеш мин, Тажи дус?

— Нигә сөенәсеңне күңелең сизмимени?

— Сизми, сузма, әйт, ярты инде кесәңдә дип исәплә.

— Хатының килде.

Оля килгән... Аркамнан, гүя, салкын тараканнар чабышып узды. Өнсез калдым.

— Күптән килдеме? Кайда, редакциядәме ул? — дидем телемне чак әйләндереп.

— Син моннан каядыр китү белән килде. Монда түгел, Питрәч белән танышып йөри бугай әле. Кайтмадымы, дип инде ике-өч тапкыр кереп белеште.

Җәнҗал чыгарырга, мине мәсхәрәгә калдырырга килгән Оля Питрәчкә. Монда эшләвемне кем әйтте икән аңа? Хәер, монысы бу кадәр мөһиммени? Өлкә газеталарында, «Чаян» журналында ара-тирә мәкаләләрем чыга, яшеренеп яшәмим бит... Аның белән ничек тә монда — редакциядә очрашмаска кирәк, аңардан теләсә нинди этлек көтәргә мөмкин. Нинди уй белән килде икән ул Питрәчкә? Гривки дамбасында арабызда яңадан бернинди бәйләнеш-аралашу да булмаслыгын төшенерлек иткән идем бугай аңа югыйсә. Юк, килүе тикмәгә түгел Оляның, түгел...

Эшкә кулым бармады, балык хуҗалыгыннан кайтканда табигатьне саклау турында мәкалә язарга ниятләгән идем, аны язуны иртәгә калдырып, хезмәттәшем Кәтибә ханымнан уртак эшебезне бүгенгә ялгызы гына башкара торуын үтенгәч, фатирыма кайтып киттем.

Ни гаҗәп, һава бозылырга чамалый, күрәсең, көн сүрәнләнгән, җил чыккан, күктә болыт өемнәре пәйда булган. Мин Үшмәдән кайтканда көн искиткеч матур, тын иде. Аз гына арада ул нәкъ минем кәефем кебек капыл үзгәргән... Алда мине нәрсә көтә, нәрсә?.. Эреле-ваклы күңелсезлекләр мине гомерем буе борчырлар, ээрлекләрләр микәнни шулай?..

Төрмә һәм колонияләрдә вакытта мин еш кына иреккә чыккач урманчы булу, карурманда кешеләрдән читтә тик җанварлар арасында гына яшәү, беркем белән дә аралашмау турында хыялланa идем. Көннәрем тыныч, тәшвиш-борчылуларсыз үтсә, башка берни дә кирәк булмас, җанварлар кеше түгел, кыерсытмаслар, алар арасында гамьсез генә гомер кичерермен кебек иде. Тоткынлыкта бер мин генә түгел, бик күпләр тормышка ашмас шундый хыяллардан тәм табып, иреккә чыккач, йә көтүче, йә каравылчы, йә урманчы, йә берәр зур елгада маякчы, йә бакчачы булырга, фани дөньядан мөмкин кадәр ераклашырга, кешеләр белән бик сирәк алыш-биреш итәргә хыяллана иде. Хыял нинди генә матур, татлы, мавыктыргыч булса да, тормыш, чынбарлык, гадәттә, көткәннән ачы, кырыс. Язмышым ирек яулавымның тәүге сәгатьләреннән үк үтәсе сукмакларыма киртә арты киртәләр сала, мине кайта-кайтаныклыкта, түземлелектә, сабырлыкта сыный башлады. Халыкта, бәла аяк астыннан чыга, дигән тәгъбир бар. Ярдәмчел, киң күңелле, беркатлы, эчкерсез булып күренгән Оляның асылды мегера — миһербансыз зат булуы гамемә дә кермәде бит. Аны кемдер элек шундый пырдымсыз, дуамал, холыксыз дисә, мин аның шундук якасына ябышыр идем. Кем белгән Оляның игелекле, шәфкатьле бәндәдән шушы көн кебек кинәт үзгәрәсен...

Фатирыма кайтып кергәндә, хуҗабикәм Марийша түти белән Оля зур бүлмәдә өстәл янында гәп куерталар иде.

Чакырылмаган кунакның тору урынымны эзләп табуына гаҗәпләнмәдем, аның шулай буласы табигый иде.

— Исәнмесез, — дип, үз бүлмәмә үттем.

Оля шундук атылып янымa керде.

— Иркуша, мин бит бу, әллә танымадыңмы? Минем килүемә шат түгел кебек син?

— Нигә шатланырга тиеш мин?

— Беләсеңме, бик-бик сагындым сине, Иркушам. Минем синнән дә якын беркемем дә юк бит, гаебем булса, зинһар, гафу ит мине.

— Куй, Оля, түбәнсетмә үзеңне.

Кунакның күзләреннән яшь бәреп чыкты. Күрәлмим күз яшен, ул җанымны кыйный, рухымны изә, күңелемне тетрәтә. Үзгәргән Оля, күпкә үзгәргән. Олыгайган, ябыккан, күз төпләрендә, ирен читләрендә җыерчык сызыклары беленә башлаган, карашында сагаю, басынкылык, кыюсызлык сиземләнә.

— Мин монда укытырга киләм. Алексеевскидан киттем. Роного кереп сөйләштем, Питрәчнең үзендә үк урын бар, алырга биш куллап ризалар. Безгә кушылырга берни дә комачауламый хәзер. Син инде теге вакыттагы шикелле үз шәүләңнән дә өркә торган, ярдәмгә мохтаҗ мескен түгел, дипломың бар, максатыңа ирештең, эшлисең. Гөрләтеп яши башлыйк, мин шуңа килдем.

— Булмый, Оля, мин Питрәчтән китәм. Син кил, миңа карама.

— Кая китәсең?

— Әлегә билгесез, бераз ял итәргә телим. Сиңа барыбер түгелмени?

— Түгел. Син — минем ирем.

— Кәгазьдә — ирең. Бәхеткә, ул тик кәгазьдә генә.

— Хәзер безгә бергә кушылырга, бер гаиләгә берләшүебезне чынбарлыкка әверелдерергә нәрсә комачаулый?

— Холык-фигыльләребезнең төрлелеге, Оля. Миндә сиңа бернинди җылы хис тә, тойгы да, хәтта инде хөрмәт тә юк. Өзелгән бауны ялгагач, төен кала.

Оляның кашлары җыерылды.

— Бу актык сүзеңме?

— Актык, җанкисәгем. Үзеңне дә, мине дә газаплама син. Без бергә була алмыйбыз. Мин гаилә тормышымның төенсез булуын телим.

Оля, күзләрен мөлдерәтеп, миңа текәлде. Бу минутта аның кыяфәте гаҗиз, аяныч иде. Шулай бер-беребезгә карап байтак басып тордык. Аннары кунагым, нииндидер карарга килеп, редикюленнән кульъяулыгы алып күзләрен тиз-тиз сөртте дә:

— Нигә соң син минем белән аерылышмыйсың? — диде.

— Безнең кушылганыбыз юк ич, кушылмаган кешеләр ничек аерылыша алалар?

— Без — деюра ир белән хатын.

— Ә дефакто? Мин кем беләндер тормыш корырга җыенмыйм, сиңа аерылышуыбыз кирәк икән, мин каршы түгел. Бу очракта җиде кат үлчәп торасы юк.

— Мин аерылышуыбыз турында судта эш кузгатам, алайса...

— Кузгат.

— Кая, үбим сине соңгы тапкыр...

— Кирәкми, Оля.

— Озат мине, алайса. Автобус моннан Казанга ничәдә китә?

Кунагымның бернинди йөге дә юк иде, без, автобус тукталышына җиткәнче, сөйләшми тын гына бардык. Автобуска кертеп утырткач, Оля:

— Ирек, ачуланма миңа, мин сине яратам бит, яратам, — диде, йөзен читкә борып.

— Үпкәләмә миңа, Оля, без бер-беребезгә пар түгел, хуш, — дип, мин автобустан чыктым...

Бераздан автобус кузгалып китте һәм аның артыннан ук коеп яңгыр яварга кереште.

## Тугызынчы бүлек

### 1

Оляның Питрәч урамнарында калдырган эзләрен, мине тынычландырырга теләгәндәй, көчле яңгыр юды. Гүя, көн бары шуның өчен генә махсус бозылган иде. Ул иркә сабый күк азга гына көйсезләнеп алды да, кичкә аязып, янә купшыланды.

Оля, киткәндә, күңелемдәге тирән яраларны кабат әрнетеп, бөтен тынычлыгымны үзенә ияртте шикелле. Йөрәгем авыртып сыкрый. Онытылырга, берни турында да уйламаска тырышам, булмый. Мин урыным-

да бүлмәм тәрәзәсе аша караңгы күктә җемелдәгән йолдызларга карап ятам. Бәлки, аларның кайсындадыр минем кебек берәү йоклый алмый газапланадыр... Хуҗабикәм Марийша түтинең мич башыннан иплә генә гырлаганы ишетелә. Ул бөтен ел әйләнәсендә төннәрен шул сәкле мич башында үткәрә. Идән астында базда нәрсәләр сак кына кыштырдый. Тычкан, ахры. Аңа, төнлә эч пошырмаса, көн житми микәнни?.. Күз алдыма кинәт ни өчендер сугышның соңгы елында Германиядә күргән җимерек немец шәһәрләре, ярым хәрәбә йортлар, ул йортларның исән калган фатирларында кемнәр тарафыннандыр актарылып идәнгә чәчелгән кием-салымнар, урын-җир әйберләре, бала уенчыклары, төрле музыка кораллары, савыт-саба, китаплар, чит телдәге газета-журналлар, кәгазьләр килә. Шулчак ирексездән үземнең абзар кебек иркен, тик шыксыз бүлмәм эченә күз йөртәм. Караңгыда берни күрмим, әлбәттә. Әмма, күрмәсәм дә, тирәмдәге котсызлыкны ап-ачык тоям. Тормышым да фатирыма тәңгәл минем. Көн саен бер үк нәрсә, һәр туган иртәмнең кичәгем төсле үк эчпошыргыч буласын, һичнинди үзгәрешсез киләсен белеп торам. Инде менә дүртенче дистәне ваклый башладым, ә нәрсәгә ирештем әле? Берничә ирешмәдем һәм, ышанам, ирешмәячәкмен дә. Шуңадыр яшәүдән, үз-үземнән тәмам туйдым, кайдадыр укыдыммы, кемнәндер ишеткән идемме, хәтерләмим, кеше кырыкка кадәр үз-үзен тапмаса, кырыктан узгач, тапмый да тапмый, имеш. Берәүләрнең бәхетсезлеге икенче берәүләрне куандыра. Нигә алай? Мин аны берничек тә аңлый алмыйм. Шуңа рухи газабымны тирәмдәгеләргә сиздермәскә, яшерергә тырышырга кирәк дип саныйм. Дөньяны газап-интегүләр түгел, мәрхәмәт, игелеклелек, шәфкать, миһербанлылык бизи бит. Газапмихнәтләрне үзенә нинди генә кыен шартларда да, тешләрне кысып, әйләнәндәгеләргә сиздермәскә тырышу хәерле. Тормыш тоткасы — рәхимлелек. Ләкин аны күреп тә, капшап та булмый. Аны сиземләр өчен үзең дә рәхим-шәфкатькә ия булу кирәк. Без еш кына кемнеңдер хәленә керергә тырышабыз. Хәтта кемнеңдер кайгысын уртаклашканда бераз яшь сыгарга да сәләтлебез. Әмма бу ихлас күңелдән эшләнми, хәсрәт сөременнән читкә борылу белән аны онытабыз.

Шулай итеп төн артта калды. Иртән хуҗабикәм:

— Син бүген төне буе аз гына да черем итмәден бугай? — диде.

— Каян чыгып әйтәсез аны, Марийша түти, әллә сезгә йокы бирмәдемме? — дидем.

— Миңа комачауламадың комачаулавын. Бер ягыңнан икенче ягыңа әйләнә-әйләнә караватың пружиннарын туктаусыз ыңгыраштырганына әйтәм.

Мич башында хуҗабикәм иплә генә гырлаган иде, димәк, йокламый да гырлап була икән...

— Сезне инде алай күп тынычсызламам, Марийша түти, Питрәчтән мин китәргә җыенам.

— Кая китәсең, Оляң янынамы? Ул үзе монда киләм дип утырды ич миңа кичә.

— Оля белән минем бернинди бәйләнешем дә булуы мөмкин түгел, Марийша түти. Ул теләсә нишләсен. Без аның белән ир һәм хатын була алмыйбыз. Миңа тормышымда җан тынычлыгы кирәк.

— Тиледән туры хәбәр, диләр. Миңа да ошамады Оляң, улым. Улым, диюемә ачуланма, син үз балам күк хәзер миңа. Оляң үтә шикчел, көнчел, тик үзен генә ярата, үзен генә хаклы саный торган кеше булып күренде. Миннән синең турыңда, хөкем залындагы судья күк җентекләп, бәйнә-бәйнә сорашты. Нинди хатыннар белән бәйләнеш тота, куңарга көн дә кайтамы, янына кемнәр килеп йөри, дип төпченеп теңкәмә тиде. Чәчләреңне аның чәчләре белән бәйләмәвең хәерле синең. Ул ирәнә көн күрсәтмәячәк. Китсәң дә ташлап бетермә мине, кайчан теләсәң, шул чакта әниең янына кайткан күк кайт монда. Бәлки, китмәссең дә әле. Кичә дәҗҗалың килгәнче ул уең юк иде бугай бит?

— Бар иде, Марийша түти, Оляның бернинди дә катнашы юк аңа. Мин башта берәр яры барып ял итеп кайтырга уйлыйм. Аннары, кем әйтмешли, алдагысы аллада.

— Кайчанрак китәм дисең соң ялыңа?

— Атна-ун көннән.

— Янә убырлы карчык күк берүзем калырыма күп түгел икән инде,— дип, авыр сулады хуҗабикәм.

— Күңелегезне төшермәгез, Марийша түти. Мин киткәч кемне дә булса тагын фатирга кертерсез, ялгыз булмассыз,— дип тынычландырырга тырыштым аны.

## 2

Эшкә барырга чыккач, урамда редакторыбыз Николай Ильич Маловка тап булдым. Безнең фатирларыбыз бер-берләренә орынып диярлек торсалар да, эшкә барганда да, эштән кайтканда да ничектер очрашмый идек. Редакторым, мине күтәп алып, кул бирде.

— Очрашуыбыз яхшы булды әле,— дип, сүз башлады ул.— Яңа гына райкомнан шалтыраттылар, бүген районга Брест каһарманы Гаврилов кайта икән. Мин сезгә ул мөхтәрәм якташыбыз турында газетабызга материал әзерләүне йөкләргә булдым.

— Аны миңа түгел, иптәшләрнең берәрсенә кушыгыз, Николай Ильич. Минем турыдан бәрергә яратканымны беләсез, язганым тагын Антон Егоровичка ошамас. Нервларын кузгатмыйк аның,— дип, каршы килдем.

— Зарар юк, материалыгыз объектив булса, аның кәефе кырылмас һәм аңа дуларга сәбәп тә чыкмас.

— Материалымда мин районыбыз җитәкчеләренең Петр Михайловичны туган төбәген ташлап китәргә мәҗбүр итүләрен, аларның сугышның башында ук авыр яраланып фашистларга әсир төшкән каһарманны монда төрлечә мәсхәрәләүләрен телгә алмый калмаячакмын бит.

— Очрашу вакытында Петр Михайлович аларны үзе искә төшерсә, материалыгызга кертерсез ул хәлләрне, «онытса» сез дә яңартып тормассыз.

— Булды, килештек.

Көн матур иде. Герой белән очрашырга район культура йорты янына Питрәчнең үзеннән һәм аңа якын тирә-күрше авыллардан меңнән артык кеше җыйналды. Кадерле кунак республикабызда тик партия өлкә комитетының иң зур түрәләре генә утырып йөри торган кара машинада кайтып төште. Аңа үз машиналарында Татарстан хәрби комиссариаты вәкилләре һәм унлаган газета хәбәрчеләре дә ияреп килгәннәр иде. Райондашлары Геройны бәйрәмчә киенеп, кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре һәм ипи-тоз белән каршыладылар. Менә машинадан урта буйлы, хәрби киемле, түшендә Алтын йолдыз медале һәм ике Ленин ордены балкыган кеше төште. Культура йорты янына җыйналган кешеләр аны алкышка күмделәр. Вахитов исемендәге колхозның алдынгы терлекчесе Хезмәт Кызыл байрагы ордены кавалеры Минзифа Галимуллина, Герой якташына түбәнчелек белән баш иеп, чигүле сөлгедә ипи-тоз тәкъдим итте. Кунак ипине сул кулы белән бер кабарлык сындырып, тозга манып, бер уртлады. Шундук аның күзләре яшькә чыланды. Ул үтә дулкынланган иде.

— Петр Михайлович, үзегезне әллә начар хис итәсезме?— дип, аның янына район советы башкарма комитеты председателе Трусов килеп басты.

— Борчылмагыз, Сергей Васильевич, әйбәт сизәм мин үземне. Тик менә иң кысен чакта тәвәккәлләп үземә хет бер чиләк бәрәңге язып

бирүегезне теләнеп килгәч, сезнең: «Ашарыңа син бездән түгел, фашистларыннан сора, Гитлер көчеге»,— дип кабинетыгыздан мәсхәрәләп куып чыгарганыгыз исемә төште. Шуна күзләрем чыланды. Зарар юк, борчылмагыз, кибәр күз яшем. Ул чакта да мин шушы ук Гаврилов идем югыйсә, тик түшемдә бу орденнар белән Алтын йолдыз гына юк иде. Монда халык минем түшемә тагылган дәүләт бүләкләренме, әллә минеме каршылый, төшенә алмыйм. Төшендерегез әле шуны мин тинтәккә, Сергей Васильевич...

— Халык сезне каршылый, Петр Михайлович, сезне...

...1956 елның урталарында күренекле урыс язучысы Сергей Смирновның «Брест крепосте» исемле китабы чыкты. Кешеләр аны китапханәләрдә чират торып алып укыдылар. «Брест крепосте» Бөек Ватан сугышы башында беренче булып дошманга кискен каршылык күрсәткән совет сугышчыларының дәһшәтле язмышларын бернинди купайту, уйдырмаларсыз һәм чачаклы бизәкләүләрсез сурәтләгән тәүге гадел һәм кырыс китап иде. Әдип Брест крепостен фашист яуларыннан батырларча саклауны оештырган фидакарь совет офицерлары арасыннан Татарстанның Питрәч районындагы Әлбәден авылында туып үскән полк командиры майор Петр Михайлович Гаврилов турында аеруча сокланып язган иде. Шуннан соң озакламый Петр Михайловичка Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Ул легендар Брест крепостен саклауда тере калкан булучылардан исән калган бердәнбер Герой офицер иде. СССР Югары Советы Президиумының Гавриловка Герой исеме бирү турындагы Указын радиодан тапшыргач, газетабызга каһарман якташыбыз турында материал әзерләп кайтырга дип, мин Әлбәденгә бардым. Ул авылда аңа кадәр берничә тапкыр булсам да, Петр Михайлович Гаврилов турында берни дә ишеткәнем юк иде. Сораштыра торгач, Геройның бик яшьтән ятим калып, балалык һәм үсмер елларында җәйләрен авылларында көтү көтеп үткәрүен, кышка кергәч байларга тамак хакына көнлекчелеккә йөргәнен, гражданнар сугышы чорында Кызыл Армиягә язылып, Әлбәденнән киткәнен һәм анда калган бердәнбер сеңлесе янына сирәк кенә кайткалаганын белдем.

— Шул үзе теләп Армиягә киткәненнән соң авылыгызга озакка кайтканы булмадымыни?— дип кызыксындым мин.

— Сугыштан соң берничә ел кайтып торды ул Әлбәдендә. Кырык яра алган, пленда булган, хатынын, улын югалткан, аксаклап көчкә йөри, уң кулы бөтенләй гарип иде. Аңа матди ярдәм күрсәтүче булмады, сугыштан соң, исән-имин кешеләргә дә, беләсездер, үтә авыр иде. Петр Михайлович теркелдәп, уфалла арбасын көчкә тартып, ике көнгә бер урманга утынга бара иде. Авылыбызда да, районда да аңа, пленда булганы өчен, син Гитлер эте, фашистлар ялчысы, дип игелек күрсәтмәделәр. Хәле бик мөшкелләшкәч, ул авылдан китте. Сугыштагы батырлыклары өчен Герой исеменә лаек булырын кем белгән аның ул чакта? Петр Михайлович үтә инсафлы, сабыр, тыйнак һәм түзем бит. Сугышта ниләр эшләгәнен, нинди кыенлыклар кичергәнен берәүгә дә сөйләмәде. Аның Герой икәне төшебезгә дә кермәде. Искиткеч тотнаклы, әдәпле кеше ул Петр Михайлович. Җәрәхәтле күңеленә, кыйналган җанына җылы эзләп туган туфрагына кайтты, без аны ярдәм кулы сузмыйча мәсхәрәләп арабыздан кудык. Һичкайчан кичермәслек хата, юк, хата түгел, чын җинаять бу!..— диде миңа, намусның әле нәрсә икәнен онытмаган бер авылдашы, сызланып.

Питрәчкә Герой якташыбызның кайту тантанасы истәлекле сәхифә булып күңелләргә уелды. Петр Михайлович халык алдында тәкәллефле, җылы чыгыш ясады, трибуна артыннан районлашларын кызыксындырган бик күп сорауларга җаваплар бирде. Аннары туган авылында кунак булды. Кокушкинода, Апакай авылында яшәүче Советлар Союзы Герое Галимҗан Камалиев белән күрешеп сөйләште.

3

Район газетасында өч елга якын эшләү дәверемдә мин берәү белән дә әшнәләшмәдем. Хезмәттәшләремнең һәркайсының минекенә охшамаган үз үткәне, үз дөньясы, үз офыгы, минем исә аларның барысыннан да аермалы үз үткәнем, үз дөньям, үз бүгенем иде. Хезмәттәш иптәшләремнең күбесе аралашырга атлыгып тормавымны өнәмәделәр. Алар белән якынлашмавыма эчмәвем дә комачаулады, әлбәттә. Кыскасы, мин Питрәчтә иптәшләрем арасында үз кеше була алмадым. Язган һәр мәкаләмне диярлек райкомның игътибардан читтә калдырмавы да, район колхозларындагы башбаштаклыклар турында «Чаян» журналында чыккан «борычлы» язмаларым да хезмәттәшләремне үземнән ераклаштырырга сәбәп булды шикелле. Алар мине баш әйләнгеч биеклектә тартылган тимерчыбык аркан өстендә биюче акробат кебегрәк итеп күзаллыйлар иде бугай. Ул чыбыкка янәшәмдә биергә менәргә тәвәккәлләүче табылмады. Әйдә, биектән мәтәлеп төшеп муенын сындырса, безгә түгел, үзенә үпкәләр, диделәр, күрәсең. Инде килеп, үткәнемдә минем биш елга якын халык дошманы исәпләнеп, тоткынлык шулпасы чөмерүем дә аларны сагайтырга мәҗбүр иткәндер. Безнең илдә кешене гел юкка гына кулга алалармы, аның гаебе булмый калмагандыр, ул аны әйтеп кенә бетерми, утсыз төтен каян килсен, дип шикләнделәр шикелле.

Питрәчтә минем бердәнбер үземә ошаган һәм күзгә күренгән эшем редакция һәм типография биналарын салуны башлап йөрү һәм аларны озакка сузмый торгызу булды. Бу эштә миңа райком да нык булышты. Әмма Казанда редакция һәм типография биналарын салырга проект эшләтү, ул биналарны төзетү, осталар табу тулысы белән минем өскә төште. Редакторыбыз Николай Ильич, син бу эшне, Сабирыч, үзең башлап җибәрдең, үзең үк очлап чыгып ахырына җиткер инде, дип, тулысы белән минем өскә аударды. Дөрес, төзелешкә кирәкле материаллар кайтартырга колхоз һәм совхозлардан транспорт юллауны ул үз өстенә алды.

Июнь башында редакциябез һәм типографиябез кышларын күпме яксаң да җылынмый торган чиркәүдән махсус проект буенча төзелгән яңа бинага күчкәч, без барыбыз да җиңел суладык. Төзелеш мәшәкатьләре артта калды, эш шартларыбыз чагыштыргысыз яхшырды, барыбызның да аерым бүлмәләребез булды.

## Унынчы бүлек

1

Кичә ялга чыктым. Көньякка барам, эшкә Питрәчкә яңадан кайтмаска уйлыйм. Редакция белән исәп-хисабымны әле өзмәдем өзүен. Аны эшләү кайчан да соң булмас дим. Китүемә берәү дә каршы төшмәс кебек. Бүген төне буе йокламый шуны уйлап яттым. Аннары таң белән урынымнан торып, гадәтемчә, Мишә буена йөрергә чыктым. Офыкта йөрәкне җилкетеп ал нурлар уйный, елга аръягындагы болынны сыек томан каплаган, болын күкрәгендәге печән кибәннәре томанда сөт эчендә йөзәләр төсле. Аларның итәкләре күренми, очлы түбәләре генә төсмерләнә. Кибәннәр артында урман эчендә чүнник. Зәйнәп хәзер андамы, әллә өнендәме икән?.. Хәтеремдә Питрәчкә килгәч тә, Мишә тугаена кармак салырга чыккач, Зәйнәп белән тәүге очрашуым, аның белән хуҗабикәмнең печәнлегендә сөйләшеп төн үткәрүем, аның үбүе яңарды. Кеше буларак та, башка күп яклары белән дә алтын бәясе хатын бит ул. Мин аны урынсызга үземнән читләштердем. Ул минем

янымa ялгызлыктан, жанын кыйнаган бертөрлелектән качарга, теләктәшлек табарга өметләнеп һәм азга гына булса да күңеленә жылы эзләп килгән иде бит. Мин, әкәм-төкәм сыман, үз кабыгыма яшеренүне яхшырак күрдем. Баштарак миңа ул әле жан өрергә, иптәш булырга, мәрткә киткән хисләремне уятырга тырышып карады. Ләкин минем кыймылдарга да теләгем юклыкны, йөрәгемдәге боз кантарының эри башлавыннан шүрләвемне күреп кул селтәде. Ә миңа тик шул гына кирәк тә иде. Арабызда очрашканда бер-беребезгә сүзсез генә баш кагып узудан бүтән нәрсә калмады. Бәлки, мина, моннан киткәнче, аңардан гафу үтенергә барыргадыр?.. Бармыйм, ул үземнең дә, аның да күңелен кузгату гына булыр. Ничек булды, шулай калсын. Кемне дә бәхетле итәрлек хатын ул. Нигә үз бәхетемнән үзем үк качам мин? Инде дүртенче дистәмне ваклый башладым, әле һаман гаиләм дә, үз куышым да, күңелем яткан шөгылем дә юк. Мәшәкатьләрне мин һаман иртәгә калдыра киләм. Кем белә, бәлки акылым камил түгелдер?..

Алда әйткәнемчә, ялымны көньякта, диңгез буенда үткәрергә булдым. Кешеләрдән Кырым, Кавказ турында күп ишеткәнем бар, китаплардан да укып беләм. Көньякта ял иткәннәр аеруча диңгезне мактыйлар. Нигә миңа да күреп кайтмаска кешеләр авыз суларын корытып мактаган жирдәге жәннәтне, дидем үземә, Питрәчтән Казанга килгәч. Казанда калсам, ялым барыбер ял булмас, ни фатирым, ни баш куяр урыным юк, саф һава сулап диңгезне күреп кайтыйм булмаса... Туры кая барырга, дип башымны тинтерәтмәдем, поездга билетны кая жиңелрәк алып булса, шунда юл тотармын, дидем. Кырымга барырмын, бәлки, Севастопольны, Ялтаны, Бакчасарайны, Балаклаваны, Аюдагны күрермен, кан кардәшләребез Кырым татарлары күп гасырлар дәвамында яшәгән урыннарны тамаша кылырмын... Берәү кассага берсекөнгә Казаннан Евпаториягә китәсе поездга алган билетын ничек тапшырырга белми каударланып йөри иде, сатып алдым шунын билетын. Ә ул билетның язмышымны кинәт йөз сиксән градуска борып куясы уема да кермәде. Көньякка китәсе көнемә кадәрге вакытым ял өчен кирәкле әйберләр алуга, юлда ашарга вак-төяк юнәтүгә китте. Ниһаять, чемоданымны күтәреп, тимер юл вокзалына килдем. Әллә ялга барам, әллә командировкага, күңелем йолкынмый, тыныч иде. Менә радиодан Казан-Евпатория поездына утырту башлануны белдерделәр. Мин ашыкмый гына, анекдоттагы теге ваемсыз чуваш сыман, «пилит кесәмдә, соңка калсам та поез минсез китә алмый», дигән төсле, билетта күрсәтелгән вагонга юнәлдем. Менә ул сигезенче вагон. Аның ишеге төбенә пассажирлар һәм аларны озата килүчеләр жыйналган.

Төркемдәге хатын-кызларның берсе миңа:

— Исәнмесез, Ирек. Ни хәлләр? Ай күрде, кояш алды сезне теге вакытта, юкка чыктыгыз. Үзегез каядыр юл тотасызмы, кемнедер озатырга килдегезме монда? — диде.

Чү, Кабан күле буенда яшәүче, шәп фатирлы медицина фәннәре кандидаты ич бу!..

— Исәнмесез, Мөнирә туташ. Югалмадым, Питрәчтә мин. Берәүне дә озатмыйм, үземнең Кырымга ялга барышым.

— Урыныгыз шушы вагондамы?

— Шушында.

— Юлдашлар икәнбез. Мин чиксез шат сезне очратуыма.

— Мин дә шат, Мөнирә туташ.

Безнең урыннарыбыз да, алдан сөйләшенгән кебек, бер үк купеда булып чыкты. Тагын ике урынга Харьковка баручы кызлар урнашты.

Кайларда һәм ничек кенә бер-берләре белән очрашмый кешеләр! Теге тәүге очрашудан соң аз гына да үзгәрмәгән кебек Мөнирә. Шул ук тыйнак уйчанлык, шул ук гөнаһсыз караш, шул ук ирен читләре белән генә сизелер-сизелмәс елмаю. Мине очраткач ул ничектер югалып калды кебек. Тормышында әле бернинди дә үзгәреш булмаганга ошый. Үз-

төреш булса, ялгызы бармас иде көньякка. Үзен туташ диюемә дә каршы килмәде.

— Ник мина бүтән юлыгыз төшмәде, Ирек?

— Вакыт тимәде, уңайсызландым да. Башта укып һәм эшләп йөрелде, аннары Казаннан киттем, Питрәчтә эшләдем.

— Мин сезне гел искә төшердем. Рәйсәдән, очрашканда, сезнең турыда сораша идем.

— Рәхмәт.

— Матбугатта чыккан әйберләрегезне Салих җыеп бара, аларны укыдым... Путевкагыз кайчаннан башлана сезнең?

— Путевкам юк минем. Кырымда «кыргый» хәлдә күпме теләсәм шулкадәр калырга исәбем. Ә сез?

— Минем Евпаториядә дус кызым яши, шуның янына кунакка барам.

Мин көнләшеп куйдым.

— Сез бәхетле кеше, Мөнирә туташ.

Юлдашымны бу сүзләр сагайтты. Ул:

— Көлүегезме бу? Әйткәнегезне ничек аңларга?— диде, үпкәле тавыш белән.

— Көлмим, нигә көлим. Теге яки бу нәрсәгә һәркем үзенчә бәя бирә бит, шул гына. Бәхетне без икебез ике төрле аңлыйбыз булыр.

— Ялгызлыктан, үз-үземнән туеп, бераз онытылып тормаммы, дип барам мин Кырымга. Ә сез мине бәхетле дисез. Эһ, Ирек, Ирек...

Мөнирә белән без бөркү вагонда юлда барганда өч тәүлек буена күп нәрсәләр турында сөйләштек. Евпаториягә барып җиткәндә бер-беребезгә тәмам ияләшкән, күнеккән идек инде. Евпатория вокзалында Мөнирәне дус кызы каршылады. Ул ачык йөзле, теле азга гына да тик тормый торган такылдык ханым иде, мине дә вокзалда ялгызымны калдырмады, үзләренә ияртте.

— Казан кешеләре миңа туганнарым күк, әйдәгез, әйдә, карышмагыз. Мөнирәнең хет кайда тукталганын белерсез. Юлда талашмагансыздыр, шәт, үзара. Теләсәгез, бездә үк тукталырсыз. Теләмәсәгез, мин сезгә фатир табарга булышырмын. Буш кеше түгел мин монда, врач әсәре, мондагы кешеләрнең яхшыларын да, яманнарын да беләм, авыр хәлгә куймам, курыкмагыз. Үземдә үк тә торырга мөмкин. Мин көне буе эштә, ирем Атлантикада балык тота, өем буш. Миндә тукталсагыз, Мөнирәгә дә күңеллерәк булыр, бергә ял итәрсез,— дип тезеп китте.

Гайшә ханым, аларга кайтып бергәләп ашап-эчкәч, мине беркая да җибәрмәде.

— Менә сезгә ябык веранда, түләү-фәлән сорамыйм, торыгыз. Ирем җәһәннәм артына олагып, романтика эзләп йөргәндә, фатирыма хет ир-ат исе керер. Алтышар ай өйдә булмый ул. Кайтып атна-ун көн тора да, монда миңа иркенлек юк, дип, янә сәфәргә әзерләнә башлый. Инде күптән үз телебездә сөйләшергә зар-интизар идем, менә сезнең икегез белән татарча сөйләшеп ләззәтләнермен...

Көн кызуы басылгач, Гайшә ханым Мөнирә белән мине Евпатория белән таныштырырга алып чыкты. Ахирәтләр бер-берләрен сагынганнар иде, күрәсең, туктаусыз гәп куерттылар, аларның сөйләшүләренә комачауламыйм дип, мин берничә адым арткарак калып атладым. Евпатория — гадәти шәһәр. Урамнарында автотуристлар машиналарын кирәккә дә, кирәкмәскә дә туктаусыз кычкырталар. Гудоклар тыелулы зур шәһәрләрдән соң алар монда үзләрен чикләүне кирәк санамыйлар шикелле. Тротуарларда курортка килүчеләр арлы-бирле тулгана. Аларның барысының да башларында читләре чачаклы йомшак пляж эшләпәсе, күзләрен ялтыравыклы кара күзлек каплаган, күбесенең кояшта тиресе купшыган борыннарына кәгазь ябыштырылган. Ул кешеләр кай яклары беләндер дәү чикерткәләргә охшыйлар. Шунысы гаҗәпләндерде: әбиләр яшенә җитеп килгән бичәләрне алардан егерме-утыз яшь кече ирләр

култыклаган иде. Моны мин, һәр төбәкнең үз тәртибе, күрәсең, дип кабул иттем.

Евпаториянең үзәге миңа ярыйсы ук төзек һәм чиста төсле күренде. Анда күбрәк диңгез кабырчыгыннан салынып акка буялган кибетләр, ашханәләр, төрле дәүләт учреждениеләре, санаторийлар, кинотеатр, музей урнашкан булып чыкты. Диңгезгә якынлашкан саен өйләр кечерәя барды. Алар бер-берләренә орынып диярлек салынганнар иде. Һәр йорт алдында бакча бар, аларда озын торыклы үтә жете чәчәкләр утыртылган. Ул чәчәкләр, үзләренә иркенлек сораган төсле, башларын урамга сузганнар. Агачлардан кипарислар, сәрби куаклары, магнолияләр күп очрый.

Урам сулга борылып сөзәкләнгәч, куе сәрби агачлары арасыннан диңгез күренде. Башта ул тар гына сызык булып төсмерләнде, аннары киңәйгәннән-киңәя барып, караш иңли алмастай иркен дәрьяга әверелде. Минем ирексездән сулышым кысылып, йөрәгем тибүдән тукталгандай булды. Диңгезнең мин башта нинди төстә икәнен шәйли алмый тордым. Ул куе яшел дә, ачык зәңгәр дә кебек иде. Бәлки яшькелт-зәңгәр булгандыр, төшенмәдем. Әмма исеме Кара дип аталса да, ул һич тә кара түгел иде.

Вак дулкыннар яр читендәге комга тәгәрәп менәләр дә, өсләрендәге ак күбектән арынып, артка чигенәләр. Күберәк, гәрәбә төсле яр комына сеңеп, мизгел эчендә юкка чыга.

Мин диңгезне тәүге кат күргәнгә, нык сихерләндем. Гайшә ханым, шаяртып:

— Егетебез диңгезгә мөкиббән китеп, безне бөтенләй онытты бугай. Зөмрәт дулкыннар тәмам сихерләгәнче, аңа ярдәм кулы сузыйк. Су кызлары буйдак егетләрне көтеп кенә торалар монда. Без ул кызлардан кай ягыбыз белән ким? Әйдә әле чишеник, карасын башта безгә. Су керик, Ирек, ишетәсезме безне?— диде.

— Ишетәм, Гайшә ханым, бик яхшы ишетәм.

— Ишетсәгез, чишенегез сез дә. Диңгезнең иң җылы чагы хәзер, кереп калыйк.

Юлдашларым, коену костюмнарыннан гына калып, акрын гына ягымлы вак дулкыннар арасына кереп киттеләр. Мин дә өстемне чишенеп, плавкидан гына калгач, дулкыннар кочагына атылдым...

## 2

Диңгез буеннан кайткач, Гайшә ханым кадерле кунагы Мөнирә туташ хөрмәтенә мул табын әзерләде. Анда төрле ризыкнигъмәтләр, тәм-томнар уртасына кукыраеп бер шешә әрмән коньягы да менеп утырды.

— Әйдәгез, әнә ул шешәне ачып мәҗлесебезгә хуҗа булыгыз әле,— диде ул миңа.

Аптырап калдым. Телемне чак әйләндереп:

— Гайшә ханым, гафу итегез, сез йөкләгән бурычны үтәү минем кулымнан килмәс,— дидем.

Мөнирә туташ миңа ярдәмгә килде.

— Тынычлыкта калдыр аны, Гайшә, ул эчми дә, тартмый да.

— Хатыннарны да кочмыймы?— дип, уенчак елмаеп, хуҗабикә миңа төбәлде.

— Хатын-кызлар кочарга аның вакыты булмаган...

— Утызга житепме? Базда гомер кичергәнме әллә ул?

— Базда гомер кичермәгән, аңа Сталин заманында халык дошманы исәпләнеп, баздан хәтәррәк җирләрдә булырга туры килгән.

Гайшә ханымның күзләре дүрт булды. Мин өстәл янынан торып, верандама юнәлдем. Хуҗабикә каршыма чыкты.

— Гафу итегез мин пырдымсызны, Ирек. Чыкмагыз, утырыгыз урыныгызга.— Ул шешәне үзе ачып өстәлдәге өч рюмканың өчесенә дә коньяк салды.— Әйдә, чәркәләрегезне тотыгыз әле, айныганчы, килүегез хөрмәтенә каплыйк бу «агу»ны. Ялыгыз күңелле узсын.

Без рюмкаларыбызны чәкештердек.

Гайшә ханым рюмкасын каплады. Мин рюмканы иреннәремә якын китердем дә өстәлгә куйдым. Мөнирә туташ та уртламады, иснәгәндәй генә итте.

— Әллә син дә монашкага әверелдеңме?— дип гаҗәпләнде моңа хуҗабикә.— Назланма, чибәркәем, эчмәсәң, үпкәлим.

Мөнирә кызарынды.

— Үпкәләмә, Гайшә, инде мин дә ничә ел исерткеч эчемлекләрне авызыма алганым юк. Тартмыйм да.

Хуҗабикә карашын бер миңа, бер Мөнирә туташка күчерде.

— Зиһенем җитми аңларга сезне, бу «агу»ны каплыйк әле диюемнән курыктыгыз, ахры. Ярар, эчмәсәгез эчмәссез, мин кыстый белмим. Әйдә, ашагыз, монда төн озын, ачыгырсыз. Сезнең килүегезгә шатланып бетә алмыйм, рәхмәт икегезгә дә, эштән буш өйгә кайтмам. Ялгызлыктан башымны кая куярга, нишләргә белми идем...

Нигә эчкән, тарткан кеше генә кеше дә, исерткеч эчемлекләрне авызына якын китермәгән, организмын тәмәке төтене белән агулауны кирәк санамаган бәндә чак кына мөртәт исәпләнми бездә? Татар халкы гомер-гомергә эчмәгән дә, тартмаган да бит. Аңа карап деградацияләнмәгән, үз йөзен югалтмаган. Нигә хәзер кая гына барсаң да, иң олы сый булып табын уртасына аракы менеп утыра? Эчү, исерү әхлаксызлыкның иң чирканыч нокталарыннан берсе икәнен аңларга теләмибез без. Хатын-кызлар булып хатын-кызлар да аракыдан ләззәт эзли башлагач, кая барып чыгарбыз без? Бәлки инде барып чыкканбыздыр да? Киләчәктә безне кабат маймылларга әверелеп яңадан агач башларына үрмәләү көтмиме, дип уйладым мин, верандада үземә билгеләнгән урынга яткач, борчылып. Мөнирә туташ молодец, үз-үзен җиңгән — ара-тирә аракы белән шаяруын да, тартуын да ташлаган. Исерткеч эчемлекләрне инде өч ел авызыма якын китергәнем юк, диде ул, никтер кызарынып. Тартмый да икән. Теге вакытта, минем ихтыяр көчем өчле-тугызлы гына, дип үзенә ул яла яккан булган. Димәк, кемнәрдер инанганча, эчү дә, тарту да гомергә төзәлмәслек чир түгел икән...

Гайшә ханым иртән санаториена эшенә китте, өйдә без Мөнирә туташ белән икебез генә калдык. Мин аңардан:

— Бүгенгә сезнең планнарыгыз нинди?— дип кызыксындым.

— Ә сезнең?— диде ул.

— Кичәге кебек пляжка барырга, диңгез белән хозурланырга уйлыйм.

— Мин дә сезгә иярсәм, ачуланмассызмы?

— Киресенчә, шатланырмын гына.

— Пляжга барганчы башта без, базарга чыгып, помидор, кыяр кебек нәрсәләр алып кереп тамак ялгыйк. Сез моңа ничек карыйсыз?

— Мин биш куллап риза, Мөнирә туташ.

— Исемемне «туташ» коерыгын кушмый атау авырмыни сезгә, Ирек?

— Туташ дию ем мәсхәрәлимени сезне?

Мөнирә, уңайсызланып, кызарынды.

— Бер сез генә атыйсыз мине шулай. Миңа сез алай көлеп әйтәсездер кебек.

— Аллам сакласын, андый нәрсәнең күңелемдә йогы да юк, Мөнирә...

Без базардан үзебезгә кирәкле нәрсәләр алып кереп, җиңелчә генә ашап-эчкәч, сөйләшә-сөйләшә пляжка юл тоттык. Эшенә киткәндә, Гайшә ханым безне:

— Хәтерегезгә нык беркетегез, кояшта берьюлы унбиш-егерме минуттан артык кызынмагыз, көньякта кояш мәкерле, янарсыз, карагыз аны,— дип кисәтте.

Пляж бүген кичәге шикелле иркен һәм буш түгел, анадан тума диярлек калып кояшта кызынучы егетләр, кызлар, ир-атлар, хатын-кызлар, төрле яшьләрдәге бала-чагалар белән тулы булып чыкты. Анда хәтта әбиләр һәм бабайлар да бар иде. Мин, җирдәге җәннәт тә, мәхшәр дә шушында, күрәсең, дип уйлап алдым. Күктә ялкау гына канат җилпеп акчарлаклар оча, диңгездән су коенучыларның чыр-чуы, көлешүләре ишетелә. Кая күз салма, анда ал, кызыл, ак, зәңгәр, сары, яшел һәм башка бик күп исемсез төсләрдәге җыйнак һәм купшы резин башлыкларны күрәсең. Пляждагылар инде барысы да кояшта чуен күк янарга өлгергәннәр.

Без Мөнирә белән пляжның бер читендә бушрак урын табып, өс киемнәребезне салдык һәм бер-беребезгә карап, уңайсызланып калдык. Безнең тәннәребез мондагы бронза төсендәге тәнлеләрдән ап-ак булулары белән аерыла иде. Пляждагы бөтен кешенең игътибарын үзебезгә юнәлттек бугай, дип уңайсызландым мин. Мөнирәнең дә уе минеке кебек үк икән. Ул:

— Без монда, Ирек, нәкъ «ак карга»ларга охшап калдык,— диде.

— Зарар юк, Мөнирә, без тормышта да «ак карга»лар бит борчылмагыз,— дидем.

Ун-унбиш минут комда аунагач, янәшәбездә утырган яшүсмер бер кызчыктан өс киемнәребезгә күз-колак булуын үтенеп, диңгезгә коенырга кердек.

Диңгез суы, һичшиксез, тылсым көченә ия дер. Аңа бер кергән кеше күп тапкырлар тагын керергә омтыла. Ул сине чын мәгънәсендә сихерли, үз итеп коча, җай гына тирбәтә, яратып иркәли. Анардан чыгасы, аерыласы килми. Диңгез кочагында тормыш чатаклыкларының бөтенесен онытып, үзеңне чиксез бәхетле итеп тоясың. Без — диңгездән еракта яшәүчеләр (сүз биредә Кара диңгез турында бара), күпме хозурлыктан, искиткеч ләззәттән, тәшләребезгә дә кермәгән рәхәтлекләрдән мәхрүм икәнбез... Халык, күрми күргән, үпми кочкан, ди. Минем белән дә шулайрак булды. Мин диңгезне беренче күрү, аның күкрәгенә тәүге кат колач салу белән дөньямны онытып гашыйк булдым һәм, бу тойгыны миңа нигә иртәрәк китермәдең, дип язмышыма үпкәләдем.

Без Мөнирә белән, ике атна эчендә кояшта сәгатьләр буе ятмасак та, ярыйсы ук яндык һәм пляжга йөрүче башка күпләрдән беренче көннәрдәге төсле бөтен игътибарны үзебезгә юнәлдерүдән инде арындык шикелле. Ял итүчеләр дә, поездлардагы юлдашлар кебек, тиз танышып, тиз аралашып китәләр икән. Беренче көннәрдән үк пляжда безнең белешләребез барлыкка килде, алар пляжга соңарыбрак килсәк, анда үзләре тирәсендә безгә урын алып куя торган булдылар. Без Мөнирә белән яңа белешләребезгә кушылып кәрт сугарга да өйрәндек. Белешләребез безне ирле-хатынлы исәплиләр иде. Пляжда мин ялгызым гына күренсәм, белешләребез, хатыныгыз кая, сырхауладымы әллә, дип кызыксыналар иде. Соңыннан белдем, Мөнирәдән дә пляжга үзе генә килсә, ирегез кая, әллә әчелештегезме, дип төпченә торган булганнар.

Кырымда без көннәребезне гел комда гына аунап, кәрт сугып, диңгездә коенып кына үткәрмәдек. Көн аралаш диярлек Кырым шәһәрләренең йә берсенә, йә икенчесенә барып кайттык. Акмәчеттә дә (Симферопольдә), Акъярда да (Севастопольдә), Бакчасарайда да, Балыклауда да, Ялитәдә (Ялтада), Мансарда да, Евпаториянең күршесендәге үк диңгез ләме белән дәвалау урыны Сакида да булдык. Көн саен диярлек көн кызуында һава суырткычлар өзлексез эшләп торган җиләс залда кино карадык. Анда Лев Толстойның мәшһүр эпопеясы буенча америкалылар эшләгән «Сугыш һәм дөнья» фильмы да күрсәтелде. Аны карагач, Мөнирә:

— Наташа Ростованың авызында папирос кына җитми бу картинада, калганы барсы да бар. Толстой үз романын мондагыча бозганны күрсә, бөтен әсәрләреннән ваз кичәр иде,— диде.

Бер көнне, Кавказда, Сочида да булып кайттык. Кавказ безгә Кырымнан ныграк ошады. Кырымда яздан бирле яңгырлар яумаган, җир таш кебек каткан, кая карама үләннәр саргайган, агачлар дым юклыктан шәлперәйгәннәр, юлларда тубыктан тузан. Әз генә җил иссә, ул тузан дәррәү күтәрелеп, сулышны каплый, күзләргә, колакларга тула иде. Кавказда бөтенләй башка дөньяга юлыктык, анда безне суларга рәхәт дымлы һава, һәр җирдә җете яшеллек каршылады.

Фатирда мин Гайшә ханым белән Мөнирәгә, алар миңа — комачауламый. Без, хәзерге сәяси җитәкчеләр әйткәндәй, бер-беребезне уңайсызламый янәшә тыныч яшибез. Йокларга яткач, мин урамнан үткән машиналарның, фара утларының йорт алдында үскән агачларның куе ботаклары аша веранда түшәменә төшкән сәер шәүләләрен күзәтәм. Алар минем уйларымны еракта калган дәһшәтле сугыш кырларына, иксез-чиксез себер тайгаларына, чәнечкеле тимерчыбык киртәләре артында үткән тоткынлык көннәремә алып кайталар. Ул сәер шәүләләр веранда түшәмендә капыл гына туалар да, адашып үзләрен хасил иткән машиналарыннан аерылып калмаска теләгән шикелле, мизгел арасында юкка чыгалар. Төнлә йөргән машиналарның мотор тавышлары көчле түгел, кешеләрне тынычсызламаска теләп сагайган кебек басынкы. Ә менә күршедәге иске агач амбарга оялаган цикадаларның бер-берләрен уздырырга тырышып чәрелдәүләре, өзлексез сызгырган милиционер сыбызгысын искә төшереп, саруны кайната. Шуңа мин кичтән бик озак йокыга китә алмый азапланам. Йоклагач та теләгәнчә ял итә алмыйм, зиһенем уяу кала, төшләнәм. Төшемә үткәннәрем керми, никтер гел пляж, шаян дулкыннар, краблар, медузалар, эреле-ваклы балыклар керә. Моннан берничә көн элек Мөнирә белән радиодан тол хатыннарның да, хәтта иң ямьсез кызларның да игътибарына лаек була алмаган бер бичара буйдакның, аптырагач, үзенә кардан кыз әвәләве һәм кар кызның, буйдак каядыр чыгып киткәч, эреп юкка чыгуы турында шаян украин җырын тыңлаган идек. Кичә төшемдә үземне шул беркемгә дә кирәксез бичара буйдак итеп күрдем. Имеш, мин кардан бик чибәр кыз әвәләп, Марийша түтинең өенә керткәнмен дә кайтуыма кар кыз эреп идәндә күлләвеккә әверелгән. Шуның өчен нишләргә белмим, бик нык хәсрәт чигәм, имеш. Каяндыр Мөнирә пәйда була һәм күзләреннән яшь түгеп:

— Кар кызы урынына мин бар бит сиңа, ярат мине, юкка кайгырма,— дип юата, имеш.

Кинәт, якында гына бик ямьсез итеп мәче мыраулауга йокымнан уянып, күзләрем ачтым. Верандада ул-бу юк, бөтен нәрсә кичтәгечә: әнә бер-берләреннән уздырырга тырышып, цикадалар чәрелди, веранданың ачык тәрәзәсеннән эчкә үтәргә кыймыйча канатларын җилпер-җилпемәс ярканатлар тулгана, төнге караңгылыкта яктырткыч коңгызлар сүрән генә аркылы-торкылы эзләр сызалар. Гайшә ханым белән Мөнирәнең шыпырт кына сөйләшкәннәре ишетелә. Мин аларның гәбенә ирексездән колак салам.

Гайшә ханым Мөнирәдән минем турында төпченә иде. Кем мин, аның белән арабыз ничек, бер-беребезне күптәннән беләбезме, нигә мин өйләнергә ашыкмыйм һәм башкалар, һәм башкалар. Мөнирәнең җаваплары кыска булды, җәелеп сөйләмәде. Моннан өч ел элек театрда танышуыбызны әйтте. Гайшә ханым аңа, ул болай яман кеше түгел кебек, кулыңнан ычкындырмаска тырыш син аны, инде укаң коела бара, уйла, файдалан форсаттан, кушылыгыз, дип киңәш бирде һәм шунда ук:

— Төптәнрәк уйлаганда, син бәхетле, Мөнирә. Дөньяң иркен, берәүгә дә хисап бирмисең, җаның тыныч, фәнни дәрәҗәң бар, минем белән сине һич чагыштырырлык түгел...— дип, үз тормышыннан зарланырга керешге.

— Ни сөйлисең, аңламыйм, акылыңа кил, Гайшә, син бәхетсезмени? Мин синең тормышыңнан, үзеңнән көнләшәм, беләсең килсә,— диде аңа Мөнирә.

— Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә,— дип зерәгә җырламыйлар, Мөнирә. Син мине, бу ирле, эше тыныч, тормышы курорт шәһәрендә үтә, бәхете түм-түгәрәк дисеңдер. Алай уйласаң ялгышасың, ахирәткәем. Бәхет өләшкәндә үз өлешемнән коры калган мәхлукмын. Ирем, дөресен әйткәндә, паспортымда гына. Аның үз кыйбласы, минем үз кыйблам. Рафисымны ел әйләнәсендә бер айдан артык күрмим, гомере диңгездә үтә. Уртак тормышыбыз юк, аның ике ятып бер төшенә дә кермим, дисәм, ялган булыр. Тапканын җилгә җибәрми анысы, өйгә кайтара. Әмма тормыш акчада гына түгел бит. Матди муллык рухи фәкыйрьлекне алыштыра алмый. Рафисның өйгә ялга кайткан арасында да миндә кайгысы аз, уйлары тик диңгездә генә. Телендә тик фәлән җирдә булуы да, төгән гаҗәеп урыннарны күрүе... Үзем дә, эшем дә, тормышым да аны аз кызыксындыра. Курорт шәһәрендә яшәвемнән дә канәгать түгелмен. Менә син эш урыныңнан аерылып, һава алмаштың, монда килеп кешечә ял итәсең. Ә курорт шәһәрендә «рәхәттә яшәүче» минем син кунагым белән иркенләп эчем бушатырга хәтта вакытым да юк. Көннәрем дөнья куып уза. Монда инде ничә ел яшәп, әле бер тапкыр да ялга килүчеләр шикелле, дөньямны онытып, пляжда аунап кояшта кызынганым да, үзем теләгән чакта диңгезгә кереп алдым-артым карамый иркенләп коенганым да булмады. Тормышым түгәрәк түгел, өчпочмаклы минем, Мөнирә. Өем, эшем, кибетләр һәм базар кирә ул өчпочмакка.

— Ник китмисең, нәрсә тота соң сине монда?

— Нәрсә тота?— Гайшә ханым тирән көрсенде, аннары:— Мәсләгем тота,— диде.— Уйлап кара, монда инде эшем дә, яшәү рәвешем дә эзгә салынган. Фатирым, хезмәттәшләрем арасында күпмедер абруем бар. Әйтик, моннан Казанга кайтсам, миңа барысын да яңабаштан башларга кирәк булачак. Минемчә, бер урыннан икенче урынга күченеп йөрү яшь, яшел чакта гына берни түгел, акылы бар кеше олыгайгач, һавадагы ниндидер дәү торнага алданып кулындагы кечкенә чыпчыкны ычкындырмый. Бу фатирымны югалтуым гына да мине акылымнан яздырачак. Моннан кайда гына китсәм дә, бер җирдә дә мине колач җәеп каршы алучы булмаячак. Без — язмыш коллары.

— Син, Рафисыңнан зарлансаң да, аны яратасың бит. Яратмасаң, санаториегызга килүчеләр арасыннан ук берәүне инде үзеңә каратыр идең.

— Ярату кешене яшь чакта гына иләсләндерә, Мөнирә. Миңа Рафис күптән — бары таяну ноктасы гына. Санаториягә килүчеләр арасыннан кемнедер үземә каратуны күрәләтә мәсхәрәләнү саныйм мин. Бездә ир-атлар да, хатын-кызлар да килгән көнне үк бер-берләренә пар табалар. Өйләрендә аларны хатыннары, ирләре, балалары көтә, ә алар, бәйдән ычкынган айгырлар һәм бияләр кук, гыйшык-гыйшрәт өянәгенә биреләләр. Кайберләре санаторийда егерме дүрт көн ял итү, дәвалану дәверендә парларны ике көннең берендә алмашалар. Әхлак, этика, әдәп кануннары — юк ул кешеләргә. Турысын әйтәм, ирләргә дә, хатын-кызларга да хөрмәт калмады миндә. Ярар, җитсен бүгенгә, сүзне иртәгә дәвам итәрбез, торып миңа эшкә барасы, йоклыйк әйдә...

Миңа бәлага тармый яшәү язмаган, күрәсең. Көнгә меңнәрчә кешеләр бертуктаусыз диярлек арлы-бирле мыжгыган диңгез читендә мине үткен кырлы кабырчыкмы, кемдер ваемсыз ташлаган шешә ватыгымы, башка хәвефле әйбердерме көтеп яткан икән. Аңа берәү дә басмады, мин бастым. Табанымнан шарлап кан китте. Һәм ярам йөрәгемә төшеп әрнеп сызлый да башлады. Мин шулай һич уйламаганда көньяк кояшы назыннан һәм диңгездә коену рәхәтеннән мәхрүм калдым. Ашыгыч ярдәм машинасында килгән врачның мине шифаханәгә илтү ниятенә Мөнирә, каршы килеп:

— Мин — врач. Авыруны дәвалауны үз өстемә алам. Сез безгә фатирыбызга кайтырга гына булышыгыз,— диде.

Столбнякка каршы укол биреп (ярамны юып бәйләгәч, ашыгыч ярдәм машинасы безне фатирыбызга кайтарды) Мөнирә мине урынга салып, култык таяклары һәм ярамны дәваларга кирәк булачак дарулар юнәтергә аптекага китте. Ялгызым калгач, мин башым әйләнә һәм күнелем болгана башлавын тойдым. Миемдә, шушы гына җитми иде миңа, дигән борчулы уй борынлады. Хәтеремдә бала чагымда Бәеш тегермәнендә кадаклы тактага баскач шактый вакыт титаклап йөрүем, Камали бабай, аның белән атларга ашатырга кәрешкә печәне чабарга басуга баруларыбыз, Чуал буйлары, Бәеш өстеннән аэроплан очып үтүе һәм үземнең очучы булырга карар бирүем яңарды. Башым әйләнү сизелерлек көчәйде. Күзләремне йомсам, тирәмдәге нәрсәләр зырлап бөтерелгән кебек булды. Тәнем хәлсезләнгәннән-хәлсезләнә барып, акрынлап тәмам онытылдым.

Борынымны нашатырлы спирт яруга аңыма килдем. Инде кич булган, хуҗабикәбез Гайшә ханым эшеннән кайткан иде. Бөтен гәүдәмдә ару-талчыгу, алҗу, йөгенү, иләмсез авырлык тойдым.

— Сезнең аягыгызга без операция ясарга булдык,— диде Мөнирә, маңгаема кулын куеп.— Һуштан язган идегез шикелле, температурагыз кырыкка якынлашкан, аны үлчәвебезне дә сизмәдегез. Ярагызга пычрак кергән булырга тиеш: аягыгыз гөбе күк шеште. Ничек, нык сызлыймы ярагыз?

— Түзәрлек болай. Ярамда кызган кадак бар кебек. Мөнирә, әчәсем бик килә, су бирегезче, зинһар...

Салкын су йоткач, хәлем бераз җиңеләйгәндәй булды.

— Сез аягыгызны монда калдырып китәргә ниятлисез, ахры. Тирәгездә шәрә хатын-кызлар йөрүгә күзегезне тондырмаска, алдыгызны-артыгызны карап йөрергә кирәк иде. Бала белән бер сез,— диде моңарчы сүзсез торган Гайшә ханым.

— Аягымны гына түгел, үзем монда калсам да исем китми, Гайшә ханым. Яшь сыгар кешем юк, хаҗәтем ни аллага, ни муллага...

Хуҗабикә кырысланды.

— Җүләр сатмагыз. Мөнирә, чиш әле аягын, карыйк ярасын, бу тәмуг кисәүлегенә кандидатның.

Ярамны бәйләгән бинтны чишкәч аларның кашлары җыерылды.;

— Яраны теккән җөйдән арындырып, тиешенчә чистартыйк, Гайшә. Аны башкарып чыгарлык кына инструментларың һәм антисептика даруларың бардыр бит синең?— диде Мөнирә. Ул бу минутта җитди һәм таләпчән иде.

Мин аны андый базымлы һәм катгый итеп белми идем әле.

— Табарбыз. Мин инструментларны кайнатып стерильләштерим, син авыруның аяклары астына әнә теге шкаф өстендәге клеенканы җәеп кулларың юа тор...

Бу матавык миңа нигәдер көлке тоелды. Мин аңа, әйдә теләсә нишләсеннәр, дип карадым. Бәлагә тарыган аягыма наркоз ясагач, аның сызлавы бөтенләй тынды. Аңа жгут салгач, ярам тирәсен юып, йод сөртеп зарарсызландыргач, Мөнирә кулына скальпель алды.

— Гайшә, күр, ярага җөй ничек салынган, ташкулчим бит,— дип сукранды ул.— Аз гына арада никадәр үлек җыелырга өлгергән. Димәк, пычрак кереп калган ярага. Тампон бир әле.— Ул ярамда нәрсәдер кайнаштырды. Аннары миңа:— Авыру үзен ничек хис итә?— диде.

— Ничек бар, шулай...

— Пульсын сана әле, Гайшә.

— Пульсы нормада. Эшне тиз тоттың, Мөнирә, молодец. Бәлки китмәссең, калырсың,— диде хуҗабикә кунагына.

— Калмыйм, Гайшә, аллам сакласын. Казаным, эшем, фатирым көтә мине. Синең көньягыңнан өч атна эчендә дә инде гарык мин.—

Аннары, аягымдагы жгутны чишеп, миннән:— Ничек, Ирек, бераз басылдымы яраң сызлавы?— дип кызыксынды.

— Басылды. Сезнең икегезгә дә эш ясадым, гафу итегез.

Нindидер ачы төймәләр йоттыргач, Мөнирә белән Гайшә ханым мине тыныч йокы теләп ялгызымны калдырдылар. Инде караңгы төшкән иде. Ярамда казыныр алдыннан аягыма кадалган өшетү уколының куәте төкәнә бара иде бугай, акрынлап аягым сызлавы янә сизелә башлады. Күңелемне төшенкелек биләде. Үземне ярдәмгә мохтаҗ хәлдә гомерем буе ятам кебек тойдым. Әмма, ни гаҗәптер, аңа көенмәдем.

Мөнирә төнлә биш-алты тапкыр яныма килеп, маңгаема кулын куеп, хәлемне белеп китте. Уяу ятуымны, онытыла алмавымны аңа сиздермәдем. Иртән аягымның шеше кайтмавы, температурам төшмәү Мөнирәне борчуга салды. Ул:

— Пляжда нәрсәгә басканыңны тикшерергә, аның чистамы, түгелме икәнен анykларга тиеш идем мин. Аягыңнан шарлап кан агуны күрүгә югалып калдым. Мин врач этикасына хыянәт иттем. Врач беркайчан да тойгыга бирелергә тиеш түгел,— дип шелтәләде үзен.

Мин бәлагә тарыганның икенче көнендә үк без бер-беребезгә «сез» дип рәсми дәшүне гап-гади «син»гә алмаштырдык.

— Борчылма, сызлап туйгач төзәлер әле, төзәлми калмас,— дип, тынычландырырга тырыштым мин Мөнирәне.— Мине саклап утырма син, һавага чык, пляжга бар, коен. Диңгезне, ял итүне бөтенләй оныттың бит.

— Диңгезгә ялгызым баруның кызыгы юк миңа, Ирек. Мин сине ничек тизрәк аякка бастырырга икән дип баш ватам, аяксыз калуыңнан куркам...

## Унберенче бүлек

### 1

Казанга мин култык таякларына таянып кайттым. Ул гына түгел, Мөнирә белән без көньякта башлы-күзле булдык, өйләнештек. Капылт кына никахлашуыбызга үкенмәм дип уйлыйм. Шат мин, замат арасында хатынлы да, фатирлы да булдым. Әмма үземне бик уңайсыз хәлдә сизәм. Никтер Мөнирәнең ышанычын акламам кебек. Ул күңелемне мөлаемлеге белән генә түгел, кешелеклелеге, эчкерсезлеге, гадилеге белән яулады. Вагонда көньякка барганда ук мин тормышымда яңа сәхифә ачыла башлавын тойдым. Мөнирә мине чын-чынлап сихерләде сыман, уйларым гел аның тирәсендә буталды. Кырымга килгәч, ул рухи кояшыма әверелеп, мине өзлексез җылытты, иркәләде. Үземдәге бу сәер халәтнең мин беркайчан да бетмәвен, даими дәвам итүен теләдем. Диңгез читендә аягымны яраламасам, Мөнирәгә тәкъдим ясарга батырчылык итә алыр идемме, белмим. Паспортымда хатынлы идем бит әле мин — арабызда Оля бар иде. Безнең үзара аңлашуыбызга минем бәлагә таруым — аягымны имгәтүем ярдәм итте, дисәм хакыйкатькә хыянәт итмәм кебек. Мин култык таякларына калгач, Мөнирә янымнан бөтенләй китмәде диярлек. Шул рәвешчә без, үзебез дә сизмәстән бербөтенгә әвереллек. Бу үзеннән-үзе килеп чыкты. Паспортымның пычранган булуына Мөнирә:

— Паспортыңдагы тап мине борчымый, аны син юк дип сана. Безне нindидер рәсми кәгазь кисәге кушмый, беребезнең беребезгә ихтыяҗыбыз, бер-беребезне ошатуыбыз, яратышуыбыз куша,— диде.

Казанга кайтуыбызның икенче көнендә үк мин Матбугат йортына эш белешергә бардым. Анда китап нәшриятында эшләүче бер иптәш «Кызыл Татарстан» газетасының партия бүлегенә әдәби хезмәткәр кирәген әйтте. Мин газетаның баш мөхәррире Галим ага Рябков янына кердем. Гозеремне әйткәч, ул:

— Партия бүлегенә кереп, аның мөдире иптәш Гобәйдуллин белән сөйләшегез, ул сезне үз бүлегенә алуны хуп күрсә, мин каршы килмәм,— диде.

Кирәкле бүлмәгә кердем. Бүлек мөдире урынында иде. Ул Бөек Ватан сугышында катнашкан офицер икән, түшендә ике орден һәм берничә медаль ялтырый. Кыяфәтенә караганда бик җитди кеше күренә. Йомышымны әйткәч, мине башымнан аягыма кадәр күздән кичереп, ашыкмый гына тәмәке кабызды.

— Эшкә алсак, сезгә авыл районнарына командировкаларга чыгу авыр булмасмы?— диде, авызыннан төтен өреп.

— Булмас, култык таяклары миңа вакытлы юлдашлар,— дип җавап кайтардым.

— Авыллар тормышы танышмы сезгә, газетада эшләгәнегез бармы?

— Таныш. Мин авылда үстем. Газета эшен дә беләм шикелле: инде менә өч ел Питрәч район газетасында эшлим.

— Аннан нигә китәсез?

— Мин анда, хатыным монда, шуңа күрә.

— Сынау шарты белән бездә бер ай эшләп карагыз, аннары күз күрер. Гариза язып, кадрлар бүлегенә кертегез. Киләсе атнада эшкә керешерсез. Менә шул.

Юк, зур гәүдәле, такыр башлы, чытык чырайлы бу агай белән эшләп булмас, бик төксе кешегә ошаган, дип, уйлап газетаның партия бүлеге мөдире утырган бүлмәдән чыктым. Сынау шарты белән бездә бер ай эшләп карагыз, имеш. Казанда бер «Кызыл Татарстан» гына түгел бит, монда эшләгән арада башка җирләрдә эш белешә торырмын, андый тәҗрибәм бар ич инде минем. Чытык чырайлы агай биографиям белән дә, фиркалегем белән дә кызыксынмады, тикмәгә түгел бу, туктамас бездә дигәндер...

Питрәчкә бардым. Култык таякларына таянып редакциягә килеп керүемә андагы хезмәттәш иптәшләрем:

— Нәрсә булды сиңа?— дип гаҗәпләнделәр.

— Егылдым,— дидем, ваемсыз күренергә тырышып. Ничек бәлагә таруымны, аягымның һаман шеше кайтмавын, ярамның үлекләвен сөйләп торуны кирәк санамадым. Хезмәттәшләрем белән бераз гәпләшкәч, редакторыбыз янына кердем. Ул эшләп утыра иде, сәламемне алу белән нindидер конверт чыгарды һәм:

— Бу хат сезне инде шактый көтеп ятты,— дип миңа сузды.

Конвертка күзем төшүгә үк аның Олядан икәнен күрдем. Хатны ачып тормадым, редакторга рәхмәт әйтеп кесәмә салдым.

— Нигә култык таякларына калдыгыз, ялыгыз ничек үтте?— дип кызыксынды Николай Ильич.

— Рәхмәт, шәп ял иттем,— дидем. Аягым турында аңа да хезмәттәшләремә әйткән егылдым сүзен кабатладым. Аннары:— Районда эшләр ничек, нинди яңалыкларыгыз бар?— дип кызыксындым.

— Районда да, бездә дә күзгә күренерлек яңалыклар юк диярлек. Наборщицабыз Надя Трусованың туе булды, шул гына яңалыгыбыз. Райком тирәсендә иптәш Филипповны Питрәчтән Казанга алалар, дигән сүзләр йөри, аның урынына безгә яңа беренче секретарь киләчәк, имеш.

— Иптәш Филиппов монда мәңге утырыр кебек иде бит?

— Монда без беребез дә мәңгелек түгел.

— Антон Егорович моннан китәсе булгач, сез мине дә эшемнән азат итегез инде, Николай Ильич.

Редактор көлде.

— Монда ул булмагач, сезгә күңелсез булыр дисезмени?

— Юк, минем Казан һавасын сулыйсым, Себер колонияләреннән соң бераз кешечә гомер сөрәсем килә.

— Казанда нинди эшкә урнашырга исәп тотасыз?

— Тәгаенләгән урыным юк әле. Муеным бар, берәр оешмада ана кулай камыт табармын дим.

— Табарсыз билгеле, бирсен ходай. Сез киткәч газетабыз күпкә төшсезләнәчәк, кызганыч. Аңа жан өрүчеләрнең берсе сез бит.

— Николай Ильич, сезнең белән килешмим мин. Газетаның юнәлешен билгеләү дә, аны үзгәртү дә редактор кулында, минемчә.

— Бәлки, китәргә ашыкмассыз, бирелә тагын берәр ел эшләрсез?..

— Кыстамагыз, Николай Ильич, минем теләгәнчә яшәп карыйсым килә.

— Ә ни комачаулый монда сезгә?

— Башка нәрсәләрне инде әйтеп тә тормыйм, хәтта мунчаның да булмавы. Авылларда һәм вак поселокларда яшәүчеләрнең тормышлары төрмәдәгеләрнеке белән бер бит. Күп авыллар әле радиодан да мәхрүм, электрны да төшләрендә генә күрәләр, культура учагы исәпләнгән клублар онытылганда бер ачылалар. Казанда мин хет тубыктан пычрак ермам, асфальтта йөрермен.

Мин кесәмнән эшемнән азат итүне сорап язган гаризамны чыгарып, редакторга суздым. Ул аны кулына алып укып чыккач, расчет бирергә, дигән резолюция салды.

— Өч ел буе бергә эшләп иркенләп сөйләшеп утырырга да туры килмәде безгә. Эшкә кайда урнашсагыз да чын күңелдән уңышлар телим сезгә. Питрәчтә бүген куна калсагыз, кичен миңа рәхим итегез.

— Рәхмәт. Бухгалтерия тоткарламаса, бүген үк китәргә тырышырмын. Миңа, һичшиксез Казанга кайтып җитәргә кирәк. Монда килми тормам, килермен әле, күрешербез дә, гәп тә куертырбыз. Хәзер мин, фатирыма кайтып, кайбер нәрсәләремне алып киләм, расчетны, приказны тоткарламасагыз иде, Николай Ильич.

— Барыгыз, сез әйләнеп килүгә барсы да әзер булыр.

Марийша түти, минем кайтуымны күргәч, шатланган иде. Бүген үк Питрәчтән китәсемне әйткәч, кәефе кырылды.

— Шуны иртәрәк әйтергә ярамадымы сиңа, алла бәндәсе,— диде ул, үпкәләп.— Менә кешечә озата да алмыйм бит инде. Нишлим хәзер, улым белән бер бит син миңа, бәлки, бүген кунарсың, иртәгә генә китәрсең, ә?..

— Иртәгә кадәр кала алмыйм, Марийша түти, үпкәләмә. Мин инде элеккечә ялгыз түгел бит, Казанда хатыным көтә.

— Оляңмы?

— Юк, Мөнирәм.

— Ул кемсә тагын? Аны каян таптың?

— Мөнирә врач, мин аны түгел, ул мине тапты. Бер дигән кеше ул.

— Сукага җигеп сынамый атыңны, биш ел тормый хатыныңны мактама, дигән борынгылар. Кәләшеңә мәдхияне бик иртә җырлыйсың, авызың пешмәсен. Хатыныңны беренче көннәрдән үк мактап узындырма, улым. Муеныңа менеп атланыр да, сине чүпрәккә әйләндерер, уйла шуны. Хатыннарның чәче озын, акылы кыска. Дөньяда җүнле хатын-кызлар йөзгә бер генә. Җүнле дигәннәренең дә әле икесенең берсе җил тегеләй иссә алай, бире иссә болай. Күптән белә идегезме бер-берегезне?

— Күптән, моннан өч ел элек танышкан идек.

— Берни аңламыйм, синең ул булачак хатының турында телең тибрәтеп бер кәлимә сүз катканың юк иде бит. Аягың нишләде, ник култык таякларына калдың?

— Егылдым.

— Дөрес аңласам, кемдер сине үзенә өйләндергән, егылып аягың имгәткәч, башың миңгерәүләнгәндер, улым, башка түгел бу. Китәргә ашыкма әле, иркенләп сөйләшик, хатының әллә кая китмәс, көтәр.

Мин хуҗабикәмне тыңламадым.

— Булмый, Марийша түти, китәм. Әйберләремне җыештырып тормыйм, аларга Мөнирәне ияртеп килермен, шунда сөйләшербез.

— Башыңны тәки бутаган чәчбиең. Тагын сорыйм әле, ниндирәк нәмәрсә соң ул?

— Игелекле, инсафлы, фатирлы кыз.

— Ничек, син аның үзенә өйләнденме, фатирынамы?

Хуҗабикәмнең мәсхәрәле бәйләнчек сораулары ачуымны китерә башлады.

— Үзенә, Марийша түти, үзенә. Менә синең дә фатирың бар югыйсә, мин сиңа никахлашырга тәкъдим ясамадым бит.

Хуҗабикәм бу сүземнән рәхәтләнеп көлде.

— Теләсәң өемне мин сиңа никахлашусыз-нисез бирәм, ал.

— Якын иткәнең, үз улың кебек санаганың өчен рәхмәт, Марийша түти. Ярый, мин китим, әйберләремне алырга, аягым төзәлгәч, иркенләп килермен. Бүген кайбер алмаш кием-салымнарым белән иң кирәкле кәгазьләремне генә алам. Исәнлек-саулык телим сиңа. Бигайбә, Марийша түти. Хуш хәзергә.— Мин хуҗабикәмнең иңенә кулым салып, битеннән үптем.

— Сау бул, улым. Син мине онытып бетермә, кайчан теләсәң шул вакытта кил миңа. Сине мин улымны көткән кебек көтәрмен.

Алып китәсе әйберләремне кечкенә чемоданга тутыргач, карчык мине урамга кадәр озата чыкты. Бераз киткәч, артыма борылып карадым һәм хуҗабикәмнең керле алъяпкыч итәге белән күзләрен сөртеп торуын күрдем. Моңа йөрәгем авыртып кысылды.

Редакциягә кереп, хезмәт кенәгәмне алгач, өч ел бергә эшләгән иптәшләрем белән саубуллашып, автобус тукталышына титакладым. Башымда, менә Питрәч белән дә арам өзелде, киләчәктә монда үткән тормышымны да сагынып искә алырмын, ядкәрем булып биредә редакция һәм типография биналары кала, мин бу район үзәгендә бәлки бер Марийша түтинең генә түгел, кайбер башка берәүләрнең дә исенә төшәрмен, дигән уйлар буталды...

## 2

Оляның кесәмдәге хаты Казанга өебезгә кайткач кына исемә төште. Әмма мин аны, юньле нәрсә язылмагандыр, кәефемне кырмыйм, дип ачып укырга ашыкмадым. Конвертны кесәмнән чыгаргач, уйларым ирексездән Оля тирәсенә кайтты. Күз алдымнан аның белән беренче очрашуыбыз, икәүдән-икәү генә сөйләшә-сөйләшә, мин кулга алынган елның январь кичләрендә Казан урамнарын таптауларыбыз, минем кулга алынуым алдыннан аның елап, тыны-өне кабынып Васильево ял йортыннан кайтып тулай торактагы бүлмәмә атылып килеп керүе, син исән, исән, дип бернинди тартынусыз муеныма сарылып, бит алмаларымны, күзләремне, иреннәремне тәүге кат шашынып үбүе, хөкем залына килүе, судтан соң эчке төрмәгә «хатыным» сыйфатында күрешергә кергәне, Вахитов лагеренда чакта яныма көнаралаш килеп, авыр эштән соң ял итәргә ирек бирми йөдәтүләре, хатлары бер-бер артлы ап-ачык булып кичтеләр...

Мөнирә каядыр киткән, өйдә юк иде, тормышымда Оляга бәйләнешле сәхифәләрне барлау мине булыктырды. Үземне ул эшләгән яхшылыкларга тик яманлык белән генә җавап биргән мәнсез итеп сиздем. Ул мине, тоткынлыктан аралап, яңадан ирекле тормышка кайтарырга күпме көч, тырышлык куйды, аның аяклары астында туфрак буласы урында, аңардан йөз бордым. Шундый әдәпсезлектән соң кешеләр арасында оялмый яшим, хәтта менә өйләндем дә. Чыннан да, миңгерәүдер мин, хактыр Марийша түтинең әйткәне...

Мин шулай ут йотканда Мөнирә кайтты һәм ишектән керү белән хәлемне чамалап алды.

— Нәрсә булды сиңа, әллә юлың уңмадымы?— дип, яныма килде.

— Син нәкъ балтасы суга төшкән кеше кук. Кая карыйк әле, аягың борчымыйдыр бит? Әле ашамагансың да бугай... Йә, әйт, нәрсә булды? Сөйлә, кәефеңне кырган нәрсә, бәлки, игътибарга да лаек түгелдер?..

— Олядан хат алдым.

— Борчылдырырлык нәрсә язган ул?

— Белмим, укымадым әле хатын.

Гаҗәпләнүдән Мөнирәнең күзләре шар ачылды.

— Ә нигә соң сөмсерең коелды?

— Үземнең тере кулэгә булуымны төшендем. Зинһар, гафу ит мине.

— Оляны читкә кагып, миңа өйләнгәнеңә үкенәсеңме әллә?

Мин, урынымнан торып, Мөнирәне күкрәгемә кыстым.

— Сөйләмә юкны, син — кояшым минем. Үткәннәрне күңелдән сызып ташлавы авыр һәм ул мөмкин дә түгел. Алар мине гомерем буена борчырлар, йөдәтерләр кук.

— Ярар, онытып тор хәзергә ул турыда. Ничек, Питрәчтә юлың уңдымы.

— Уңды, Мөнирә.

— Мин ашарга әзерлим, син хатыңны ач, сузма, укы, күңелеңне тынычландыр,— дип, Мөнирә, кочагымнан чыгып, кухняга кереп китте.

Сиңа киңәш бирүе җиңел, дидем аңа эчемнән генә. Оляны үзең кебек тыныч, сабыр холыклы дисеңдер син. Ул вөҗдансыз кыбырсык бит. Соңгы очрашуыбызда Питрәчтән тыныч кына киткән иде кебек бит инде, тагын нинди әйтәсе сүзләре калган? Аңламаса аңламас икән кеше...

Конвертын теләр-теләмәс ачып, хатка күз салдым. Нәрсә, әллә янгыр астында булганмы ул? Андагы күп юллар җебеп җәелгәннәр. Ни гаебем бар, нигә мине газаплаудан тәм таба ул?.. Бәлки, укып та тормый утка ягаргадыр бу хатны? Юк, укыйм әле.

**«Хатымның сине шатландырасына шикләнмим, аны мин инде күптән язарга тиеш идем, әмма, нәрсәгәдер өмет баглап димме, уйларымны кәгазьгә күчерергә ашыкмадым. Монда язылганнарны син үз каршыңда минем тәүбә-истигъфарым дип исәплә. Безнең, чыннан да, икебез бер бөтен тәшкил итә алмавыбызга инде тулысынча инандым. Миңа син тик үзеңне генә яратасың кебек тоелган иде, юк икән. Уйлана торгач, төп гаепнең үземдә икәнен танырга мәҗбүр булдым. Мин — хыял колы. Хыял белән чынбарлыкның икесе ике нәрсә икәнен бутавым, хыялымны чынбарлык итеп күрергә тырышуым синең белән бәхетемне табуга киртә булды миңа. Синең тоткынлыкта вакыттагы булышлыгыма мохтаҗлыгыңа инануым, сине инде, бернинди нигезсез, үземнең бүленмәс яртыма санавым, сине өчле-тугызлы гына белүем ялгыштырды мине. Мин, әле соң түгел, ялгышымны төзәтергә, арабыздагы фиктив никахны суд аша юкка чыгарырга карар бирдем. Эшебезне Казанның Киров районы халык суды карарга тиеш. Аерылышачагыбыз турында газетага белдерү бирдем, ул озакламый чыгар. Судка сине, элекке рухи яраларыңны кузгатып әрнетмәс өчен, чакыртып тормам, дим. Анда аерылышуыбызга ризалыгың турында мөһер сугып имзаң расланган язуыңны җибәрсәң, җитәр. «Насильно мил не будешь»,— дип бик дөрес әйткәннәр. Этле-мәчеле яшәвебезгә чик куеп, кешеләр булып калыйк. Рәсми аерылышкач, сине бүтән беркайчан да борчымам. Хатны миңа главпочтамтка язарга мөмкин. Сиңа эшеңдә һәм тормышыңда уңышлар телим. Оля».**

Бу юлларны укыгач, Оля кызганыч булып китте. Ләкин бу тойгы мине исертергә өлгермәде, хәтерем шундук тоткынлыктан азат ителгәч Алексеевскига кайтуым, загста язылышуыбыз минутлары, загстан кайтуыбыз, Мурзиха пристане, Казанда китап кибетендә аның урынсызга Рәйсәне мәсхәрәләве, халык алдында битемә төкерүе яңарды. Оля бер караганда болай, икенче караганда тегеләй бит, нәкъ хамелеон кук үзгәрә. Тимерне кызуында сугарга — аерылышырга риза икәнлегемне

нотариуста раслатып тизрәк судка җибәрергә кирәк. Өйләнгәнемне белеп алса, аның, мин сине тоткынлыктан кемнедер бәхетле итәр өчен араламадым, дип аерылышуыбызга аяк терәп каршы килүе бар...

Мөнирә кухнядан чыгып, миңа:

— Ирек, әйдә, юын да ашарга кер,— диде.

Табын янында Мөнирә, кирәк тапса үзе сөйләр диптер, Оляның хатында нәрсә язылу белән кызыксынмады. Ул сүз арасында Рәйсәне очратуын, аңа өйләнешүебезне сөйләвен һәм аларның Салих белән икәүләп иртәгә кичкә безгә киләселәрен әйткәч:

— Синнән узып эшләдем моны, ачуланмыйсыңмы?— диде.

— Нәрсә өчен ачуланыйм, нигә син мине теге яки бу теләгеңә каршы килер дип исәплисең? Сине мин чикләүле кысага ябарга тиешмени? Һәр мәсьәләдә үзеңне мин янында юк чактагыча иркен тот, мин синең бер генә ниятеңә дә каршы килергә җыенмыйм, чөнки аларның барысы да дуамаллык җимеше булмасларына шикләнмим. Әгәр без бер-беребезнең ирeген чикләсәк, тормышыбызның кысыр, күңелсез, әчпошыргыч булачагы көн кебек бит.

— Мин, ир белән хатын үзара киңәш-табыш итеп яшәргә тиешләрдер, дип карыйм, Ирек. Кеше үзенең кылган гамәлләре өчен намусы алдында хисап бирергә, яшәү мәгънәсе турында уйланырга, ялгышларын кабатлаудан сакланырга тиеш, минемчә.

— Тормыш кеше өчен үкенечләр җыелмасы, дия иде минем бер дустым, Мөнирә.

— Дөньяда үзең теләгәнчә яшәү мөмкин түгел бит.

— Әйе, тормыш без уйлаганнан күпкә катлаулы, шуның нәтиҗәсендә кешеләр арасында мөнәсәбәтләр дә тотрыклы түгел.

Мөнирә сагайды.

— Безнең мөнәсәбәтләр дә шундый булыр дисеңме әллә син?

— Аллам сакласын! Икебез дә — яңа гына балигъ булган җилбәзәкләр түгел, тормышның ярыйсы ук ачысын-төчесен татып, күпмедер тәҗрибә туплаган кешеләр. Безгә кешеләрчә көн итәргә берни дә комачауламый. Менә Оля минем белән рәсми аерылышырга судта эш кузгатырга җыенуы турында язган һәм минем аның ниятенә каршы килмәвемне үтенгән. Озакламый мин тулысынча синеке генә булачакмын, Мөнирә.

— Минеке түгелмени әле син?

— Арабызда Оля бар иде ич...

— Ул минем өчен инде күптән киртә түгел, син — тик минеке генә.

## 3

«Кызыл Татарстан»да эшем тиз җайга салынды. Миңа яңа эшемдә турыдан-туры җитәкчем, газетаның партия бүлеге мөдире Насиб ага Гобәйдуллин белән бүлектә инде берничә ел эшләгән кулдашым Габдулла Шәрәфетдинов ярдәм итте. Насиб ага башта уйлаганымча туң күңелле, тупас һәм чикләнгән кеше булмады. Ул кем белән дә бик җиңел аралаша алучы, редакциягә килгәнче Кама аръягындагы районнарның берсендә райкомның беренче секретаре вазифаларын үтәгән булган икән. Аны хатын-кызларга талымсызлыгы, «киң күңеллелеге» өчен эшеннән алганнар. Насиб аганың ул «йомшаклыгы» районда калмаган, ияреп Казанга, «Кызыл Татарстан» редакциясенә дә килгән иде. Чибәррәк, мөләемрәк хатын-кыз күрсә, яшьме ул, инде олыгаеп чәчләре чаллана башлаганмы, талымлап тормый, кабына һәм дөньясын оныта иде. Көчең барда үзеңне хатын-кызларны яратуда чикләмә, үкенерсең, электә майтарырга җай чыкмаган күңелеңә хуш гөнаһны форсат килсә үтә, дигән китап, ди иде ул Габдулла белән миңа. Бүлектә күпмедер эшләгәч, миңа Насиб аганың усал-усал юмористик һәм сатирик

шигырьләр язуы мәгълүм булды. Аның шигырьләрен үз газетабыз гына түгел, «Чаян» журналы да теләп баса иде.

Бүлектә минем кебек үк әдәби хезмәткәр вазифаларын үтәүче кулдашым Габдулла да җор сүзлектә мөдиребездән калышмый, әмма ул аның кебек орып-бәрми, җинелчә сүз уйнату белән канәгатьләнә иде. Миңа аның әдәбиятка малай чактан ук гашыйк икәне, шигырьләр язуы газетада эшли башлавымның беренче көннәрендә үк мәгълүм булды. Мин килгәндә ул үзенең бөек адашына ияреп язган «Батыр егет» исемле әкият-поэмасын нәшриятта аерым китап итеп чыгарырга әзерли иде. Соңыннан аның тәүге кат 1941 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыкканын белдем. Габдулла — дуслыклы, үтә тыйнак егет. Берәүнең дә үтенечен кире какмый, сүз тыңлаучанлыгын белүчеләр аның бу күркәм сыйфатын оятсызларча файдаланалар. Ул үзенә йомыш белән кергән кешегә мөгез читле калын күзлеге өстеннән текәлеп карап, дикъкать белән тыңлый һәм нинди генә ашыгыч эшен дә читкә куеп, үтенечне үтәргә керешә иде. Мин аңардан пөхтәлеккә, төгәллеккә, кыскалыкка, әйбернең төп асылын ансат кына тотып алырга өйрәндем.

Кулдашымның эштән тәм табуына сокланырлык иде. Дөньяның ачысын-төчесен ул күп татыган, сугыш башлангач, укуын ташлап эшли башлаган, аннары җиде ел солдат хезмәтен үткән, Япониягә каршы сугышларда катнашкан. Армиядән кайткач, биш ел электромонтажчы булып эшләгән, кичке урта мәктәпне тәмамлап, Казан университетын бетергән егет иде. Без аның белән, бер-беребезгә ярдәмләшеп, бик тату эшләдек.

Шулай елга якын вакыт үтте. Имгәнгән аягым инде күптән төзәлде, Оля белән шау-шусыз, тыныч кына аерылыштык. Ата булу бәхетенә ирештем — Мөнирә миңа үзе кебек үк чибәр кыз тудырды. Насиб ага мине эшкә алганда командировкаларга чыга алу-алмавым белән кызыксынган иде. Әмма унбер ай эчендә минем Казаннан читкә чыкканым булмады. Шәһәрдәге төрле партия оешмаларында үткән отчет-сайлау җыелышларыннан репортажлар бирү, Казанны төзекләндерү, шәһәр транспортының ихтыяҗлары, урамнарны яктырту, халыкны азык-төлек, яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин итү турында эреле-вaклы мәкаләләр язу белән чикләндем. Казаннан читтәге нинди дә булса берәр авыл районына җибәрүен сораганда Насиб ага, һәр нәрсәнең үз вакыты бар, ашыкма, өлгерерсең, дия иде.

Һич көтмәгәндә миңа газетадан «үз теләгем белән китәргә» туры килде.

Газета эше — катлаулы һәм үтә четрекле эш. Газетаның бер санын чыгаруга да йөзләгән кеше катнаша. Анда бастырырга әзерләнгән материаллар унлаган кешеләр тарафыннан җентекләп каралып, унлаган кешеләр кулыннан үтә, аларны җыйганда җибәрелгән хаталар кат-кат төзәтелә. Шуңа да карамастан, нинди генә газетаның да хатасыз чыккан санын табуы кыен. Бу — ашыгу-кабалану, каударлану аркасында килеп чыга. Кайчакта газетаның бер бите дә иртәдән кичкә кадәр кырыкка төрләнә. Ә газетада бер генә түгел, дүрт полоса. Йә бик җитди хөкүмәт белдерүен бирергә, йә полосада урнаштырылган нинди дә булса материал обкомдагы югары түрәне канәгатьләндерми, йә газетада макталасы кешенең көтмәгәндә ниндидер ярамас эше беленә, йә телетайптан кичектерергә ярамый торган бик мөһим материал килеп төшә. Нәтиҗәдә, полосаларны, туктаусыз үзгәртүдән соң газетаны басарга рөхсәт тик ярты төн авышкач кына бирелә. Бу аерым линотипистлар, кизү корректорлар, метранпажлар, чыгаручы, курьер, җаваплы секретарь урынбасары, газетаны басучылар һәм «саф баш» бергә әвәрә килеп, төн уртасына кадәр аяк өстендә булалар.

Миңа унбер ай эчендә «саф баш» вазифасын күп тапкырлар үтәргә туры килде. «Саф баш» — газетаның сонармый чыгуын тәэмин итүгә җаваплы кизү хезмәткәр. Кизү көнне «саф баш» эшкә яхшылап ял итеп,

төштән соң гына килә. Килү белән ул башта полосаларның бөтенлеген, аларга нинди үзгәрешләр кертелгәнен, искәрелгән хаталарның ни дәрәҗәдә төзәтелүләрен, кайсы полосаларда күпме эш калганны, эшне озакка сузмас өчен кемнәрне ашыктырырга кирәген барлый. Аннары полосалардагы әзер материалларны дикъкать белән укырга керешә.

Газетада мин соңгы кат саф баш булганда анда КПССның Генераль секретаре Н. С. Хрущевның зур чыгышы басылды. Ул чыгышның эчтәлеген һәм кемнәр алдында сөйләнүен инде хәтерләмим, телетайпта ул бик соңга калып тапшырыла башлады һәм безгә чыгасы номерның макетын баштанаяк үзгәртергә туры килде. Чыгышны тәрҗемәчеләрдән Габитов белән аның кулдашы Әскәров үтә кабаланып татарчага аудардылар һәм бер-берсенең тәрҗемәләрен карап чыкмыйча ук, кисәкләп-кисәкләп наборга озата тордылар. Алар нәкъ янгын сүндерүчеләр кебек ашыктылар, каударландылар. Аннары тәрҗемә ителгән материал җыелып версткага салынгач, аңа кат-кат төзәтмәләр кертелде. Мин, «саф баш» буларак, анда сәяси хата китмәвен төп вазифама санап, һәр кертелгән төзәтүнең яңадан җыйганда хәвефсез үтәлүен күзәттем. Газета, графиктан күпкә соңарып, сәгать өченче киткәч кенә басыла башлады. Мин өемә таң алдыннан гына кайттым.

Иртәгесен эшкә килүемә:

— Сезне редактор эзләтә, аның янына керегез,— диделәр.

Кердем. Редакторның йөзе кара коелган, алдында бүгенге газета ята. Ул, исәнләшүемә җавап бирмичә, канәгатьсез тавыш белән:

— Кичә редакциядә «саф баш» сез идегезме?— дип миңа текәлде.

— Мин идем, Галим абый.

Редактор урыныннан торып, газетаны сул учына бөгәрләп, яныма килде һәм аны миңа сузды.

— Бу газетаның редакторы кем?

— Сез,— дидем, берни дә аңламыйча.

— Кайдан белеп була аны? Редакторы юк бу газетаның, менә карагыз.

Үземә сузылган газетаны кулыма алып, аның ахыргы битенә күз салдым. Гадәти урында, чыннан да газетаның җаваплы редакторы Галим Рябков дигән сүзләрне күрмәдем, алар төшеп калган иде.

— Кичә мин газетаның алдагы өч полосасы белән әвәрә килеп, соңгы полосага игътибар итмәгәнмен, гаеп миндә,— дидем.

— Гаепне тану гына җитми, аны төзәтергә дә кирәк. Обком алдында сез минем дә, газетабызның да абруен төшердегез. Бүген йокыдан торуыма агитация һәм пропаганда бүлегеннән, сез газетаның редакторы түгелмени инде, анда имзагыз юк, дип шалтыраттылар. Инде нишлибез?

Мин аны-моны уйлап тормастан:

— Газетабызның бүгенге санында, газетабызның кичәге санының да редакторы Галим Рябков иде, дигән төзәтү бирик,— дидем.

— Мәсхәрәләргә ничек җөрьәт итәсез, югалыгыз күземнән!— дип акырды редактор, аяк тибеп.

Мине редактор бүлмәсеннән куып чыгаргач, бер ун-унбиш минуттан, тиз арада газета хезмәткәрләренең гомуми җыелышы җыйналды. Җыелышта сүз шәхси җаваплылыкны, сәяси сизгерлекне икеләтә, өчләтә көчәйтү, эшкә минем бармак аша каравым, җинаятьчел ваемсызлыгым аркасында газетабызның соңгы санында гафу ителмәслек хата җибәрелү, мине эшемдә калдыру, калдырмау турында барды.

— Редакторның имзасын куймый газета чыгару сәяси аңгыралык кына түгел, зур җинаять тә. Моның өчен Кадыйровны партиядән куарга кирәк,— диде совет-хуҗалык бүлеге әдәби хезмәткәре, керфекләрсез кабаклы, зур шәмәхә борынлы Хан Җәмил.

— Бик дөрес әйтәсең,— дип хуплады аны газетаның әдәбият-тәнкыйть бүлеген җитәкләүче, шагыйрьләр һәм әдипләр арасында дуамал тупаслыгы өчен Кабан дуңгызы дигән кушамат алган, өске тешләре

ямьсез булып авызыннан тышка тырпайган каратут йөзле, мәрхәмәтсез Фатих Мөсәгыйт.— Мондый хәлнең бездә Ибраһим Үзбәков бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга адресланган хатта аны мәсхәрәләгәне, яла якканы өчен арабыздан куылганнан соң булганы юк иде. Кадыйровка кичекмәстән, бүтән бер генә матбугат органына да якын бара алмаслык бүре билеты тоттырып, арабыздан куарга кирәк.

Җыелыш озак барды. Мин анда үз адресыма бик күп мәсхәрә сүзләре ишеттем. Ахырда редактор миңа үз теләгем белән эшемнән китәргә теләвем хакында гариза язарга кушты.

Җыелыштан соң кулдашым Габдулладан мин:

— Ибраһим Үзбәков редактор чакта газетада нинди хата киткән булган, белмисеңме?— дип кызыксындым.

Кулдашым, гадәтенчә, елмаеп, як-ягына каранды да:

— Хәтәр хата, Ирек дус, бик хәтәр, ул чакта «сезгә» дигән сүздә «з» хәрефе төшеп калган Сталинга язган хатта,— диде...

Мин шулай үзем дә сизмәстән «Кызыл Татарстан»нан китеп бардым. Газетадан куылуыма кайгырмадым, эшемне партия җыелышына куймауларына, учет карточкамның чиста калуына шатландым. Бүлектә Насиб агай мәкаләләргә, укучыда күз төшерү белән кызыксыну уятырдай, үзенчәлекле исем эзләтеп, көн дә тинтерәтә иде, менә хет ул бәладән котылдым, дип үземне юаттым. Кызык кеше ул Насиб ага, бер мәкаләгә унлап баш таптыра да шуларның син иң уңышсыз дип санаганын сайлап ала. Каршы килсәң, әйбернең кыйммәте исемендә түгел, җисемендә, ди. Ходайга шөкер, мин партия эшенә кагылышлы әчпошыргыч мәкаләләргә оригинал башлар эзләп бүтән беркайчан да саруымны кайнатмаячакмын.

## Уникенче бүлек

### I

«Кызыл Татарстан» белән арам өзелгәч, берничә көннән соң Матбугат йортына килеп, дустым Салих Хәкимов утырган бүлмәгә күтәрелдем.

— Уз түргә, әнә урындык, утыр. Баедың син, бер бинада эшләсәк тә, күзгә-башка сирәк күренәсең,— дип, үпкәләп каршылады ул мине.

— Мин бу бинада эшләмим инде, дус, киттем,— дидем, ул күрсәткән урындыкка утырып.

— Киттең? Кайчан, кая киттең?— дип төпченде сабакташым, ышанырга теләмичә.

— Шушы көннәрдә, Мөнирә янына.

— Шаяртма!..

Мин ничек эшсез калуымны җәелми генә бәян иттем.

— Инде нишләргә уйлыйсың?

— Белмим, дустым, ул турыда уйларга вакыт тими әле.

— Карале, бәлки, безгә — нәшриятка килерсең?

— Мине кем ала монда? Газетадан, сездән ул ник китте, дип сорасалар, ул ваемсыз, эшкә бармак аша карый, нәшриятка якын китермәгез аны, диячәкләр.

Салих,ниндидер карарга килеп, урыныннан торды.

— Син утырып тор, мин җәһәт кенә Гани абый янына кереп чыгыйм әле, ул җитәкләгән редакциягә редактор кирәк иде шикелле, бәлки сине алыр.

— Кем соң ул Гани абый?

— Нәшриятның политик редакция мөдире.

Салих бүлмәдән чыгып китте. Мин дустымның Гани абыйсын борчуы корыны бушка аудару гына булыр, политик редакциягә мине инде якын да җибәрмәячәкләр, дип уйладым.

Озак та үтмәде, Салих мөлаем йөзле, илле яшьләр тирәсендәге бер кеше белән бүлмәсенә әйләнеп керде.

— Менә «Кызыл Татарстан»ны мөхәррир имзасыз чыгарган иптәш шушы инде, Гани абый,— диде ул, үзе белән кергән кешегә мине күрсәтеп.

Мин аягүрә бастым.

— Әйдәгез, Салихка комачауламыйк, минем бүлмәгә керик әле,— диде дустым Гани абый дип атаган кеше миңа. Бүлмәсенә кергәч:— Минем фамилиям Гыйльманов, сезнең Кадыйров бугай? — дип ачыклады.— Сез партиялеме?

— Әйе.

— Белемегез?

— Югары. Моннан дүрт ел элек педагогия институтын тәмамладым.

— Беләм, беләм,— диде бүлмә хуҗасы сабырсызланган кеше кебек.— Сез менә бу кулъязманы өч көн эчендә редакцияләп китерегез әле. Эшкә алу-алмауны редакцияләвегезнең сыйфатына карап хәл итәрбез.

Редакция мөдире миңа бармак калынлык кына папка тоттырды.

— Сезнең фатир ягыгыз ничек? Гаиләгез бармы?

— Фатирым да, гаиләм дә бар.

— Әйбәт, әйбәт. Өч көннән керерсез. Кеше кирәк безгә. Сезнең белән уртак тел табарбыз, дип уйлыйм. Хәкимов миңа йөзенә кызыллык китерердәй бәндәне тәкъдим итмәс, ышанычлы егет ул. Булды, барыгыз...

Гани аганың бүлмәсеннән чыккач, мин тагын Салихка кагылдым.

— Йә, ничек, «Беләм, беләм» белән уртак тел таптыгызмы? — дип каршылады ул.

— Таптык шикелле. Рәхмәт сиңа, дус. Нигә аны алай атыйсың? — дидем, аптырап.

Нәшриятта кушаматы шундый аның, гаҗәпләнмә. Хәтта урыслар да аны яратып «Блям, блям» дип йөртәләр. Эчкерсез, әйбәт кеше Гани абый. Сөйләшүегез ни белән тәгәлләнде?

— Менә өч көн эчендә редакцияләп китерергә кульъязма бирде. Эшегезнең сыйфатына карап, эшкә алырлыкмы, алмаслыкмы икәнне чамаларбыз, диде.

— Беренче карашка Гани абый сиңа ашыга, каударлана кебек күренгәндер. Уртак тел табарсыз сез. Гомере хәрби хезмәттә үткән аның Фронтта булган кешене туганы кебек күрә. Сугыш елларында фронт газетасының мөхәррире булган. Ленин ордены белән бүләкләнгән...

Гани ага ипле, җыйнак, тыныч кеше. Ул берәүгә дә тавышын күтәрми. Авторларга үтә таләпчән.

Нәшриятның политик редакциясендә эшләгән редакторлар янында буш өстәл юк иде, Гани ага мине фән-техника редакциясе бүлмәсенә кертеп утыртты һәм:

— Монда әйбәт егетләр эшли, сезгә алар белән күңелсез булмас,— диде.

Ул бүлмәдә миңа кадәр ике редактор — Мәҗит Рафиков белән Адлер Тимергалин бар иде, мин өченче кеше булдым. Яңа хуҗам ул егетләр янына мине юри утыртты, дип уйлыйм. Чөнки 1950 елның башында без өчебез дә республика дәүләт иминлеге министрлыгының эчке төрмәсе җылымына эләккән идек, язмышлары аларның беркадәр уртак, әйдә бергә-бергә эшләсеннәр дигәндер...

Эчке төрмәдән соң, безнең язмышларыбыз өчебезнең өч юлдан киткән булып чыкты. Мәҗитне, махсус киңәшмә карары белән ун ел биреп, Тайшет-Братск тимер юлы төзелешенә алып киткәннәр, Адлерны эчке төрмәдә ике елга якын тинтерәтеп тә гаебен икърар иттерә алмагач,

шым гына иреккә чыгарганнар. Мине, инде беләсез. Менә без элекке өч тоткын, укуыбыз берничә елга өзелеп торгач, өчебез дә югары белем алган өч «халык дошманы» бер бүлмәгә җыйналдык. Мәҗит белән Адлер ничек булгандыр, белмим, мин алар белән бергә эшли башлавыма чиксез шатландым.

Бер көнне, истә-санда юкта, безнең эш бүлмәбезгә киң елмаеп, башын егетләрчә югары тотып, язучы Мин Шабай килеп керде.

— Исән генә яшисезме, асыл егетләр, хәл-әхвәлләрегез ничек? Мин менә нәшрият бухгалтериясенә килгәч, махсус сезгә комачауларга кердем. Башкорт әйткәндәй, бүз егетләр алларындагы кәгазьләренә кадалып утыра-утыра күзләрен талдырганнардыр, сафсатамны тыңлатып аларны әзрәк ял иттереп чыгыйм дидем. Кая, бер очрашкач куллар да кысышыйк, әдәп кагыйдәләренә туры килсен... Булды, кулларыгыз рухыгыз кебек үк көчле сезнең, алдыгызда баш иям, ихлас менә,— дип гөрелдәде ул, безнең өчебез белән дә исәнләшә-исәнләшә.

Йөзе һәрчак елмаюлы, җор сүзле, теләсә кем белән уртак тел таба белә торган бу әдип Матбугат йортына (Ул: Матбугат йорты — минем Мәккәм, мин монда хак мөселман хаҗга килгән кебек киләм, ди) килсә, газета-журналлар редакцияләрендә һәм нәшриятта эшләүче бөтен үз күргән кешеләрен барлап чыга. Мин ага хәрбиләрчә пөхтә киенә, башында һәрвакыт Сталин сугышка кадәр кияргә яраткан фасондагы фуражка була, өстендә төймәләре чишелеп җилбәгәй җибәрелгән кара күн пальто, пальтосы астыннан зәңгәр галифесе һәм биле солдат каешы белән буылган гимнастерка күренеп тора, аякларында ыспай хром итекләр. Кыяфәте егетләрчә, йөзе шат елмаюлы, зур борыны астындагы мул, калын мыегының бер читендә һәрвакыт папирос төти. Беренче күргәндә мин аны, бу отставкадагы югары чинлы офицер, ахры, дип уйладым. Аның белән мин «Кызыл Татарстан»да эшли башлагач таныштым. Ул мине коридорда:

— Сезне дә минем шикелле академик диләр, дөресме ул? — дип туктатты, киң елмаеп.

Аптырап калдым. Аннары:

— Гафу итегез, иптәш, сез мине кем беләндер бутыйсыз бугай,— дидем.

— Танышыйк. Мин — язучы Мин Шабай. Утырдыгызмы сез?

— Утырдым.

— Статьягыз нинди иде?

— 58—10.

— Бутамыйм, димәк. Кардәшләр без — Гулаг академиясенең гамәли әгъзалары. Күптән түгел генә халык дошманнары исәпләнгән кешеләрне хәзер халык арасында академиклар дип атауларын ишетмәгән идегезмени әле сез?

— Беренче сездән ишетүем.

— Академик төшенчәсенең бездән — татарлардан алынганын да белмисезме?

Мин, белмим дигәнне аңлатып, кулларымны җәйдем.

— Академик — ахак димәкнең урысчалаштырылган варианты ул. Сталин илебездәге иң асыл шәхесләрне юк итү, аларны тамырдан корыту сәясәте алып барды бит. Аңлашылдымы инде, брат, безгә кагылышлы академик сүзенең төп мәгънәсе, ә? Бу мин уйлап чыгарган нәрсә түгел,— бу — хакыйкать! — Ул бөтен коридорны яңгыратып, шаркылдап көлде.

Шуннан соң без Себердәге иң хәтәр лагерь һәм колонияләрдә унбиш ел буе газап чиккән, әмма рухы сынмаган авырлыклар алдында биле бөгелмәгән бу оптимист бәндә белән, ул Матбугат йортына килгәндә, очраша, аралаша башладык. Аның эчкерсез елмаюы күпвакыт миңа рәнҗүле кайнар күз яшен яшерә кебек тәэсир калдыра иде.

Бүлмәбездәге буш урындыкка утырып алгач, Мин агабыз безгә:

— Тыңлагыз әле, бер гыйбрәтле мәзәк сөйлим сезгә,— диде, барыбызга да берьюлы хәйләле күз кысып.

— Рәхәтләнеп тыңлыйбыз, сөйләгез,— дидек.

— Кичәгенәк мин, хатын колхоз базарына ит алып кайтырга чыгаргач, бер кыргыз, бер казакъ, бер әзербайҗан һәм бер татар агаеның үзләрендәге күлләрнең зурлыгы белән мактануларын ишеттем. Иң зур күл беләсезме кайда булып чыкты?

— Белмибез, кайда?

— Казанда, агай-энеләр.

— Кабан күлеме?

— Юк, Черек күл.

— Ул күл юк ич инде,— дидек бертавыштан.

— Бар икән ул, агайнеләр, бүлми тыңлагыз әле. Сүзне кыргыз башлады. Ул: «Безнең Ыссык-күл гаять зур, аны җәяүләп бер атна эчендә көчкә әйләнеп чыгасың»,— диде. Аңа казакъ «Бер атна эчендә җәяү әйләнерлек күл зурмыни ул? Безнең Арал күлен, ат менеп, бер айда көчкә әйләнәләр. Менә ул күл дисәң дә күл»,— дип каршы төште. «Ә мин үзебезнең Каспий күлен, машинама утырып, ел дәвамында көчкә әйләнеп чыгам»,— дип мактанды аларга әзербайҗан. Татар агае аларны тыңлап бетерде дә: «Илебездәге иң зур күл — безнең Казандагы Черек күлдер. Чөнки минем бер туганымны инде утыз җиденче елда ук Черек күлгә алып киткәннәр иде, әле һаман кайткан юк һәм кайчан әйләнеп кайтасы да берәүгә дә мәгълүм түгел»,— диде. Йә, егетләр, татар агае хаклымы, ничек уйлыйсыз? — дип, кунагыбыз урыныннан торып, тәмәке кабызды.

Без:

— Хаклы, бик хаклы,— дидек, көлешеп.

Черек күлне — эчке төрмәне искә төшерү минем күңелемне тырнады. Чыннан да, зур да, тирән дә ул «Черек күл», әнә әти белән әнине йотуы гына җитмәде, куенында мине дә «иркәләде». Мин Шабай ага бу мәзәкне кешедән ишетмәгән, үзе тудырган булыр...

Мәҗит күңеленә хуш килгән яңа гына сөйләнгән мәзәкне өстәле тартмасында саклана торган биш-алты кесә дәфтәренең берсенә тиз-тиз генә теркәп куйды.

Мин ага безнең янга керсә, кызык сөйләми калмый. Күп чакта ул үз-үзеннән көләргә тырыша. Ә көлүе астына аның үзен бимазалаган тормышы чатаклыклары яшерелә.

— Беләсезме, мин бит күптән инде ике хатынлы карт хәзрәт хәлендә, башымда тик яшел чалмам гына юк,— дип сөйләп китте ул, бүлмәбезгә бер керүендә.— Мин өемдә һәр төнне ике хатын арасында үткәрәм. Бер караватка өчәүләп вальтом ятабыз да, берәребез идәнгә егылып төшмәсен өчен бер-беребезнең аякларын кочабыз. Гөнаһсыз сабыйлар кебек үзара тәрткәләшә-типкәләшә рәхәтләнеп йоклыйбыз шулай. Андый бәхеткә ничек ирештегез дисезме? Авыр булмады миңа аңа ирешү, хатыным, улым һәм балдызым алты квадрат метрлы тавык кетәгедәй зу-у у-ур бүлмәдә гомер сөреп яталар иде, яннарына ындырт ел югалып торып, онытылып беткәч тып итеп мин кайтып төштем. Фатирлары тар булса да күңелләре киң хатыным белән балдызымның, сиңа баш төртер урын да юк бездә, аны бүтән җирдән эзлә, дип куып чыгармадылар. Малайны яннарыннан өстәлгә күчереп, бердәнбер караватка үз араларына мине дә сыйдырдылар. Яшибез шулай, чучкалар кебек мыркылдашмыйбыз гына. Рәхәт, валлаһи!.. Ничек һәм кайда язасыз сез, дисезме? Өйдә язам. Көндез безнең кысан бүлмәбез, иркенәя, малай мәктәпкә, хатын белән балдыз эшкә китәләр, караватыбыз көндезгә минем үземә генә кала. Шуңа иплап кенә менеп, аякларымны төрек солтаны күк бөкләп утырам да, иҗат ләззәтенә чумам. «Кызыл Татарстан» берәр колхозга миннән мәкалә әвәләтергә, катык ашарга җибәргәндә, аннан нәрсә дә булса әмәлләп кайтам.

— Язучылар союзыннан сезгә фатир вәгъдә итмиләрме соң?

— Итәләр. Таудан кысла сызгырганны көт, ул сызгырган көнне үк өч бүлмәле, бөтен уңайлыклары булган фатир алырга килерсең, диләр...

Кышка кергәч Мин ага шактый ара югалып торды. Күптән күренми, берәр авылга «катык ашарга» киттеме, әллә басылып язып утырамы икән ул, дип юксындык аны. Кар эреп, табигать җанлангач кына күру бәхетенә ирештек Мин агабызны.

Бер көнне бүлмәбездә мин ялгызым гына эшләп утырганда кемдер сак кына ишек шакыды. Эшемнән аерылмый гына:

— Керегез,— дидем.

— Кермәгез, монда эзегез булмасын, дисәгез дә керәм мин сезнең бүлмәгә. Магниты бар аның хәерсез, шул тарта,— дип ишектән гадәтенчә шаулап Мин ага керде.

Мин урынымнан сикереп тордым, кочаклашып күрештек.

— Кая югалдыгыз сез, кыш буе күренмәдегез?— дидем.

— Кыр казларына ияреп җылы якларга киткәнемне белмәдегезмени? Яз җиткәч менә кайттым, әйләнеп,— дип шаркылдады кунагым.— Шаяртам,— диде аннары, җитдиләнеп,— хәстәханәдә аунадым.

— Анда шулай озак аунарлык нинди яман чиргә юлыктыгыз?

— Минем аякларның рәтләре юк бит, брат. Кайчандыр алар тайгадагы аю төбәгендә бер кышны мина үч итеп өшегәннәр иде. Татарстан туфрагын кайтып таптыйсыгыз килмәсә, икегезне дә кистереп шушы җәһәннәм астында калдырам сез юнсезләрне, дип куркыткач кына әзрәк игә килгәннәр иде. Монда кайткач тагын назлана, кәҗәләнә башладылар. Минем эшләр шулай, брат, сезнең нинди яңалыкларыгыз бар монда? Мәҗит белән Адлер кая, ник син үзең генә?

— Безнең яңалыкларыбыз юк диярлек, Мин ага. Адлер бу арада башлы-күзле булырга йөри. Бүген, редакцияләре мөдире эшендә юклыктан файдаланып, үзәк китапханәгә гашыйкасы янына китте, озакламый кайтыр. Мәҗит университетта. Анда ниндидер мөһим очрашу булачак, диде.

— Үзеңнең берниндә дә яңалыкларың юкмыни?

— Минем яңалыгым шул — кызым тәпи йөри башлады.

— Әфәрин! Котлыйм. Бәхетле син, брат. Ә минс менә улымны куанып үстерү читләтеп үтте...

Елап та үтә көн, көлеп тә үтә, тәрәлеп тормый. Син еласаң яшеңне сөртү түгел, аңа игътибар да итмиләр; көлсәң, хәл иленчә, сиңа кушылып елмаялар, диярга ярата ул. Аның күңеле төшеп, кәефе кырылып йөргәнен беркайчан да күрмисең.

Җәй уртасында беркөнне, төш авышкач, минем янга, гадәтенчә шат елмаеп, Мин ага керде.

— Брат, бүген төнгә Идел буена һава суларга чыгуга син ничек карыйсың?— диде ул, кул бирел исәнләшкәч, тирләгән маңгаен чиста кульяулыгы белән сөртә-сөртә.

— Анда хәзер кешечә төн үткәрер урын табуы кыен инде. Иделнең бу як ярларының хозурланырлык җирләрен су басты, теге якка чыксак кына,- дидем.

— Чыгарбыз соң, безне нәрсә тоткарлар? Су трамваена утырырбыз да Байраккамы, Ташовкагамы, Шелангагамы элдерербез. Үзебез белән бәрәңге, башка кайбер ашамлыклар алырбыз, саф һавада, үзең беләсең, аппетит кузгала. Сәйранга чыккач, көлдә пешкән бәрәңге үзе генә дә корольләр сыена тиң. Анда балыкчылар да очрар, бәлки. Аларны очратсак, дөньябыз тәмам түгәрәкләнер, әйләнә-тирәдә бездән дә бәхетле кеше булмас. Уха хәстәрләп, талгын гына янган учак янында Идел дулкыннарының ярга бәрелеп чупылдауларын тыңлый-тыңлый, төне буе иркенләп гәп куертырбыз. Синең белән бер утырып тәмләп сөйләшәсем, эчемне бушатасым килә...

Кичен, кирәк кадәр азык-төлек, чиләк, табак һәм кашыклар алып, елга трамваенда Шелангага юл тоттык.

Трамвайдан төшкәч яр буенда тын, аулак урын табып төне буе учак сүндермәскә җитәрлек утын әзерләдек. Утын юнәтеп йөргәндә балыкчы өч ир-атка юлыктык.

— Менә алланы юк диген инде,— диде, аларны күргәч, Мин ага һәм балыкчыларга,— егетләр, сез без сукбайларга бер уха пешерерлек балык сатмассызмы? Без, шәһәр хәерчеләре, монда уха кесәнеп килдек бит, каһәр. Үтенечебезне кире какмассыз, бәлки?— дип мөрәҗәгать итте.

Балыкчы ирләрнең арада иң тазасы:

— Акчага сатмыйбыз балыкны, аракыга алмашабыз. Яртыгыз булса, бер ухалык кына түгел, биш ухалык бирәбез, җәл түгел,— диде.

Мин аганың балыкчылар белән моңарчы да алыш-биреше булган, күрәсең, ул:

— Бар ярты, брат, бар, сездәй киң күңелле бәндәләргә үзебезгә дигәне дә кызганыч түгел,— дип, рюкзагы янына йөгерде.

Ул аракы алып килгәч, таза гәүдәле балыкчы:

— Әнә сезгә балыкның ниндие күпме кирәк, алыгыз көймә төбеннән,— диде.— Бәлки яртыгыз бер генә түгел, тагын бардыр? Өч кешегә бер ярты авыз чылатырлык кына бит.

— Юк шул, брат, булса сездәй киң күңелле бәндәләргә һич кызганмас идек,— дип җавап кайтарды аңа Мин ага, көймәгә балык сайларга барышлый.

Уха искиткеч тәмле булды. Мин ага аны бөтен шартларын китереп, кул астыма кереп мишайть итмә, брат, дип учак янына мине якын да китерми, үзе генә пешерде. Мин аның чиләккә нәрсәләр салуын, нәрсәләр белән тәмләндерүен күрмәдем.

— Балыктан да шушындый шәп ризык әзерләп булганын уема да кертми идем инде,— дидем, ухааны ашаганда, Мин агага.— Колониядә череп сасыган балык ашатып теңкәбезгә тиделәр безнең. Шуннан бирле балыкны авызыма алу түгел, аны ашаучыны гына күрсәм дә күңелем болгана иде. Ә сез пешергән бу уха кайчандыр мин җирәнә-җирәнә ашаган балык шулпаларыннан гади судан татлы ширбәт ничек аерылса, шулай аерылып тора. Мең рәхмәт сезгә сыегыз өчен, Мин ага, чын күңелдән рәхмәт. Тылсымын беләсездер сез уха пешерүнең.

Мин ага көлде.

— Урысларның, «ананны кыш көне салкын кар өстеннән яланаяк йөгертим» диюгә ошаган шакшы «догаларын» укып түгел, бисмилла әйтеп пешерелде бу уха. Үзебезчә — мөселманча пешерелде. Бөтен хикмәт шунда, миндә түгел, брат.

Юк, тыйнаклык күрсәтә әдип ага. Куллары алтын аның, нинди генә эшкә тотынса да, аны сокланырлык итеп башкарып чыга ул.

— Сез пешергән балык шулпасының бар күркәмлеге бисмилла әйтүгә генә кайтып калса, ашаганда телне йотарлык булмас иде ул,— дип, каршы төштем ана.

— Мактама мине, җитәр, сөймим үземне мактаган кешене, дошманлашуыбыз бар. Бөтен хикмәт монда минем чын табигать баласы булуымда, брат,— диде Мин ага, тирән көрсенеп.— Табигатьнең улы булуым бүгенгә кадәр яшәтте. Югыйса туганнан бирле инде йөз генә түгел, мең тапкыр аякларымны сузар идем. Сабый чагымнан ук үз күнемне күрәм. Бала чагым, бала чагым гына түгел бөтен гомер юлым меңләгән сикәлтәләрдән тора минем. Киләчәк буыннарга гыйбрәт өчен кәгазьгә күчерәсе иде дә башлап кичкәннәрне, әмма вакыты түгел әле аның. Хәзергә халтура белән шөгыльләнүдән уза алмыйм. Халтурага тотынмасаң, ач утырырга кирәк. Шулай да урамыбызга бәйрәм килгәнен көтмичә, инде җитди нәрсә әвәли башларга чамалыйм, брат. Аның урысча исемен дә таптым инде. «Сохатый» ул. Исеме нигә урысча дисеңме? Әлегә шуңа тәңгәл татарча исем табылмаганга. Сохатый — күп чатларга аерылган авыр мөгезле тәкәббер поши үгезе — алдындагы барлык киртә-каршылыкларны җиңәргә үзендә көч тә, куәт тә, тәвәккәллек тә, сәләт тә таба, юлын кармалап түгел, иң куе чытырманлыкларны да бар дип тә белми кодрәтле күкрәге белән ерып үтә. Әйберем шул сохатыйга тиң көчле рухлы кешенең язмышы, рухи дөньясы турында булачак.

— Кемнәр сатты сезне? Үндүрт ел гомерегезне урлаган хаиннар белән очрашасызмы, сөйләшкәнегез бармы, Мин ага? — дип кызыксындым мин.

— Брат, әйдә аларны искә алып бу матур төннең ямен дә җибәрмик, авызыбызның тәмен дә бозмыйк,— дип, кырт кисте әдип агам, озын куе чәчләрен уң кулының бармакларын җәеп артка тарап.— Йә, хәзер син сөйлә үзең турында...

Мин ага белән мина шул төннән соң яңадан иркенләп гәп куертырга туры килмәде. Шуңа күрә аның «Сохатыең» кәгазьгә күпме күләмдә күчерергә өлгергәнен белмәдем. Соңгы очрашуларыбыз вакытында ул турыда үзе сүз кузгатмагач, мин оятсызланып сорарга кыймадым. Кызганыч, сорыйсым калган. Кем уйлаган Мин аганың бары илле беренче яшендә көзге бер матур көнне бакчага ял итәргә чыккач кинәт кенә дөнья куярын...

## 2

Редакциябезнең чираттагы планеркасы бер сәгать чамасы барды. Гани абый анда эшебездәге күп җитешсезлекләрне телгә алды.

«Безнең иң зур кимчелегебез авторлар белән пассив эшләү»,— диде ул, басым ясап. Узган ел ук нәшриятнең тематик планына «Җидееллык маяклары» рубрикасы астында республикабыздагы Социалистик Хезмәт Геройларына багышланган брошюралар сериясы чыгару кертелүен, ләкин бүгенгә кадәр редакциягә ул темага бер генә кульязма да килмәвен ачынып искә алды.

— Болай ярамас, иптәшләр, очерк язу, һич шикләнмим, сезнең һәркайсыгызның кулыннан килә. Шуңа күрә «Җидееллык маяклары» сериясендәге брошюраларны җиң сызганып башлап җибәрерсез дим мин. Кайсыгыз кем турында язарга алына, уйлашыгыз. Казандагы Хезмәт Геройларыннан башлыйсызмы, районнарда торучыларданмы, анысын үзегез карагыз. Брошюраны үзегез язасызмы, әллә берәр автордан яздырасызмы, карагыз, минем өстәлемә өч ай эчендә һәркайсыгыз бер кульязма салырга тиеш.

Гани абый безнең алга мәсьәләне шулай кабыргасы белән куйды. Кемнәрнеңдер чиле-пешле кульязмаларын күпме төзәтеп чиләнергә була, тотынсам мин дә кайбер надан авторлардан да койты язмас идем, шәт, дип уйладым мин. Ләкин кем турында язарга? Брошюрада кешенең ничек герой булуын гына күрсәтмәскә, аның эш тәҗрибәсен дә бирергә кирәк бит. Ә мин нинди эшне беләм? Автор үзе сурәтләгән кешене, ул башкарган хезмәтне биш бармагы кебек белергә тиеш. Кем турында язарга? Бәлки, миңа нефть районнарына барып кайтыргадыр?.. Үзем яза алмасам, анда нефтьчеләр һәм аларның эшләре белән яхшы таныш берәр журналистны язарга күндерермен... Күпме генә уйлансам да мин ныклы бер карарга килә алмадым. Шуңа күрә бу мәсьәләдә редакциябез мөдире Гани абый белән киңәшергә булдым. Фикеремне тыңлагач, ул:

— Чыннан да, нефтьчеләр янына барып кайт син. Анда урыннардагы җитәкчеләр белән очрашып сөйләшерсең. Без, монда утырып, кемнең кем икәнен бөтенләй белмибез бит. Берәүнең төшендә Алтын Йолдыз, ә тормышта, гаиләсендә ул телгә дә алмаслык зат булуы мөмкин. Укучыларга без тәкъдим иткән Герой һәрьяктан уңай һәм керсез булырга тиеш. Сине Лениногорскигамы, Әлмәткәме ике атнага командировкага җибәрү турында Салих Борһанович белән сөйләшәм. Әйт, кайда барырга телисең?

Нинди җавап бирергә? Минем ул әйткән япь шәһәрләрнең икесендә дә булганым юк, кайсына барсам уңасымны белмим. Ләкин турыдан-туры куелган сорауга ачык җавап бирергә кирәк.

— Өзеп фәлән шәһәргә бара, дип урынын ачыкламый гына, нефть районнарына нәшрият йомышы белән җибәрелә, диеп булмыймы?

— Була, ник булмасын...

## Унөченче бүлек

### 1

Аэропортта билетны Бөгелмәгә алдым. Июнь башының иң матур көннәренең берсе иде. Самолетта урыным иллюминатор янына туры килде. Иллюминатордан юл буе җир өстен күзәттем. Самолет, очмады, бер урында торды төсле. Әмма җирдәге күренешләр даими алмашындылар. Казан читендәге төрле зурлыктагы яшел ямаулыкларга охшаган урман кишәрлекләрен соргылт кырлар, кечкенә генә болынлыклар алмашты. Кырлар уртасыннан бормаланып-бормаланып аккан инешләр, ямьсез яра җөенә охшаган коры чокырлар, анда-санда эреле-ваклы күлләр, сулыклар, тирә-якка киң җәелгән Кама елгасы, аның аръягына сибелгән кәрке-бөкре урамлы авыллар артта калды. Аннары кырлар киңлегендә челтәрле вышкалар, утлы ялларын як-якка җилфердәтеп күксел төтен бөркеп янган факеллар пәйда булды. Мин аларны кызыксынып күзәттем һәм үземнең инде нефть районнары өстеннән очуымны аңладым. Челтәрле вышкалар да, купшы факеллар да отыры ишәя бардылар. Хәтеремдә, 1959—1965 елларда СССР халык хуҗалыгын үстерүнең контроль саннарында билгеләнгән «1965 елда нефть чыгаруны 230—240 миллион тоннага яки 1958 елдагы белән чагыштырганда ике тапкырдан күбрәккә арттыру, газ чыгару һәм газ җитештерүне 1958 елдагы 30 миллиард кубометр урынына 150 миллиард кубометрга җиткерү яки чама белән биш тапкырга үстерү күздә тотыла», дигән сүзләр яңарды.

Бөгелмә аэропортында самолеттан төшкәч, беренче очраган машинага утырып, Лениногорскига килдем. Анда партиянең шәһәр комитетын эзләп тормадым, туры шәһәр газетасы редакциясенә юнәлдем. Нининдидер эчке сиземләвем миңа, журналистлар тормышны да, кешеләрне дә партия эшкуарларыннан яхшырак та, якыннанрак та беләләр, әлегә партия шәһәр комитетына кереп вакыт сарыф итмәскә кушты.

Бәхетемә, редакциядә, кулга алынуыма кадәрге студентлык елларымдагы дустым Мәүлә Хәсәнов белән бергә театр училищесында укыган Шамил Бикчурин очрады. Без аның белән якын танышлар булмасак та, ике-өч тапкыр күрешеп сөйләшкәнебез бар иде.

— Ирек, син түгелме соң бу? — дип, каршыма килде ул, мин редакциянең дубляж бүлмәсенә барып кергәч.

— Әйе, Шамил, мин бу, исәнме,— дидем, аңа күрешергә кулымны сузып.

— Сине нинди җилләр ташлады монда? Кайда туктадың?

— Беркаяда туктамадым, әле килешем генә.

Шамилнең озынча ябык йөзендә елмаю, көләч соры күзләрендә шатлык очкыннары кабынды.

— Булды, миндә тукталасың. Миңа кайтабыз.

— Мин берничә көнгә генә түгел, озакка килдем бит, Шамил.

— Хет ел буена кил, үземә туктыйсың, сине мин беркая да җибәрмим. Фатирым шәп — өч бүлмәле. Гайшәм, балаларым белән танышырсың. Миндә сиңа комачаулаучы булмас. Әйдә хәзер үк кайтабыз безгә.

— Туган, ашыкмыйк, зинһар. Миңа бераз сулу алырга бир. Башта мин партиянең шәһәр комитетына кереп, төп йомышымны йомышлыйм, бәлки монда тоткарланырга да туры килмәс миңа.

— Ул нинди йомыш? Сер булмаса әйт.

Шамилгә мин Лениногорскига ни өчен килүемне озынга сузмый гына сөйләп бирдем.

— Горкомга кагылуның һич кирәге юк сиңа. Тот та әнә вышка төзүчеләр бригадиры Социалистик Хезмәт Герое Александр Григорьевич Тимченко турында яз. Үзе коммунист, үзе шәһәр советы депутаты. Һич арттырып әйтмим, кристалл кебек кеше. Гаиләсе дә бер дигән.

Хатыны Анна Павловна белән гөрләтеп дүрт бала үстерәләр. Өстәвенә, күптән түгел үзенең алдынгы бригадасын ташлап, ул артта сөйрәлгән бригадага күчте, аны җитәкли башлады. Александр Григорьевич турында мин үзем күптән язарга кыҗрый идем инде, синең килүең әйбәт булды әле, өстемнән ул йөк төшәчәк, боерган булса.

— Мин сиңа комачауламам, яз соң, сиңа нәрсә комачаулый?

— Булмый, Ирек, мин инде күптәннән башка эш белән мәшгуль. «Тальян гармун» исемле музыкаль комедия өстендә утырам. Сиңа материаллар җыйнауда кулымнан килгән кадәр булышырмын. Менә бүген кич үк Тимченконың үзен күреп сөйләшеп, иртәгә бригадасының эш урынына барырбыз. Һич тә борчылма, очрашуыбыз әйбәт булды әле. Иркенләп сөйләшербез. Хәзер безгә кайтабыз.

Шамил — нефть төбәгендә туып үскән егет. Әлмәттә урта мәктәпне тәмамлаганнан соң ул ике ел Казанда театр училищесында укыган һәм училищены бетергәч Әлмәт драма театрына актер булып кайткан. Аннары дүрт ел чамасы Совет Армиясендә авиация частьләрендә хезмәт иткән. Армиядән кайткач Әлмәттә алты елга якын төзелештә эшләгән. Инде менә дүрт елдан артык Лениногорскида чыга торган «Ильич васыятьләре» исемле шәһәр газетасы редакциясендә промышленность бүлеге мөдире вазифаларын үти икән.

Без аның фатирына кайтып, ашап-эчкәч, мин партиянең шәһәр комитетына кереп командировка кәгаземә билге ясатып чыктым. Аннары Шамил мине Лениногорск белән таныштырып йөрде. Шунда нефтьчеләр һәм вышка төзүчеләр турында да сөйләде.

— Менә син үзеңнең брошюраңда вышка төзүчеләргә, образлы итеп әйтсәк, «албастыларны йөгәнләүче»ләргә мәдхия җырлаячаксың. Ә бит нефть бораулау вышкаларын бер урыннан икенче урынга күчергәндә табигатькә никадәр зыян китерелүен, вышкаларның юлларында очраган бөтен каршылыкларны җимереп үтүләрен, чәчелгән күпме иген кырларын аяусыз таптауларын, урманга юлыкканда йөзьяшәр агачларны вәхшиләрчә аударып, вышканы үткәрергә утыз-утыз биш метр киңлектә сукмак салуларын мактаячаксың. Бер уйласаң, нефть — каза ул безнең Татарстанга. Республикабыз аңардан зыяннан бүтән нәрсә күрми. Киләчәк буыннарга без үзебездән соң вәхшәттән башка нәрсә калдырмыйбыз. Аянычлы бу. Әмма без, Татарстан илгә һәр көн фәлән мең тонна кара алтын бирә, дип ахмакларча лаф орабыз. Безне талыйлар, без шуңа куанабыз. Ник беребезнең моңа йөзе кызарсын да, намусына хилафлык килсен. Беребез дә төнлә йокысыннан куркып уянмый, беребез дә байлыгыбызның талануына борчылмый, һәммәбезнең җаны сабыйларныкы күк тыныч. Ә бит безгә күптән разбой салырга, талыйлар, коткарыгыз, дип каравыл кычкырырга кирәк. Инде күпме бер дигән чәчүлек җирләребез әрәм булды, күпме елгаларыбыз, күлләребез пычранды, түкереп тә бирмибез аңа, бер көн белән яшибез. Нефть бездә мәңгелек түгел, күп дигәндә тагын кырык-илле ел чыгар. Аннары ул хәзинә чишмәсе корыр. Туган төбәгебездә тик берничә яраксыз җирләр һәм бары шымытыр гына калдырганыбыз өчен безгә оныкларыбыз ләгънәт укырлар. Син брошюраңда шул турыда да телгә алырга онытмассың, шәт?..

— Алдынгы тәҗрибә турында язуның мәгънәсе юк дисең син, алайса? — дидем мин, сагаеп.

— Син мине дөрес аңламадың, — дип каршы килде миңа Шамил. — Алдынгы тәҗрибә, фидакарь кешеләр, ирешелгән уңышлар турында язарга кирәк. Ләкин шул ук вакытта хакыйкатькә дә күз йоммау, аны да читләтеп үтмәү хәерле. Әнә факелларда көн саен меңләгән кубометр кыйммәтле чимал — нефтькә ияреп чыга торган газ яна. Газ түгел, күз алдыбызда берниндн файдасызга акча-валюта көлгә оча, шагыйрьләребез моңа зар елыйсы урынга, ахмакларча куаналар. Газ факелларыннан алар илһам алалар. Ә бу төбәктәге авылларда гомер сөрүче кешеләр торакларын утын ягып җылытырга мәҗбүрләр. Сөйли китсәң күп ул

бездәге житешсезлекләр. Шуларга үзебезнең битараф калып күз йомуыбыз чыгырымнан чыгара мине. Хәлне кемнеңдер читтән килеп үзгәртүен, төзәтүен көтәбез. Ә аның алай булмасын, бөтен чатаклыкларны үзебезгә юк итәргә туры киләчәген уйларга куркабыз...

Шул рәвешчә күп зарланды Шамил. Мин аны бүлми тыңладым. Ул тормышның үзәгендә кайный, мин мондагы җирле хәлләрне бөтенләй белмим, ни әйтим... Дөрес сүзгә җавап юк, диләр бит. Уйланырга шактый азык бирде миңа Шамил, ләкин сөйләгәннәре турында нигә үзе беркая да язмый икән, аңлашылмый.

Шамилнең ай-ваена карамыйча кунак йортына урнаштым. Сөймим кемгәдер бәйле булуны, кемгәдер комачаулауны. Кунак йорты — кеше фатиры түгел, анда син үзеңә-үзең хуҗа, теләгән вакытыңда теләсәң нишли аласың, кемнәндер тартынасы юк. Аннары безнең халыкта «кунак — өч көн генә кунак, өч көннән соң имгәк» дигән әйтем дә бар.

## 2

Кичен булачак героем Александр Григорьевич Тимченконың өенә бардык. Партиянең шәһәр комитетыннан аңа минем килүемне һәм аның белән сөйләшергә теләвемне инде хәбәр иткәннәр иде.

Герой тыйнаклыгы, гадилеге белән миндә уңай тәэсир калдырды. Шамил белән минем үзен нигә борчуыбызны әйткәч, ул уңайсызланып:

— Мин 1927 елның мартында Краснодар краендагы Ильская станицасы казагы Григорий Тимченко гаиләсендә дөньяга килгәнмен. Утызынчы елны әти-әниләрем станицадан Грозный шәһәренә күчкәннәр һәм әтием анда нефть промыселында тракторчы булып эшли башлаган. Кечкенәдән үк мин әзмәвердәй таза агайларның ничек нефть скважиналары бораулауларын, биек-биек буровой вышкалары төзүләрен дөньямны онытып күзәтергә ярата идем. Әмма бала чагым бөтенләй булмады диярлек. Кырыгынчы елны әнием үлеп китте, тагын өч елдан әтисез дә калдым. Тәрбиячеләремне югалткач, әтинең дуслары мине һөнәр мәктәбенә урнаштырдылар. Мәктәпне бетергәч, Грозный нефтегазразведка конторасында вышкалар төзү бригадасында эшли башладым. 1950 елның җәендә без — өч аерылмас дус — Коля Литовченко, Саша Зайцев һәм мин эшкә монда — Татарстанга килдек. Кыскача биографиям минем шундый. Тормыш юлымның калган өлешен әнә Нюра сөйләр, ул аны биш бармагы кебек белә. Бүгенгә сүзне шуның белән тәгәллик. Иртәгә таңнан ук сез автовокзалга килегез, мин шунда булырмын, бригадам членнары белән танышырсыз, бергәләп вахта машинасында эш урыныбызга барырбыз,— дип, Александр Григорьевич сүзен тәмамлады.

Александр Григорьевич Тимченко, беренче карашка, башкалардан аз гына да аерылып тормый. Уртачадан аз гына калку гәүдәле, нык бәдәнле, озынчарак йөзле, киң маңгайлы, калын иренле бу кешенең уйчан соры күзләре һич онытылмас булып күңелгә уела. Геройның хатыны Анна Павловна да аның турында, уены-чыны белән:

— Ул мине күзләре белән сихерләде,— диде.

Мин Александр Григорьевич белән тиз дуслашып китеп уртак тел таптым. Ул, башта уйлаганча, сүзгә саран булып чыкмады. Үзе турында:

Мин 1954 елның май аенда вышка төзүчеләр бригадасына җитәкчелек итә башладым. Озакламый безнең бригадага Татарстанда беренче тапкыр 111 нче буровойны сүтмичә борыслар ярдәмендә күчерергә рөхсәт иттеләр. Куанычым эчемә сыймады,— дип, сөйләргә керешә ул үзенең үткәне турында.— Әмма буровойны күчерә башлаганчы зур әзерлек эшләре үткәрергә, яңа ысул белән кешеләрне яхшылап таныштырырга кирәк иде. Әзерлек эшләренә бер атна вакыт бирелде, ләкин ул аз булып чыкты. Коллективта бердәмлек тә, тәҗрибә дә җитәрлек түгел иде. Шуңа күрә беренче коймагыбыз төерле булып чыкты, уңышка ирешмәдек...

Уңышсызлыкка очрау Тимченконың рухын төшерми, ул шунда ук икенче — 104 нче буровойны күчерү эшләренә хәзерләнә башлый. Төннәр, көннәр буе бу авыр бурычны ничегрәк уңышлы башкарып чыгу турында уйлана. Александр Григорьевич 104 нче буровойны иске бораулау торбаларыннан әтмәлләнгән чана-чаңгыларда күчерергә карар бирә.

Ниһаять, әзерлек эшләре тәмамлана. Вышканы күчерергә сигез трактор бирелә. Кешеләр эшнең башлануын түземсезлек белән көтәләр. Бар кешедән бигрәк, Тимченко үзе дулкынлана.

Менә тракторлар да, вышкачылар да үз урыннарында. Александр Григорьевич, дулкынлануын җиңеп, күчерүне башларга боерык бирә. Тракторлар, әйләнә-тирәне дер селкетеп, урыннарыннан акрын гына кузгалалар. Бөтен кешенең күзләре вышкага төбәлә. Ул, очын күккә сузып, урыныннан һич тә кузгалмас төсле утыра. Кинәт иләмсез зәү вышка, бөтен гәүдәсе белән калтыранып куйгач, тракторлар артыннан шуыша башлый. Шулчак тракторларның көчле гөрелтесен басып «ура» яңгырый. Кешеләр бер-берсен кочаклыйлар, сабыйлар күк бии-бии вышка артыннан йөгерәләр.

Сәгать ярымнан буровой үзенең яңа урынына барып төпләнә. Бу Татарстандагы нефть мәйданнарында вышкалар төзү эшен яңа юнәлешкә борып җибәрүнең башы була.

Соңгы өч елда Тимченко бригадасы 145 вышка төзи. Ә 1951 елда исә бу бригада эшләгән конторада нибары 10 вышка монтажланган булган.

1959 елның 20 мартында Александр Тимченко һәрвакыттагы кебек эш урынында була. Ул үз коллективы белән Анатолий Криушин җитәкчелегендәге бригадасына буровой әзерләү белән шөгыльләнә. Көтмәгәндә алар янына җиңел машина килеп туктый һәм аннан КПССның шәһәр комитеты секретаре белән вышкалар монтажлау конторасы начальнигы төшә. Алар Тимченко янына килеп, аны иң югары бүләк — Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү белән котлыйлар.

Александр Григорьевич Тимченко белән элемтәм көтмәгәндә өзелде. Аңа Ставрополь краена нефтьчеләрнең ниндидер киңәшмәсенә кичекмәстән барырга кушкан телеграмма китерделәр.

— Менә, гел шулай, миңа тыныч кына эшләргә мөмкинлек юк. Йә бер җиргә, йә икенче җиргә «туй генералы» сыйфатында барырга боералар,— диде миңа Герой, үртәлеп.— Сез үзегезгә кирәк кадәр материалны инде туплагансыз, шәт? Безнең аралашуыбыз хәзергә шушының белән тәгәлләнсен. Үтенәм сездән, язмагызда мине күкләргә чөеп мактап, хакыйкатькә, зинһар, хыянәт итмәскә тырышыгыз...

Александр Григорьевичка телеграмма китергән машинада миңа урын табылмады, мин вышкачы егетләр янында кыр уртасында басып калдым.

Герой, бригадасына ашыгыч күрсәтмәләр биреп, кабаланып китеп барды. Аны, кем әйткәндәй, ай күрде — кояш алды. Мин эшемнең капыл гына өзелүенә борчылмадым. Тимченконың үзе турында да, эше турында да инде шактый материал тупларга өлгергән идем. Кырдан шәһәргә кайткач, озак уйлап тормастан, Герой кайдадыр «туй генералы» вазыйфаларын башкарып йөргән арада Каран районына кайтып килү турындагы күптәнге хыялымны тормышка ашырырга, ике-өч көнгә Бәешкә барып килергә булдым.

## Уندүртенче бүлек

### I

Нефтьчеләр төбәгендә үзем соңгы көннәрдә генә күргән Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт кебек чәчәкләргә күмелеп утырган шәһәрләрдән соң Каран миңа кечкенә дә, артык ябай да булып күренде. Әмма, шунысы да бар, ул бала чагымда актык кат күргәндәгедән ярыйсы ук төзекләнә төшкән, күпмедер киңәйгән дә иде.

Каранга килгәч, күңелем тизрәк Бәешкә барырга атлыкса да, бәлки Гайфине очратырмын, дигән өмет белән башта райкомга кагылырга уйладым. Райком моннан әле берничә ел элек кенә салынган ике катлы матур бинага урнашкан булып чыкты. Бинаның беренче каты буш иде, анда беркем дә очрамады. Йомшак, киң палас җәелгән баскычтан икенче катка күтәрелдем. Баскычның уң ягындагы бүлмәләрнең берсендә кемнеңдер телефоннан ярау тавыш белән сөйләшкәне ишетелде. Хуҗаларча сөйләшә бәндә. Сөйләмендә тартынып тормый, әдәпсез, тупас, ятышсыз тәгъбирләр дә куллана. Мин, кулымдагы кечкенә юл чемоданымны куяр урын эзләп, як-ягыма карандым. Коридор икенче катта да шып-шыр иде. Телефоннан сөйләшүче, кызганнан-кызып, кемнеңдер тетмәсен тетүен дәвам итте:

— Миңа синең кемлегеңне кешедән сорыйсы юк, аклануыңа үз тизәгеңне ашап күрсәтсәң дә ышанмыйм. Икейөзлелекне җенем сөймәгәнен беләсең. Сиңа районыбызны бүтән артка сөйрәргә ирек куймам. Хатының зарланып хат язган миңа, өстемнән йөри, тәртипкә чакырыгыз, түземем төкәнде, печегез ул мир үгезен, дигән. Бер мәкаеңә хуҗа була белмәгән нинди ир син?..

Ирексездән ишеккә бардым. Ул яртылаш ачык иде. Аңа беркетелгән пыялага бик матурлап «Райкомның беренче секретаре Гайфетдин Баһаветдинович Бәдретдинов» дип язылган булып чыкты. Димәк, бөтен райком бинасын шаулатып, телефоннан кемнедер Гайфи сүгә! Юк, ул булмас, ул түгелдер. Балалык дустымны мин мәрхәмәтсез түрә итеп күз алдыма китерә алмадым. Гайфетдин Баһаветдинович Бәдретдинов, бәлки, Гайфи түгел, бүтән кешедер?.. Шулай уйлап та бетермәдем, ишекне шар ачып башындагы кызгылт чәчләре керпе инәләре күк тырпаеп торган таза, нык гәүдәле кеше коридорга атылып чыгып, миңа:

— Сезгә нәрсә кирәк, нигә минем ишегем төбендә шпионить итәсез? — дип акырды.

Мин ихтыярсыздан артка чигендем.

— Миңа берни дә кирәкми, Җирән, тынычлан. Шпионлык итү минем вазыйфам түгел.

— Тукта, син Ирек бит? Ирек Кадыйров...

— Булсам соң!..

— Син исән, димәк?! Әйдә, кабинетка үтик, сөйләшик. Бир чемоданыңны миңа.

Кабинетка кергәч, кочаклашып күрештек.

— Син кайда, нинди эштә хәзер? Нинди җилләр ташлады безгә?

— Мин синең кебек зур кеше түгел, Гайфи. Нәшриятта мөхәррирмен. Торуым Казанда.

Кабинет хуҗасы тиз генә барып ишекне бикләде һәм китап шкафыннан коньяк шешәсе чыгарып, ике бәллүр чәркәгә коньяк койды.

— Әйдә очрашуыбыз хөрмәтенә каплыйк әле шуны.

Чәркәләрне кулларыбызга алдык.

— Синең исәнлеккә, Ирек, — бүлмә хуҗасы коньякны күз ачып йомганчы эчте. — Әйдә сузма, син дә түнтәр.

— Рәхмәт, дус, эчмим бит мин, үпкәләмә.

— Ни дигән сүз ул — эчмим? Эчмәгән кеше юк ул дөньяда. Кыстасаң, хәтта тавык та эчә.

— Ә мин эчәргә өйрәнмәдем, дус.

Гайфи миңа сынаулы текәлде.

— Эчмим дигәнеңә ышанмыйм, Ирек. Ярар, эчмәсәң эчмәссең, әйдә сөйләшик әле. Очрашмавыбызга өч дистә ел бит инде. Монда күпмегә кайттың? Ниләр майтармакчы буласың?

Без кара-каршы утырдык. Мин озынга сузмый гына үземнең нефть районнарына нинди йомыш белән килүемне, анда эшемдә көтелмәгән өзеклек тугач, форсаттан файдаланып, берочтан Бәешкә дә кагылып китәргә дип монда кайтуым, җай килсә өлкә газеталарының берәрсенә бу

районндагы берәр кеше турында очерк язарга ниятләвем турында сөйләп бирдем.

Бөкерене кабер генә төзәтә, диләр, рас ул. Моны мин Гайфигә карата әйтәм. Ул малай чактагы дуамаллыгыннан һаман арынмаган күренә. Районыгызда син кем турында язарга киңәш итәр идең, дигәч, уйланып та тормый:

— Тот та минә минем турыда яз,— диде турыдан-туры.— Районым Татарстанда алдынгылар рәтенә үк күтәрелә алмаса да, артта сөйрәлми, уртада бара. Республикабыз җитәкчеләре алдында йөземне кызартырлык эшләмәдем, менә тиздән бу эштә унбиш ел инде, партия өлкә комитеты бюросына чакырып ник туганыма үкенерлек итеп сүккәннәре юк әле. Тыныч елларда да инде ике орден алдым. Чынлап әйтәм, яз минем турыда. Бала чакта аерылмас дуслар идек, бары Бичура гына аерды безне. Биш бармагың күк беләсең син мине.

— Кайда икән хәзер ул Бичура, белмисеңме? — дидем.

— Исән әле ул, исән эт җан.— Гайфи урыныннан торып тәрәзәгә барды.— Бәештә ул. Сугыш вакытында үзе тәмам аяктан еккан авылыбызны калдырып китә алмый, әле дә кисәү башы кебек пыскып ята.

— Бәешне ул ничек аяктан екты?

— Сугыш башлангач, Зиннәт абый урынына аны колхоз председателе итеп куйдылар. Аннары аны райком секретарына күтәргәннәр. Шунда бирепме-биргән районның кирәген. Дәүләт йөкләмәләрен даими арттырып үтәп, республика җитәкчеләре алдында яхшы атланып талаган колхозларны. Районыбызны дәүләткә ашлык, ит тапшыру йөкләмәләрен бер ярым-ике тапкырга арттырып үтәткән. Урыслар, ахмакны чукынырга кушсаң маңгаен яра, диләр. Бичура да шулай чукынышмы чукынган. Алдын-артын уйламый һәр кушканда ләббәйкә дип, түрәләргә тугрылыклы хезмәт итүче андый ахмакларны югарыдагы иптәшләр яраталар, хуплыйлар. Кырык сигезенче ел йомгаклары өчен Бичура хәтта Почет билгесе ордены белән дә бүләкләнә. Бүләкләмәскә, районны тәмам хәерчелеккә чыгарганы өчен, стенага терәп бөтен халык алдында атарга кирәк иде аны. Юк, атмыйлар, бүләклиләр. Аның эшчәнлегенең җимешләрен мин менә әле дә татыйм. Районыбыз тиешенчә тернәкләнә алмый, әҗәл чире йоккан хаста шикелле изалана.

— Хәзер ни эшли Бичура Бәештә?

— Берни дә эшләми. Ходайдан кылган гөнаһларын, кешеләргә эшләгән этлекләрен ярлыкауны сорап намазлык өстендә тәсбих тарта, диләр. Бәеш кешеләренә әллә ул бар, әллә юк, да. Аннары бүгенге Бәеш элек син белгән Бәеш түгел инде. Баргач күрерсең, бетте ул.

Мин Һаҗәр апаны намазлык өстендә тәсбих тартып утыра итеп күзалларга тырыштым, әмма булдыра алмадым.

— Диннән җан тынычлыгы эзләргә утыргач, коммунистлыгы, кызыллыгы шулкадәр генә булган инде аның.

— Без бала чакта ук үз йөзе юк иде бит Бичураның. Ролен ятлау кулыннан килми торган хәтерсез артистка кебек иде ул. Хәтереңдәдер, дәрескә таушалып беткән «әфтияген» алып кереп шуңа карап безгә «белем» бирә иде. Күрсәң, танымыйсың син аны. Элек сыра кебек кипкән, көчле җил очырып алып китәрдәй арык иде, хәзер сыра мичкәсе белән бер, ана үрдәк төсле әле уңга, әле сулга янтаеп көчкә йөри. Мине элеккечә үк күрәлми, тәкерекләрен чәчә, тәһарәте бозылып, үткән юлын юешлиюешли, күзе кая караса, шул якка теркелди. Габбасы сугыштан кайтмады, фашистларга әсир төшеп дөмеккән, диләр.— Гайфи, сөйләвеннән бүленеп, тәмәке кабызды.— Син, кем турында языйм, дисең. Яз менә Бичура турында. Сиңа мин аның стартыннан финишына кадәр бөтен үткән юлын күзалларга булышырмын. Үз «геройларын» белсен халык. Килештекме?

— Юк, дус, килешмәдек, мин үләксә козгыны түгел.

— Сәер кешегә әйләнгәнсең син, Ирек дус. Ул хәшәрәтне үлгәч түгел, исән чагында хурлык баганасына кадакларга, аның гомер юлының

чирканычлыгын бөтен кабахәтлеге белән ачып салырга кирәк. Менә без хәзер Сталинга нинди генә ләгънәтләр яудырмыйбыз. Даһи атабыз үзе исән чакта кайда булган бүген ана, каһәрле каргыш яудыручы акыллы башлар? Бу бит сугыш тәкәнгәч, җиңелгән дошманның чыраена лач итеп төкереп үч алуга бәрабәр. Ярый, Бичура турында ни өчен язарга теләмәвең аңлашылды, ә минем турыда нигә язарга теләмисең?

— Синнән аллы-гөлле куык өрәсем килми.

Балачак дустым миңа сынаулы текәлде.

— Аңлат, ни дигән сүз ул аллы-гөлле куык?

— Гомере чикле, үзеннән-үзе шартлап юкка чыга торган куык. Сабын куыгы. Менә мин әле генә синең кемнедер телефоннан пешекләвеңне ишетеп тордым. Кешеләргә дә, үз-үзеңә дә хөрмәтең юк синең.

— Син үзеңне минем урынга куеп кара, шунда хөрмәтнең нәрсә икәнен бәлки аңларсың...

— Кеше кайда да кеше булып калырга тиеш. Агым иркенә бирелү берәүне дә бизәми.

— Шәп сөйләштек, әйбәт бәя бирдең син миңа, Ирек дус, рәхмәт. Кеше күзендәге тузан ясмык кадәр булып күренгәндә үз күзеңдәге юан бүрәнә чәч калынлыктан артмый, дия иде безгә Камали бабай. Ничек акыллы әйткән ул зирәк карт,— диде уйланып кабинет хуҗасы...— Эчмәдең син минем коньякны, кая, әрәм булмасын, салыйм әле мин аны.

— Камали бабай исән түгелмени инде?

— Исән түгел, үлде ат җанлы риясыз карт. Аның сыңар бәбәге йомылгач, Бәештә атлар да калмады, бетте.

Кинәт йөрәгем кысылып куйды. Күз алдыма төнге урман, алан уртасында янган зур учак, әйләнә-тирәдә ара-тирә пошкыргалап кертт-кертт үлән кыркучы атлар, учак янына тезелеп утырган малайларга сул кулын ялкау гына селтәп ашыкмый гына нәрсәдер сөйләүче сыңар күзле карт килде...

Балачак дустымның:

— Районымда минем куык булмастай кешеләр дә бар,— дигән сүзләре уйларымны бүлде.— Әнә элекке сабакташыбыз Сәлмәнне «Правда» газетасына язарлык. Бәештә ул хәзер шикәр чөгендере үстерә, һәр елны гектардан дүрт йөз центнердан артыграк уңыш җыеп ала. Быел мин аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирергә тәкъдим итәчәкмен. Ул элеккечә үк мыштым булса да фронттан да түшендә орден ялтыратып кайтты. Хатыны Таифә дә аңардан калышмый. Анысы алдынгы сыер савучы. Икесенең дә рәсемнәре район мактау тактасында. Һич икеләнми яз шулар турында. Күрерсең, ике куянны берьюлы тоту булыр бу сиңа: бүгенге Бәешне дә күрерсең, кешеләр күңеленә хуш килердәй әйбер дә язарсың.

Мин китәргә дип урынымнан тордым.

— Олылап каршылавың өчен рәхмәт, дус. Сине бераз эшеңнән бүлдем, ачуланма. Юлчының юлда булуы хәерле, ди китап. Мин Бәешкә юнәлим булмаса.

— Сине эшеңнән бүлдем, ачуланма... Нинди сүз ул? Бүген мин сине беркая да җибәрмим. Утыз елдан соң бер очраш та, ай күрде, кояш алды кебек аерылыш. Син үзең турында, Сабир абый, Мәликә апа турында ләм-мим сүз әйтмәдең бит әле. Хәзер менә миңа кайтабыз, хатыным, балаларым белән танышырсың. Син миңа иң якын туганымнан да артык, бел. Еш искә алам мин безнең үткәнне. Кәрим сугышта бетте. Сәләй утырып кайтты да, авылда төпләнмәде, читкә, шахтага олагасы итте. Аның белән күрешмәгәнгә дә инде биш былтыр. Син дә менә күпме югалып торгач кына пәйда булдың. Мин безнең бу очрашуыбызның чынлыгына ышанып бетә алмыйм әле. Бәлки, бу күңелле төш кенәдер?

— Төш түгел, өн бу. Өндә очраштык без, Гайфи дус.

— Әйдә, киттек миңа...

## 2

Гайфи мине өенә алып кайткач, Бәешкә җибәрмәде, кунарга калдырды. Без төне буе черем итми сөйләшеп чыктык. Иртәгәсен, ашап-эчкәч, балачак дустым мине райком машинасында Бәешкә илттереп куйдырды. Гайфи белән без өч көннән очрашырга килешеп аерылыштык.

Бәешкә яңадан аяк баскач мин үз күзләремә ышанмадым. Балачагым эзләре тирән уелган, кайларда гына булсам да үзен сагындырган, нинди генә кыенлыклар кичергәндә дә күңелемдә нурланып, үзенә тартып торган авылны мин, аңа кабат аяк баскач, танымадым. Бәешнең электәге җисеме инде юк, тик исеме генә калган булып чыкты. Авыл урамына яңадан аяк басуымның беренче минутларында ямьсез төш күрәм кебек хис иттем. Аптырап, як-ягыма карана-карана, электән таныш нәрсәләрне эзләдем. Әнә Каршы тауның Кәңгелде борыны, әнә Кызылъяр... Чыннан да, алармы соң? Кәңгелде борыны сөзәкләнгән, Кызылъяр ничектер тәбәнәкләнеп, басылып калган кук. Авыл читеннән бормаланып аккан Чуал да үзе түгел сыман. Ярлары шәрә. Мин белгән Чуал ярларының ике ягында да шаулап таллар, шомыртлар, зирекләр, тупыллар, миләшләр үсә иде, кая киткән алар, аңлый алмадым. Күп еллар элек Ярулла абзыйлар бүре өне тапкан тын коры чокыр тирәләре дә шып-шыр, анда да тик күңел өчен ник бер агач түгел, койты гына куак әсәре сакланасын! Әнә чокыр үзе иләмсез дәү ямьсез яра җөенә охшап калган. Тәкәрлекләр, кыр үрдәкләре, тузбашлар патшалыгы Чәтертән дә юкка чыккан, аның өстендә кайчандыр яшел зифа камышлар үскәнгә ышанырлык та түгел, сазлыкны табигатькә гүя үч итеп киптергәннәр. Аны кыл урталай ярып, Чуалга таба киң һәм тирән канау ерылган. Бәлки кыр уртасындагы борынгы кабер өстендәге ялгыз карт нарат та юктыр, ул да кемгәдер комачаулаган, аны да вәхшиләрчә кискәннәрдер инде? Юк, ул бар, тарих шаһитенең яшәвен чикләргә мәнсез залимнәрнең ничектер куллары житмәгән, әнә аның еллар инде шактый сирәкләгән ябалдашы миңа еракган сәлам бирә. Тукта, авылда өйләрнең яртысыннан күбрәге кая киткән? Нигә урамнар тешләре санаулы гына калган әби авызына охшыйлар: анда бер өй, монда бер өй... Санап бетергесез бушап калган пуҗымнарны тигәнәк, алабута, билчән, әрем, кычыткан кебек фәкыйрьлек үләннәре баскан. Бәлки Бәешкә түгел, бөтенләй чит-ят авылга тап булганмын мин?.. Юк, бу Бәеш — мин юкта үзгәргән яңа Бәеш. Әнә манарасы кисеп төшерелгән мәчет-мәктәп. Эх, әти, әти, шундый матурлыкны бозарга ничек кулың барды синең? Бәлки, Бәешнең йөзен үзгәртүгә беренче булып син өлеш керткәнсең, мондагы бөтен вәхшилекләр шуннан башлангандыр һәм син шуның тиешле җәзасын алгансың, ә? Җинаятеңә күрә җәзаңны... Мәчет-мәктәп бүгенгегә үткәннең шелтәле һәйкәле булып, ишелергә ниятләп янгайган. Аның таш атып бала-чага өлгеләрен койган чепи тәрәзәләре дөньяга битараф, бернинди кызыксынусыз карыйлар. Тирәсендә түбәләрен тубал-тубал карга оялары бизәгән карт тупылларның инде берсе дә юк, алар кая киткән? Бәлки, ул тупыллар корыганнар һәм утынга туралганнардыр?

## 3

Үземә бөтенләй ят, таныш түгел Бәешкә юлыгуыма аптырап, мин бер урында озак басып тордым. Башлап кай тарафка юл тотарга, базып кем ишеген шакырга белмәдем. Зада апалар өенең күе кычыткан баскан урыны гына калган, без торган өй дә юк, таш амбар да каядыр юкка чыккан. Ярулла абзыйлар өе урынында яңы белән салынган алты почмаклы, шифр түбәле яңа чибәр йорт калкып чыккан. Чү, ул өй алдында кайчандыр мин утырткан өч миләш агачының икесе исән икән

бит!.. Алар ничек үскәннәр, биегәйгәннәр! Үзем бала чакта утырткан миләш агачларын күргәч, дулкынланудан тыным кысылды, тамагыма тозлы төер бәялде. Мин аларның дөньяда барлыкларын бөтенләй оныткан идем бит инде. Шуларны күрер өчен генә дә кайтырлык булган миңа балачак сукмакларыма. Ә Ярулла абзый белән икәүләп утырткан шомыртларыбыз юкка чыкканнар, сакланмаганнар...

— Сәлам сезгә, ерак үткәнемнең җанлы шаһитләре, сәлам, миләшкәйләрем!..

Яңа йортка якынрак миләшнең коңгырт төстәге шома кабыклы кәүсәсен учым белән сыйпаганда, күзем ике тәрәзә арасына беркетелгән кара мәрмәр тактага төште. Анда, чокып алтын хәрефләр белән: «Бирелә Советлар Союзы Герое Ярулла Габделмалик улы Маликов яшәде. Ул, шушы нигездән фронтка китте һәм 1943 елның сентябрендә, Днепрны кичкәч, батырларча һәлак булды»,— дип язылган иде. Гаҗәпләнүдән авызымны ачып катып калдым. Үз-үземә ышанмый язуны кат-кат укыдым. Бу минем өчен көтелмәгән бик зур яңалык иде. Нигә аны теге вакытта миңа Сөләй, кичә Гайфи әйтмәде? Ул аны инде күптән белә булыр дигәннәрдер, бәлки? Күңелле хәбәрне соңарып ишетсәң дә шатландыра. Молодец, Ярулла абзый, кыю һәм батыр сугышкансың син, «аерым хуҗалык Бүре Ярулла» дип, үзеңне өнәмәгән авылдашларыңа алардан тамчы да түбән булмавыңны үзеңә бүтән тел-теш тидермәслек итеп исбатлагансың. Без, Ярулла абзый, синең белән бер үк тирәләрдә сугышкан булганбыз, күрәсең. Мин дә Днепрны кичү сугышларында катнаштым бит. Бәлки, частьләребез дә бер үк булгандыр әле. Мин танкист идем, син кем идең?

Ашыкмый гына, алдымдагы чибәр йортның киң болдырына күтәрелеп, өйалды ишеген шакыдым. Бераздан ишек төбенәчә ачылды.

— Нигә шакып торасың, кер, рәхим ит...

Тагын аптырап калдым. Бусага артында Хәбибә түти басып тора. Чәчләренең тоташ көмешләнүләренә күз йомсаң, ул, әз генә дә үзгәрмәгән, элеккечә кебек.

— Ирек үскәнем, син түгелме соң бу?..

— Мин, Хәбибә түти, мин...

Тиз генә бусаганы атлап кереп, гаҗәпләнүдән күзләрен зур ачып үземә текәлгән тутамны күкрәгемә кыстым.

— Ник бу көнгә кадәр күренмәдең, кайда югалган идең? Бәеш, без ике ятып бер төшеңә дә кермәдекмени, Ирек? Әйдә, өйгә керик. Салып торма аяк киемнәреңне, салма, салма...

— Бәешкә әле килешем генә, берәүгә дә туктарга өлгермәдем, менә килә-килешемә туп-туры сезгә кердем.

— Рәхмәт үз итүең өчен, үскәнем. Исән булса Ярулла абзаң шатланып бетә алмас иде килүеңә. Бик ярата иде бит ул сине, бик-бик ярата иде. Сугыштан кайта алмады мескенем...— Хәбибә түти яулык чите белән күзләрен сөртеп алгач, сөйләнә-сөйләнә чәй куйды.— Фатир эзләп беркая да барма, күпме теләсәң, шулкадәр монда торырсың. Менә бер атнадан оныкларым кайтыр, алар белән танышырсың. Әлфия белән Рәүф. Игезәкләр алар. Әби дип өзелеп торалар. Бала-чагагыз юк иде бит сезнең, оныкларың каян килде сиңа дисеңме? Ярулла абзаң сугышта башын салгач, бер ятим малайны үземә иптәш булыр дип уллыкка алдым мин. Әлфия белән Рәүф — шуның балалары. Зурлар инде, унынчы яшь белән баралар. Әтиләре — Якуб җир мае бораулый, әниләре укыта. Яшәүләре Әлмәттә. Якуб улым, әнкәй, кил безнең янга шәһәргә, ятма Бәештә бербашың, дип үзләре янына бик чакыра, минем гомер иткән нигеземә хыянәт итәсем килми. Мин китсәм, Ярулла абзаң монда кайтыр да мине эзләп бимазаланыр кебек. Ихлас менә. Мин, урман тавыгы сыман үз җырыма мавыгып, сиңа авыз ачарга да бирмим. Йә, сөйлә, кайда яшисең, гаиләң, балаларың бармы? Әтиең белән әниең синең беләнме?

— Яшәвем Казанда, Хәбибә түти. Хатыным һәм кечкенә кызым бар. Әти белән әнинең кайда икәннәрен белмим. Алар икесе дә утыз җиденче елны эзсез юкка чыктылар.

Хәбибә түтинең күзләре дүрт булды.

— Әтиеңне азат итмәделәрмени синең?

— Юк, Казанга баргач, әнине дә кулга алдылар.

— Тиле кешедәй сорыйм, аларга нинди гаеп яктылар?

— Их, Хәбибә түти, бүгенгә кадәр минем әле әтинең дә, әнинең дә гаепләрен белә алганым юк.

Хәбибә түти, ничектер күзгә күренеп үзгәреп, басылып калды. Ул, самавырын өстәлгә утырткач, табын әзерләде.

Мин йорт хуҗасының стенадагы зурайтылган фотосына, аның янындагы шүрлектә кечкенә пыяла тартмадагы Советлар Союзы Герое дипломына, Ленин ордены белән Алтын йолдыз медалена сокланып карадым. Мине моңарчы Ярулла абзый турында бернәрсә дә белмәвем борчыды. Татарлар арасында Геройлар һәр ун кешенең берсе түгел бит югыйсә, ничек аның фамилиясенә тап булмадым икән? Үз кайгым гына кайгы булу, башкалар белән кызыксынмау бәласедер инде ул. Аннары шул да бар, Ярулла абзыйны мин беркайчан да башкалардан аермалы итеп күрми идем бит.

— Безнең Бәешнең, күргәнсең, норы бетте, Ирек үскәнем. Бусаганы атлап урамга чыгарга тартынам, җаным әрни. Шүрәле каргаган авыл күк хәзер Бәеш. Сугышка чаклы соклангыч иде ул, хәтереңдәдер. Гитлер зәхмәте Бәешне дә читләтеп үтмәде, дим мин.

— Авылыгызның үз гитлерлары да өлеш кертмәделәрмени аңа?

— Кертмәгән кая, керттеләр. Иманны, оятны бетерделәр халыкта. Зада апаң белән без — ике аңгыра корткa, инде ахырзаман якынлашамы икән әллә, дип төннәр буе борчылып сөйләшәбез. Аңлый алмыйбыз бүгенге тормышны.

— Зада апа күренми, кая соң әле ул?

— Йә Хәйрүшенең чишмәсе янында кайнашадыр, йә бакчасында казынадыр, йә бүтән берәр җирдә нидер майтарадыр. Мин генә өй тавыгы күк өйдә утырам, кайдадыр буталып йөрүне сөймим.

— Хәбибә түти, ачуланмагыз, мин элек йөргән сукмакларымны чыгып барлап керим әле,— дип, урынымнан тордым.

Мин буеннан-буена тирән һәм сай казылмалар, төрле чүп-чар өемнәре белән чуарланган урам буйлап Чүлмәк тау ягына атладым. Бөтен әйләнә-тирәмдә ниндидер әсәрү бар кебек иде. Нәрсә җитми, нигә тирәюньдә сәер тынлык? Чү, элек авылга үзенә аерым бер хозурлык биргән, аны җанландырган тегермән буасы арыгының шавы ишетелми түгелме? Әйе, тегермәннең салмак кына эшләве ишетелми, ул тынган. Шуңа авыл мәет озаткан чактагы шикелле моңсу, басынкы...

Аякларым ирексездән тегермән урнашкан җиргә атлады. Тегермән юк, кая ул, монда мин әллә ялгыш килдемме? Буа да юк, ул кая киткән?.. Тегермән тирәсенә урнашкан ындыр табагы, рига, сушилка һәм башка корылмаларны әллә җир йотканмы? Тегермән кемгә комачаулаган, аның тирәсендәге хуҗалык каралтыларын сүтеп шәрәләү кемгә кирәк булган, аңлашылмый. Бәлки Чүлмәк тау да тигезләнгәндер, юкка чыккандыр инде?.. Алдымда яткан котелмәгән бушлык мине шыксызлыгы белән мәсхәрәләгән кебек булды, кәефемне кырды, рухымны рәнҗетте. Монда инде тормыш туктаган, калмаган иде. Мин кайчандыр гөрләп тегермән эшләп утырган, Бәешкә үзенчәлекле ямь, җанлылык биргән, инде тик минем хәтеремдә генә электәгечә сакланган урында артык калып җанымны әрнетүне кирәк санамадым, борылып, башым иеп, авыл эченә атладым. Һәр адымымда үзгәрешкә юлыгуым мине инде борчымады. Бәешкә килгән бәлаләрнең Мирсәет абыйның көйле хуҗалыгын читләтеп үтүләре, ул хуҗалыкка бернинди дә зыян ясамаулары мине гаҗәпләндерде. Әнә аның өе үз урынында. Ул инде шактый искереп, чүгә-басыла

төшкән. Әмма әле күңел кайтарырлык ямьсез дә, ямьсез дә, яшәмәслек тә түгел. Аңардан ишегалды белән аерылган җимеш бакчасындагы алмагачлар, караҗимеш, чия куаклары электәгечә үк күз явын алырдай матурлар. Алар хуҗаларына мул уңыш вәгъдә итәләр, ботаклары тулып килүче җимешләреннән хәзер үк инде сыгыла башлаганнар. Җимеш агачлары араларына урнаштырылган такта умарталар күпкә ишәйгәннәр — элек алар бишме-алтымы гына иде, хәзер ике дистә чамасы күренәләр. Умарталар төрле төсләргә буялган: ал, зәңгәр, кызыл, сары, күк, ак, яшел... Бер төстәгеләренең алларына йә чәчәк, йә агач яфрагы, күбәләк, гөмбә, йә кошлар сурәтләре ясалган. Бу — балкортлары үз умарталарын бүтән умарталар белән бутамасыннар, танысыннар өчен эшләнгән, күрәсең.

Мин урамнан рәшәткәле тәбәнәк койма аша Мирсәет абыйның җимеш агачларына, аллы-гөлле умарталарына сокланып басып торганда өйалды болдырына хуҗа үзе чыкты. Ул, чәчләре чалланып сирәкләнгәнен, гәүдәсенең юкаруын, аркасының бөгелә төшүен исәпләмәгәндә, күп үзгәрмәгән төсле күренде миңа.

— Кунак нигә урамда тукталды, керми, әйдә өйгә үтегез,— диде ул, иңләп кенә ишегалдына төшеп.

— Үтәрмен, Мирсәет абый, рәхмәт. Борчуым, тынычсызлавым өчен алдан ук гафу итүегезне сорыйм.

— Булмаганны сөйләмәгез, без кунакка һәрвакыт шат. Әйдә керегез, өйгә узыйк.— Мирсәет абый килеп урам капкасын ачты.— Кем дип әйтим сине? Тукта, әйтми тор, үзем таныйм...— Карт укытучы инде күрәкарауга әйләнә барган соры күзләрен миңа текәде.— Безнең элекке мәктәбебез өстендәге манараны кисеп аударган директорыбыз Сабир дисәм, ялгышырмын күк. Ул да, еллар үткәч, минем шикелле үк олыгайгандыр инде, картайгандыр... Аның улы, минем кайчангыдыр шәкертем Ирек бугай син?..

Шулай сөйләшә-сөйләшә өйгә үттек. Мотаһара апа өстәл әзерли иде. Мирсәет абый аңа:

— Күр, карчык, безгә кем килде, таныйсыңмы?— дип сүз кушты.

Мирсәет абыйның карчыгын еллар аямаган төсле. Электә һәрчак елмаюлы мөлаем йөзен тирән җыерчыклар чуарлаган, коры сөяккә диярлек калган кулын бүртеп өскә калыккан калын күрән тамырлар ямьсезләгән. Күзләре генә электәгечә үк яшь калганнар, картаймаганнар.

— Синең ишегалдында шар ярып сөйләшкәнеңне ишетеп тордым. Мәктәбегез өстендәге манараны кыеп төшергән директорыгыз Сабир малае Ирек диден бит. Кара, тач атаң икәнсең, балакаем. Әти-әниләрең, ничек, әле сау-тазалармы? Кайда алар?..

Мин җавап бирергә өлгермәдем, Мирсәет абый карчыгын ашыктырды:

— Әйдә чоланнан балыңны алып кер, атка җиккәнче үк чөнгермиләр. Башта өстәл янына утырыйк, сорауларыбызны чәйли-чәйли бирербез.

Чәй янында сүз башта җәйнең быел бик матур килүе, бакчаларда яшелчә-җимешләрнең мул булачагы, бал кортлары турында барды. Аннары әңгәмәбез мәктәп тормышына кайтты. Мирсәет абый инде байтак еллар укытмый, пенсиядә икән. Бәештә югары класслар бетте, башлангыч класслар гына калды, авылда балалар бик аз, алар бармак белән генә санарлык, ди.

Хәзер Бәештәге балаларга нибары ике укытучы белем бирә. Беренче, икенче сыйныф укучылары бер бүлмәдә — ике класс бергә, өченчеләре — аңысы чыгарылыш классы исәпләнә, аерым укый. Әйтергә оят, өч класска җәмгысе ундүрт бала. Өченче классны тәмамлагач, алар Чокырлыга китәләр. Анда сугыштан соң урта мәктәп ачылды. Ничек без бу көнгә калдык, башым җитми. Урысларның: «Моя хата с краю», дигән тәгъбирләре сиңа таныштыр, улым, соңгы егерме елда мин үзем дә, Бәеш

тормышында нәрсә булса шуңа ризалашып, аны хәзерге җан әрнеткеч хәленә китерергә булышучыларның берсе бугай...

— Бәешне дә, мәктәбегезне дә адәм мәсхәрәсенә калдыруны Һаҗәр башлады. Аны, ни кыланса да сүз әйтми, сез узындырдыгыз. Хәзер әллә кайчан китеп күздән югалган пароходка аулык болгап азапланма инде, карт,— дип иренә шелтә белдерде Мотаһара апа.

— Ярар, син һәрвакыттагыча хаклы, карчык, сүз көрәштермим,— дип тынычландырды Мирсәет абый карчыгын һәм миңа борылып, бүленгән сүзен дәвам итте.— Мәктәбебезнең һәлакәте синең әтиеңне кулга алу көненнән башланды дип исәплим мин. Әтиең кулга алынгач, директорлык вазыйфасы Һаҗәргә күчте. Без, укытучылар, аның наданлыгын, киреле-морлы холкы белән аңа җитәкче эшне ышанып тапшыру ярамаганны белә торып, район җитәкчеләренә, безгә Һаҗәр күк дуамал администратор кирәкми, дип беребез дә бармады. Коллективыбыз акрынлап таркалды, укучыларыбыз, мәктәптә сабак тыңлауга караганда, урамда трай тибүне артыграк күрә башладылар, мәктәптән күңелләре суынды. «Таләпчән» директор аларның укудан җаннарын биздерде. Сугыш башлангач, аны мәктәптән алып колхоз председателе иттеләр. Күпме кешене төрмәгә тыкты, күпме кешенең төрлечә теңкәләренә тиеп зар елатты ул, моны бер алла гына белә. Кемдер аңа ачудан өенә ут төртте, шунда ул чак янып үлмәде. Әмма янгыннан исән котылуы да акылга утыртмады аны. Аннары Һаҗәрне, каты куллы җитәкче дип, райком секретаре иттеләр. Анда да Бәештәге күк дуамаллыгын, пырдымсызлыгын куды. Кырык тугызынчы елның язында, Киртәледән Каранга кайтканда, кемдер атты аңа. Шайтан таягына кырау тияме, үлмәде, аксак булып кына калды. Шуннан соң, больницада дәваланып чыккач, райком секретарьлегеннән төшеп, Бәешкә кайтып төпләнде. Хәзер дин тота башлаган диләр. Үземнең аңа барганым да, аны якыннан күргәнем дә юк...

Карт укытучы, сүзеннән бүленеп, чынаягындагы суынган чәен уртлады.

— Мирсәет абый, каһәрләмәгез үзегезне, кирәкми. Заманы шул Һаҗәр апа ише «чаялар»ны узындырган заман иде бит. Дөрес, кояшлы көнне күләгәбезне ничек кенә узырга теләсәк тә уза алмаган шикелле, үткәндә эшләгән ялгышларыбызны да күпме тырышсак та оныта алмыйбыз, дигән иде миңа акыллы бер агай. Әйдәгез, Һаҗәр апаны читкә куйыйк, колагы шауламасын явызның. Сезнең менә дүрт улыгыз бар иде, алар хәзер кайда, дүртесе дә исән-иминнәрме?

Мирсәет абыйны бу соравым җанландырды.

— Кая, карчык, чәең суынды, самавырыңны яңарт әле, кунакны сүз белән генә сыйламыйк,— диде ул хатынына. Аннары миңа борылды.— Исән-иминнәр, малайларыбыз шөкер, әмма дүртесе дүрт яры. Өлкән улыбыз Әлмәттә. Ул минем һөнәрне сайлады. Педагог. Абаныбыз галим, Новосибирскидагы академгородокта. Алмазыбыз Карандагы үзәк шифаханәдә баш врач. Төпчегебез Альберт авиконструктор, Иркутскида яши. Бакча, хуҗалык, умарталар булмаса, кунактан кайтып керерлек түгел безгә, улларыбыз берсе артыннан берсе үз яннарына чакыралар. Ташлагыз шул чүплек башы Бәешне, күченегез теләсә кайсыбызга, үз өегездә ничек яшәсәгез, безнең янда да шулай иркен яшәрсез, диләр. Әмма Мотаһара апаң белән без Бәештән йөз чөерергә, аңа хыянәт итәргә теләмибез. Гомеребез шушында үтте, дөньялыктан да шушыннан китәрбез, дибез.

Чәйдән соң хуҗалар әти һәм әни белән кызыксындылар.

— Исән түгелләр, ахры, алар,— дидем мин, авыр сулап,— әти дә, әни дә утыз җиденче елны төрмәдә беттеләр шикелле...

— Нәрсә, әниеңне дә утырттылармыни? — дип гаҗәпләнде Мотаһара апа.— Син кем кулына калдың? Кайда үстең соң?

— Башта халык дошманнарының балалары асралган махсус төрмәгә урнаштырдылар. Бәхетемә мине аннан Кәбир исемле олы җанлы бер абый аралады.

— Син кем соң хәзер? Кайда яшисең, гаиләң бармы?

Картларга үземнең Бәештән киткәннән соңгы тормышым турында озынга сузмый гына бәян итәргә туры килде.

— Һәй, ниләр генә кичермәгәнсең яшь кенә башың белән, балакайгынам!.. Сугыш дәһшәтен дә үткәнсең, укыгансың да, өтермәндә дә утыргансың. Алла бәхеттән генә мәхрүм булма инде, кана,— дип, йомгак ясады мин сөйләгәннәргә Мотаһара апа, яулыгы чите белән күзләрен сөртеп.

Мирсәет абый исә сөйләвемне дә бүлмәде, карчыгы кебек юк-бар сораулар да бирмәде, тып гына утырды. Аннары сүз Казан хәлләренә күчте. Мин үземнең нефть районнарына нәшрият йомышы белән килүемне һәм форсаттан файдаланып Бәешкә дә кагылуымны әйттем. Бөгелмә, Азнакай, Лениногорск, Әлмәт тирәләрендә чәчүлек җирләрне нефтьчеләрнең кыргыйларча яраксыз хәлгә китерүләреннән, нефтькә ияреп чыккан газның еллар буе факелларда әрәм януларыннан зарландым.

— Әйе, бихисап кыйммәтле чимал күк җылытуга исраф ителә. Нефтьнең үзен дә дәррәү кубынып түгел, ашыкмыйча, план нигезендә, иплəп кенә чыгарасы бит югыйсә. Кабаланыпмы кабаланабыз. Әйтерсең, озакламый дөнья бетәчәк, өлгерми калачакбыз. Артыбыздан бастырып куып киләләр кебек. Минемчә, Татарстан хәзер турыдан-туры талана, нефть чыгарудан зыяннан башка нәрсә күрми. Бездә алга карау юк. Иртәгәсе өчен ишәк кайгырсын дип, бүгенебездә бернигә дә борчылмый гомер сөрәбез. Начар, бик начар чир бу. Мин инде алты дистәмне тутырдым, үз гомеремдә мин илебездә чәчләрне үрә торгызырлык әллә никадәр башбаштаклыкларга юл куелуга шаһит булдым. Тормышыбызда нинди генә тәҗрибәләр үткәрелмәде! Көчләп күмәк хуҗалыклар оештырулар, крәстиянне игенчелектән биздерүләр дисеңме, диннән ваз кичтерүләр, мәчетләрне, чиркәүләрне җимерүләр дисеңме — барысы да булды... Өлкәннәргә, ата-анага хөрмәт көннән-көн югала бара. Менә Әлмәттә яшәүче педагог улым Азатның бер атна элек кенә яныбызга кайтып киткәнен әйттем бит әле, аңа да зарландым шушылай. Күлә. Аларны син генә үзгәртә дә, төзәтә дә алмыйсың инде, әти, юк-барны күрмәскә тырыш, ди. Каян килгән аңа шундый пошынмау, гамьсезлек, битарафлык? Аның өчен миңа оят булды, үртәлдем. Һәр нәрсәне йөрәгенә якын кабул итмә, әти, җиргә мәңгегә килмәгән син, болай да какшаган нервларыңны бетермә, сафтан чыккан нерв күзәнәкләре кире яңармый, яшә тыныч кына, дип үгетли, җитмәсә. Кем өйрәтте сиңа ул мәгънәсез юату сүзләрен, кайчан сукыр обывательгә әверелдең, улым, дим. Тормыш, яшәешебез өйрәтте, ди, күзен дә йоммый.

— Карт, чамадан ашасың түгелме син, ә? — дип, йомшак кына иренең сүзен бүлде безнең әңгәмәне игътибар белән тыңлап утырган Мотаһара апа.

— Чамадан ашсам, тыңлама, карчык, сиңа сөйләмим. Азатның рухи гариплеге безнең икебезнең ике төрле тәрбиябез нәтиҗәсе ул. Бер дә бүтән түгел.

Мотаһара апа көлде.

— Һәй, карт, гомер иттек, дүрт бала үстердек, аларга синең уңай, минем ялгыш тәрбия биргәнемне, әйтмәсәң, белми идем. Рәхмәт күзләремне ачуыңа, Мирсәет...

Хуҗа белән хуҗабикә арасында тынычлык урнаштырырга кирәк, табак-савыт шалтырый башларга чамалый кебек, дигән уй узды башымнан, һәм:

— Мирсәет абый, улларыгызның фотолары булса күрсәтегез әле, миңа алар ни гаҗәптер, һаман электәгечә кечкенәләрдер шикелле,— дидем.

— Булырлар кечкенәләр, алар әтиләрен күптән узып киттеләр инде,— диде миңа Мотаһара апа, горурлык белән.— Күрсәт, атасы, альбом әнә синең янәшәңдәге шкафтадыр.

Мирсәет абый альбомны миңа алып биреп, яныма килеп утырды да андагы һәр рәсемгә аңлатма бирә башлады.

— Менә бу Мотаһара апаң белән мин туган авыл. Бусы минем әти карт. Дин әһеле иде ул, шуңа башына чалма урап төшкән. Бу — минем Минзәлә педтехникумына укырга кергәч алдырган рәсемем. Авылдан икәнем, гыйбатлыгым йөземдә. Объективка күзләремне шар ачып текәлгәнмен дә, авызымны да ябарга оныткакмын әнә. Ничек булганмын, шулай төшелгән. Бусы инде Мотаһара апаң белән гыйшык-мыйшык уйнаганда алдырган сүрәтебез. Бусы менә өйләнешкәч төшкәнє. Инде балаларның бәләкәй чактагы фотолары. Монысы менә Азат, монысы Абан, бу икесе Алмаз белән Альберт.

— Ә бу төпчек улыгыз Альберттыр инде? Аңарда Мотаһара апа чалымнары. Ә Алмаз, Абан, Азат сезгә тартканнар, Мирсәет абый.— Мин альбомның соңгы битен яптым.— Нигәдер сезнең мәктәптә эшләгәндә төшкән фотоларыгыз күренмәде монда?..

— Син безнең гаилә альбомын карадың, ә мәктәптә эшләү елларын, укытучы иптәшләрем рәсемнәрен бүтән альбомга җыйдым мин. Менә рәхим итеп аны да кара.

Мирсәет абый шкафтан миңа яңа альбом алып бирде. Аны актарганда мин күп кенә таныш кешеләрнең сурәтләренә юлыктым. Алар арасында сабакташларым да, кайчандыр үземне укыткан укытучыларым да очрады. Менә Нәмә — Нурулла абый, менә Зиннәт абыйның хатыны — урыс теле укытучыбыз «Прокурор» Хөршидә апа, менә «Мишәр» Җамалый абый, Һаҗәр апа... Чү, бусы утыз җиденче елның март башында кулга алынган Фәсхи абый бит!.. Молодец, курыкмаган Мирсәет абый, Фәсхи абыйны халык дошманы булды димәгән, аның фотосын башка хезмәттәшләре рәсемнәре арасында кадерләп саклаган. Менә хезмәт укытучыбыз Кәшиф абый, Оркыя, Нәгыймә апалар... Альбомның яңа битен ачкач, мин әтием рәсемен күреп өнсез калдым. Ул миңа кинәт кенә, исәнме, улым, менә без, ниһаять, очраштык, дигән кебек булды. Дулкынланудан күзләремне яшь томалады, берни күрмәс хәлдә калдым. Әмма бу озакка бармады, тиз үтте. Әти фотога бүлмәдә түгел, җилле көнне тышта төшкән булган, күрәсең, озын чәчләре тәртипсез таралып тузгыган. Карашы уйчан — кашыннан иягенә таба сузылган ямьсез яра җөе аермачык. Түшендә орден балкый. Фотоны альбомнан алып артын карадым. Анда берни дә язылмаган булып чыкты. Аны яңадан өс ягына әйләндереп, әтинең уйчан йөзенә текәлдем. Чыннан да, охшаганмын икән мин аңа. Тышкы охшашлыгыбызга гомер сукмакларыбыздагы кыен охшашлыклар да өстәлде. Бәештә искәрмәгәндә аерылышып, Бәештә үк көтмәгәндә очраштык та. Дөрес, моны очрашу диярлек тә түгел, шулай да озак еллардан соң фотоңны гына күрү дә миңа әйтеп бетергесез шатлык, әти. Иркенләп гәпләшергә, уй-фикерләребезне уртаклашырга иде хәзер. Син дошман булмаган кебек, мин дә коточкыч ГУЛАГ колонияләрен үтсәм дә, дошман түгел бит, түгел...

Мирсәет абый иңемә кулын салды.

— Теләсәң, әтиеңнең сурәтен үзеңә ал,— диде ул, хәлемне аңлап.— Чын ихластан хөрмәт итә идем мин Сабирны. Аның дошманлыгына да, корткыч икәненә дә ышанмадым, шуңа сурәтен югалтмый сакладым. Алтын кеше иде әтиең, Ирек улым, тәвәккәл иде. Бәешнең көнчел, түң күңелле кеше кыяфәтле этләре күпсенделәр аны. Әтиеңне кулга алу Бәешнең бу көнгә калуының, мәктәбебезнең юкка чыгуының башы булды.

— Мин Бәешне бүген, яңадан аның урамына аяк баскач, танымадым, Мирсәет абый. Аның кайсы кая таралган кешеләренең, туган нигезләре юкка чыгуга, аз гына да эчләре пошмый микәнни?

— Аларның туган төбәкләренә ваемсыз карауларына мин үземне дә гаеплим, Ирек улым. Әйләнә-тирәгә, туган табигатькә мәхәббәт орлыгын җитәрлек кадәр сала алмаганмын, дим.

Мин аңа каршы килдем.

— Таякның юан башын зерәгә үз аркагызга төшерәсез, Мирсәет абый. Сез түгел, җепләре чәбәләнеп сүтелмәслек чуалган йомгакка охшаган тормышыбыз гаепле ул гамьсезлеккә. Без үткәннәребезне, изге гореф-гадәтләребезне, йола-ышануларыбызны оныттык. Хәтта татар икәнебездән тартына, ояла башладык. Якын тирәдәге башка авылларның да бүгенге Бәеш хәленә калуларына да сез гаепleme? Кешеләребезнең алга карамый, тик бер көн белән чикләнеп яшәүләре, хәтта үз күләгәләреннән дә өркеп, тик бүгеннәре турында гына кайгыртып гомер сөрүләре гаепле. Безне моңа нәрсә китергәнен беләсез булыр...

— Ярар, Ирек улым, килеп хәлебезне белгәнең өчен рәхмәт сиңа. Моннан соң элемтәдә торыйк инде, хатлар яз. Сине без улларыбыз белән дә таныштырырбыз, теләсәң алар белән дә хатлар алышырсың.

Без Мирсәет абый белән альбомнар караган арада Мотаһара апа, бакчаларына чыгып, җиләк җыеп керде.

— Менә абыең сине сүз белән сыйлады, мин бакчабызда үскән җиләкләребез белән дә кунак итим әле,— диде ул.

— Рәхмәт, Мотаһара апа, сыйланыр урыным калмады инде минем. Мең рәхмәт сезгә.

— Бездә ашамасаң, үзең белән алырсың. Бәештә кемдә туктадың соң әле син?

— Туры Ярулла абзыйларга кердем. Хәбибә түти әнием кебек каршылады. Алар белән без теге чакта күршеләр идек бит. Мин Ярулла абзый белән Хәбибә түтине наданлыкны бетерү чорында укырга-язарга өйрәткән идем. Кунак иттегез, иркенләп гәпләштек, сезгә рәхмәт яусын. Китим булмаса. Сезнең эшегезне шактый калдырдым шикелле, ачуланмагыз.

— Сөйләмә юк сүз,— дип каршы килде миңа Мирсәет абый.— Килүең бик әйбәт булды әле, эчемне бушаттым. Менә әтиең белән әниеңнең безнең өчен бүгенгә кадәр сер булган фаҗигале язмышларын ачыкладың, үзеңнең исән-иминлегеңне күрдек, тормыш сикәлтәләрендә абынып калмыйча кеше булуыңа сөендек. Мин шат синең өчен, Ирек улым.

Мотаһар апа, җиләкләрен пыяла банкага салып, газетка төрде дә:

— Ал моны, тартынма. Үзең ашамасаң, Хәбибә тутаңны сыйларсың,— дип кулыма тоттырды.

## Унбишенче бүлек

### 1

Хәбибә түти:

— Югалттык сине, кайда йөрдең, иртәдән бирле ач бит син, кунак,— дип битәрләп каршылады мине.

— Мирсәет абыйларга бардым, борчылмагыз, мин тук. Менә сезгә Мотаһара апа күчтәнәч җибәрде,— дип, кулымдагы газета төргәген Хәбибә түтигә тоттырдым.

— И-и-и, мине танымыйсыңдамы әллә, Ирек? Хәбибә тутаң әйткәч, көтә-көтә көтек булдым бит инде. Сине чыгып эзләп тә кердем,— дип, каршыма басты Зада апа. Ул, элек тә бәләкәй хатын, бөтенләй кечерәеп калган, иреннәре бөрешкән, чәчләре, кашлары ап-ак.

— Таныдым, Зада апа, ник танымаска, үзгәрмәгәнсең син.

— И, Ирек. Исән кеше бер кайта шул, кайтмый калмый. Бәлки, Миләүшә дә кайтыр әле, ә?

— Кайда соң ул, Зада апа? Миләүшәне әйтәм.

— Син белмисеңмени аның сугышта булганын? Кырык бишенче елны, «батырларча һәлак булды», дигән хәбәр килде аның турында. Нишләп син күзгә-башка күренмәдең моңарчы? Нигә Бәештән киткәч,

бер хәбәрегез дә килмәде? Миләүшә белән без сездән көн дә хат көттек бит...

— Мин хатлар язарлык хәлдә түгел идем, Зада апа.

— Нишләп?..

Хәбибә түти сөйләшүгә катнашмады, табын әзерләде.

Аштан соң Зада апага мин әти белән әни һәм үзем турында аңа кадәр Хәбибә түтигә һәм Мирсәет абыйларга сөйләгәннәремне җәелмичә генә кабатладым. Аннары Зада апа миңа Миләүшә турында сөйләде, аның фронтта төшкән фотоларын күрсәтте.

Миләүшәне мин фоторәсемнәрендәгечә хәрби орден һәм медаль таккан медицина лейтенанты итеп берничек тә күз алдыма китерә алмыйм. Ул хәтеремә кечкенә буйлы, чандыр гәүдәле, йөзен сипкелләр чуарлаган кызчык булып уелган. Фоторәсемнәрдә Миләүшә бөтен. Җитди, уйчан. Аңарда сабыйлыкның эзе дә юк. Кайчандыр минем белән бер партада утырган, Бәештәге соңгы кичемдә Җидегән чүмече сабында мин билгеләгән йолдыз янәшәсендә үз йолдызын билгеләгән сыек толымлы Миләүшә сабый гына иде. Фотоларында толымнары юк. Бәлки, аларда аны кыска чәчләре олыгайтадыр? Ләкин, ничек кенә булмасын, фоторәсемнәрдәге хәрби киемле Миләүшә белән минем белән укып йөргән үсмер кыз Миләүшә арасындагы уртаклык аларның карашларында, юка борын яфракларында, ирен читләрендә, бит алмалары урталарындагы мөлаем чокырчыкларда, иякләрендә, күзләрендә, бигрәк тә сипкелләрендә ярылып ята. Миләүшәнең сипкелләре үскәч тә бетмәгән булганнар. Зада апа аны:

— Әрмиягә киткәндә бик тә чибәрләнгән иде инде ул,— ди. Эх, кайсы анага үз баласы чибәр күренми?! Бала чактагы, доктор булам, дигән хыялын тормышка ашырган сабакташ күршем. Әнисенә генә түгел, миңа да чибәр күренде ул. Сугышта һәлак булмаса, бүген ул кем булыр иде икән инде? Әлбәттә, ул яки кыз үстерер, халык арасында игътибарлылыгы, иглеклелеге, ягымлылыгы, осталыгы белән дан тоткан бик яхшы врач булыр иде. Бәлки, берәр медицина учреждениясенә җитәкчелек итәр яки укытыр иде. Үзенең тыелгысыз омтылышлары, дәрте, эш сөюе белән Бәешкә генә сыеп калмас иде Миләүшә...

## 2

Сәлмән янына барыр алдыннан Зада ападан:

— Сәлмән Яңа урамдагы шул элекке өйләрендә торамы?— дип сорагач, ул:

— Элекке өйләре күптән җук инде аларның. Алты почмаклы шыңгырдап торган өр-яңа нарат өй салып керде Сәлмән. Андый өй Бәештә бер генә. Матурлыгы белән әллә каян үзенә тартып тора. Авылда иң хәлле кеше хәзер Сәлмән. Эшләгәненә акчаны көрәп ала, трактор үзендә. Аңа бар син, Ирек, бар, иркенләп үткәннәрегезне искә алырсыз. Сәлмән әйбәт ул, кешегә ачык, җәрдәмчел, кече күңелле, ыхтымат,— дип тезеп китте.

Сәлмән бала чакта йомыкый гына малай иде. Хәзер бөтен Каран районының горурлыгына әверелгән. Гайфи минс аның турында очерк язарга тикмәгә кызыктырмаган булыр.

Мин Сәлмәннәргә килгәндә, алар өйдә иде. Ишекләрен шакуыма:

— Кем бар анда, кер, шакып азапланма,— диде эчтән ир-ат тавышы.

Ишекне ачып бусаганы атлауга, аптырап калдым. Бөтен өй җиһазлары, табак-савытлар, урын-җир әйберләре идәндә чәчелеп ята. Сәлмән — аны мин инде шактый үзгәрсә дә таныдым,— түрдәге урта тәрәзә пәрдәсенең бавын чишеп азаплана, хатыны бүлмә ишеге янагына сөялеп, аны күзәтә иде. Исәнләшүемә теләр-теләмәс кенә җавап бирделәр. Шунда башымнан, вакытсыз килдем боларга, дигән уй узды.

— Күңелсез чагыгызга юлыктым бугай, гафу итегез,— дидем, уңайсызланып.

— Бик тә күңелле чакка туры килдең, рәхим ит. Без театр куябыз, әйдә тамаша кыл,— диде, хатын, борыстан аерылмыйча.

— Юк, театр түгел, тормыш бу, Кәтибә җаным, ялгышасың,— диде аңа Сәлмән.

Ул мине танырдымы, танымадымы, белмәдем. Бусага төбеннән ары үтмәдем, туктап калдым. Хуҗа исә өйләре эченә үтәргә чакырмады.

— Вакытсыз кереп комачауладым сезгә. Зинһар, гафу итегез, дип, ишеккә борылдым.

— Нинди гафу ул, ташла, безнең аерылышуга шаһит булырсың, чыкма,— диде хуҗа, тәрәзә пәрдәсе бавын шартлатып өзеп.

Мин өйдән чыгарга да, чыкмаска да белми туктап калдым. Нинди аерылу, нәрсә сөйли ул? Нинди аңлашылмаучылык килеп чыккан алар арасында, дип уйладым.

— Райкомнан миңа Гайфи синең кагыласыңны шалтыратып әйтте. Безнең бүгенге бу тамашаны күргәч, сиңа кәгазь пычратырга туры килмәс, яшьти.

— Нәрсә булды сезгә?— дидем өй эченә борылып.

— Мин колхозда артык калмыйм, шәһәргә китәм. Сәбәп — көчемне, тырышлыкларымны алда да җилгә җибәрәсем килми.

— Аңламадым. Ачыкларсың, бәлки?

— Арты белән киртә җимермәкче ул. Нишләвен үзе дә белми,— дип сүз кыстырды хуҗа хатын.— Адәм көлкесе бит, ир уртасына житкәч, яшь гидайлар күк, аерылабыз, дип дулый. Маена чыдый алмый, пәрие котырта үзен. Мине ташлап, яшь бикәч алыргадыр уе...

— Эх, туган, ни өчен борчылуыңны, кыбырсынуыңны гомер иткән хатының да аңларга теләмәсен инде! Аянычның да теге ягы бит бу. Яшь бикәч алырга чамалыйм, имеш. Хурланып үләрсең. Берәүдә әнкәй, икенчедә җәнкәй кайгысы, тьфү!..

Мин, идәндә чәчелеп яткан әйберләргә ымлап:

— Өегездәге бу тәртипсезлекне ничек аңларга? Ни өчен, сезнең турыда язып кәгазь пычратмаска, дисең? Колхоздан нигә китәргә булдың?— дидем.

— Әйттем ич, колхозда бүтән эшләмим, китәм авылдан. Менә аерылышабыз. Әйберләребезне тигезләп бүләбез. Мин үз өлешемне Чуал буена алып төшеп яндырам.

— Аларны тулысы белән хатыныңа калдырырга ярамыймыни?

— Ярамый. Мин моннан тамырларымны тәмам өзеп, яңадан бу йортка әйләнеп кайтмаслык итеп китәргә тиеш.

— Сәбәбе?

— Сәбәбе гади аның. Хезмәтем җилгә очу. Елның җиде-сигез аен кырда тир түгеп эшләп үткәрәм. Районыбызда яңа культура — шикәр чөгендере үстерәм мин, райком секретаре әйткәндәр. Елына карап һәр гектардан өч йөз илле-дүрт йөз центнер уңыш алам. Яныма әйләнәтирәдәге колхоз-совхозлардан, хәтта күрше районнардан эш тәҗрибәмне өйрәнергә, хезмәт алымнарына карарга кешеләр килә. Күзен, җаен үстергән уңышны буйлары ун, иңнәре өч-дүрт, калынлыклары ике-ике ярым метрлы өемнәргә туплыйбыз. Аларны буртлар дип атыйлар. Җыелган уңышны шунда ук тәҗел генә шикәр заводына ташырга транспорт булмый. Көзге яңгырларда чөгендер өемнәре үтәли чыланып, кышын шакыраеп каталар. Язга чыккач, мин үстергән чөгендер шикәр ясарга яраклы булу түгел, терлекләргә ашатырга да ярамый, бозыла. Ул хәл ел саен кабатлана. Быел да шулай булачак. Ә иптәш Бәдретдиновка мактанырга булсын. Сине мин Герой итәм, даныңны бөтен илгә таратам, дип лаф ора. Кешеләргә файда бирмәгән хезмәт өчен бирелгән Алтын йолдызны ни йөзең белән тагып йөрергә кирәк? Китәм колхоздан, көлмәсен миннән райком секретаре. Эз басмыйм Бәешкә бүтән.

— Аерылышмыйча хатының белән бергә китәргә ярамыймыни соң сиңа?

— Булмый. Кәтибәнең кендеге ябышкан авылга. Мин Бәешне үлсәм дә ташлап китмим, ди. Монарчы аны тыңлап, аның көен көйләп яшәдем, житте. Түземем төкәнде, аерылышабыз. Ул Бәештә яшәсен, мин шәһәргә сыптырам.

Менә ир дисәң дә ярый Сәлмәнне, дидем үз-үземә. Эше кешеләргә файда бирсә дә, бирмәсә дә каерып акча алу турында гына кайгыртучылар бихисап бит. Сәлмәннең юкка көч түгүенә үстергән чөгендеренең әрәм булуына эче поша, жаны әрни. Ул шул турыда уйлап күпме төннәрен йокысыз үткәргәндер, хатыны белән аерылышып, Бәеш белән саубуллашу карарына да бүген генә килмәгәндер.

— Тәвәккәллегеңне хуплыйм, сабакташ, дөрес эшлисең,— дидем мин әле һаман тәрәзә пәрдәләре белән кайнашкан хужага.— Эшегез кызу чакта килеп борчыдым сезне. Китим, хушыгыз.

— Хуш, Ирек. Яхшылап сөйләшә алмадык, гаепләмә. Миңа тимерне кызуында сугарга, кырт кисәргә кирәк.

### 3

Сәлмәннәрдән чыккач, мин Чуал буена элек үзебез балык каптыра торган тугайны карарга юнәлдем. Уйларым Сәлмән тирәсендә буталдылар. Бәлки, язаргадыр миңа аның турында? Әле генә бер дигән материал бирде бит ул миңа. Андый материалга юлыгу зур бәхет журналистка. Әмма берничә мең тонна шикәр чөгендеренең ел саен дәү-дәү өемнәрдә файдасызга черүен фаш итсәм, Гайфине кыен хәлгә куям, аның карьерасын бозам була. Нәтиҗәсез хезмәте өчен Сәлмәнгә ул хәттә орден да бирдергән бит. Инде Герой итәргә яскына. Язасы иде моны, хакыйкатьне гәүдәләндергән гадел мәкалә чыгар иде. Сәлмән кебек үз хезмәтләреннән тәм тапмаучылар аз түгел бездә. Төптән уйласаң, кешеләребезнең дүрттән өче шундыйлардыр бит. Хезмәт кешесен кол хәлендә бушка диярлек эшләтү нәтиҗәсе бу. Кешеләр туган нигезләрен ташлап шуңа качалар. Күпме сагынып жирседем, балалык сукмакларыма яңадан әйләнеп кайтырга күпме хыялландым мин монда. Менә кайттым да. Ә Бәеш минем дөньяда барлыгымны да оныткан инде. Ул әҗәл чиреннән бетерешкән хастага ошап калган. Мәктәбе юк дәрәҗәдә, әйләнә-тирәсе үзгәреп танымаслыкка әйләнгән, үткәндәге истәлекләрне яңартырдай Каршы тау һәм Кызылъяр гына калган. Алар да инде электәге төсле күркәм түгел, алмашынганнар, тәбәнәкләнгәннәр кебек. Безнең малай чактагы уеннарыбызның мәркәзе Чүлмәк тау да электәге сокландыргычлыгыннан бөтенләй мәхрүм калган. Аның өстенә нефть вышкасы менгереп утыртканнар. Ул тинтәклек кайсының башына килгәндер, билгесез. Тирәндәге девон катлавына тишек ясарга Бәештә сокландыргыч Чүлмәк тау түбәсеннән дә кулайрак жир тапмаганнар, күрәсең.

Мин, үрмәләп, Каршы тау итәгенә юнәлдем. Күр, Хәйрүш абзый чишмәсе янындагы тирәкләр ничек картайган!.. Уйларым ерак үткәнемә кайттылар, күз алдыма дәртләнеп курай уйнаучы Хәйрүш абзый, тау буена таралган көтү килде. Колак төбемдә курай тавышы яңаргандай булды, йөрәгем рәхәт кысылып алды. Тирәкләр мин Бәештән киткәндә нибары үндүрт төп иде, инде утыздан артканнар. Кем өстәгән аларны һәм нигә өстәгән?.. Чишмә шул ук, элек ничек акса, хәзер дә шулай ук шарлап ага. Улагы да жимерелмәгән, тирәсенә түшәлгән ташлар да урыннарында. Әйтерсең, Хәйрүш абзый монда әле генә булып киткән.

Чишмәдән аерылып, мин, үзем дә сизмәстән, Кызылъярга күтәрелә башладым. Гүя, ул мине сихерләде. Тик аңа мин малай чактагы кебек елгыр менә алмадым. Ун-унбиш метр күтәрелгән саен туктап ял иттем.

Тыным кысылып, йөрәгем шашынып типте. Шулай да кире борылмадым, таш билбауга менеп җиттем.

Бәешлеләрнең уйган хәтирәләрен үз күкрәгендә саклаучы таш билбау, сәлам сиңа! Синең белән күп еллар күрешмәдек без. Ләкин кайда гына музей сүзен ишетсәм дә мин сине искә ала, уйларымда сиңа кайта идем. Күрсәт миңа яңадан күкрәгеңне, укыт үзеңә уелган язмаларны.

Әһә, байтак үзгәрешләр булган монда да. Таш стенада хәтта бармак төртер урын да калмаган бугай. Кая, карыйм әле, Миләүшә белән минем теге вакыттагы ядкарь-язуыбыз сакланды микән? Менә ул. Әле кичә генә язылган кук. Һәр хәрефе аермачык. Чү, бу нинди язма?..

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, Ирегем.—
Сине уйлап утларга да,
Суларга да керермен...
*М. 1942 ел. Сентябрь.*

Миңа атап Миләүшә язган ич моны! Миләүшә... Миләүшә... Бала чакта Сөләйнең чәчәкләр белән бизәкләп язган гыйшык хатын укыганнан соң ана биргән соравыма җавабы ич бу партадашымның. Ул чакта Миләүшә: «Сөям шул...»,— дип, Чуал буена йөгергән һәм берничә көн минем белән очрашырга оялып йөргән иде. Ә монда, таш билбауда, ул үзенең керсез хисләрен бирәүдән дә яшерми уеп калдырган. Минем Бәешкә киләсемне, монда менәсемне, аның бу язуын кайчан да булса укыячагымны каян белгән ул? Каян?..

Ташта Миләүшәнең үзмә атап язган юлларына маңгаемны куеп күпме басып торганымны хәтерләмим. Ул минутларда башымда нинди уйлар куерганы да исемдә калмады. Хәзер беләм, Бәештән киткәннән соң да монда мине юксынучы, сагынучы, минем турыда уйлаучы булган. Үземне мин Миләүшәне еш искә ала идем дия алмыйм. Җай чыгып, күзләремне төнге күктәге Җидегәнгә төбәгәндә, гадәтемчә, Гайфине, Кәримне, Сөләйне искә ала, урманга ат сакларга барган төннәрне хәтеремдә яңарта, ирексездән гамьсез бала чагымны сагышланып күздән кичерә идем. Шунда кайчакта күз алдымнан Миләүшә дә чагылып уза иде. Әйе, Миләүшә уйларымда чагылып кына уза, чөнки хәтеремдә аның сурәте яңаргач, курае белән күңелемдә Хәйруш абзый гәүдәләнеп, аны арткы планга чигереп оныттыра иде.

Гомер, һәркөнне зур һәм кечкенә үкенечләрдән, дәү һәм бәләкәй шатлыклар һәм борчылулардан торган гомер, миңа сине тагын бер кат үтәргә туры килсә, үткәндәгеләремне кабатламас, башкача үтәр идем. Минем тормышым тоташ табышмак бит. Нигә әти-әниләремне югалттым, белмим. Нигә әни белән Бәештән сөреп җибәрелгәндәй киттек, нигә Моталлап абыйларда түгел, әллә кайда үстем, нигә әле дә моңа үземне канәгатьләндерерлек җавап таба алмый? Ул чакта да шушы ук совет власте, бүген очрашканда минем белән бик теләп сөйләшүче шул ук кешеләр иде ләбаса — мин малай чакта да...

Сугыш. Сугышта мин гомеремне ничек тә сакларга тырышып, кемнәрнеңдер аркасына посып сугышмадым. Тирәмдә усал кигәвеннәр күк пулялар өзлексез сызгырганда да, кайда кушсалар карышмый шунда бардым. Миңа үлсәм дә, исән калсам да барыбер иде. Кайдадыр төннәр йокламый минем турыда уйлаучы, минем исән йөреп сау кайтуымны көтүче кешем булмаганга, тормышымның кинәт киселүеннән курыкмаганмын мин. Шулай да үлемне үзем эзләмәдем. Сугышта биш танк югалттым... Дөньяда минем турыда уйлаучы, мине көтүче кеше юк дип ялгышканмын мин. Әнә булган ул, Миләүшә уйлаган, Миләүшә көткән. Ә мин аның дөньяда барлыгын да хәтерләми идем. Аңа тик бер генә хат язсам соң! Юк, язарга күңелем дә тартмады, кулым да бармады. Үз кайгым гына кайгы иде минем. Халык дошманнарының улы идем бит. Шуңа

күрә, бирәүгә дә хажәтем юк, дип дөньяда барлыгымны кемнеңдер исенә төшерүне үзем өчен артык саный идем.

Миләүшә, Миләүшә, кичер мине изге хисләреңне сизмәгәнем, керсез сөюеңне тоймаганым өчен кичер! Безне малайлар «кияү-кәләш» дип үртәгәндә, сине кәләш сүзен ишетү, бәлки, куандырган, канатландырган булгандыр. Мине исә кияү дип атаулары үтә гарьләндергәнгә, мин сине бөтен барлыгым белән күрәлми идем. Соң булса да кичер, гафу ит мине, Миләүшә. Мин гомерем буена туң йөрәк булдым, кемне дә булса сөюдән урман җанвары уттан курыккан кебек курыктым. Мин, хатыным булса, аны тол, балаларым булса, аларны — үзем ятим үскәнгә ятим итүдән курыктым. Әти кулга алынгач, әнинең ничек бәргәләнгәне, күпме төннәр күзләренә йокы кермәгәне, тамагына ризык үтмәгәне хәтеремнән беркайчан да чыкмады. Ятимлек ачысын үзем татыганга, кемнедер бәхетсез итү юлына басу миңа төпсез упкынга мәтәлү белән бер иде. Үкенәмме моңа хәзер? Юк, үкенмим. Үземне мин аңлы тормышымны ялгышларсыз үттем дип юатам. Озак вакытлар, дөньяда үземнән соң улым яки кызым калмый икән, кемгә зыян, дип карадым. Моны сугышта шәһит киткән миллионлаган буйдак егетләрнең кемгәдер тормыш бирә алмаулары кебек итеп санарга була иде.

## Уналтынчы бүлек

### 1

Хәбибә түти белән Зада апа икесе дә өйдә юк, каядыр йөриләр. Мин Ярулла абзыйның фронттан язган хатларын караштырып утырам. Алар барысы да Хәбибә түтигә исемләнгәннәр, башларыннан ахырларына кадәр гап-гади сүзләр белән юлланган кайгыртучан, үтә җылы хатлар. Менә шуларның 1943 елның башында язылган берсе:

**«Исән-имингенәме син, Хәбибә канатым!**

**Сагынычлы сәламемне кабул итеп ал, җанашым. Мин исән, ходайга шөкер, имин, әлеккечә үк сугышта.**

**Сиңа ялгызыңа гомер кичерүләре бик авырдыр, җанашым. Алсалар, мине көтеп торма, кер колхозга. Җүләр булдык без, вакытында аңа кермичә. Колхоз себеркедәге чыбыклар күк нык бит ул. Аны күпме боргалама, сразы гына сындырам димә, сынмый, туктаусыз бөгелә дә тора. Ә аерым хуҗалыкта яшәү, без аны үз җилкәбездә татыдык, ялгыз чыбык күк аз гына бөк, шартлый да сына. Дулкынга каршы йөзүе авыр, аны син мин әйтмәсәм дә беләсең. Хәзерге акылым булса икән минем әлек... Аллаһы теләсә, киләчәктә үткәндәге ялгышларыбызны кабатламабыз, канатым. Кайгырам, синең өчен бик кайгырам, канатым. Хатларыңны загырып көтәм. Син бит минем дөньяда бердәнберем. Бер рәхәт тә күрсәтә алмадым сиңа, үпкәлисеңдер. Әмма терсәкне тешләргә тырышудан инде файда юк. Исән кайтуымны көт.**

**Мине искә алучыларга, Бәешебезгә, Чуалга, Кызылъяргa, Кәнгелде борынына, Чүлмәк тауга, Хәйрүш күршебез чишмәсенә миннән сәлам диген.**

**Кочып, сине өзелеп сагынучы Яруллаң».**

Хат чатлы-ботлы тигезсез хәрефләрдән оештырылган. Кайчандыр мин өйрәткән латин хәрефләре белән. Аны укыганда күзләремнә бернichә тапкыр яшь пәрдәсе томалады. Нинди нечкә хисле, олы җанлы кеше булган Ярулла абзый, дип гаҗәпләндем ирексездән. Хәбибә түтине ничек яраткан, аның өчен ничек борчылган, үткәндәге ялгышлары өчен үзен ничек битәрләгән ул.

Стенадан миңа Ярулла абзыйның зурайтылган рәсеме карый. Ул ничектер аңа охшаган да, охшамаган да кебек. Минем хәтеремә ул мыексыз уелган. Рәсемдә исә Ярулла абзый калын мыек җибәргән, йөзе житди, күзләре уйчан. Аны Хәбибә түти Ярулла абзыйның фронт газетасында чыккан кечкенә генә рәсеменнән зурайттырган. Минем алдымда яткан, инде саргаеп беткән ул газетада Ярулла абзыйның фидакарьлеге турында җыйнак кына очерк та бирелгән. Ул рәсемен алдырганда нәрсә уйлады икән булачак Герой, беләсе иде...

Газетадагы очеркка,— мин инде аны берничә кат укыган идем,— яңадан күз йөртә башладым. «Н-че укчы дивизия пулеметчысы Ярулла Маликов чал Днепрның уңъяк ярына расчеты белән беренчеләр арасында кичте. Ул, икенче номерлы Геннадий Перминов белән, яуланган плацдармда дошманга сиздерми уңайлы урын сайлап, «Максимны» тиешенчә урнаштыргач, фашистларның һөҗүмен кире кагарга әзер иде инде...»

Кайчандыр тулы хокуклы булып авылдашлары арасына керергә, үзе белән бергә үскән, бер үк туфракны таптаган, бер үк суны эчкән, бер үк һаваны сулаган кешеләр белән кулга-кул тотынып эшләргә йөрәге житмәгән «ялгыз хуҗалык» Ярулла абзый башкалардан берние белән дә аерылып тормаган бит. Бәештә аңа шәхес итеп карарлык югарылыкка үсмәгән булганнар, күрәсең. Кызганыч, андый стереотиплык чире әле дә бар, яшь. Кешегә кайчандыр бирелгән бәя гомере буена ябыша. Ярулла абзый үзенең башкалар әвәләнгән үк камырдан әвәләнүен сугыш кырында илебез бәйсезлеге өчен барган аяусыз орышта, гомерен биреп, дәлилләгән. Ул үз частьларында беренчеләрдән булып шанлы Днепр елгасын кичкән укчы взводның пулеметчысы булган. Взвод сугышчылары караңгы сентябрь төнендә дошман искәрмәс урында елганы көймәләрдә һәм аннан-моннан укмаштырылган кечкенә салларда мыштым гына кичә башлыйлар. Шул мәлдә үк, фашистларны буташтыру өчен, Ярулла абзыйлар взводы Днепрны кичәргә керешкән урыннан дүрт-биш йөз метрлар тирәсе өстәрәк чын мәхшәр куба. Фашистларның уңъяк ярдагы тимер-бетон ныгытмаларын йөзләгән туплар, минометлар, самолетлар дәһшәтле утка тоталар. Ул мәхшәр ун минут чамасы дәвам итә. Фашистлар көтелмәгән һөҗүмнән югалып калалар. Ярулла абзыйлар взводы, форсаттан файдаланып, бернинди югалтуларсыз уңъяк ярга чыгып, плацдарм яулый. Куркудан җаннары үкчәләренә киткән фашистлар үзләренең борын төпләрендә нәрсә булганын абайламый калалар. Ләкин аларның миңгерәүләнүләре озакка бармый. Безнең сугышчыларның берсе, уйламаганда, яхшылап яшерелгән җир куышына юлыга. Анда дүрт фашист, дер калтырап, артиллерия, миноментлар, бомбалар мәхшәренең ахырын көтеп утырган булалар. Сугышчы аларга озын автомат чираты бирә. Шул ату тавышы башка куышлардагы фашистларны аякка бастыра. Шундук тәртипсез атыш башлана. Дошман паникага бирелеп, запас позицияләренә чигенә һәм совет сугышчылары яулаган плацдармны бик хәтәр утка тотарга керешә. Снаряд һәм миналар кыю взвод өстенә дә, шаулы Днепр өстенә дә, безнең төп көчләр тупланган сулъяк ярга да мул ява. Дошман батыр сугышчылар өстенә, атака арты атакасын кабатлап, туктаусыз һөҗүм итә. Әмма уңышка ирешә алмый, күп корбаннар биреп, һәр тапкырында хурлыклы рәвештә кире чигенә. Шундый тигезсез сугыш тәүлек ярым дәвам итә. Төп көчләр взвод яулаган плацдармга кичеп чыккач, анда берданбер исән калган кешене — пулеметчы Ярулла абзыйны гына табалар. Аның әйләнә-тирәсе фашист мәетләре белән түшәлгән, ул үзе берничә тапкыр авыр яраланып, бик күп канын югалткан була. Аны шундук сулъяк ярдагы кыр госпиталенә озаталар. Ләкин Ярулла абзый, врачлар күпме тырышлык куйсалар да, яңадан инде аякка баса алмый, сүнеп, күзләрен йома.

Газетадагы ашыгып язылган җыйнак кына очерк мине үткәндәге дәһшәтле елларга алып кайтты, ирексездән, инде онытылган авыр сәхи-

фәләрне хәтеремдә яңартып, берни белән дә чагыштыргысыз җирәнгеч сугыш гөрелтесен колак төбемдә яңгыраткандай булды...

Ярулла абзый, исән булса, күп, бик күп нәрсәләрне искә алыр, күп нәрсәләр турында гәпләшер идек без. Синдәй эчкерсез, киң күңелле, саф намуслы, батыр йөрәкле, үзләре турында кайгырта белмәүче затларны гомер юлымда бармак белән санарлык кына очраттым мин...

## 2

Башында акылы бар кеше күптән сүнгән учак көленнән очкын эзләми. Бәешкә кайтып, бала чагымда йөргән сукмакларны барлавым салкын көлдән очкын эзләү белән бер түгелме? Әйе, шулайдыр. Ләкин күпме генә казынсам да тапмам мин ул очкынны, акылга килергә вакыт, тыйлыгыйм. Булдым Бәештә, күрдем аны, җитте, инде саубуллашыйм. Нәшрияттан Гани абый мине сайранда йөрергә җибәрмәде, эш майтарырга җибәрде. Мин, тезгенемне чорнап тотучы булмагач, дөньямны оныттым. Миңа, йә хәзер үк Лениногорскига барырга, йә тизрәк туры Казанга кайтырга кирәк.

Иртән торып, ашап-эчкәч, Хәбибә түти белән Зада апага юлга кузгаласымны әйттем.

— Китәсеңне кичтән үк әйтсәң, кешечә булыр диденмени? Юлда ашарыңа, хатының белән кызына күчтәнәчкә берни дә әзерләмәдек бит. Ничек була инде ул? — дип үпкәләде Хәбибә түти.

— Берни дә кирәкми, Хәбибә түти, рәхмәт. Мин туры Казанга кайтмыйм, Лениногорскига кагылам бит әле. Анда тоткарлануым да мөмкин.

Төнлә көчле яңгыр явып үткән, юл җебегән иде. Мин, басарга корырак җирләр сайлый-сайлый, Карангa юнәлдем. Йөрәгемне кузгатмас өчен әйләнә-тирәмә күз ташламыйча, башымны күтәрми атладым.

Бәештән шактый җир киткәч, мин юл читенә чыгып туктап калган «Запорожец» машинасына тап булдым. Машинаның ишекләре ачык, хуҗасы башын рульгә терәп тын гына утыра иде. Нәрсә булган аңа, бәлки авырыйдыр, дип уйладым.

— Иптәш, ни булды сезгә, бәлки, ярдәм кирәктер? — дип, барып, аның иңенә кулым салдым.

Машина хуҗасы рульдән башын аерып, миңа карады.

— Арбамның көпчәге тишелде.

— Ә запас көпчәгегез юк, шуңа балтагыз суга төштеме?

— Запас көпчәк бар, тик аны һавасы бушаган көпчәк урынына куярлык чутым юк.

Агай исерек кебек түгел, ник чуты юк икән, дип гаҗәпләндем.

Машина хуҗасы миннән күзләрен алмады. Бераздан:

— Сезне Сабир Кадыйрович дисәм, яшь күренәсез, ул димәсәм нәкъ аңа суеп каплаган кук охшагансыз. Әллә улымы сез аның? — дип кызыксынды.

— Әйе, улы.

Әтине белгән бу кешегә текәлебрәк карадым. Чү, теге чакта түшенә нинди значогы бар, шуларның барысын да тагып «җанарал» булып йөргән авыл советы рәисе Әюп Муллин абый бит бу. Картайган, йөзен тирән җыерчыклар телгәләгән, арык, бөтенләй танырлыгы калмаган аның. Ул машинасыннан көчкә төште. Мин аның ике аягы да протез икәнен шәйләдем. Әһә, менә аның көпчәген алыштырырга чуты нигә юк икән...

— Йә, күрешик тә инде. Исемең ничек иде әле синең?

— Ирек, Әюп абый.

— Кара, таныдың, онытмагансың. Әтиең исәнме әле, ул хәзер кайда?

— Әти, кулга алынгач, хәбәрсез юкка чыкты.

— Юкка чыкты? Булмас, ышанмыйм...

— Анысы сезнең эш, Әюп абый, мин алдашмыйм. Запас көпчәгегез, инструментларыгыз багажниктамы?

— Багажникта. Мәгез, ачып алыгыз,— дип, Әюп абый кесәсеннән ачкычлар чыгарды.

Көпчәк белән мин озак булышмадым, биш-алты минут эчендә алыштырып куйдым. Эш беткәч:

— Инде безгә кайтабыз, утыр янәшәмә,— дип боерды миңа элекке авыл советы рәисе.

— Булмый, Әюп абый.

— Зерә. Әтиеңнең Бәештәге соңгы сәгатьләрен беләсең килми, күрәсең. Хәтереңдәдер, аны кулга алганда мин дә бар идем бит. Әтиеңнең ордены миндә калды, ул исән. Мин аны сиңа бирергә телим, кайтыйк.

Мин ризалаштым.

— Әтиең бик тәвәккәл, кыю кеше иде синең,— дип башлады сүзен Әюп абый, машинасын Чокырлыга кайтырга кузгаткач.— Эшемдә гел киңәшләре белән ярдәм итә иде. Ялгышуы җиңел, халык әнә, «дүрт аяклы ат та сөртенә», ди, ялгышны төзәтүе авыр, кешеләргә ышан, аларга таян, тупас булма, дип үгетли иде ул мине. Берәр чатаклык эшләвемне күреп, ачуы чыкса, гадәтенчә, гади генә Әюп дими, рәсмиләшә, иптәш Муллин, диюгә күчә иде. Ул тормышында күпне кичергән гыйлем кеше, мин туган авылымнан кырык чакрымнан ары китмәгән надан гыйбат идем бит, рәнҗеми идем аңа. Сабирга, һәрвакыт яхшы, файдалы киңәшләр генә биргәне өчен, әлегә кадәр рәхмәтле мин. Хәзер, сугышка кадәр авыл советы рәисе чагымда, төрле значоклар җыярга, аларның барын да түшемә тагып йөрергә хирыслыгымны да шул наданлыгым чагылышы булгандыр, дим. Турысын әйтәм, җүләр идем, ниндидер өстенлегем булмагач, шул төрле төсләрдәге значоклар белән аерылып торасым, гыйбатлыгымны каплап каласым килә иде...

Менә Әюп абыйның ул вакытта Камали бабайга «җанарал» булып күренүенең сәбәбе нәрсәдә булган икән, дидем үз-үземә.

— Әтиең кулга алынасы көнне мин эш белән Каранга райбашкармага барган идем. Анда районыбызның ул чактагы милиция начальнигы Сәхапов очрап, мине коридордагы бердәнбер диванда тәмәке пыскытып утырган хәрби киемле өч кеше янына алып барды да, сиңа поручение, Муллин, бу иптәшләрне кайтканда үзеңә иярт, алар зур йомыш белән Бәешкә баралар, диде. Ияртүен ияртермен, ну минем трантаска без дүртәү ничек сыярбыз икән, дидем. Ул турыда башың авыртмасын, аларның үз транспортлары бар, дип тынычландырган иде мине Сәхапов. Бәешкә нинди йомыш белән баралар алар, дип кызыксынмадым, була, ияртермен, дидем.— Әюп абый, сөйләгәннән бүленеп, тирән көрсенде. Аннары, сул кулын рульдән алып, кесәсеннән сигарет чыгарды, әмма аны авызыма капмады, бармакларында йомшартты-йомшартты да машина тәрәзәсеннән тышка чөйде.— Хәрбиләрне ияртеп кайттым Бәешкә. Яхшы атлар җигелгән ике трантаста иде алар. ОГПУ вәкилләре икәннәрен, аларның әтиеңне кулга алырга килгәннәрен мин ахырда гына белдем. Бәешкә кайткач, колхоз идарәсендә хәрби юлдашларымны Зиннәт белән таныштыргач,— хәтереңдәдер, Зиннәт абыең ул чакта колхоз рәисе дә, партоешма секретаре да иде бит Бәештә,— сезне теләгән җирегезгә алып кайттым, сау булыгыз, иптәшләр, мин өемә Чокырлыга кайтыйм инде, диюемә, хәрбиләрнең күзләрен каш астыннан гына караучы җитди кыяфәтле берсе, син китәргә ашыкма әле, рәис, эшебездә син дә булышырсың безгә диде. Аннары ул Зиннәтне читкәрәк алып китеп, аның колагына нәрсәләрдер пышылдады. Зиннәт шундук идарәдәге йомышчыны әтиең урынына мәктәп директоры буласы Һаҗәр Хаҗиеваны чакырырга җибәрде. Хаҗиева идарәгә килгәнче, без колхоз фатирына кереп, кичке ашны ашадык. Зиннәт аш алдыннан хәрбиләр, юлда килгәндә ярыйсы ук

өшедек, бераз җылынып аласы иде, дигәч, аларга ике ярты аракы салдырды. Караңгы төшкәч, хәрбиләргә ияреп, сезгә киттек. Сездә ниләр булганын искә алып тормыйм, аларны син үзең күрден, онытмагансың.

Әтиең ордены синең кулга ничек керде, дисеңме? Һич уйламаганда, Ирек энем. Миңа ияреп кайткан кунакларның Зиннәт эчергән ике шешә аракы аппетитларын котырткан булып чыкты. Әтиеңне иртәгә колхоз идарәсенә кайткач, теге каш астыннан гына карауч житди кыяфәтле хәрби мине ишегалдына алып чыгып, хәзер син безгә тәҗел генә өч литр аракы табып китер, тапмасаң сине дә контрик директорга иярнтербез. Ярты сәгать вакыт сиңа, мин ике сөйләшмим, аң бул, диде. Адәм ышанмас бик хәтәр заман иде бит ул, эткә сан бар, кешегә юк иде, кинәт кенә өтермәгә утырасым килмәде, йөгердем кибетче Бану янына. Төн уртасы, кесәмдә сукыр бер тиен акчам юк. Зинһар, хәлемә кер, Бану, язмышым синең кулда, бир өч литр аракы, бәһасен иртәгә таңнан китереп түләрмен, дигәч, шулкадәр аракының сиңа нигә алай бик ашыгыч кирәге чыкты, дип төпченмәде кибетче, бирде. Башка вакытта аңардан түләүсез инә дә алып булмый иде, хәлемнең мөшкеллеге чыраема чыккан булгандыр, мең рәхмәт аңа, өтермәдән йолып калды. Мине әтиеңә ияртү белән янаган хәрбигә таләбен үтәвем хуш килде, күрәсең, киткәндә, егет икәнсең, рәис, менә моны да мине бер искә алып медалларың арасына тагарсың, дип, түш кесәмә нәрсәдер салды. Аның, аракы тапмасаң сине дә... дип янаганы котымны алган иде, кесәмә нәрсә салуын тикшермәдем.

Озакламый хәрбиләр үзләре янына Сабирны утыртып, Каранга юл тоттылар. Мин, алардан җиңел генә котылуыма шөкер итеп, Чокырлыга — өемә кайтып киттем. Җәлладның аракы өчен миңа әтиеңнең орденын калдырганын икенче иртәнне кибетче Бануга аракы өчен акча илтергә барырга чыкканда кесәмә тыгылгач кына белдем. Ышанасыңмы, орден кулымны өтеп алгандай булды, үземне әтиеңне рәшәткә артына мин дә кертештем итеп тойдым. Күз алларым караңгыланды, аякларымның хәле бетте, чайкала-чайкала сәкегә барып утырдым. Бану янына үзем бармадым, улым Әнвәрне җибәрдем. Ул орденны значокларым арасында минем беркайчан да тагып йөргәнем булмады. Турысын әйтәм, значокларга хирыслыгым да шул көннән сүрелде. Хәзер әнә сугышта кан түгеп алган хөкүмәт бүләкләрен тагып йөрүне дә хуп күрмим. Алар әллә бар миңа, әллә юк. Башта теге хәрбиләр әтиеңнең орденын алырга килерләр, килми калмаслар, дип көттем. Хәтта, ул-бу булса ярап куяр, дип хатыннан бер капчык сохари да киптерттем, урамдагы һәр ят тавышка дерт итеп төннәр йокламадым, тамактан калдым. Алла саклады, килүче булмады. Аннары Сабир иртәме, соңмы кайтыр, орденын җылы кулдан аның үзенә тапшырырмын дип хыялландым. Сабир кайтмады. Орден намусымны борчып, өстемә капланган авыр таш кебек бүгенгә кадәр миндә сакланды. Ярый, ходай кушып, мине ул җанымны талаучы йөктән арындырырга син очрадың...

Чокырлыга кайткач, аннан тизрәк китәргә кыбырсындым. Әюп абый миңа:

— Кабаланма, Ирек энем, килен әнә чәй куя, юлга кузгалганчы, чәй эчеп, бераз хәл алыйк, гәпләшик, артыбызга ут капмаган. Сине мин кая теләсәң шунда илтеп куярмын, борчылма. Өемә кочләп диярлек алып кайткан кунакны чәй дә эчерми җибәрсәм, ни йөз белән кешеләргә күренермен? — диде...

Без өстәл янында сәгатьтән артык утырдык. Хуҗа юлга чыгарга ашыкмый төсле иде. Минем тәкатем тәмам төкәнде. Ахырда, түземсезләнеп:

— Әюп абый, сыегыз өчен рәхмәт, мин юл кешесе бит, бәлки озатып куярсыз инде мине? — дидем.

— Хәзер, хәзер... — диде хуҗа, әмма урыныннан калыкмады, утыра бирде.

Килене өстәл җыярга керешге. Шулчак Әюп абый, көтмәгәндә миңа:

— Минем килендә кемнәр чалымы бар, бәлки чамаларсың? — дигән сорау бирде.

Мин үземә бөтенләй таныш түгел яшь хатынга теләр-теләмәс кенә күз ташладым. Күпчелек авыл хатын-кызларына хас озын һәм юан кара толым, мөлаем караш, шомырттай кара күзләр, килешле борын, өлгергән чия төсендәге тулы иреннәр, каратут йөз, тулы күкрәкләр, зифа гәүдә...

— Әйтә алмыйм...— Аның кемнәр кызы булуы минем өчен бик мөһим микәнни, дигән уй узды башымнан.

— Ул — Бәештәге элекке колхоз рәисе Зиннәт абыең белән укытучы-гыз Хөршидә апаңның төпчек кызлары.

Мине, әйтерсең, янтыгыма төртеп йокымнан уяттылар.

— Исеме Иркә түгелме аның? — дидем күзләремне шар ачып.

— Иркә. Син аны белә идеңмени?

— Белмәскә, аның кендек абыйсы ич мин. Аны беренче кулыма тоткан, тәүге тавышын ишеткән кеше.

— Шулай булса да кем икәнен чамаламадың,— дип шаяртты Әюп абый, киң елмаеп.— Киленнең үз сабыена — минем оныкка өч яшь инде. Гомер уза, тукталып тормый. Йә, килен, кул биреп күреш кендек абыең белән.

Чәй эчү җиһазларын урыннарына куярга шкаф янына илткән яшь хатын томырылып миңа карады. Аннары ул:

— Мин сезне күрергә бала чактан ук хыялландым, Ирек абый. Әни мәрхүмә миңа сезнең турыда сөйли иде. Минем исемем сезнең исемнән алынган бит,— дип килеп күреште.

— Әниегез исән түгелмени инде?

— Әтинең сугышта юкка чыгуы кайгысын күтәрә алмады әнкәй, җир куенына керүенә тугызынчы ел китте инде...

Мин Иркә белән сөйләшкән арада Әюп абый кыршылып беткән иске чемоданнан әтинең берничә кулъяулыкка пөхтәләп төрелгән орденын сүтеп алып:

— Мә, Ирек энем, әтиеңнең каһарманлык билгесе бу, күз карaң күк сакла аны, югалтма,— дип, миңа тоттырды.

Мин, чиксез дулкынланып:

— Әтиемә карата кешелеклелегегез, аны ихтирам иткәнегез, онытмаганыгыз өчен рәхмәт яусын сезгә, Әюп абый,— дип, аны күкрәгемә кыстым.

Әюп абый мине Кaран аэропортына кадәр озатып куйды. Мин вакыт уздырып Гайфи янына кереп тә, яңадан Лениногорскига барып та тормадым, шул көнне үк самолетка утырып Казанга кайттым.

## Унҗиденче бүлек

### 1

Александр Тимченко турындагы брошюрам басылып чыгып, инде күптән сатылып бетте. Гани абыйга йөкләгән эшен озакка сузмый башкарып чыгуым ошады. Ул, брошюрам чыккач, кулымны кайнар кысып:

— Каләмең бар, Ирек, тагын яз, кая теләсәң шунда җибәрәм, вакытыңны бушка үткәрмә, эшлә,— диде...

Соңгы вакытларда миемне бертуктаусыз, яшәвемнең мәгънәсе нәрсәдә, дигән тынгысыз сорау яңадан бораулый башлады. Инде дүртенче дистәне ваклыйм, әмма һаман күңелемә хуш килердәй эш майтарганым юк әле. Һәр туган көнем эзсез үтеп юкка чыга тора, хезмәтемне тоталитар аждаһа ничек теләсә, шулай файдалана. Бу күпме шулай дәвам итәр,

аңа чик куелырмы бирәр? Безнең илдә дә кеше кайчан да булса үзе теләгәнчә, үзе кирәк санаганча яши алырмы? Дөньяга ул кемгәдер бил бөгәргә, кол булырга килми, үзенә ничек кирәк шулай яшәргә, җирне бизәргә, эзен ярырга килә бит. Без исә әйләнә-тирәбездәге бөтен нәрсәне бозабыз, ватабыз, җимерәбез, пычратабыз, башкача әйткәндә, туган көнебездән башлап гомеребез буе үзебезгә һәм бездән соң туачак буыннарга кабер казыйбыз, шуннан тәм табабыз. Аңа чик килерме, нокта куелырмы бирәр вакыт?

Бәхетемә димме, очраклы рәвештәме, бер көнне нәшриятка Казанда әле күптән түгел генә яңадан эшли башлаган документаль фильмнар студиясенең баш редакторы Виталий Гузанов килеп, безнең редакциягә сектантлар турында бармак калынлык кулъязмасын калдырып китте. Редакция мөдиребез Гани абый аны карап чыгып, фикереңне әйт, дип миңа бирде.

Йөгерек тел белән бәян ителгән мавыктыргыч эчтәлекле кулъязмалар безгә сирәк керә иде, мин Гузановның кулъязмасын, ярыйсы ук күләмле булса да, баш күтәрми бер утыруда укып чыктым. Аны киң массага авыр аңлаешлы дини терминнардан, төрле кабатлаулардан, таркаулыктан арындырганда, сектантлыкның чын асылын һәм зарарын ачыклыйрак төшкәндә, һичшиксез, бастырырлык иде. Ләкин брошюраның автордан кала тагын кемгә хаҗәте булыр? Сектантлар безнең Татарстанда бөтенләй юк та бугай бит әле. Шуңа күрә, олы кубып, алар турында китап чыгарсак, безнең баштан сыйпамаслардыр, дип уйладым мин. Икенче көнне, кулъязма турындагы фикерләремне кәгазьгә теркәп, Гани абыйга керттем. Ул, минем белән килешеп, кулъязманы авторга кире кайтарды. Әмма эш шуның белән бетмәде, берничә көн үткәч, Гузанов, телефоннан шалтыратып, мине күрергә теләвен әйтте һәм без киностудиядә очрашырга килештек.

Киностудиянең баш мөхәррире искиткеч киң эрудицияле әйбәт әңгәмәче булып чыкты. Ул хезмәтенә мин биргән бәя белән килешмәс, дәгъвалашыр дигән идем, ялгышканмын. Кулъязмасын нәшрияттан кире борганым өчен Виталий Григорьевич, гаҗәп хәл, миңа хәттә рәхмәт тә әйткәч, күзләрем дүрт булды. Сез минем язмам турында мәскәүлеләр әйткән фикерне үк кабатлагансыз, димәк, әйбер әле тиешле кондициягә җитмәгән, диде ул, сүзне бүтән озайтырга урын калдырмаслык итеп.

— Мин сезне безнең студиягә эшкә күчәргә кодаламакчы булдым. Ничек карыйсыз моңа?

Мин, уйлап та тормый:

— Берничек тә карамыйм,— дидем.

— Ашыкмагыз,— дип текәлде миңа Гузанов.— Миңа сезнең ординар фикер йөртмәвегез ошады. Студиябездә әйберләргә тәнкыйть күзлегеннән карый белүче, анык фикерле бер ярдәмче кирәк миңа.

— Киноның үз хосусияте, аңа гына хас үз кануннары бар бит, Виталий Григорьевич, барып чыкмас миннән киночы.

— Аю тикле аюны да биергә өйрәтәләр, акрынлап өйрәнерсез. Эшегездә баш-күз алганчы үзем булышырмын. Чүлмәкләрне аллалар түгел, кешеләр яндыра бит. Икеләнмәгез, ризалашыгыз, агайне.— Гузанов урыныннан торды.— Әйдәгез әле, без бергәләп берничә киножурнал карыйк. Әңгәмәбезне кече залда экран алдында дәвам итәрбез. Китәргә ашыкмасагыз, дим...

## 2

Мин, нәшрияттан китеп, киностудиягә күчтем. Яңа эшемдә Виталий Григорьевич белән өлкән режиссер Виктор Петрович мине чын мәгънәсендә шефлыкка алып андагы мөхәррирлек эшемнең беренче көннәреннән үк зур булышлык күрсәттеләр. Шуңа күрә мин яңа урындагы вазифаларымны тиз һәм авырлыксыз үзләштердем.

Көннәр бер-бер artлы артта кала торды. Миңа кино ыгы-зыгысында кайнау тормышымда бернинди үзгәрешләр дә китермәде дисәм, ялган булмас. Студиядә дә, нәшрияттагы кебек үк, чынбарлыкны бизәкләп күрсәтүнең беренче планга куелуы, булмаган уңышлар турында шапырынулар, чебенне дөягә әверелдерүләр тынычлыгымны төкәндереп эчемне пошырды. Без документаль фильмнар эшлибез бит, нигә алар ялганга, күрәләтә алдауга корылырга тиеш, нишләп моңа өлешемне кертәм дип, мин үз-үземне таладым. Бу турыда Гузанов белән дә сөйләштем. Ул исә:

— Утырып чыгуың сиңа берни дә бирмәгәнгә ошый. Шуны аңла, кеше — үзе яшәгән заманның җимеше. Анарда заманның бөтен уңай һәм тискәре яклары көзгедәге кебек чагылыш таба. Без бөек чорның бөек документларын кинотасмада теркибез. Киләчәк буыннар без яшәгән бу заманны шул документлардан карап билгеләрләр. Уйларыңны, үзеңә яңадан да күңелсезлек килүен теләмәсәң, бүтән берәү белән дә уртаклашма. Кино-сәнгать купайтуларсыз, бизәкләүләрсез яши алмый, үлә. Борынгы юнан һәм рум сынчыларының кайсы безгә ямьсез сыннар ясап калдырган? Алар ясаган сыннарның барысы да сокландыргыч. Ул сынчылар тирәсендә гел матур затлар гына булгандыр дисеңме? Алар тик гүзәллеккә генә табынганнар, без шул бөек сынчылардан үрнәк алабыз, аң бул,— диде.

Гузанов күп сәләтләргә ия: язучы да, артист та, режиссер да, рәссам да, бик шәп администратор да, заман белән эзгә-эз басып атлаучы патриот та. Ул Бөек Ватан сугышы вакытында, малай килеш, Соловкида илебезнең Хәрби диңгез флоты командованиесе оештырган юнгалар мәктәбендә укыган һәм сугышта катнашырга өлгереп, хөкүмәт бүләкләре алуга да лаек булган. Студиягә баш мөхәррир еш кына түшенә орден һәм медальләр тагылган капитан-лейтенант погонлы диңгезче кителен киеп килә. Аның иң яраткан шөгыле — тарихи китаплар җыю. Бу эштә мин дә аңа кулымнан килгән кадәр булыштым.

Кинода эшли башлавыма өч ел тулганда, безгә Мәскәү кинематография институтын тәмамлаган бер егетне мөхәррир итеп җибәрделәр. Чиксез шатландым моңа. Икенче көнне үк, үземне мөхәррирлектән картина директоры итеп күчерүне сорап, язган гаризамны тотып, студия директорына кердем. Ул гаризамны укыды да:

— Турыдан-туры начальнигың — баш мөхәррир риза булса, мин каршы түгел,— диде...

Мин чирле үгез шикелле гомерем буе гомуми көтүдән читтә калдым. Моңа бәлки, тиешенчә аралаша белмәвем, эчмәвем комачаулагандыр, әйтә алмыйм. Кайда да ялгызлыктан иза чиктем. Ялгызлык авыр, бик авыр нәрсә ул. Аны үзе кичергән кеше генә белә. Агачлар булып агачлар да ялгызлыкны өнәмиләр, яннарында иптәшләре була. Ялгыз агач корый...

Киногруппа белән Каспий диңгезенә Казан мех комбинаты турындагы фильм өчен тюлень көчекләрен аулау күренешләрен төшерергә барган командировкадан арып, талчыгып, җен ачуларым чыгып кайтып төштем...

Өйдә, мин юкта, гадәттәгечә, бер кочак газета-журналлар җыйналган. Иртән, хатынымны эшкә, кызымны мәктәпкә озаткач, шуларны карарга утырдым. Менә, беренче чиратта, Татарстан яңалыклары кызыксындырды. Нефтьчеләр элеккечә үк «удар темплар белән» эшлиләр, терлекләрне кышлату уңышлы бара, колхозлар һәм совхозлар язгы чәчүгә әзерләнәләр, партия укулары һәрвакыттагыча «тиешле югарылыкта үтә» икән. Кинәт кенә «Кызыл Татарстан» газетасында кара рам эченә алынган «Гайфетдин Баһаветдин улы Бәдретдинов» дигән некрологка юлыгып, өнсез калдым. Гайфи бит бу!.. Ул үлгән?.. Кайчан? Ничек?.. Некрологка кабаланып күз йөртә башладым. Казаннан кайтканда, машинада Кама аша чыкканда, һәлак булган. Машина, астында кинәт боз җимерелеп, пассажирлары белән бергә су астына киткән. Ул фаҗига инде моннан ай ярым элек булган. Димәк, Гайфи юк инде. Нигә

аның урынына боз астына мин китмәдем, мин исән? Гайфи урынына мин үлсәм, гаделрәк булыр иде... Гайфи, Гайфи, кем уйлаган сиңа — тормышка чын-чыннан гашыйк затка шундый мәгънәсез әҗәл килерен... Синең елмаюлы йөзең гел минем күз алдымда. Арабызда син иң бәхетлебез идең бит. Кәрим сугыштан кайтмады. Сөләй, фашист концлагерен үткәч, үзебездә дә биек коймалары катлап-катлап чәнечкеле тимерчыбыклар белән бизәлгән «җәннәт»не татыды, хәзер җанын асрарга кайдадыр җир астында күмер чаба, мин юк исәбендә — тышкы кабыгым бар, эчем буш — җил иркендәге тамырсыз дүңгәләк белән бер. Бала чакта урманда атлар саклаганда, күктә үз йолдызларыбызны билгеләгәндә, алдагы язмышыбызны беребез дә куе томан эчендә күзалламаган булганбыз, якты, матур, шатлыклы итеп күргәнбез. Их, тәкъдир, тәкъдир, аллап булса икән сине...

Мин киностудиядән киттем, хәзер эшсез. Алда кайда һәм нинди эшкә урнашырмын — билгесез. Әлегә ял итәм, кем әйткәндәй, «баш-күз алам». Кая барабыз без, кая, аңлый алмыйм, башым җитми, зиһенем чуалды...

Роман-трилогия тәмам.

*1970 ел. Казан.*

**Редакциядән.** Роман-трилогиянең I һәм II кисәкләре журналыбызның 1990 ел. 3—4 нче саннар һәм 1991 ел. 10—11 нче саннарында басылып чыкты.

# ШИГЪРИЯТ



## Фәнис Яруллин

КОЕНА КАЛӘМ — ЯКТЫЛЫКТА

### Үкенмим

Үтелде, күп юллар үтелде,
Өстәге киемнәр тетелде:
Кай көннәр яшь булып түгелде,
Кай көннәр гөл булып сибелде.

Кичелде, дәрьялар кичелде,
Иелеп сулары эчелде.
Өсләргә тау-ташлар ишелде,
Тауларга менелде, төшелде.

Янылды, туктаусыз янылды,
Гел ялкын эченнән барылды.
Ут алып йөрәгем-учактан
Күкләрдә яшеннәр кабынды.

Күрелде, барсы да күрелде,
Өметләр мең үлеп терелде.
Үкенмим, бар утым, бар көчем
Һәммәсе халыкка бирелде.

### Юнәлеше үзгәрүчән җил

Синоптиклар хәбәр итә еш кына:
«Юнәлеше үзгәрүчән көчле җил!»
Кайсы яктан ышыкларга соң өйне,
Җилләр шулай борылгалап торгач гел?!

Әллә барлык тәрәзәсен кадаклап,
Качаргамы, башны алып, өйләрдән?

---

Фәнис Яруллин (1938) — *шагыйрь, прозаик, драматург; күпсанлы китаплар авторы, М. Җәлил исемендәге бүләк лауреаты. Казанда яши.*

Бик арыдык, бик алжыдык бит инде
Юнәлеше үзгәрүчән җилләрдән.

Кайчан әйтер синоптиклар ышанып:
«Алда матур, аяз көннәр көтелә...»
Ә хәзергә тотырыксыз салкын җил
Тузан сибә кешеләрнең битенә.

* * *

Ыргыттылар эткә әйбәт сөяк,
Ә эт аны тик бер иснәде,
Кимермәде,
Башын читкә борды,
Юк иде шул аның тешләре.

Сискәндерде мине этнең күзе,
Ул күзләрдә тирән моң иде.
Бер якта эт, ә бер якта сөяк,
Ә арада
Гомер дигән озын юл иде.

## Өч нәрсә

Туган ягына кешене
Өч нәрсә гел тартып тора.
Кайда йөрмә — шул өч нәрсә
Тартып алып кайтып тора.

Беренчесе — балачагың,
Агачтагы алма чагың.
Эзли кеше шул алманы,
Белсә дә алданачагын.

Икенчесе — була өең.
Ул — кендек бәйләгән төен.
Йөртә кеше үз тәнендә
Шул төеннең бетмәс җөен.

Өченчесе — газиз анаң,
Бар яхшылык безнең аннан...
Кеше ятим, кеше үксез,
Шушыларны алсаң җаннан!

* * *

Арыдым, арыдым —
Бәгырьсездән шәфкать көтеп,
Хәтерсездән рәхмәт көтеп,
Тәртипсездән әдәп көтеп,
Аңгырадан аңлау көтеп,
Йөрәксездән яклау көтеп,
Мәгънәсездән санлау көтеп
Арыдым!

Туйдым, туйдым —
Ямьсезгә матур диюдән,
Куркакка батыр диюдән,
Кәкрегә туры диюдән,
Кечегә олы диюдән,
Башсызга башлы диюдән,
Яманга яхшы диюдән
Туйдым!

Инде нишлим? —
Хакны гына сөйләргәме,
Әллә егылып үләргәме?!
Хак сөйләсәң — көләчәкләр,
Юләр диячәкләр...
Үлсәң — сөенәчәкләр.

## Кирәклек

Бакчачы җәй буе, тырышып,
Чәчәкләр үстерде түтәлдә:
Утады, йомшартты, су сипте —
Күңелен куймады бүтәнгә.

Гөлләре үстеләр шәп булып,
Бакчага таратып сихри ямь.
Рәхәтлек өстәлде күңелгә
Аларны хәтта бер күрүдән.

Ә менә беркөнне бу турга
Туктады бер олы машина.
— О-о, тирес килгән! — дип, бакчачы
Йөгерде машина каршына.

Нишләргә? Бушатыр урын юк,
Бакчасы сыйдырмый — кечкенә.
Аудартты Хуҗа бу байлыкны
Чәчәкләр түтәле өстенә...

Рәнҗемә, әй күңел, дөнья бу!
Ә анда еш җиңә кирәклек.
Кирәклек өстенлек иткәндә
Югала акыл һәм зирәклек.

* * *

Кешеләр бик вакланды дип,
Күңелем, гаҗәпләнмә:
Аккан сулар да саега,
Тау да тәбәнәкләнә.

Мәңгелек түгел икән шул
Биеклек һәм олылык.
Шушы хаклыкны аңларга
Җитми бары кыюлык.

* * *

Урманда агач башында
Бер көтү ала карга —
Бер-берсен уздырмак булып
«Кар» да «кар» килә бар да.

Язны чакыралар алар,
Күмәкләшеп каркылдап.
Ала каргалардан урман
Күләп тора шаркылдап.

Әйе, кәлә, чөнки белә —
Урман хәтере нык әле:
Ала карга кычкырганга
Яз килгәне юк әле.

Без генә ул —
күмәкләшеп
Каркылдаса каргалар,
Кушылабыз каргаларга,
Яз китерер дип алар.

## Шуңа шөкер

Хыяллар хыянәт итте,
Өметләрем — алдады.
Инде яңа хыялларга
Җанда урын калмады.

Данлы юллар үтәрмен дип
Йөрәк күпме янмады —
Мин кердсе дан сараен
Һәрчак ялкын ялмады.

Ярый инде, өметләрем
Алдаса гел алдады —
Данлы эзләр калмаса да...
Канлы эзләр калмады.

## Бүген кемнәр?

Бер ак каурый алып кайттым
Су буеннан, чирәмнән.
Каурый калган, ә соң кошын
Язмыш кая җибәргән
Туган-үскән җирләрдән?

Кулларымда ап-ак каурый,
Әйтерсең ак кулъяулык.
Ярым киткән, истәлеккә
Калган бары шул яулык —
Бер ярага ябарлык.

Ак каурыйның ап-ак төсе
Сакланырмы озакка?
Бүген кемнәр, каурый тотып,
Аккошларын озата
Кайтмас җиргә, еракка?

## Үлчәү юк

*Нурсөягә*

Җылылыкны үлчәр өчен үлчәү бар,
Олылыкны үлчәр өчен үлчәү юк.
Шуңа ахры кешедәге олылык
Ята күпчак бәяләнми, онтылып.

Авырлыкны үлчәр өчен үлчәү бар,
Сабырлыкны үлчәр өчен үлчәү юк.
Данланса да, макталса да сабырлык,
Сабырлыкның ни даны бар калырлык?!

Ныклыкны үлчәр өчен дә үлчәү бар,
Тугрылыкны үлчәр өчен үлчәү юк.
Шуңа ахры бәрелеп тә сугылып
Күпвакытны җанда үлә тугрылык.

Мәрхәмәтне үлчәргә дә бизмән юк.
Мәхәббәтне үлчәргә дә бизмән юк...
Иң-иң асыл затларның да алдына
Әле зурлап гөлчәчәкләр тезгән юк.

## Синең яктылык

Шигырь дәфтәремә бер нур төшә,
Ул, ахыры, синең яктылык.
Утырамын шигырь язарга мин,
Шушы яктылыкка тартылып.

Коена каләм шушы яктылыкта,
Әверелеп сылу аккошка.
Аккош канатыннан тамчы чәчрәп,
Күл өсләрен күмә балкышка.

Әллә нинди бер ашкыну белән
Сиңа бара җаным тартылып:
Сөю турындагы шигырьләргә
Сеңә бары синең яктылык.

## Оныттыр

Юллар авыр, юллар ерак,
Коткара тик юлда җыр:
Мәңге җырлар җырым бул да,
Юл газабын оныттыр.

Мин суларың эчкән саен
Чишмә булып тулып тор:
Башка чишмәләрнең тәмен
Оныттыр син, оныттыр.

Баш өстемә болыт килсә
Җилләр булып куып тор —
Җилләр булып куып тор да,
Хәсрәтемне оныттыр.

Йә гөл булып, йә көн булып,
Гел яңарып туып тор —
Табындырып, кабындырып,
Бар дөньямны оныттыр!



# Кадыйр Сибгат

## КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАП

* * *

Арттагылар инде куып килә.
Булмый хәзер юлда тукталып.
Кая таба бара —
күрә микән,
белә микән бүген бу халык?

Упкын тирән алда...
Ярлар биек...
Бер ычкынып китсәк түбәнгә,
башлар бетәр безнең —
эз дә калмас,
сөякләр дә калмас күмәргә.

Нигә сөяк?
Нигә мәет?
Кабер?
Кемгә кирәк булсын күмүләр?
Сибелербез тагын томан булып...
Яшәү булып сибелер үлүләр.

Яңа түгел.
Котылгысыз.
Безнең
кич тә булыр,
булгач таңыбыз...
Сыеп булмас Җиргә.
Галәм иркен:
азат булыр безнең җаныбыз.

*1991*

---

Кадыйр СИБГАТ (1942) — *шагыйрь. «Гамь», «Әманәт», «Гомерем дулкыннары» һ. б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

* * *

Бу күкләрне нигә ачтың миңа?
Йолдызларны нигә күрсәттең?
Уй-сагышлар, ашкынулар икән —
яшәргә дип биргән рөхсәтең...

Бер сәбәпсез җаннар ашкынмыйдыр.
Сәбәпләрен кайдан эзләргә?
Нигә йөрәк ешрак тибә башлый,
йолдыз нуры төшсә йөзләргә?

Нигә кирәк андый ашкынулар,
яшәр өчен Җирдә ярасам?
Шунда менеп китәселәр килә —
күтәрелеп Күккә карасам.

Мең ел элек сүнгән йолдыз яна.
Яктылыгы килә нур булып...
Бу галәмдә без бик кечкенә шул,
ә яшисе килә зур булып.

*1990*

## Яшик

Меңәр еллык тарих та бар.
Исем дә бар, ат та бар.
Милләт тә бар, халык та бар,
хокук та бар, хак та бар.

Инде без ярлы да түгел,
үтте бездән фәкыйрьлек.
Инде без мескен дә түгел.
Горур диеп әйтерлек.

Барысы да үзебездә.
Бөтенесе бирелгән.
Әллә нәрсә эзләгән күк
башлар гына иелгән.

Түбән карап эзлибезме? —
Яшик лә ансыз гына...
Милләт бөек, халык бөек, —
бары тик сансыз гына.

*1989*

## Намус

Бик әйбәт булыр күк бу тормыш —
тигез дә, дөрес тә, гадел дә...
Һаман да җитешми бер нәрсә
бүгенге кешелек гамендә.

Бераүләр интегеп эзлиләр.
Булмаса, ул эзләп табылмый.
Булганда күренә. Беркайчан
намус ул — өстенә ябынмый.

Намуска кагыла, намуска:
кыйныйлар, сүгәләр, хурлыйлар...
Кемнеңдер үзендә булмаса,
намусны кайвакыт урлыйлар.

Бераүнең җанына орына:
намусны асалар, аталар...
Кешегә тынгылык бирми ул.
Шуңадыр намусны саталар.

Бернәрсә тормый ул кемгәдер
сытарга намусны, таптарга.
Бик кирәк вакыты булыр дип,
тырыша кемнәрдер сакларга.

Кешегә бирелгән чамалап.
Кешегә күптәннән җитмәгән.
Караган ул теге дөньяга,
бусыннан гаделлек көтмәгән.

Намуска бәйләнгән, намуска:
йә өстә дөреслек, йә аста.
Намусның кирәксез чагы юк.
Намусны тотмыйлар запаста.

*1989*

* * *

Безнең инде азмы таңнар аткан.
Азмы өмет туган таңнарда!
Кайсылары чынлап эшкә ашкан,
җитәр, дидек, безгә алар да.

Безнең өчен әле таңнар белән
офыкларның күпме янасы...
...Юк,
җитмәгән икән,
таңнар атса,
өметләрнең туа яңасы.

*1986*

* * *

Мин икенче кабат яшим бугай:
җире бүтән,
һава,
көн бүтән...

...Мондый түгел иде минем гомер,
бер яшәгән идем мин күптән.

Без үлчибез кеше гомерләрен
Әнкәсеннән туган көненнән.
Үлә, диләр, кеше бер мәртәбә,
ничә тапкыр туа —
кем белгән?!.

*1989*

## Ирләр елый

Елыймы ирләр? — дисәгез,
сорагыз, әйтер сезгә...
(Аңлашылып бетмәс, бәлки,
җансызга, бәгырьсезгә.)

Әйтер сезгә Әфганстан,
әйтер Пишаварлары...
Унсигез яшьлек улларын
югалткан аналары.

Керегез госпитальләргә:
егетләр нык хәтерләр.
Ирләр елыйлармы бүген?
Инвалидләр әйтерләр.

Мәет булып кайтканнарның
тыңлагыз каберләрен.
Исән-сау кайтканнарының
җаннары җәберләвен.

Күрделәр алар үлемне,
үтерүне күрделәр.
Иптәшләрен генә түгел,
җанны ярып күмделәр.

Бармадылар бәхет эзләп, —
Илдә урын тармыни?
Үлем алып баручыга
читтә тормыш бармыни?

Унсигез яшьтә уйланмый —
кеше гомере бер генә.
Шул бер гомер күпме тора:
алар шуны белделәр.

Еламый дип беләсезме
Әфганның егетләре?
Илгә тешләрне батырып
суырдык җелекләрен.

Елады безнең малайлар,
елады безнең ирләр.

Бәгырьсезләр аркасында
елады безнең җирләр.

Коточкыч булыр иде ул
егетләр еламаса.
Үлем түгел, үтерәш бит!
Мөмкинме еламаска?!

Еларга кирәк, еларга.
Елау көчсезлек түгел.
Елый-елый үсә кеше,
елап чыныга күңел.

Күз яшьләренә буылып,
елый-елый аттылар.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә,
олыгаеп кайттылар.

*1989*

* * *

Көннәр туа.
Безнең көннәр туа.
Үткәннәрен озатып каласың.
Бик беләбез
туган көннәр белән
гомерләрнең кая барасын.
Көннәр безгә,
шөкер,
буш килмиләр.
Уйландырмый гына китмиләр.
Йөрәкләргә керә,
җаныбызга —
Кояш нурын әрәм итмиләр.
Гомер безгә күптән бирелгән ул.
Күптән куйган инде исәпләп.
Көннәр алар гомер алып килми,
алып кына китә кисәкләп.
Яңа Кояш...
Яңа көннәр,
гомер...
Исәндер без — янып,
яндырып...
Нәрсә ала,
үзе нәрсә таба —
китә барысын да калдырып.
Килер бер көн...
Безне килеп алыр...
Җисмебезне кире кайтармас.
Сез карагыз —
балкып Күктә калыр —
безнең җаннар китмәс,
картаймас.

*1987*

## Арал

Әлсерәгән комнар. Янып ята —
сулышлары кайнар ярларының.
Табигатьне тагын кайгы басты —
хәле начар бүген Аралының.

Чирен аның кеше өсти тора.
Табибына мохтаҗ, даруына.
Бер тамчы су кирәк, бер тамчы су
ирен чылатырга авыруга.

Диңгезгә дә сулар җитми әнә,
гомер буе әгәр таласалар.
Эчеп калыйк! Безнең гомерләргә
җитәр әле диеп карасалар.

Комсызлыкның чиге булмый калмас.
Андый чаклар килеп җитә икән.
Гомер иткән үз ярларын сулар
андый чакта ташлап китә икән.

Диңгез китәр. Китәр барлык сулар.
Һавасы да калмас суларына.
Кайнар комнар гына сибелеп ятар
бүген чәчәк үскән юлларына.

Кырын ята ярда кораблары
һава җитми үлгән балык кебек.
Балыкчылар йөри башын иеп,
үле җиргә кайткан халык кебек.

Кайнар комга басып үтә кеше.
Дулкыннары килеп күмми эзне...
Шул кораблар кебек калырбыз без,
барысы да ташлап китсә безне.

*1989*

# Чәчмә әсәрләр

**Фәрит Яхин**



# СОҢАРГАН ДАСТАН

хикәя

Котбетдин Әр-Рази хәзрәтләренең Сарайга килгәненнән алтынчы елында Үзбәк хан көтмәгәндә вафат булды. Шәһрәте белән бар тарафны тетрәтеп торган олуг тәхет хуҗасының гүр иясе булуына мирас бүлешү башланып, көннәр хәвеф эчендә туа вә бәндәләрне тетрәндерә иде. Җанибәк белән Танибәк угыллар арасында оят вә үзара хөрмәт хисе калмады. Бүген булмаса, иртәгә ике яктан да ут уйнатып, кылыч айкап, бер-бер ахмаклык эшләп ташлыйсылар иде.

Котбетдиннең бәгыре көйде. Тирә-якта шөһрәтле вә мактаулы Алтын Урдада бара иде шул бу хәлләр. Әле кайчан гына Танибәк аның каршында тез бөкләп дәрес ала, үзенең зирәк вә сизгер булуы белән сокландыра иде. Хәзер остазы сүзенә колак та салмый, киңәш-табыш та итми башлады. Угланнар ут белән генә түгел, тәхет вә баш белән уйный иделәр, аңлаган кеше генә моның ни аяныч хәл икәнлеген сизенергә мөмкин.

Иделдә боз соңарып кузгалды. Җәй башларында су улаклардан басуларга йөгерде, буа һәм ермакларны бүсеп чыкты, иңкүлекләрдәге чәчүлек җирләр су белән болганды. Болгар иленнән арырак Көнчыгышка таба җәелгән нугай башы җәйләвендә Агыйделгә килеп кушылган Чулман дәрьясы хакында, хәтәр күперде, дип сөйләде сәүдәгәрләр. Базар бу вакытларда элегрәк кайнап тора иде инде. Быел Гыйрак, Һират вә Рум ягыннан сәүдә кораблары килә алмады. Кәрвандагы бер дөя хакы, былтыргы белән чагыштырганда, унына бәрабәр тора башлады. Бәркә ханнан бирле урнашып калган кануннар какшады. Бигрәк тә салым вә ясак күләме артты, хак вә бәя үсте. Халык арасында, казнаны Танибәк талап, Җаек суы артына качкан икән, дип сөйләделәр. Җанибәк исә аның иярченнәрен аулады. Котбетдин үзенең дә исемлек башында торганлыгын аңлады. Үгет-нәсыйхәт биреп, сөекле укучысы Танибәккә ярдәм кулын сузмакчы булды. Ут белән уйнамасын, күңелен тындырсын, абыйсы Җанибәк белән килешсен, дуслашсын!

Инде икенче кичәне Котбетдин Әр-Рази шигырь язуга, бәетләр чыгаруга багышлады. Төрки вәзен белән төзүе җиңел вә рәхәт иде. Бала чактан күңеленә сеңеп калган угыз теле аның анадан килгән мирасы булып,

чактан күңеленә сеңеп калган угыз теле аның анадан килгән мирасы булып, фарсы вә гарәп исә үзенең иҗтиһат җимеше иде бит. Ничәмә-ничә тарихи, дини вә фәлсәфи дәфтәр һәм китапларны гарәптә, кайвакыт фарсыда тәпләгән, теркәлгән, төзәткән олуг остаз өчен кабаттан төркигә кайту ничектер күптән элек хәтереннән чыккан балачагын күңелендә яңарттырды. Яратып укыган әсәреннән берсе Низами хәзрәтләренең «Хөсрәү вә Ширин» дастаны иде. Шушы борынгы тарихи язмышлар белән Алтын Урда хәлләренең тәңгәллеген күреп, Котбетдин Әр-Рази башта курка калды, аннан соң бу хакта укучысы Танибәккә аңлату кирәклеген төшенде. Искәндәр Зөлкарнәй хәзрәтләрен голамәи Ариста рухи азык белән тукландырып ничек илаһи каһарман ясаган булса, Котбетдин дә Танибәкне шул рәвешле олы шәхес дәрәҗәсенә күтәрергә өметләнде. Әмма Танибәк вак җанлы, артыгы белән кайнар һәм киңәштән үзен өстен саный торган шаһзадә иде шул. Алай да зирәк һәм эшлекле булуы сәбәпле, аңа карата остазы күңелендә ышаныч вә өмет тә яши иде. Боларны уйлап, Котбетдин авыру кешегә ярдәм кулын сузмаган табиб кебек сизде үзен.

Җәй уртасы җиткәндә Котбетдин дастанны тәмам итү алдында иде. Җәйләүгә чыккан Сарай шәһәре таифәсе шаулашып, тузан күтәреп, кубарылып кире кайта башлады. Барысының да күңелләре кузгалган, күзләре аптыраш вә хәерсезлек белән акайган иде. «Тәхетен Җанибәк ташлап качты»,— дигән хәбәр тиз арада таралып өлгерде. Шәһәрне Танибәк урдасы камап алган иде. Сарай сугышсыз бирелде. Тәхеткә менеп утырган яңа ханны котларга бай сәүдәгәрләр һәм галим-голамә кичкә таба җыела башлады. Танибәк тәбрик сүзе белән килгән Котбетдинне дә кабул итте. Остаз һәм шәкерте шаһзадә очраштылар.

— Йа, остазым!—дип фәрман кылды Танибәк хан.— Син миңа нәрсә әйтерсең?

Котбетдиннең акылы кайнады, күңел кошы күкрәк читлегендә бәргәләнде. Ничек җавап бирсә дөрес булыр икән?

— Син минем тәхет каршында булырсыңмы?—диде шаһзадә үзалдына канәгатьлек табарга теләп.

Озакка сузарга ярамый иде. Котбетдин Әр-Рази әле ахырына кадәр ирешмәгән дастанны аңа сузды:

— Бу сезнең игътибарыгызга тәгаен кылынган иде,—диде ул түбәнчелек белән.

Танибәк хан каләм иясе Бәркә Фәкыйһка ым какты. Тегесе җәһәт кенә Котбетдин кулыннан дәфтәрне алды һәм укый башлады. Аны хан түземсезләнеп бүлдерде:

— Кирәк җиреннән укы!

Бәркә Фәкыйһ буйсынды, Аллаһы тәгаләгә, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм сәхабәләргә дан җырлау урыннарына күз йөртеп кенә узды да, үз табышына үзе сөенеп, Танибәк исеменә аталган юлларны укып китте. Ханга шушы кирәк иде.

— Бүләгең белән олыладың, тугрылыклы булуың өчен сөендерү лазем булыр үзеңне,—диде Танибәк яшь йөзенә ирлек төсе чыгарып.

— Ханым, дастан әлегә ахырына ирешмәде,—дип өстәде аңа Котбетдин. Бу сүзләре бал тәпәненә дегет кашыгын китергән кебек булса да, яшь хан үзен бөтенләй башкача тотты. Әллә олыларча уйлый алмый иде, әллә остазына хөрмәте зур идеме?

— Хәзергә монысы да җитәр, тәмамын көтеп торма, булган кадәресен кичәләребездә укып сөендер!—дип белдерде ул.

Котбетдин шул рәвешле Сарайда калды. Язылган һәр бүлекне хан тыңларга ашыкты. Әмма Җанибәкнең, тәхетне даулап, ауга киткән җиреннән олуг гаскәр белән кайтып килгәнлеге беленде. Шәһәр халкы Танибәк ягыннан Җанибәк тарафдарына әверелде. Сарай бушап калды. Танибәккә бер чара бар—ул да булса тәхетне ташлап качу иде.

Бу хәл Котбетдинне тетрәндерде. Ул дастан язу белән артык мавыгып, Хөсрәү белән Ширинненң мәхәббәт маҗараларын сөйләү белән

дәртләнеп, тормыштан артка калганлыгын, хакыйкатьтән читләшкәнлеген аңлады. Бу вакытта әсәрендә Фәрһадның Ширингә гыйшкы сурәтләнә иде.

Хәвефлек хәбәрне аңа Танибәкнең бахши-кәтибе Бәркә Фәкыйһ китерде. Тизлек белән җыенырга һәм Сарай таифәсе белән кузгалырга кирәклеген хан фәрманы буларак җиткерде. Котбетдин монда кала алмый иде.

Танибәк хан йорты белән бергә Җаек ягына таба кузгалды. Җанибәкнең Болгар иле белән куа килүеннән өректе ул. Җаек буендагы Алатау җәйләвенә чатырлар корып урнаштылар. Котбетдин, киңәш тотып, ханның катына барды, әмма кабул кылынмады. Хәле авыр, диделәр. Ә чынлыкта Танибәк, үз туганы Җанибәктән хурлыклы рәвештә сугышсыз качуыннан соң, остазының күзләренә туры караудан ояла һәм үз йөзеннән үзе чиркана иде. Котбетдин моны аңлады. Кире кайтып, дастанны тәгәлләү эшенә керешә. Әмма уе буталып, кулыннан каләме төште.

Иртәгәсе көн йорт халкы ханбикәнең ачыргаланып кычкыруыннан шаша калды. Күкрәгенә хәнҗәр кадалган хәлдә Танибәк урын өстендә канга батып ята иде. Тәненең суык булуыннан аның инде төн урталарында ук үтерелгәнлеген һәркем аңлап алды. Куа чыгарга соң иде.

Тарих кабатланды. Хөсрәү ничек үтерелсә, Танибәк тә Җанибәк ханның шымчысы тарафыннан һәлак ителде. Котбетдин Әр-Рази үзенең укучысы — шаһзадәгә ясин чыкты. Күзләре яшьләнде һәм башка һичвакыт Сарай тирәсендә кайнашмаска сүз бирде. Аңа хәзер бу илдә калырга ярамый иде. Гыйракка, үзенең туган иленә төбәп юлга чыкты. Артыннан тансык дала җиле озата барды.

Хәзер ул кая бара? Кемгә килә, аны нәрсә көтә? Берсе дә билгеле түгел иде. «Хөсрәү вә Ширин дастаны» тәмам булды. Аны да бар китаплары белән бергә бахшигә тапшырды. Танибәккә үгет-нәсыйхәт, киңәш-табыш бирәчәк әсәре инде аталган кешесе колагына барып ирешмәс. Бу — остазның тарихларны айкап йөрүе аркасында соңаруы иде.

## Сәйделгыйлем Зарипов

# ЮЛ ЧАТЫНДА КАБЕР

ПАРЧА-ИСТӘЛЕК

**Сәйделгыйлем агай Зариповка 73 яшь. Ул гомерен Мөслим районының Вәрәшбаш авылында үткәргән. Ярты гасырдан артык балаларга немец теле һәм география укыта. Бу — аның төп һөнәре. Әмма җанында күп төрле тойгылар, тынгысыз уйлар саклаган Сәйделгыйлем агай кулына каләм ала, якташлары аның мәкаләләрен, очеркларын, парчаларын «Авыл утлары» исемле район гәзите битләреннән даими укып баралар. Йөзләгән мәкалә һәм парчалар аның каләме аша якташларына барып ирешкән. Алай гына да түгел, Сәйделгыйлем агайның хикмәтле сүзләре, якташлары хакында җан җылысы белән язган парчалары республикабыз гәзитләрендә дә басыла килгән. Ул язган хәбәрләрдә Мөслим ягының данлы кешеләре дә, авыл тарихы да, укытучы-педагогны борчыган тәрбия мәсьәләләре дә урын ала.**

**Авыл хәбәрчесенең тынгысыз каләме ирешкән әдәби-сәнгатьчелеген искә алып, мин аның бер парчасын яраткан журналыбызга тәкъдим итәм.**

**Гариф АХУНОВ.**

Тау башындагы ул каберне мин балачактан бирле хәтерлим. Зөбәйдә кабере дип атала ул. Сабый чакта без юа җыеннынан кайтучы атлы кунакларны шул кабер торган тау астындагы басу капкасын ачып каршылый идек. Кунаклар чәчеп калдырган кәнфитләрне яшел хәтфә чирәм арасыннан җыеп ашаулар инде еракта калган...

Җиде юл чатындагы әлеге кабернең чардуганы чирәм төсле яшелгә буялган, урта бер җирендә зур ак каен үсеп утыра иде.

Шул тирәдән узучылар: «Монда нинди зат ята икән? Нигә ялгыз ул кабер?» — дип уйлагандыр, билгеле.

Мин дә сабый чагымнан ук моның серен белергә тырыштым. Тик аны үсеп җитеп, мәктәптә укытучы булып эшли башлагач кына ачык белә алдым. Балаларны да, география дәресләрендә сәйранга чыккач, шушы кабер янына алып килә идем. Ни әйтсәң дә, Зөбәйдәнең гомере мәктәп белән, мәгърифәтчелек белән бәйле.

Зөбәйдә...

Аның чын исеме Зинаида Васильевна Тутаева (Бочкарева). Ул Казан шәһәрендәге керәшен татары Василий Кузьмич Бочкарев дигән сәүдәгәр гаиләсендә туган. Зинаида үз заманына күрә укымышлы, зирәк кыз була. Ул үсеп җиткәндә, әтисе Василий Кузьмич йолым түләп керәшенлегеннән баш тарта һәм, ислам диненә кире кайтып, Госман Барбашевка әйләнә. Шул чагында кызына да Зөбәйдә дип исем куштыра.

Бераздан Зөбәйдәне Сабадагы зур бер сәүдәгәр Кәрамулла Тутаевка кияүгә бирәләр. Тик яшь кәләшкә ире белән озак яшәргә туры килми. Кәрамулла ярман сугышына китә, анда өлкән офицер дәрәҗәсенә күтәрелә, тик өенә кайту гына насыйп булмый аңа — сугыш кырында ятып кала. Сугыштагы батырлыклары өчен ул зур бүләк — икенче дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән була. Бүләкне соңрак хатынына тапшыралар.

Шул чорларда безнең авылда да бай сәүдәгәрләр яшәгән. Аларның берсе Хәрбәтулла Рәхимжанов сәүдә эшләре белән Казанга йөри. Шулай бер баруында аңа якын дусты Госман Барбашев сөекле кызы Зөбәйдәнең тол калуы турында әйтә.

— Әфәндем Госман, миңем бертуган энем Зарифулланың җәмәгате Фатыйма да гүр иясе булды бит инде...— ди Хәрбәтулла.

Госман сәүдәгәр дустының тел төбен шундук аңлап ала, кулы белән ияген учлап, арлы-бирле йөренеп тора да әйтә:

— Әллә соң, кордаш, бу ике ятим җаннарны кавыштырып, башлы-күзле итәбезме?

Авыл сәүдәгәре моңа, әлбәттә, риза була.

Әнә шулай итеп, шәһәр кызы, укымышлы Зөбәйдә безнең авылга килен булып төшә. Ятим калган ике баланы, үз балалары кебек якын күреп, куенына сыендыра. Зарифулла белән бик матур, бик тату яши алар. Авыл кешеләре дә Зөбәйдәнең зирәклеген бик тиз таный. Вәрәшбашта урысчаны «су кебек эчүче» бер Зөбәйдә генә була. Хатларга адресны ул яза, авылга урыс агае килсә, тылмачлык итүен сорап, Зөбәйдәгә йөгерәләр. Урыслар белән аралашырга туры килгән ул чакларда Ольгино, Яңа Мажын, Шуган, Зар Усы, Приют Шуран авыллары Вәрәшбашка якын гына. Мажын, Шуган базарларына безнең авыл халкы еш йөргән. Күрше тирәдәге урыслар да безнең авылга гел килеп торган. Менә шул чагында инде Зөбәйдәнең урысча белүе ярап куя.

Бер мәлне хәтта авылның иң белемле кешесе Ризатдин мулла да Зөбәйдәгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Хәлбуки, авылдан узып баручы урыслар, арба тәртәләре сынгач, Ризатдин мулланың ишегалдына кереп, ярдәм итүен үтенгәннәр. Тик мулла аларның үтенечен аңламый. Мулла абзый олы кызы аша Зөбәйдәне чакырып килергә мәҗбүр. Шуннан соң гына урысларның гозере аңлашыла, мулла абзый лапас түбәсендәге бер тәртәлеген тегеләргә биреп җибәрә.

Тагын бер вакыйга. Көннәрдән бер көнне безнең авылның өч егете — Гаяз, Котдус, Фәтхелбаян — Пьяный Борга (аны совет чорында Красный Бор дип атадылар) ашлык илткән чакта урыс авылына чәй эчәргә керәләр. Фәтхелбаян исә, араларында урысчаны әйбәт белүче, арба тәгәрмәче ватылып артта калган була. Котдус белән Гаяз йомышларының ни икәнен әйтә алмыйча, байтак азапланалар. Шулай да маржа әби, самавыр сүзен ишеткәч, егетләрнең гозере ни икәнен төшенә. Әмма самавыр кайнап чыгып, чәй эчәргә керешкәч, егетләргә сөт тә кирәк булып чыга. (Авылларда бит татар гомер буе сөтле чәй эчә!) Ә менә сөт дигәнне егетләр берничек тә аңлата алмыйлар. Шунда аңлатып азаплана торгач, егетләрнең берсе — Гаяз дигәне, иелеп, дүрт аяклы мал булып баса да мөгрәп куя, ә Котдус аны савып күрсәтә. Маржа әби моны күреп башта бик аптырый, тораташ булыпката, тик бераздан гына мәсьәләнең асылына төшенеп, шаркылдап көлеп җибәрә, егетләргә сөт кертеп бирә.

Көлсәң көл, еласаң ела, дигәндәй, ул чактагы авыл тормышыннан хәзер мәзәк булырдай нәрсәләрне күп сөйлиләр. Моның белән әйтәсе килгәнем шул: Зөбәйдә авыр хәлдә калган кешеләргә һәрчак ярдәм итә. Ир-атларны ул урысча укырга-язарга өйрәтә. Әйтик, Гыйздулла, Зиннәтулла, Әхтәм ише кешеләр нәкъ менә аның ярдәмендә урысча сөйләшә алучы булып китәләр. Киң күңелле, изге җанлы Зөбәйдә бик күпләрнең күңеленә мәгърифәт нуры сирпи. Ә үзенең язмышы — аянычлы...

Әнә шулай безнең якларда әйбәт кенә яшәгәндә ул кинәттән үлеп китә. Безнең авылга гына түгел, тирә-күрше авылларга да зур кайгы, авыр югалту була бу. Зөбәйдәне җирләргә иң мөхтәрәм кешеләр җыела. Аңа кәфен тегәргә ситсы эзләп актарынганда сандык төбенә яшерелгән «тавык тәпие»нә — тәрегә күзләре төшә. Моны күргәч, кәфенлек эзләүче остабикә-абыстайның куллары калтырый башлый. Аның янына карчыклар килә. Шунда араларыннан берсе: «Аллам сакласын! Ул мөселман булмаган икән...» — дип, әлеге нәрсәкәйне башкаларга да күрсәтә.

Мәетне соңгы юлга озатырга килүчеләр, куркышып, берәм-берәм таралалар. Хәбәр яшен тизлегендә авылга таралып өлгерә. Әлбәттә, бу хәбәр олы муллага да барып җитә. Олы мулла катгый карар чыгара: «Кяферләрне мөселман зиратына күмү — харам!»

Авырлыкның башы Зөбәйдәне Зарифулла белән кавыштырган Хөрбәтулла картка төшә. Мәетне аның подвалына төшереп, кар базыннан алып чыгылган «суыткычка» куялар. Карт исә шул ук көнне губернаторга китә: күмү өчен җир сорарга кирәк бит. Ничек итсә итә, рөхсәт язуы алып кайта,— бәлки, кодасы Госман сәүдәгәрнең дә файдасы тими калмагандыр.

Аны түземсезлек белән көткән халык:

— Йә, Хөрбәтулла, ниләр майтардың? — дип сорыйлар.

— Губернатордан рөхсәт бар. Зөбәйдәне җиде юл чатына күмәргә куштылар,— ди Хөрбәтулла вәкарь белән генә.

Авыл старостасы Зөбәйдәне күмү өчен урын күрсәтә. Һәм ул без белгән өч юл чатындагы чокырлы урынга күмелә...

Дөньялар катлаулы. Авыл халкы Зөбәйдәнең кешелекле булуын да белә, халыкка никадәр файда китерүен дә аңлый, әмма дин кануннарыннан читкә дә китә алмый шул! Ә бит әлеге көмеш тәре иренең сугыштагы батырлыгы өчен бирелгән «Георгий тәресе» булган. Һәм аны Зөбәйдә гаиләсенең якты бер истәлеге итеп саклаган...

Юл чатында Зөбәйдә кабере тора. Гүяки, ил кызының игелекле эшләрен онытмасыннар өчен язмыш аны үзе олы юл чатына чыгарып куйган.



Казакъ халкының мәшһүр шагыйре Мәгжан Җомабаев 1893 нче елның 26 нчы июнендә Акмулла төбәгенең Булаев аймагында дөньяга килә. Бик иртә укырга, язарга өйрәнеп, Кызылъяр каласының атаклы кешесе Мөхәммәтҗан Бегишев мәдрәсәсендә башлангыч белем ала. 1910 нчы елда Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга килә.

1906—1916 нчы еллар эчендә бу югары уку йорты төрки халыкларга 950 югары белемле асыл ир-егетләр тәрбияләп бирә. Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич, Солтан Габәши, казакъ Мәгжан Җомабаев, Үзбәк Ширмөхәммәтов, Сәлиев, адыгәйле Керашов, Хальков, кыргыз Аралбаев кебек олуг затларның исемнәре шушы мәдрәсәгә бәйле.

Аларны әдәбият белеменнән Галимҗан Ибраһимов укыта.

Әдипнең 1911 нче елда язып тәмамлаган «Казакъ кызы» романының эпиграфы итеп тә шәкерте Мәгжан Җомабаевның шигъри юллары алынган:

Киң дала, күрәсең гуй, ана жаткан,
Җебәктәй җәсел чүптә битен җапкан.
Аскар тау, балдай татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан.

Шәкертенең зирәклегенә сокланган Галимҗан Ибраһимов аңа: «Монда син алырдай белем тәмам, хәзер сиңа яңа юл сайларга кирәк» — дип, 1913 нче елны акынны Омбыга укытучылар семинариясенә җибәрә.

1913—16 нче еллар — Мәгжанның дөнья һәм урыс әдәбияты белән җенләнеп, иң югары шигъри биеклеккә күтәрелгән еллары. Аның алдында яңа бер галәм ачылгандай була. Гете, Толстой, Гейне, Горький, Верлен, Мережковский, Бальмонт, Брюсов, Блок, Сологуб — менә аның ул елларда укыган һәм тәрҗемә иткән, теленнән төшермәгән авторлары.

Мәгжанның 1912 нче елда Казанда басылып чыккан «Чулпан» шигырьләр мәҗмугасы да Галимҗан Ибраһимов ярдәме белән мәйданга килә.

Октябрь фетнәсен йөзләгән, меңләгән чордашлары кебек ул да канатланып каршылый. Ут-ялкын эченә атыла. Алдануын ул 1929 нчы елда Мәскәүдәге Бутырка төрмәсенә килеп керү белән аңлый. Ун елга Карелиягә сөрелә. 1935 нче елда М. Горькийга хат язып, азат ителә. Ике ел Кызылъяр мәктәбендә урыс теле һәм әдәбияты укыта.

1937 елның декабрендә яңадан кулга алына һәм 1938 елда атып үтерелә.

Аның язмышы, остазы Галимҗан язмышы кебек, әнә шулай фаҗигале тәмам була.

Җомабаевлар бер атадан, бер анадан җиде ир туган, җиде кыз туган булалар.

Үзен генә түгел, «халык дошманы» туганнары буларак аларны да Сталин палачлары аямаган...

Узган ел шагыйрь-акынның йөз еллыгы иде. Без бу санда аның иҗатыннан берничә үрнәк тәкъдим итәбез.

## Ут

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын,—
Көнгә генә багынам.
Үзем — көнмен, үзем — ут,
Сүзем, кысык күзем ут,—
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз тәңре — ут.
Уттан башка тәңре юк.

Ялкын йомшак сөядер,
Сөйгән җирең — көядер,—
Ялмап-сыйпап юмалар.
Очраганны ут кылыр,
Ут кабынып юк кылыр.
Аның аты — Ут булыр.
Мин дә утмын — кабынам.
Ут — син, Тәңрем,— табынам.

Адәм — күкнең ялкыны,
Кысыр сулыш аркылы
Ялкын йоткандай тоям.
Гаиләм, өем, котыма,
Тиңсез тәңрем-утыма
Вакыт-вакыт май коям.
Май коямын — ут лачын
Күккә җәя колачын...

Көйде елан чорналып,
Көйде аждаһа ялманып —
Яндың, чыгар кем синнән?
Чынында мин үзем — ут.
Кысык кара күзем — ут.
Мин уттанмын, ут миннән.
Яндырамын, янамын,
Уттан туган баламын.

Караңгылык батканда,
Кояшы калыкканда
Көн утыннан туганмын.
Йөрәгемне, җанымны,
Иманым, вөҗданымны
Ялкын белән юганмын.
Йөрәгем, җаным да — ут,
Иман, вөҗданым да — ут!

Ут яндырып туганга,
Бугазымнан буганга
Караңгылык — дошманым.

Шул явызны юк итсәм,
Сукыр күзен ут итсәм
Үтим Тәңре кушканың:
Алып чыккан Алтайдан
Балкангача — Кытайдан —
Барган юлым нүл булыр...

Көннән туган баламын,
Яндырамын, янамын.
Үзем — Кояш, Үзем — Ут.
Сүзем, кысык күзем — Ут.
Үз-үземә табынам.
Җирдә ялгыз Тәңре — ут.
Уттан башка Тәңре юк!

## Баланың кабер ташына

Кайгырмагыз бу сабыйны үлде, диеп,
Тач кызыл гөл мизгел җитми сулды, диеп.
Бәхете юк зарлы ата-ананың
Янар-янмас шәм-чырагы сүнде, диеп.

Ис китәрлек: җирне ташлап киткәненә —
Чын бәхеткә иртә барып җиткәненә,—
Изге өең — җайлы җәннәт түреннән
Урын алып, ата-анасын көткәненә.

## Пәйгамбәр

*Устремляя наши очи*
*На бледнеющий Восток,*
*Дети скорби, дети ночи,*
*Ждем, не придет ли наш Пророк.*
МЕРЕЖКОВСКИЙ

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Кояшы батып, яңа таңы атмаган.
Көнне төнгә әйләндергән пәриләр
Үз тәңресен табан илә таптаган.

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Ник бер йолдыз калсын күктә батмаган;
Төн баласы, үз изгесен үтереп,
Табанында изә-изә таптаган.

Көнбатышны караңгылык каплаган,
Бер җан да юк караңгыга эләкмәгән;
Белүче юк иман нәрсә икәнен,
«Корсак» дигән сүзне алар ятлаган.

Төн баласы... Төн юлына төшкән ул,
Син сакау, дип, Муса телен кискән ул,
Тәңресенең сөекле улы Гайсәнең
Тетрәнмичә уртлап канын эчкән ул.

Төн баласы төн киемен ябынган,
Аллага, юк, газазилгә табынган.
Инҗил ягып, алтынга башын иеп,
Гаделлек котә корсактан-карыннан.

Төн баласы гомерең тәмам таң белән,
Кабил углы авызланган кан белән.
Табынырга эре җанвар күрдисә,
Саубуллашырга да әзер җан белән.

Юк, түгелми ярыннан ашса да су,
Юк, үтерми сөюдән ташкан агу,
Төн баласы, күтәреп түр өлгене,
Күзеңне сал — конбатыш ул кан агу.

Күзгә төртсәң күренмәслек кара төн,
Инрәүче кем, көлүче кем — әллә кем?
Алай итәр, болай итәр дә китәр,
Ул кем булыр? Төн баласы кара җен!

Кап-кара төн. Төн баласы инридер.
Инрәүченең берсе уннан бередер.
Сыгынды, сүрелде, тагын аһ итте,
Кара төндә тагын нәрсә күрердер.

Кап-кара төн. Шагыйрь күзе моңлана.
Кап-кара төн. Кайгы, кан уйнап ала.
Кайгы белән кара канга тончыгып
Төн баласы авыр уйлар уйлана.

Заманында утлы көннән Һун* туган,
Утлы Һуннан утта уйнап мин туган.
Йөземне һәм кысык кара күземне
Туганда ук ялкын белән мин юган.

Бик кайгырма, сукыр чор, дип, килде зар.
Мин Көн улы, күземдә Көн нуры бар.
Мин киләмен, мин киләмен, мин киләм —
Көннән туган, Һуннан туган пәйгамбәр.

Сукыр чорны, күрмим димә, күзем, күр?!
Көнчыгыштан таң беленә инде, күр.
Таң да туа, мин дә туам — пәйгамбәр,
Кот син мине, «ләхәүләңне» укы бер?!

Көнчыгыштан таң беленә — мин киләм.
Күк күкрәде. Мин күкрәдем күк белән.
Җирнең йөзен караңгылык каплаган,
Җир йөзенә нур бирәмен. Көн бирәм.

Кап-кара төн. Хәсрәт тулы җир җыры,
Кап-кара төн. Инрәп егълый төн улы.
Көнчыгышта ак алтын бер сызык бар:
Мин киләмен, мин — пәйгамбәр,— Көн улы.

*Татарчага* **Мөдәррис ӘГЪЛӘМ** *күчерде.*

---

* Һ у н — төркинең борынгы атасы *(М. Җомабаев искәрмәсе).*

Хәбиб Хәкимов

# ЧЕХЛАР ЗАМАНЫНДА

*Бу язма 1919 елда Чистай типографиясендә гарәп имлясында аерым китап итеп чыгарылган. Безгә калса, әлеге язманың актуальлеге югалмаган. Чөнки Октябрь инкыйлабына, большевиклар хакимиятенә караш һәм бәһаләүләр нык үзгәрде. Илдә гражданнар сугышы кабызу, аклар-кызылларга бүленеп, канга-кан бәрелешү — шушы гарасат чоңгылына килеп эләккән һәркем өчен фаҗига иде.*

*СССР дигән империя таркалгач та әнә бу гигант биләмәнең байтак төбәкләрендә «кайнар нокта»лар барлыкка килде, гражданнар сугышы кабынды. Болары инде — бүгенге көннәр фаҗигасе. Фаҗигалардан исә гыйбрәт ала белү дә кирәк...*

*Авторның тел-стиль үзенчәлекләрен сакларга тырыштык. Язманы журналыбыз өчен, бүгенге алфавитка күчереп, Әдәл Яһүдин әзерләде.*

Мәкаләм чехлар турында, шул вакыйгаларга мөнәсәбәтле булганга, азрак читкә китеп, авылыбызда чехларга кадәр үткән эшләрне языйм әле. Керенский хөкүмәте җимерелгәч, бераз вакыт шуристларның (советларның) хөкем сөрүе һәркемгә мәгълүм. Нәкъ шул вакытта Яуширмәдә анархия хөкем сөрә башлады. Авылыбызның куштаны, тирә-якта дан тоткан Шәйхетдин Җамалетдинов дигән кеше (Николай вакытында провокатор иде), талаучы шайка оештырып, коралланып, өй саен кереп, талап йөри башлады. Төнлә белән ирсез хатын-кызларны мәсхәрә итүдән дә тартынмадылар. Шайкага каршы нәразыйлык көннән-көн куәтләнеп, һәркемнең авызыннан: «Бу каракларны ничек бетерергә, ничек болардан котылырга?» — дигән тавыш бик еш ишетелә башлады. Болар шулай талауларында дәвам итеп килгән вакытта, Октябрь инкыйлабы *(революциясе)* башланып, большевиклар хөкүмәт сөрә башлагач, караклар: «Большевиклар боярларны таларга рөхсәт итәләр»,— дип, эшләгән кабахәтлекләрен большевиклар өстенә ташлап, тирә-яктагы боярларның нәрсәләрен өйләренә ташып бетерделәр. Болар котырып йөри торгач, ниһаять, актык сәгатьләре сукты.

Сәбәбе болай.

Чистайда бер итек кибете таланып, урлаучылар Яуширмә караклары икәне беленеп, авылга байтак милиция килеп халыкка: «Без шундый эш белән килдек»,— дигәч, караклардан тәмам туйган халык, бик тиз арада җыелып житеп, мәгълүм карак Гафиятулла Сөнәгатуллин йортын камап, каракны тотып, итекләрнең кемдә икәнен әйттереп, аны шундук җәһәннәмгә олактырдылар. Җыелган халык: «Боларның башлыгы Шәйхине бетерергә кирәк!» — дип Шәйхи йортына барды. Шәйхи Чистайда булып, малайлары да качканга, йортыннан урланган нәрсәләрне алып чыктылар. Соңра халык шул ук төнне кем боярга барган, һәркайсыннан бояр нәрсәләрен алып, бергә җыйнап, каравыл куйдылар. Ул төн байтак каракларны кулга алганнар иде. Иртәгесен алардан җавап алып, барсын да җәһәннәмгә озаттылар.

Бояр нәрсәләрен тәмам җыеп бетергәч, авылыбызның аңлы сыйныфлары арасында, бу нәрсәләрне урнаштыру өчен бер оешма төзелеп, «Шура» дип исем бирелде. Авылыбызның алдынгы сыйныфларыннан Гаяз әфәнде Садыйков фронттан ялга кайткан иде. Аңлы кешеләрнең теләве буенча, шураны алып барыр өчен рәис итеп Гаяз әфәнде Садыйков сайланды. Аңлы кешеләр, авыл картлары үтенгәч, Гаяз әфәнде дә каршылык күрсәтмичә, кабул итеп, шул ук көн эшкә керешә. Бояр нәрсәләрен бәгъзеләрен юнь бәһа белән фәкыйрьләргә, бәгъзеләрен торг белән сатылып, 9 меңнән артыграк акча җыйналып, җәмгыять кулына алынды. Шулай бик яхшы эшләп килә торгач, шуралар бетерелеп, эш башына ныклап утырган совет хөкүмәтен дә күрдек... Соңра Гаяз әфәнде волостька рәис итеп сайланды. Ул, шулай булса да, волостьтагы эшен дә, авылда үзенә тиеш булган эшне дә камил гайрәт белән үтәп килде. Укучы әфәнделәр! Сез тагын уйламагыз: «Элекке караклар башлыгы Шәйхи Чистайдан авылга кайтып әүвәлгечә талап йөргәндер», дип. Юк, аны югарыда язылган шура төзелгәнче үк, Гаяз әфәнде, Чистайга барып, төрмәгә яптырды. Янә төрмәдән чыкты, янә япгылар. Яуширмә авыл советы гаять тәртипле рәвештә эшләп килә торгач, менә бервакыт вәхшияна сурәтендә чех бандалары мәйданга килеп чыктылар. Авыл кулаклары һәм аларга иярген надан халык чехларны күктән төшкән фәрештә кебек каршы алды. Бераз гына гаиб булып *(югалып)* торган большевикларны сүгеп, чехларны гарепкә күтәрделәр. «Большевиклар байларны талыйлар иде, безгә дә көн килде. Болар үз кешеләребез, болар таламаслар, боларга солдат та бирәбез, җир үзебезгә кайта»,— дип дөнья сасыттылар. Хәтта: «Киләсе елга мөгаллиммөгаллимәләрен дә куабыз, аларны куган өчен чехлар бер сүз дә әйтмәсләр. Карга карганың күзен чукымый бит! Менә искечә рәхәтләнеп торабыз»,— дигән сүзләр дә күп кешедән ишетелә иде. Ярый, чехларга солдат та бирделәр, эшләр теләгәнчә бара...

16 нчы август көн гаять матур, өйлә алдыннан халык югары очка агыла. Нәрсә бар икән, дип мин дә киттем. Юлда очраганнардан: «Югары очта җыелыш бармы әллә?» — дип сорыйм.

— Юк, Гаязларны алырга килгәннәр,— диләр.

— Кемнәр?

— Солдатлар. Гаязны, Вафаны (Гаяз әфәнденең агасы) Гайсәне, Маһруй Мусасын, Габдрахман Әхмәди малаен. Тагын Садыйкны (Гаяз әфәнденең энесе) алып китәчәкләр икән,— диделәр. Алай икән, дип кызурак киттем. Менә Хәлилрахман Муллин пулаты (хәзер народный дом) янында коралпы солдатлар күренде. Капкадан йортка кердем. Ат караучы бер солдат янына бер агай туктаган. Бүреген башыннан алып култыгына кыстырган, яланбаш, солдат каршында бил бөккән, башы чак кына җиргә тимәгән. Берничә мәртәбә баш игәч, солдат:

— Сиңа нәрсә кирәк? — дип сорады.

— Мона, господин, минем бертуган энем тарантасымны көчләп алып чыкты.

— Югал моннан, без аның өчен килмәдек, менә кемнәр большевик, шуларны әйт? — дигәч, агай борылып чыгып китте. Мин бу кеше урыска бу кадәр бил бөккәнче Аллага шулай сәҗдә итсә, Алла моңарга бәлки яңа тарантас та бирер иде, дип, ачынып, югары мендем. Пулатта Гайсә Кәбиров, Муса Сафин, Гаяз әфәнде вә Муса Садыйковларны бер җиргә бастырганнар. Өстәл янында бер-ике алтын погонлы утыра, Габдрахман Әхмәдиевне көтәләр. Бераздан, ишек ачылып, Габдрахман Әхмәдиев килеп керде:

— Товарищи! Зачем меня звали?

Бер калын корсаклы солдат (помещик Бутлеров):

— Товарищей утопили и остальных будем топить,— диде. Габдрахман Әхмәдиев агарып китте. Мин, аларга әүвәлдән дошман булганга, бу сүзләренә янә бер кат дошманлыгым артып, чыдый алмыйча, чыгып киттем, потребительгә кердем. Иптәшем мөгаллим Һади әфәнде Вәлиуллин да яныма килде. Сөйләшеп тора торгач, әлеге «Калын корсак» кибеткә керде дә: «Болар арасында кемнәр большевик?» — дип сорый. Һади әфәнде: «Һичкем, алар арасында Габдрахман Әхмәдиев чахутошный, җыенда йөткереп, халыкны йөдәткәнгә, большевик дип әйткәннәрдер»,— дип көлгәч, «Калын корсак» чыгып китте. Бераздан арестованныйларны төшереп олауга утырттылар. Гаяз әфәнденең велосипедына алтын погонлы берәү атланып, кузгалып та киттеләр. Шул вакытта чехларга каршы бер сүз әйтергә халыкның икътидары булмады. Боларның китүен кайсылары яхшы күрә, кайсылары кызганып: «Әрәм булдылар мискиннәр»,— диючеләре дә бар иде. Шулай аптырап торганда, Муса Садыйков күренде. Халык аны чорнап алды. Сөйләвенә караганда, авылны чыкканчы ук аны төшереп калдырганнар. Боларны

кемнәр күрсәткән, шуларны да әйткәннәр (күрсәтүчеләр — авылыбыздан). Җыелган халыкка Һади әфәнде белән Салихҗан хәзрәт, болай тору ярамый, советны сайлап, алар артыннан кешеләр җибәрергә кирәклеген аңлаткач, халык җыелып советны янадан сайлап, иске исеме «Шура»ны кайтардылар. Шундук Һади әфәнде белән Салихҗан хәзрәт Хәмидине сайлап, арестованныйлар артыннан җибәрделәр. Делегатлар Чистай комендантына кергәч, аларга илтифат итмәсәләр дә: «Сез нинди кешеләр? Нишләп йөрисез?» — дигәннәр. Делегатлар эшне сөйләп биргәч, комендант: «Сез безне әллә большевиклар дип белдегезме? Без делегатфәләннәрне признавать итмибез, моннан соң андый эш белән йөрмәгез!..» — дип ансат кына җавап биргәннәр. Делегатлар кайтып шулай сөйләгәч, авылдан приговор җыеп, шул приговор белән Габдерәшит Әхмәдиевне җибәрделәр. Габдерәшит Сәмигулла Салиховны күреп сөйләгәч: «Иншалла, бернәрсә дә булмас, мин аларны чыгарырга тырышырмын»,— дигәч тә, берәр көннән Салихов Уфага киткәнлектән, Габдерәшитов эше тагын тузылган. Өч көн эзли торгач, эшнең очын табып, аңарга: «Яуширмәнең фәлән-фәләневләрне оправдать итәргә, аларны чыгарырга, Шәйхи Җамалетдиновны ябарга (Шәйхи, чехлар килгәч, чыккан иде). Фәкать народный суд кына карап узасы бар»,— дигәннәр. «Следственный комиссиядә зарарлы нәрсә тапмаганнар. Иртәгә иртүк чыгарырлар»,— дигәннәр. Сонра Әхмәдиев, төрмәгә барып, тоткыннардан сөенче алган. Иртә булып, кич тә житкән, болардан хәбәр юк. Ниһаять, бер атна вакыт көтеп Әхмәдиев авылга кайтты: «Иртәгә кичкә, иншалла, авылда булырлар»,— диде. Иртәгесен кайтачак кешеләрне бөтен авыл халкы, хосусан аларның егерме икедән артык ятим балалары шатлык белән көтәләр. Кич тә җитте, үтте, икенче көн үтте, болардан хәбәр юк. Менә ике көннән, Гаяз әфәнделәрне (82 кеше) Самарага судка алып киткәннәр, дигән хәбәр ишетелде. Бер көннән соң аларны Самарага җиткәндә суга ташлаганнар, дигән хәбәр килгәч, бичара, хөррият корбаннарының ятим калган балалары, кан елап, аталарының кайтуыннан өмид кисеп, бәдбәхет Николай ялчыларына ләгънәт укып калдылар. Авыл халкы да аптырауда, чөнки Шәйхи чехлар белән авылга кайта (авылда Шәйхинең йортын җимергәннәр иде), 75 мең сум түләү сала икән, дигән хәбәрләр дә таралды. Халык: «Менә чехлар нишли? Ай, большевиклар тизрәк кайтсалар иде!» — дип, большевикларны сагына башлады. Берәр атна вакыт үтте, хөррият корбаннарыннан хәбәр юк...

5 сентябрь, көн матур. Иртә чәйдән соң урамга чыктым. Тагы халык югары агыла... Мин янә кемнәрне алырга килделәр (безнең авылдан янә 40 кешене бүген, йә иртәгә килеп алалар, дип көтәләр иде) икән, дип аптырап торганда, Муса Садыйков ат белән төшеп бара. Мин: «Нәрсә бар?» — дип сорадым. «Гаяз абзый кайтты бит»,— диде. Өйләдән соң күрешә мендем. Гаяз абзыйның өе халык белән тулы иде. Суга ташланганлыгы белән Гаяз әфәндедең ике күзен кан баскан. Аның сөйләве болай:

— **Чистайга якынлашып урман янына җиткәндә солдатлар туктадылар. Әлеге калын корсаклы солдат: «Үрдәк. Бере ата үрдәк!» — ди. (Анысы, әлбәттә, мин). Миңа шулай карарлык та. Чөнки өстә күн тужурка, башта каракүл папаха, аякта итек. Калын комиссар: «Пока закускага җитәр»,— дип, безне шундук атмакчы булдылар. Фәкать башка солдатлар: «Боларны Чистайга җиткерәбез»,— дип, ирек бирмәделәр. Без әлегә исән калдык. Чистайга барып кердек. Народный армия бәйрәме коне иде. Безне гарнизон начальнигына китерделәр. Ул анда булмагач, комендантка озаттылар. Комендантка кергәч, әлеге калын солдат алга чыгып, честь биреп: «Менә сезгә дүрт үрдәк, «боларны закускага китердек»,— дип мактанып алды. Комендант та шатлыгыннан көлеп җибәрде: «Хәзер үк мин ата үрдәкне атар идем, лакин пуля әрәм була, бер пуля 7 тиен тора»,— диде. Сонра безне тентеп, минем 750 сум акчамны алып, төрмәгә озаттылар. Велосипедым да анда калды. Төрмәдә тугыз көн яттык. Анда безнең тормышның ничек үткәнен, кеше үтерүчеләр иркендә булып, безне һава суларга да чыгармауларын һәркем аңласа кирәк.**

**Алты көннән соң бераз төрмә йортына чыгарып Кызылъяр волосте Яуширмә авылыннан килгән мәгълүм «үрдәкләр»гә самосуд булуы аңлашылды. Ниһаять, шул көнне 28 августта кич сәгать дүрттә безне, 82 кешене, пристаньга алып төшеп киттеләр. Бер пароходның трюмына төяделәр. Пароходка баржа тагып Лаешка алып киттеләр. Мурзиха белән Лаеш арасында егерме сигез комиссарны, икешәр-икешәрләп тентүгә дип чакырып алып, юк иттеләр. Аларны юк итүләрен мин бик яхшы белгәнгә, иптәшләргә: «Иптәшләр! Бу чех бандалары безне икешәр-икешәр чүпләп бетерерләр. Болардан котылу чарасына керешик (баскыч янында, түбән якта ике юнкер каравылчы иде). Бу юнкерларның берсеннән мылтыкны мин алам,**

икенчесеннән бүтән берәү алыгыз. Өскә чыгып без тегеләргә ут ачарбыз, сез дә безнең арттан чыгарсыз, ничек тә аларны кырып бетерербез (алар 12 кеше иде)»,— дип әйтсәм дә, курыккан кешеләр беләи берни дә эшләп булмады. Ахрысы, безгә тегеләр артыннан барырга туры килә, дип чын күңелдән иман укырга тотындым. Чех бандитлары: «Менә бусы — Вильһельмның чын хезмәтчесе»,— дип, мине ешеш кына килеп кыйнаганлыктан, туганым Вафа абзый: «Энем, күңелгә авыр алма, синең актык сәгатьләрең сугарга якын калды. Бәлки безне (4 кешене) калдырырлар да. Васыятеңне әйт: кемдә алачагың, кемгә бирәчәгең бар. Йортың кемгә кала? Һәркайсын әйт, мин үтәрмен»,— диде. Мин васыятьләремне әйтә бардым. Вафа абзый кенәгәсенә язып алды. Сонра бер бандит килеп: «Обыска бетте, арестантларга ятарга мөмкин»,— дигәч, йокы алмаса да, йокларга яттык. Иртә тордык, 26 август иде ул көн. Пароход Лаешка туктаган. Лаешта зобанниларга охшаган алты чехка безне ташырырга, Шәйхи сүзе беләи, дусты Бутлеров дигән алпавыт кылган иде. Чехлар безне пароходтан (56 кешене) алып, бер зур баржа трюмына керттеләр. Без урнашкач, икешәр-икешәр бастырып безне тентеп, акча һәм кыйммәтле кием-нәребезне алдылар, сонра допрос башланды.

Бер бандит:

— Сезнең арада кем яһүд? — дип сорады.

Бер яһүд укытучысы чыгып:

— Мин,— диде.

— Ә син каян килдең?

— Мәскәүдә ашарга булмагач, балалар белән Вятски Полянкага җибәрелдем,— диде.

Шулай диюенә:

— Ах, немецкий шпион! — дип яңагына салып җибәрде теге. Аның артыннан икенчесе, өченчесе хасил бер сәгатькә якын кыйнадылар. Бичара, тәмам хәлдән тайгач, бер урынга барып егылды. Сонра бер донской казак төшеп, әлеге укытучының чалбарын салдырып, камчы белән 25 мәртәбә суктырды. Суккан вакытта, бичарадан, кан шаулап югары сибелә иде. Сонра яһүдне баржаның урта борысына (баржага салган калын бүрәнә) яткырып безне (55 кеше) тезеп, бер бандит безгә карап: «Менә бу яһүд сезне юлдан аздыручы һәм Русияне сатучы, шуның өчен сез менә бу таяк белән берәрне сугарга тиешле. Кем дә кем җәлләп сукса, үзенә шул көн булачак!»— дип, әүвәл ул үзе бер мәртәбә сукты. Моның соңында берәм-берәм безне китереп суктыра башлады. Миңа рәт җиткәч, интәшемә сугар вөҗданым кабул итмәгәнгә, әкрен суккан идем, бандит: «Әһә, син комиссар, комиссарны кызганасыңмы әле?» — дип, таяк белән җилкәгә шулкадәр каты сукты, үземнән гаип булып күпмедер вакыт тордым. Ярый, 55 кеше берәр сугып чыккач, бичараның кузгалырга хәле юк. Шуның өстенә: «Тиз, тиз тор!» — дип торгызып йөртә башладылар үзен. Бераз йөрткәч, бер алтын погонлы кеше сорады: «Еврей, тәмәке тартасыңмы?»

— Юк, тартмыйм.

— Тарт! Мин хәзер тәмәке бирәм.

— Ярый, алай булгач, бирегез, тартам.

Япон штыгын китереп, очын яһүднең авызына каптырды да:

— Шулай авызың белән тот, мин ут кабызам,— диде.

Билгеле, яһүд теше белән штыкны очыннан тешләп тора алмады. Ике солдат килеп берсе башыннан, берсе тамагыннан бик каты кысып тоттылар да әлеге погонлы штыкның бер башыннан әкрен-әкрен генә түбән таба баса башлады. Бичараның кычкыруына илтифат итүче юк. Һаман җан алуларын дәвам иттеләр. Бераздан яһүднең аскы ике теше сынып, өске иясе каерылып чыкты. Сонра әлеге бандит штыкны алып:

— Немецка хезмәт иткәндә яхшы булгандыр, менә без аны кайтарырбыз әле, еврейски морда!» — дип, борынына суга башлады. Борыныннан кисәк-кисәк ит чәчрәп китте.

Яһүд чыдый алмады, җан көче белән ачынып:

— Ах сез, серб бандалары, бродягалар! Ник мине болай газаплыйсыз, ник тизрәк үтермисез?! — дип кычкырып җибәрде. Борыны тәмам ашалып беткәч: «Мине тышка чыгарыгыз! — дип сорады, ике солдат аны баржа өстенә чыгардылар. Бер кырыйга барып тышка чыккан булып, үзен-үзе ул суга ыргытты. Чехлар пароходны туктатып 10 винтовка белән бичарага 12 мәртәбә залп бирделәр. Мескенең гәүдәсе су өстенә тәмам тетелеп калыкты. Бу безнең арабызда чехлар тарафыннан иң кызганыч рәвештә үтерелгән кеше иде. Сонра әлеге бандитлар баржа астына төшеп:

— Ах вы, немецкие шпионы, әле барыгыз да качарга уйлыйсыз икән, барыгызны эт урынына атарбыз! — дип, төрле начар сүзләр әйтә-әйтә байтак вакыт

кыйнадылар. Сонра безне бер почмакка җыеп утырттылар да үзләре күмәч белән ит ашый башладылар. Безгә, эткә ыргыткан шикелле, күмәч-ит кисәкләре ыргытып,— без, өч төн ашамаган, үлә башлаган ачлар,— алып ашый башлагач, бандитлар:

— Әле синең ашыйсың килә икән! Кем кушты сиңа алып ашарга?! — дип, берәм-берәм чакырып, кыйнап, ничә көн ашамаган кешеләрне яртышар сәгать бер утыртып, бер торгызып интектерделәр.

29 август, кичке сәгать алты иде, калганнарыбызны язарга тотындылар. Арабызда 24 кеше народный армиягә язылган булган. Башта ук аларны аерып алдылар. Аларны, чехлар ягында актык тамчы каннары калганчы сугышырга, һәрвакыт чехларны сакларга сүз алып, бер кырыйга утырттылар. Боларның гафу ителүләре аңлашылды. Безнең арадан язылырга теләүчеләрне дә язып народный армеецларга куштылар. Без ун кеше калдык. Безнең арадан картраклардан язылырга теләүчеләр булса да, никтер язмадылар: «Син немецләргә яхшы хезмәт иткәнсең, безгә дә яхшы хезмәт итәргә сүз бирсәң, сине дә язарбыз»,— дигәч, мин: «Кайчан минем елгыларны мобилизовать итәрсез, шулвакыт мин сезгә хезмәт итәрмен»,— дигәч, бандитның күзләре акаеп, котырынып, кул бомбасы алды да култык астыма куеп:

— Менә ачкычны борырмын да, синең елгылар мобилизовать ителер»,— диде. Ничектер, ачкычны бормады. Безне, ун кешене бергә җыеп, «Яушырмәдән бишәү — Гаяз Садыйков, Муса Сафин, Гайсә Кәбиров, Габдрахман Әхмәдиев, Вафа Садыйков немецләргә хезмәт итүләре өстенә, Яушырмәнең Шәйхетдин Җамалетдиновның йортын туздырып, аның нәрсәләрен талаганлыклары өчен гаепләнәләр (моннан без Шәйхи доносы белән бу көнгә төшүебезне аңладык). Лаештан фәләнфәләнеевләр, өч урыс телефон чыбыгын кисүдә, ике урыс, матрос (флотский) булулары өчен гаепләнәләр, дип бер бандит бугазын киереп кычкырды. Шундук народный армеецларга икмәк бирүләреннән безгә ни булачагы аңланды. Үзара бәхилләшеп, иман укып, әҗәл көтеп калдык. Сәгать унберне сукты. Җан алучылардан 4 кеше төшеп безне икешәр-икешәр тезделәр. Өскә меңгә киемнәрне салдырырга тотындылар. Мин үлем исереклеге белән төймәләремне җилкәдән әзләп торганда бер бандит: «Немецкий шпион, төймә җилкәдә булмый, менә монда була!» — дип, яңакка бер менеп алып, төймәләремне күрсәтте. Ярый. Мин киемнәрне салып бетерүгә, кайсы күн тужурка, кайсы итек, кайсы каракүл бүрегемә ябышып, бүлеп алдылар. Без тәмам күлмәк-ыштаннан калып, кычкырып иман укый башладык. Арадан берсе кызганды булырга кирәк, боларны калдырсак, ничек булыр икән, дисә дә, сүзе эшкә ашмады. Бераздан әлегесе минем янга килеп: «Күпме акчаң бар, бир, коткарабыз!» — дигәч, минем тужурка белән подкладка арасында 209 сум контора акчасы бар иде, шуны тиз үк алып бирүемә, старшийлары күзен акайтып: «Ах, сволочь! Көндез обыск вакытында ник бирмәдең?» — дип, мылтык прикладлы белән күкрәгемә китереп бирүгә, егылып киттем, авыздан кан килә башлады. Мине торгызып Муса Сафин янына бастырдылар, старшийлары кулында тимер чыбык әвәли башлады. Мин, болар бомба белән өздерергә яки электр белән үтерергә тели, күрәсең, дип күземне кулым белән капларга мәҗбүр булдым. Менә кулны артка каерып телефон чыбыгы белән бәйләргә тотындылар. Шулвакыт, Муса Сафин миңа карап: «Энем, Гаяз, дөнья бездән кала, ахрысы, төрле вакыт булгандыр, бәхил булышыйк, Алланы онытма!» — диде.

Безне баржаның кырыена бастырып, әлеге старшийлары килеп, кулы белән җилкәбездән этеп, Иделгә бәреп төшерде. Кечкенә генә пароход, баржасын өстерәп, полный ход бара. (Безнең батасы урын, Тәтештән 18 чакрым узып, Тәтеш белән Самара арасы икәнлеге иртән беленде.) Бәреп төшерүгә төпкә үк китү уйланса да, гомер бетмәгәнгә каршы, тиз үк өскә чыгылды. Авызга су керә. Тизрәк үлү нияте белән күп-күп су йота башласам да, үлү унайсыз булганга, ни булса да булыр дип, бик каты кулны тарта башладым. Бераздан тимер чыбык бушап кулны тартып алдым. Муса Сафин 10 сажин чамасы читтә быкырдый иде. Тизрәк янына йөзеп бардым да: «Муса абзый, мин әлегә котылдым, сине дә котылдырып булмасмы?» — дип азапланырга тотындым. Бичара: «Миннән бетте инде, туган»,— дип иман укый иде. Ун минут кадәр азаплансам да тимер чыбык очын таба алмадым, авызга су тула башлады. «Муса абзый, мин киттем, син дә минем арттан калма!» — дидем. «Бәхил бул, туган, миннән булмый инде»,— диде. Төн караңгы. Иделнең кырые күренми. Пароходның тоткан юлыннан чамалап, кирәк якка йөзеп киттем. Бераз баргач һава яктысы белән Идел кырыенда агачлар күренде. Кырыйгарак чыгып үлим, бәлки берәрсе табып, күмеп куяр, дип йөзә башладым. Байтак вакыт үтте, башым каты нәрсәгә бәрелгәч, кулым белән тотып карасам, Идел яры икәнлек аңлашылды. Үрмәләп алга киттем. Урман арасы иде.

Бара торгач, печән кибәненә барып чыктым. Хәлем булмаса да, печән кибәненә баш сыярлык тишек ясап, шунда атылдым. Башым эчтә булса да, тән тышта калганга, бик өши башладым. Бераз вакыт үтте, әтәч тавышлары ишетелә башлады. Башымны кибәннән алдым. Күктә йолдызларны күреп Ходага шөкер иттем. Монда калып туңып үлүдән бигрәк, чехлар кулына төшү куркынычлы икәнен уйлап, ничек тә төнен бер авылга җитәргә кирәк, дип алга атладым. Ләкин, никадәр генә азапланып да, юлны таба алмагач, икенче кибәнгә барырга мәҗбүр булдым. Гәүдәм күмелерлек итеп казып печәнгә кереп яттым. Бераз вакыт үтеп, таң якынлашты. Мин торып киттем. Юл белән бара торгач, печән чабучы урыслар күренде. Мин болардан юлның кая барганын сорар өчен янnарына китсәм дә яланаяк, яланбаш, күлмәк-ыштан су булганга, әллә нәрсәдән курыккандай, чабып киттеләр.

30 августының таңы атты, көн яктырды. Бара торгач, бер урыс очрады. Юл сорадым. Гәрчә курыкса да, моннан берәр чакрым су тегермәне барлыгын аңлатып, тиз генә китеп барды. Озак та үтмәде, тегермәнгә җиттем. Ачлык белән туңуның чигенә ирешкәнгә рөхсәт сорый тормадым, ишек ачып тегермән өенә кердем. Урыс белән марҗа йокыдан торганнар, мине күрүгә агарып киттеләр.

— Зинһар, миннән курыкмагыз, мин бәхетсезлеккә очраган саф гражданин,— дигәч, кабул күреп, мич башына мендерделәр. Бер стакан сөт белән икмәк бирсәләр дә, тешләр карышканга, икмәген ашый алмадым, өскә тун яптылар, йокыга киттем.

— Товарищ, торыгыз! — дип урыс уятты. Өйне җылытканнар. Сәмавыр кайнап өстәлгә менгән. Үземне өйдәге шикелле хис кылдым да чәйгә утырдым. Чәй янында минем нинди кеше икәнлегемне аңларга теләвен белдергәч, мин болай җавап бирдем:

— Мин Лаешта торам, бәгъзе бер сәбәпләрдән гаиләм белән чехларга ияреп китәргә туры килде. Пароходта кеше күп булганга, артыкларын баржага төяделәр. Без Тәтештән үткәч, баржага ут кабынып яна башлады, һәркем үзен коткарыр өчен киемнәрен салып суга төштеләр. Менә мин дә шундый кеше хәзер. Җәмагатьләрем кайдадыр, белмим,— дигәч, урыс миңа карап:

— Товарищ, сез дөресен сөйләгез! Миннән курыкмагыз. Сез берәр үлемнән котылган кеше булырга кирәксез. Чөнки кулыгызның җәрәхәте шуны күрсәтә. Мин тегермәнгә чыккач, сезнең кебек судан котылып чыккан берәү миннән юл сорады. Мин, юлны әйтеп биргәч, нинди кеше икәнлеген сораштым. Ул:

— Без чехлар тарафыннан суга салындык. Әүвәл бер яшь татар белән карт татарны суга салдылар, алардан соң безне — бәйләүче чех исерек булганга, рәтләп бәйли алмады, мин котылдым, иптәшем үлде,— диде.

Мин дә дөресен сөйләп бирдем. Чәйдән туйдым, сәгать тугыз тулган иде. Урыс миңа карап:

— Товарищ! Мин үзем бер авылдан яңа гына монда килеп урнаштым. Сезгә бирергә артык киемем юк. Моннан ике чакрымда Зеленовка дигән авыл бар. Үзем сине шул авылга кадәр озатырмын, дигәч, өйдән чыгып киттек. Урман араларыннан бераз баргач, авылга якынлаштык. Урыс, кире борылып, кайтып китте. Мин дә судан чыккан киемнәрем белән — күлмәк-ыштан, яланаяк, яланбаш авылга барып кердем.

Көн матур иде, һәркем өйдә. Урам буенча киттем. Яланөс булганга, минем артымнан байтак балалар, байтак яшүсмер урыслар җыелганнар иде. Каршыга йөгән тоткан бер урыс килеп җитеп:

— Нәрсә карап барасыз, ул да сезнең кебек бер кеше бит! — дип балаларны таратты да мине үзе белән алып китте. Өенә кердек.

— Ашыйсың киләме? — дип сорагач, мин хәлне сөйләп бирдем. Миңа күп ашарга ярамаганлыгын әйтеп бераз кайнаган сөт, бераз ризык бирде. Хатыны каядыр китеп югалды. Урыс минем нинди кеше икәнлегемне сораштыргач, мин дөресен сөйләп бирдем. Ул да совет хөкүмәте вакытында, бер отделда — комиссар булып, хәзер чехлардан качып ята торган кеше икәнлеген сөйләп бирде.

Бераздан хатыны кайтып:

— Мунча өлгерде, мунчага барыгыз! — дигәч, мине мунчага алып китте. Курка-курка гына чыксам да, дөрестән дә, мунчага кердек. Мине чишендерде. Үзе киемнәрдән калганга, мин куркыбрак калдым, урыс та сизеп алгач:

— Бер дә курыкма, бу мунча синең өчен генә ягылды,— дип, мине ләүкәгә мендереп яткырды. Чамалап пар сала торды. Шулай байтак вакытлар үткәч, юындырып, чиста күлмәкләр биреп, мунчадан алып чыкты. Сәгать уникеләрдә киткән идек, сәгать дүрттә кайттык. Кайнаган сөт эчереп мине йокларга яткырып, кич булгач, чәйдән соң мине үзенең Федор исемле туганына китерде:

— Менә син бу кешене яхшы сакла, мин урманда, фәлән җирдә булырмын,— дип чыгып та китте. Иртән торгач, мине өенә чәйгә алып китте. Чәйдән соң:

— Менә, товарищ! Хәзер һәркайда фронт, бик куркыныч. Советлар килгәнче миндә торырсың, нәрсә тапсак шуны ашарбыз, гаеп итмәссең,— дигәч, мин калырга разый булып, бергә урманга киттек. Көн буе урманда торып кич кайттык. Тамак туйдыргач, янә Федорга тапшырып үзе каядыр китте.

Яттык. Йоклап булмый. Миңа: «Әгәр абзый да үлгән булса, миннән соң янә 45 кешене алып китсәләр, теге мәлгунь Шәйхи кайтып, ятимнәрне бөтенләй ач калдырыр, үзем кайтсам, дус-иш аркасында, бәлки, берәр эш эшләп булмасмы? Кайтсам, ничек булыр икән?» — дигән исәп төште. Байтак уйлангannан соң кайтырга карар бирдем. Иртәгесен, мәгълүм товарищка карарымны сөйләп биргәч, никадәр җибәрмәскә тырышса да, бик сорагач, ризалашты. Өскә киярге кием, башка иске фуражка, кечкенә капчыкка икмәк, кыяр, йомырка вә шуның кебек нәрсәләр салып, юл азыгы итеп, миңа бирделәр. Кич булгач, миңа бер ат нуктасы тоттырды да үзе белән алып китте. Төнлә сигез чакрым ара озатты да:

— Товарищ, юкка китәсең, чехларга эләкмәсәң ярар иде,— дип елап, үзенең фамилиясен әйтеп калды (Иван Сверичков). Мин ат эзләүче булып киттем. Бераздан бер урыс авылына җитеп, анда йоклап, иртән сәгать 7 дә чыгып китеп, ниһаять, Йорткүл исемле мөселман авылына килеп җиттем. Корбан бәйрәменең беренче көне иде. Мөселман авылына кергәнгә шатланып китеп Яуширмәгә кайткан кебек булдым. Күп тә бармадым, капка ачык иде, берсе корбан тәкәсе тунап тора, мин моңардан чәй эчеп чыгарга сорадым. Җавап мондый булды:

— Баш кәгазең бармы? Хөкүмәт кешеләрне кәгазьсез кертергә кушмый,— дигәч, тизрәк сызу ягын карадым. Берничә җирдән сорап карасам да җылы сүз ишетә алмадым. Ышаныч баглап кергән мөселман авылыннан мондый эш күргәч, рухым гаять төшеп китте.

Ял итәргә берәр урыс авылына җитү уе белән алга киттем. Озак та үтмәде, бер авылга җиттем. Ул да татар авылы булып чыкты. Берничә кеше корбан ашы ашап чыгалар булса кирәк, барысы да кызарганнар иде. Шул кешеләрдән чәй эчәргә сорадым. Араларыннан камалы туп кигәне: «Моның язуы бар микән? Нинди кеше икән?» — дип сөйләнсә дә, арадан бер начар киемлесе:

— Бүген аны тикшерә торган көн түгел,— дип чәй эчәргә алып китте. Корбан суймаган булса да, күршеләрдән шулпа алып чыгып, авыз иттерде. Тамак туйгач, миңа юл күрсәтеп, озатып җибәрде.

Ниһаять, Чуаш Матагына килеп җиттем, бер чуаштан:

— «Базарлы Матак»та эшләр ничек? — дип соравыма:

— Анда бернәрсә дә юк,— дип җавап биргәч, туры артымнан кычкырып туктатты:

— Товарищ, кая барасың? Синең киемнәрең дә әллә нинди, син Матакка барма, анда чехлар кругум цепь куйганнар, язусыз кешеләрне аталар,— диде.

Мин, рәхмәт укып, Матакны сулга калдырып киттем. Караңгы төшәр алдыннан Ташбилге дигән мөселман авылына килеп җиттем. Кырыйдагы бер фәкыйрь йортка кердем. Фәкать бер карт кына өйдә. Үзе дә хәер-сәдака белән генә туенып тора икән. Салкын корбан шулпасы ашатты. Ут кабызырга теләсә дә мин кабызмавын үтендем. Ашап торганда күршедән бер бала керде. Мин качарга теләсәм дә карт:

— Курыкма, ул үзе дә шундый,— дигәч, качмадым. Шул баланың атасы белән агасы, бу картның углы — барысы уялап кешене бу авыл мөселманнары чех кяферләренә биреп җибәргәннәр икән. Мин балага:

— Сезнең авыл тынычсыз икән, андый-мондый эш булса, миңа хәбәр итәрсең,— дидем.

Йокларга яттык. Бераздан бала йөгереп керде дә:

— Абзый, синең нинди кеше икәнеңне белергә киләләр. Куштаннар җыелып старостага киттеләр, тизрәк кач! — дигәч, мин каушап киттем. Бала:

— Курыкма, абзый, әйдә, минем белән! — дип алып чыгып китте. Мине курку алганнан-ала бара, зират бик якын, халык шаулый. Бераздан тавыш басылды. Әлеге бала килеп җитеп:

— Абзый, монде син турыга барсаң, Чаллыга барып җитәрсең,— дип юл күрсәтте. Мин киттем. Өйлә җиткәч, ял итү уе белән борчак чүмәләсенә утырдым. Йокыга кителгән, күземне ачсам, караңгыланып киткән. Миңа шунда төнне үткәрергә туры килде. Чаллыга җитеп бер танышка кердем. Ул мине ике көн кунак иткәч, туган илем Яуширмәгә китерде. Төнлә сәгать өчтә өйдә булып, ходага мең-мең шөкер иттем».

Гаяз әфәнденең сүзе шушында тәмам. Ниһаять, Гаяз әфәнде кайтты. Авылга шатлык тулды. Аны чехлар алып киткәндә көләп калган кешеләр һәркайсы елап күрешергә килделәр. Читт авыллардан да күпләр килде. Өч көнгә кадәр күрешә килүче өзелеп тормады.

Шул көн бер бала тарафыннан Шәйхинең кайтканы оешмага хәбәр ителде. Сөйләүләренә караганда, Шәйхинең кечкенә баласыннан: «Әллә әтиең кайттымы?» дип сорагач: «Кайтты. Иртәгә солдатлар алып кайта да тагын бик күп кешеләрне, атларын әйтеп, Чистайга озаттырам, дип әйтә икән»,— дигән. Икенде алдыннан Яуширмә авылы чолгап алынды.

Йәстү алдыннан өенә тентү төшерелеп, Шәйхине сандыктан табып алдылар. Шулай итеп, аның фетнәсеннән котылдылар.

Хәзерге көндә Гаяз әфәнде Кызылъяр волостендә һәм Волость мөселман комиссариятында рәис булып эшен дәвам иттерә. Авылны да хәтереннән чыгармый, һәрвакыт авыл кешеләрен, шулар җөмләсеннән, үзен суга салдырырга сәбәп булучыларга да дус мөгамәлә итеп, һәрвакыт юл күрсәтә. Авылыбызда халыктан бурычка акча җыелып, 35 мең сумга Казаннан двигатель алынып, хәзер биналар корылып ята. Бу да — Гаяз әфәндfestнең гайрәте һәм авыл ярлылар комитетының халык белән яхшы мөгамәләсеннән килеп чыккан нәрсә.

Шулай, Гаяз әфәнде чехлар тарафыннан вәхшиянә рәвештә суга ташланса да, Алладан вакыт җитмәгәнгә күрә, сәламәт котылды. Фәкать ирек каһарманнарының ятим калган егерме икеләп балалары, канлы яшьләрен агызып, аталарын көтәләр. Никадәр көтсәләр дә, алар кайтмый инде. Алар вәхшиләр тарафыннан корбан ителделәр. Аллаһе Тәгалә аларның рухларын шат, каберләрен киң итеп, ятим калган балаларына сабыр җәмил ихсан итсен!

## ӘДӘБИ МИРАС

# ҮЛЕМСЕЗ ИСЕМ



Быелның февраль аенда халкыбызның бөек язучысы, ялкынлы җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 116 ел тула.

Гомеренең зур өлеше чит илдә узганлыктан, иҗаты ватанында озак еллар укучылардан һәм тамашачылардан яшереп тотылганлыктан, аның тормыш юлы һәм әсәрләре әле бүген дә күпләргә тиешенчә таныш түгел. Әмма, еллар үткән саен аның исеме кара таплардан арына бара, иҗаты киңрәк һәм тирәнрәк өйрәнелгән саен әсәрләренең кадере дә арта төшә.

Шик тә юк, Исхакый иҗатын укучыларга һәм тамашачыларга тулы күләмдә кайтару өчен әле бик күп тырышасы бар. Аның киң кырлы эшчәнлеген замандашларыбызга ачу, яшь буынны аның үрнәгендә тәрбияләү иң әһәмиятле бурычларның берсе булып тора.

Дөрес, талантлы кешеләр арасында шөһрәткә сусаган, байлыкка кызыккан, шуларга ирешер өчен сәләтен дә, көч-кодрәтен дә кызганмаган затлар юк түгел. Андыйлар да үз милләтен «күтәрергә» мөмкин. Әмма Исхакый алардан аермалы буларак, газиз милләтен ирекле, бай рухлы, бәхетле итәр өчен шәхси байлыктан да, шөһрәттән дә аңлы рәвештә ваз кичкән олы җанлы сәнгатькяр, гасырга бер генә тапкыр туа ала торган даһи иҗатчы һәм каһарман көрәшче. Моны замандашлары да бөтен күңелләре белән тойганнар, аның хакындагы хөрмәт һәм мәхәббәт тулы истәлекләрен, уй-фикерләрен кәгазьгә төшереп калдырганнар.

Журналыбызның шушы санында без укучыларга Гаяз Исхакыйга багышланган әдәби мирастан өч әсәрне тәкъдим итәбез. Аларның беренчесен күренекле шагыйребез Сәгыйть Рәмиев (1880—1926) һәм нәшир Габдрахман Хөсәенов бергәләп язган һәм Г. Исхакыйның «Зиндан» (Казан, 1907) китабына сүз башы рәвешендә бастырып чыгарган. Икенче истәлек-мәкалә әдипнең мөһаҗирлектәге шәкерте һәм көрәштәше Гали Акыш (1918 елда туган) тарафыннан иҗат ителгән. Ул «Мөхәммәтгаяз Исхакый» (Анкара, 1979. Төзүчеләренең берсе — Г. Акыш) җыентыгында дөнья күргән. Өченче мәкаләне академик Владимир Александрович Гордлевский (1876—1956) әдипнең «Мулла бабай» романыннан урысчага тәрҗемә ителгән өзеккә кереш сүз рәвешендә язган һәм ул 1914 елда Мәскәүдә басылып чыккан.

Безгә калса, бер-берсенә һич тә охшамаган дүрт күренекле шәхес — Гаяз Исхакыйны күреп белгән, иҗаты белән яхшы таныш булган замандашлары сөекле язучыбыз хакында тәэсирләрен, уйлануларын, ерак дәвернең кайнар сулышын безнең көннәргә китереп җиткерәләр сыман. Язмаларны укыганда әдипнең тормыш юлы һәм эшчәнлегенең аерым сәхифәләре җанланып күз алдына баса — һәм син ирексездән сызланасың, шатланасың, горурланасың. Язучының якты сурәте безне дә халкыбызның хөррияте һәм бәхете хакына югары омтылышлы тынгысыз иҗатка һәм фидакарь көрәшкә рухландыра.

Тәүфикъ ӘЙДИ.

## Сәгыйть Рәмиев, Габдрахман Хөсәенев

# МӨХӘММӘТГАЯЗ ӘФӘНДЕ

Татарларның тупас телләрен матурлатып, аны үзенең кыйммәтле әсәрләре белән зиннәтләгән Гаяз әфәнде Исхаков җәнабләре 1878 елның 10 февралендә Яуширмә авылында дөньяга килгән. Үзенә башка куәтле бер мөхәррир булып, атасы Чистай тарафларында гыйлеме белән шөһрәт тапкан Гыйләҗ хәзрәт вә анасы — шул ук тарафның иң зур нәселе булган мулла Морад баба угылларында Мөсәлим Вәли хәзрәт кызы Камәриядер.

Гыйләҗ хәзрәтнең башка балалары туганы бере үлә барып, бер Гаяз әфәнде генә исән торганга, үзе дә ата-анага тәрбия вакытында бердәнбер генә бала булып, ата-анасы аны бик кадерләп кенә үстермешләрдер.

Гаяз әфәнде бик яшьли үк үзе кебек балалар арасыннан үзенең яхшылыгы, үткенлеге, тугрылыгы белән бик күп аерылып торган һәм дүрт-бишәр яшендә вакытында ук атасыннан ишеткән пәйгамбәрләр тарихын сөйләп, карчыкларны егълата торган булган.

Биш яшендә Гаяз әфәнде укырга тотынып, иң әүвәл үзенең анасының анасы Мәхфүзә остазбикәдән ул заманда «Әлифба» йә «Иман шарты» дип йөртелә торган китаптан сабак башлап, шул елны Гаяз әфәнде иҗекләр, сүрәләр укып, төрки танып, гарәп китаплардан ул вакыттагы бик мәгъруф[1] «Кырык хәдис» кә җиткән.

Шуннан соң дүрт-биш ел атасыннан гарәп, фарсы китапларын укып, унынчы яшендә сарыфка төшеп, иң иске ысул берлә сарыфны[2] һәм нәхүдән[3] «Кауагыйде әл-гарәп» белән «Гауамел»не дә күргән, унике яшендә вакытта 1890 елда Чистай мәдрәсәсенә кереп, «нәхүхан» булган. («Нәхүхан» дип мантыйкка төшмәс борын нәху укып йөргән шәкертләрне әйтәләр.) Бу вакытларда Чистай мәдрәсәсендә шәкертләр арасында үзенчә бер революция булганга, бу революция унике яшәрлек бала — Гаяз әфәндегә дә тәэсир иткән.

Шунысы шаять дикъкатьдер ки, унике яшәрлек бала Гаяз әфәнде ул вакытта да мәдрәсәнең низаматенә[4] разый булмаган суллар тарафында булган.

Гаяз әфәнде шәкертләр арасында иң әхлаклыларыннан вә шәрикләре арасында иң зиһенлеләреннән булса да, шәкертләрнең гомерләренең иң күбесе мәдрәсә тартышуларына китү сәбәпле, мәдрәсәдә уку бик начарланганга, Гаяз әфәнде Чистай мәдрәсәсендә өч ел торуында артык файда итә алмаган.

1893 елны Чистайның Закир хәзрәтнең вафатыны бәһанә итеп (хәйлә ясап), Гаяз әфәнде «шәмсияхан» булып Казанга, Күл буе мәдрәсәсенә килгән һәм дә Һади әфәнде Максудовтан укый башлаган. (Әгәр Закир хәзрәт үлмәсә, Гаяз әфәнденең атасы «хәзрәт фатыйхасы» дип Чистайдан җибәрмәячәк икән.)

Гаяз әфәнде укырга бик дәртләнеп килгәнгә, бик тырышып укый башлап, үзенең гайрәте, иҗтиһады берлә иптәшләренең исләрен китәрә торган вә һич көнне калдырмыйча дәресләрен бик күп итеп ала барса да, арымыйча, көн саен хәлфәсен «дәресне күбрәк бир» дип йөдәтә торган булган.

Ул вакытларда Күл буе мәдрәсәсендә «Җәдитне өркү» дигән кабахәт бер гадәт була иде.

Шәкертләр яңа шәкертне падиуслар кагып, кәвешләр, утын агачлары белән бәреп, кыйнап-сугып җәберлиләр иде. Мәдрәсәнең мөдәррисе Галим хәзрәт идарә-фәлән дигән нәрсәне белми торган кеше булганга, шәкертләрнең бу золымнарыннан, бу җәберләреннән һич бер төрле котылу мөмкин түгел иде.

Шул вакытларда, мәдрәсәдә золымнар бик куәтле булганда, Гаяз әфәндене дә бик каты җәберләгәннәр. Залимнәрнең бу золымнары, бу җәберләре Гаяз әфәнденең күңелендә бик ямьсез җәрәхәтләр калдырганга, Гаяз әфәнде әле дә бу

---

[1] Мәгъруф — билгеле.
[2] Сарыф — морфология.
[3] Нәху — синтаксис.
[4] Низамат — тәртип.

хәлләрне онытмыйча, татар мәдрәсәсендәге тормышлар мөзакәрә[1] кыйлынганда бик ачынып-ачынып сөйләштергәли.

Озак та үтмичә Гаяз әфәнде мәдрәсәнең иң укучы, иң моназыйр[2] шәкерте булып, үзенең игътибары арта башлагач ук мәдрәсәнең дәхли[3] эшләренә катыша башлаган; шәкертләрнең күнелләрендә бетмәслек җәрәхәтләр калдырып, аларны чыдар хәлдән чыгарганчы этли, җәберли торган залимнәр белән тартыша башлаган вә ахырда үзен генә җәберләтмәүдән дә үтеп, һәр мәзлумны[4] да химая[5] кыла башлаган.

Мәдрәсәгә килүенең өченче елында Гаяз әфәнде шул мәдрәсәнең диктаторы да булып, дәрес укымыйча, гел эчеп кенә йөрүче шәкертләрне бер дә яратмаганга, «тибү»не үзенә мәсләк итеп тоткан бәгъзе бер «мәхдүм хәзрәт»ләрне мәдрәсәгә кергезмичә тышта кундыргалаганы өчен, хәзрәтләрнең кырын күзләре астына да төшкәләгән.

Бу вакытларда моназарәт бик модада булганга, Гаяз әфәнде Казанның бөтен мәдрәсәләрендә моназарә кылышып йөри башлаган һәм тиз заманда моназарәт гыйлемендә шөһрәт тоткан. Начаррак мәдрәсәләрдә моназарә өчен аны кергезми дә башлаганнар.

Бу вакытларда Казанда ысулы җәдидә, ысулы кадимә тавышлары да чыгып, Галим хәзрәт мәдрәсәсе иң иске мәдрәсәләрдән була торып, шул мәдрәсәнең шәкерте Гаяз әфәнде ысулы җәдидә тарафдары булган. Мәдрәсәдәге бетмәгән-төгәнмәгән моназарәләрдә Гаяз әфәнде искеләр берлә кычкырышып, үз тарафына шактый гына иш җыйган. Шул вакытларда Гаяз әфәнде «Тәрҗеман» гәзитәсе укый башлаган. Аның соңында акыртынлап төрек гәзитләре, төрек әдәбиятлары укый башлап, 1897 елны үзенең хәлфәсе Һади әфәнде Печән базары мәхәлләсенә мөдәррис булып күчкәнгә, Гаяз әфәнде дә зур шәкерт булып Печән базарына күчкән. Анда мәдрәсәнең хәлфәсе һәм зур моназыйры булып, шул мәдрәсәнең алга баруына бик зур хезмәт иткән. Бу елны Гаяз әфәнде иске мантыйклардан туеп, яңа фәннәргә бик ихлас куйганга, ләкин яңа фәннәрдән күзгә алырлык бер китап та булмагач, Гаяз әфәнде тагы чынлабрак төрек әдәбиятлары укырга тотынган. Казанда булырга мөмкин булган төрек китапларының бик күбесен укыган. Ләкин төрекләрнең төпсез әдәбиятлары Гаяз әфәндегә канәгать итәрлек бер мәгълүмат та бирә алмаганча, анарда хассият кенә арттырган.

Гаяз әфәнде фән белер өчен урысча белү кирәклек икәненә бик ышанып, урысча укырга карар биргән. Урысча укыр өчен ул вакытларда Татарский учительский школа гына булганга, Гаяз әфәнде шушы школага кермәкче булган. Ләкин язга таба бик каты тиф белән авырганга, үзенең сәламәтлеген төзәтер өчен кымызга китәргә мәҗбүр булган. Кымызда, татар гадәтенчә, соңгарып кына кайтканга, Гаяз әфәндене школага алмаганнар. Шулай булса да Гаяз әфәнде, мәдрәсәдән чыгып, хосусый учительдән урысча укырга тотынган.

Шул көннән башлап Гаяз әфәнденең тормышы бөтенләй башкага, ул бу көнгә кадәр белмәгән дә, күрмәгән дә урыс галәменә атыла. Ул, фәкыйрь бер шәкерт, шул вакыттагы фанатизмга каршы сугыш ача...

Гаяз әфәнде бер яктан укырга, бер яктан укытырга вә бер яктан акча табарга, дип Яңа бистәдә мөгаллим була. Шул вакытта Гаяз әфәнденең Габдулла хәзрәттә торганда язган «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле әсәре мәйданга чыга, китап галәмендә һичбер тәэсирсез-нисез югала.

Яңа бистәдә Гаяз әфәнде бөтен Казанда беренче мәртәбә буларак ысулы саутия кергезә. Үзенең иҗтиһады, иптәше Хөсәен әфәнденең гайрәте саясендә мәктәп бик тиз тәрәккый итеп, барлык кешене хәйрәткә[6] калдыра. Монда Гаяз әфәнде үзенең «Кәләпүшче кыз» исемле әсәрен яза башлый һәм шул елны ук җәй көне басылып та чыга, һәм «Кәләпүшче кыз» китап базарында бик зур роль уйнап, мөхәррире Гаяз әфәндегә «татар әдибе» исемен алып бирә һәм мөхәррир таҗын кигезә. Шул елны Гаяз әфәнде «Бай углы» исемле әсәрен яза, ләкин ул вакытта андый китапларны бастырырга һәвәсле кеше булмаганга, 1903 елга кадәр басылмый кала. Шул ук елны Гаяз әфәнде «Гаҗәп бер вакыйга» исеме берлән төрекчәдән тәрҗемә кылып, үзеннән төзәтеп, тагы бер хикәя яза да, ләкин ул хикәя әйләнеп кайтмыйча, цензурада югала.

---

[1] Мөзакәрә — фикер алышу.
[2] Моназыйр — бәхәсче.
[3] Дәхли — эчке.
[4] Мәзлум — җәбәрләнгән.
[5] Химая — яклау.
[6] Хәйрәт — аптырап, хәйран булу.

1898 елны Гаяз әфәнде мәзкүр Татарский учительский школга кергән, ләкин мөгаллимлеген ташламыйча, Яңа бистәдә мөгаллимлеген дә дәвам иткән.

Гаяз әфәндегә үзе укыр өчен шәкертләр укытырга тиеш булганга вә шәкертләр укытыр өчен сарыф кыйлган вакыты бик күп булса да, алган вазифасы ашарга да җитмәгәнгә, бу ел Гаяз әфәнде өчен бик авыр булган. Шуның өстенә аны тагы язга таба мөгаллимлектән дә чыгарганнар.

Гаяз әфәнде үзе тырышып мәйданга китергән вә никадәр гайрәтен сарыф кыйлган мәктәбендән һәм сөекле шәкертләрендән аерылырга мәҗбүр булган. Ләкин Гаяз әфәнде балаларның күңелендә гомергә бетмәслек бер мәхәббәт калдырган. Шәкертләр Гаяз әфәндедән күз яшьләре белән еглый-еглый аерылышып калганнар.

Мондан соң Гаяз әфәнде вакытларын ачлы-туклы көенчә генә үткәреп, беренче сыйныфтан күчкән. Шул мәшәкатьләргә Гаяз әфәндинең нервасы чыдый алмыйча, авырый башлаган.

Икенче елны Гаяз әфәнде аталарыннан качып килеп, тагы укырга тотынган. Йокысызлык авыруы пәйда булып, тагы авырый башлаган. Ул елның кышын бик көчкә генә үткәреп, җәен кымызга киткән. Шул вакытларда Пушкинның әсәрләрендән «Капитан кызы» исемле бер әсәрен тәрҗемә иткән.

Өченче елны Гаяз әфәнденең сәламәтлеге шактый гына төзәлгән. Бу елны Гаяз әфәнде школаның пансионында торган. Бу елны Гаяз әфәнде үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз»[1] исемле әсәрен яза башлый. «Ике гыйшык» исемле әсәрен язып бетерә, «Өч хатын берлән тормыш» исемле әсәрен бастырып чыгара.

Дүртенче класста вакытта Гаяз әфәнде башка кешеләр берлән бергә шәкертләрдән мөрәккәб[2] «Шәкертлек» исемендә бер җәмгыять ясыйлар. Шул елларда әллә никадәр тавышларга сәбәп булган «Тәрәкъкый» гәзитләрен шул җәмгыять чыгара.

Мөфтине урыныдан төшерү «Шәкертлек»нең беренче эше булганга, «Шәкертлек» Русиянең бөтен тарафына мөфти төшерү хакында хатлар таратып, йоклаган татарларны уятты. Шул елны Гаяз әфәнде Гогольнең әсәрләреннән «Борынгы алпавытлар» дигән бер хикәясен тәрҗемә кыйлган («Әл-гасрелҗәдит» журналында басылды). Шул ук елны Гаяз әфәнде үзенең «Теләнче кызы» исемле әсәрен яза башлаган.

1902 елны Гаяз әфәнде школаны бетереп, җәй көне үзенең «Очрашу» исемле әсәрен язып бетереп, көз көне Оренбурга, безнең мәдрәсәмез «Мәдрәсәи Хөсәения»гә мөгаллим булып килде.

Гаяз әфәнде безгә мәдрәсәгә килгәч тә, мәдрәсәмезнең һәр тарафындан начарлыгын күреп, гаҗәпкә калды. Безнеңчә, мәдрәсәмезнең һичбер җитешмәгән җире юк иде.

Дәресләребез һәр каюсы расписаниегә язылып, стенага эленеп куелган, шәкертләр хәлфәләр сүзеннән чыкмаска, мәсҗеткә бар кешедән элек кереп, бар кешедән соң чыгарга, дип язылган низамнамә путаллы рамкалар белән рамкаланып, классларымызга асылган, шәкертләр дәрес китапларыннан башка китапка күз салмаска, атна кич өйләренә кайтканда кулларына бирелә торган рөхсәт кәгазендән башка кәгазь кулларына тотмаска, дип өсләремездән назыйрлар куелган һәм шәкертләр мәдрәсә ишек алдыннан башка һичкая да аяк атламасын өчен капкаларымыз даимән йозакланган иде. Шушы кадәр монтазам[3] мәдрәсәмезне яратмыйча гаҗәпкә калган Гаяз әфәндегә без дә гаҗәпкә калдык.

Без Гаяз әфәнде килгәнчегә хәтле, эчемездән булган хакыйкатьне күңелемездә яшереп, ул хакыйкатьнең хилафын күргәзеп, хилафларымызга ярап, сөекле булып йөри идек. Гаяз әфәндегә ярамадык. Гаяз әфәнде бездән хакыйкатьне хакыйкать көенә сорый башлады.

Без Гаяз әфәнде килгәнчегә хәтле күңелемездән бернәрсәгә ышанмасак та, хәлфәләремезнең хәтере өчен «Әйе, тәкъсир, шулай» дип йөрүемез белән алардан рәхмәтләр ала идек. Гаяз әфәндедән ала алмадык. Ул эшемез өчен Гаяз әфәнде бездән көлә генә башлады.

Шуннан соң без дә: «Юк, болай булмый икән. Бу хәлфәмезнең башка хәлфәләремез шикелле, үзләре хакыйкатьне өйрәтсәләр дә, хилафы белән эш кыйлырга кушмый икән, бу хәлфә хакыйкатьне хакыйкать көенә сорый икән», дип белеп алып, Гаяз әфәнде белән ачыктан-ачык хакыйкатьне генә сөйләшә башладык, бер-берләремезне аңлаштык вә чын күңелдән Гаяз әфәндегә ихлас куйдык.

---

[1] Инкыйраз — бетү.
[2] Мөрәккәб — кушылган.
[3] Монтазам — тәртипле.

Теше-тырнагы белән тотынып, Гаяз әфәнде мәдрәсәмезне ислях[1]ка кереште: иң әүвәл мәдрәсәбезнең китапханәсеннән тотынды. Шкаф-шкаф тулып яткан «китап»ларны идәнгә актарып ташлады да араларыннан китап эзли башлады. «Хөсәен әл-Мөшәрраб», «Аталы Гали әл-изһар», «Тәҗвид корәбаш», «Ибнәи бәни бәшәр» китапларыннан башка бер китап та таба алмагач: «Ни укыйсыз сез?» — диде. «Ә?» дидек тә башка сүз әйтә алмадык. «Әй мескеннәр, кашки татар булып тумаган булсаңызчы!» — диде дә ул да башка сүз әйтә алмады. Тик шул «китап»ларны рәте-рәте белән нумирладык та яңадан шкафка салып бикләп, ачкычын Гаяз әфәнде хәзрәткәме, әллә кемгә бирде дә куйды.

Шуннан соң Гаяз әфәнде мәдрәсәмезнең ашханәләренә, йокыханәләренә тотынды. Аларга тотынгач ук инде мәдрәсәмезне бөтенләй бикләп, ачкычын бер кеше кулына бирә дә куямы, дисәк, хәлфәләр, мөдәррисләр Гаяз әфәндегә ул кадәр үк ирек бирмәделәр, тик үзләре генә йокыханәләрнең тәрәзәләренә азрак форточкалар ясап, ашханәләрдә поварга итне азрак салкын суда тотынкырап, исен вә күгәргәнен бетеребрәк пешерергә куштылар.

Шуннан соң Гаяз әфәнде шәкертләрне укытырга башлап, әллә никадәр яңа фәннәр, әллә никадәр яңа китаплар укытты. Атна кич саен әдәбият ахшамнары[2] ясап, мәдрәсәгә әллә никадәр рух кергезде, шәкертләрдә кешелек хисен уяндырды, барысының да мәхәббәтен үзенә җәлеп итте.

Шәкертләрнең Гаяз әфәндене бик яратканыннан куркып, хәлфәләр Гаяз әфәндене алдагы елга мәдрәсәгә китерттермәскә уйлый башладылар һәм төрле-төрле хәйләләр белән Гаяз әфәндене киләсе елга килмәскә ясадылар. Май житте. Шәкертләрнең имтиханы бетте. Гаяз әфәнде дә безнең мәдрәсәдән китте. Шушы елны Гаяз әфәнде үзенең «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәрен язып бетергән иде.

1903 елны Гаяз әфәнде бездә булмады. Шәкертләрнең күңелләре Гаяз әфәндене эзлиләр, хәлфәләр Гаяз әфәндене үзләре китерттермәсәләр дә, алар да юксынып-юксынып куялар, аны матур-матур остроумиеләре белән искә төшереп, сагынып-сагынып сөйлиләр иде.

Бу заман хәлфәләр үз хәлләреннән зарланып: «Урыс халкының учительләре, ичмаса, картайгач пенсия аламыз, дип күңелләрен юаталар. Без картайгач нишләрбез икән?» — дип сөйләшәләр икән. Гаяз әфәнде: «Нигә? Без дә, табигый, татар мөгаллимнәре, татар мөдәррисләре ала килгән пенсияне алачакбыз. Агарган сач белән бөкрәйгән җилкәне кайда китәр дип уйлыйсыз?» — дигән. Хәлфәләр рәхәтләнешеп бер көлешкәннәр. Гаяз әфәндене шуның кеби остроумиеләре, мәҗлесенең хушлыгы, сүзгә осталыгы белән хәлфәләр дә аны бик еш-еш искә төшерәләр вә шәкертләр дә аның чын хәлфәлеге белән аңарга мәхәббәт утыртып калып, дәрес сәгатьләре саен аны сагыналар иде.

1903 елны Гаяз әфәнде Казанга китеп, университетка хәзерләнергә тотынды. Ләкин аталары-аналары килеп, акырып-бакырып, әллә нинди хәйләләр берлә Гаяз әфәндене өйгә алып киткәннәр. Гаяз әфәндене атасының указы алынганга, авыллары Гаяз әфәндене мулла ясыймыз дип, Гаяз әфәнде Орынбурда вакытта ук аңарга эш йөретеп, указ да алып куйганлар икән. Гаяз әфәнде авылга кайткач, үзенең киявен шунда мулла ясап китәр өчен тырыша башлаган. Ләкин эш озакка тартылып, Гаяз әфәндәнең елы үтеп киткән. Гаяз әфәнде бу елны авылына яңа мәктәп салдырудан башка бер эш тә эшли алмаган.

1904 елны Гаяз әфәнде Казанга килеп тора башлап, бу елларда хөррият хәрәкәтләре дә башланганга, Гаяз әфәнде хөррият хәрәкәтләренә кереп китте. Шул елны Чистайдан җибәрелгән мөселман делегатлары арасында Петербурга китте.

Андан кайткач, 17 октябрь манифестыннан соң, Гаяз әфәнде Чистай өязе авылларында митинглар ясап йөреп, андагы авылларның куштаны Шәйхи исемле бер кешенең һәм күрше Дүртөйле авылының мөәзине Котбиның донослары[3] берлә Гаяз әфәндене стражниклар тота башлагач, Гаяз әфәнде тагы Казанга китте. Казанда уникенче декабрьдә шәкертләр мәҗлесендә Гаяз әфәндәнең өстенә полиция басып, аны тотмакчы булсалар да, Гаяз әфәнде качып котылды. Кич берлә полиция квартирына барса да, Гаяз әфәндене өйдә очрата алмаганнар. Бик озак көтеп Гаяз әфәнде кайтмагач, аның чәен-шикәрен, күмәчләрен ашап-эчеп чыгып киткәннәр.

Шул көннән башлап Гаяз әфәнде «нелегальный»лыкка чыгып, качып йөри башлый.

---

[1] Ислях — үзгәртү.
[2] Ахшам — кичә.
[3] Донос — әләк, чагу.

Гаяз әфәндене «Казан мөхбире» гәзитенә язучылыкка чакырсалар да, гәзитәнең мәсләге бик уң булганга, Гаяз әфәнденең язган бер нәрсәсен идарә сызгалап бетергәнгә, Гаяз әфәнде үз мәсләгендә иркенләп язар өчен үз иптәшләре берлә үзләренә махсус гәзитә чыгарырга уйларга тотынды һәм Гаяз әфәнде исемендән «Таң» исемле гәзитәгә рөхсәт сорадылар. Ләкин Гаяз әфәнде «нелегальный» булганга, гәзитәгә рөхсәт бирелмәде. Гәзитәне Фуад әфәнде исеменә күчерделәр. Аңарга да рөхсәт бирелмәде. Гәзитә «Хөррият» исеме берлә яңа бер кеше исеменә бирелде. Ул кешенең редакторлыкка правасы булмады. Ниһаять, Гали әфәнде Путилаков исеменә «Таң йолдызы» гәзитәсенә рөхсәт алынды. Моңарга рөхсәт алынганчы да бик күп вакытлар үткәнгә, «Таң йолдызы» гәзитәсе 1906 ел унсигезенче майда гына чыга башлады.

Гаяз әфәнде «Таң йолдызы»ның фактический мөхәррире булды. Гәзитәнең иң күп җирен ул язды. Гәзитәгә рух ул бирде. Һаман да туйганчы яза алмады, алтмыш нумир гәзитә чыгаргач та, 30 октябрьда Гаяз әфәндене арестовать иттеләр. Кәтмәгән җирдән, берничә көннән чыгарсалар да, Казанда торгызмыйча, авылына җибәрделәр.

Гаяз әфәндене авылына кайту белән тагы арестовать иттеләр. Ләкин бер тәүлектән чыгарып, поднадзор тотып, һич кайда җибәрмәделәр.

Егерме өченче декабрьдә тагы тотып, Чистай төрмәсенә илтеп яптылар. Кызыльяр волосте аны үзе төрмәдә вакытта уполномоченный итеп сайласа да, комиссия тәсдикъ[1] итмәде.

Ике ай чамасы төрмәдә ятып, анда үзенең ошбу «Зиндан» исемле әсәрен язып, унсигезенче февраль 1907 елны төрмәдән чыгып, тагы Казанга килде. Озакламыйча «Теләнче кызы» исемле әсәрле бер романы басылып чыгачак.

Гаяз әфәнде кебек сирәк бер әдипнең, Гаяз әфәнде кебек сирәк бер мөхәррирнең һәм Гаяз әфәнде кебек сирәк бер кешенең һәрвакыт бар булып торуы безнең татар халкы өчен минут саен кирәк булганга, без бөтен татар күңеле белән Гаяз әфәнденең күп еллар яшәмәген телимез вә аның, яшәгән суретттә, һичбер арымыйча, һәрвакыт халык файдасына тырышып хезмәт итәчәгенә чын-чыннан ышанамыз вә халык та үз алдына тырышып, Гаяз әфәнде кебек егетләр белән кул-кулга тотынышып, алга таба омтылсалар, шөбһәсез, сәгадәткә чыгачакларында һич шик тотмыйбыз!

Яшә, халык! Яшә, Гаяз әфәнде!

## Гали Акыш

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ:

## Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы

Моннан йөз ел элек, 1878 елның 23 февралендә Идел-Урал төрек-татар халкының бөек язучысы, мәшһүр матбагачысы һәм сәяси юлбашчысы Гаяз Исхакый якты дөньяга күзләрен ачкан.

XIII гасырның беренче яртысыннан XV гасырның ахырына кадәр ике йөз илле ел буе Русияне хакимияте һәм идарәсе астында тоткан кодрәтле һәм мәдәни Алтын Урда дәүләте булган. Аның табигый һәм кануни варисы Казан ханлыгы, урысларның вәхши һөҗүмнәренә каршы тора алмыйча, 1552 елда җимерелгән, әмма һичбер вакыт бу буйсындыруга килешмәгән, шактый вакытлар баш күтәреп, бәйсезлеген кире кайтарырга тырышкан.

---

Гали АКЫШ (1918)—*журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе. «Идел-Урал дәгъвасы һәм Совет империализмы» (Истанбул, 1963), «Идел-Уралда хөррият мөҗадәләсе» (Истанбул, 1985) китаплары һәм алман, инглиз, татар, төрек телләрендә басылган күп кенә мәкаләләр авторы, Бөтендөнья татар лигасы рәисе, татар милли мәҗлесенең мактаулы әгъзасы. Алманиянең Мюнхен шәһәрендә яши.*

[1] Тәсдикъ итү—раслау.

Без, бәйсезлек көрәшчеләре, Гаяз Исхакый сызган милли азатлык хәрәкәте юлыннан ахырга кадәр барырга сүз бирдек һәм аны милли азатлык хәрәкәтенең символы итеп кабул иттек. Шулай итеп, милли азатлык хәрәкәтенә яңа кушылачак миллиятче яшьләребезгә Гаяз Исхакыйдан үрнәк һәм илһам алуларын теләп, һәм шул ук вакытта Төркиянең бөтен катламнарына аны таныту максаты белән бу мәкаләне язуны изге бер бурычыбыз дип беләбез.

Сөекле Идел-Урал өлкәсенең ачы язмышын күргән һәм бәгырьсе белән тойган Гаяз Исхакый, өзелеп яраткан төрек-татар халкын бәйсезлеккә, иркен тормышка һәм социаль бәхеткә ирештерү теләге һәм максаты белән гомеренең соңына кадәр көрәшергә карар биргән һәм моңа төгәл 60 ел гомерен багышлаган. Алла биргән сәләтен һәм талантын милләт бәхете өчен көрәштә куллануы һәм бу бөек идеал хакына шәхси ирегең, хәтта саулыгын да кызганмавы безнең күз алдыбызда булды. Мәрхүмне якыннан белүем һәм аның белән бергә эшләү бәхетенә ирешүем сәбәпле, аны объектив бер рәвештә күрсәтерлек һәм аның хакында фикер йөртерлек дәрәҗәдәмен дип ышанам. Чөнки 1938 елдан алып 1954 елга кадәр Г. Исхакый белән бергә эшләп, аның белән якыннан танышу, шәхесендәге тирәнлекләрне яхшырак аңлау, һәм, ниһаять, аның кушуы буенча, милли азатлык хәрәкәтебезне дәвам иттерү вазифасын үз өстемә алган елларда остазымның язмаларын анализларга форсат таптым.

Сөекле халкын ирекә, муллыкка һәм бәхеткә ирештерү максаты белән көрәшкә ташланган Г. Исхакый, 76 еллык гомеренең нәкъ 60 елын милли азатлык хәрәкәтенә багышлады, ягъни ул үзеннән соң 60 еллык көрәш тарихы калдырды. Югарыда телгә алганыбызча, Г. Исхакый турында фикер әйтү өчен аның белән таныш булу гына җитми, аның күп санлы әсәрләрен уку, әңгәмәләрен тыңлаган булу һәм мәкаләләрен өйрәнү шарт.

Г. Исхакыйның милли идеалы өчен көрәшендә түбәндәге өч сыйфаты мәйданга чыкты: **әдиплеге, матбагачылыгы, сәяси юлбашчылыгы.**

Хәзер аның шул өч сыйфатын аерым-аерым карыйк.

Гаяз Исхакый әдип буларак 45 хикәя, роман һәм сәхнә әсәре белән Казан татарлары әдәбияты тарихының алтын чорын барлыкка китерүчеләрнең беренчеләреннән. Сәнгатьнең бер тармагы булган әдәбиятны Гаяз Исхакый үзе миллиятче идеализм фикеренә бәйләп карый, ягъни «фикер өчен сәнгать» принцибына хезмәт итә. Беренче әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт»тә Г. Исхакый сөекле милләтен ислам дөньясының артта калуына сәбәп булган фанатизм кебек хаталы күренешләргә каршы көрәшкә чакыра. Аның бөтен әсәрләрендә фикер хаким. XIX йөзнең икенче яртысында, Казан татарларының уяну дәвере башланганга, яшь әдипнең беренче әсәрләрендә ул дәвергә хас фикерләр өстенлек итә. 1905 елда тиран урыс патшалыгы Япония тарафыннан җиңелгәннән соң, бөтен Рәсәй буйлап яңа бер хәрәкәт башлана. Г. Исхакый да, ул заманда башланган милли хәрәкәт һәм революцион агымның тәэсире астында, әдәби әсәрләренә шул чорның уяну фикерен кертә. Бу вакытта 30 яшенә якынлашкан һәм урыс патшалыгына каршы актив көрәшкә күтәрелгән әдип, Идел-Урал төрек-татарларының шанлы үткәненнән илһам алып, әсәрләренә милләтенең киләчәге өчен кыюлык чыганагы булырлык фикерләр сеңдерә иде. Мондый куркусыз, кыю хәрәкәтләр патша хөкүмәтенең игътибарыннан читтә кала алмый иде: әдип, берничә мәртәбә кулга алынып, төрмәгә ябыла, төньякка сөргенгә дә сөрелә. Әмма идеалыннан чигенү һичбер вакыт хәтта уена да кереп карамаган яшь язучы куркып калмый, төрмәдә дә әдәби әсәрләр язуын дәвам итә. Мәсәлән, «Зиндан» исемле әсәрендә, тоткын хәятенең тыштан күренгәнчә һич кенә дә начар түгеллеге, киресенчә, иң камил сәяси мәктәп булуы хакында кистереп әйтә. «Зөләйха» исемле әсәрендә исә, Исхакый көчләп чукындырылган бер мөселман гаиләсенең фаҗигасе турында сөйли һәм шул гаиләнең иске диненә кире кайту өчен көрәшен сурәтли. Г. Исхакыйның революционерлык чоры 1918 елга кадәр генә дәвам итсә дә, ул аннан соң да социаль хокукны һәм демократик социализмны яклаучы булып калды. 1918 елда кызыллар Идел-Урал өлкәсен хәрби көч белән басып алып, анда коммунистлар режимын урнаштыра башлагач, Г. Исхакый инде коммунистлар партиясе эзәрлекләвенә дучар була һәм, ниһаять, Ватанын калдырып китәргә мәҗбүр ителә. Мөһаҗирлек хәятендә Исхакый армый-талмый әдәби эшчәнлеген дәвам итте. Бу чорда язган иң зур әдәби әсәрләреннән берсе — «Дулкын эчендә» драмасы. Монда Г. Исхакый үзенең самими һәм тирән уйлы бер төркиче булуын ачык итеп уртага куя. Бу әсәреннән кала тагын «Өйгә таба» романында да төрки берлек фикерен алга сөрергә тырыша. 1922 елда татарча язылган бу роман ике тапкыр Төркия төрекчәсенә тәрҗемә

ителгән. «Жан Баевич» исемле комедиясендә исә, әдип европалашырга тырышкан надан бер сәүдәгәрнең көлке язмышын укучы һәм тамашачы хөкеменә тапшыра. «Утыз еллыгым» исемле әсәре белән әдип, әдәби эшчәнлегенең утыз елын хатирәләр шәкелендә укучыларына тәкъдим итәргә теләгән.*

Икенче бөтендөнья сугышы бөтен әсир төркиләрнең милли идеалының җимерелүе һәм өметләренең киселүе белән тәмамланганга, язучы Г. Исхакыйга мөһаҗирлектә булган милләттәшләрен өмет уты белән яктырту вазифасы төшә. «Олуг Мөхәммәт» исемле тарихи драмасында Г. Исхакый, милләтенең даншөһрәт тулы үткәнен җанландыра һәм киләчәге хакындагы өметләрен үзенә генә хас ышандыргыч ысул белән сеңдерә. Иң соңгы тәрҗемә әсәре — «Казан тарихы» басылмаган. Кыскасы, Исхакыйның бөтен әдәби әсәрләрендә әхлак, игелек, хөрриятькә мәхәббәт белән бергә, урта хәлле һәм бай сыйныфның кимчелекләрен тәнкыйтьләгәндә дә, үзенә тартып торучы зирәклек һәм үткен акыл өстенлек итә.

Гаяз Исхакыйның әдәби эшчәнлеге хакында белгеч сүзен әйтүне әдәбиятчыларга калдырып, аның матбагачы һәм сәяси юлбашчы сыйфатларын карыйк. Бу фикеребезне тәгәлләп, тагын шуны гына әйтәбез: хөррият сөюче буларак, аны бөек төрек шагыйре һәм әдибе Нәмикъ Кәмалга, әхлакчы буларак, француз язучысы Бальзакка, реалист буларак, тагын бер француз язучысы Эмиль Золяга охшата алабыз. Ватаныбызны басып алган урыс империалистлары һәм аларның фикердәшләре 45 әдәби әсәр биргән Г. Исхакыйны яшь буыннан яшереп тота. Аның әсәрләре коммунизм идеологиясенә һәм Совет режимына каршы дошманлык рухында язылган дип тәкърарлана. Чынлыкта исә, Г. Исхакый бөтен әсәрләрендә халык бәхете өчен көрәш максатын күздә тота. Урыс империалистлары һәм аларның куштаннары, урыс өстенлегенә хезмәт итмәгән һәр әдәби әсәрне үз режимнарына каршы дип кабул итә. Мюнхендагы «Азатлык» радиосы менә инде дистә еллар буе Г. Исхакыйның шактый әсәрләрен татар телендә пропагандалый, ватандагы яшь буынны аның әсәрләреннән мәхрүм итмәүне үзенең бурычы дип саный. Бу өлкәдә татар-башкорт редакциясенең бөтен хезмәткәрләре, үзләренә төшкән бурычны үтәп һәм бу изге вазифаны чын күңелдән башкарып, милли көрәш рухын сүндермичә дәвам иттерәләр. Г. Исхакыйны сәяси язучы яки матбагачы буларак анализлаганда, аның 55 еллык матбугатчылык эшен һәм бу озак вакыт аралыгы эчендә ул тугрылыклы калган төп принципларны монда искә алу урынлы булыр дип саныйм. Аның иң бөек төп максаты — халыкчылык. Авыл имамының улы булган Гаяз Исхакый һәрчак халык арасында кайнаган, соңгы сулышына кадәр халык өчен яшәп, халык белән бергә булу теләген үзенә максат итеп алган. Халыкчылык принцибының иң әһәмиятле ягы — социаль хокук. Г. Исхакый бер яктан патша хакимияте идарәчеләренең, икенче яктан, кайбер байларның халыкка карата эшләнгән хаксызлыкларын бетерү юлында көрәште һәм бу изге көрәштә күп төрле каршылыкларга очрады. Сәяси язучы яки гәзитче буларак Исхакыйның икенче төп принцибы — ялкынлы миллиятчелек. Аның өченче төп принцибы исә — оптимизм. Югарыда әйткәнебезчә, Г. Исхакый өмет хәрабәләре өстендә яңа бәхетле тормыш төзү эшенә бирелгәнлек, осталык күрсәтә алучы бер рух рәссамы иде. Менә шул өметне югалтмау үзенчәлеге Г. Исхакыйның иң өстен ягы да инде.

Г. Исхакый гәзитчелек эшен 1900 елда 22 яшендә башлый. XX гасыр кергәндә милли уяныш үз нәтиҗәләрен күрсәтә башлаган, әмма патша хөкүмәте татар-башкортларга әле милли матбугат чыгарырга рөхсәт бирми. Әмма төркиче фикер иясе кырымлы Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман» гәзите бу вакытта бөтен Русия төркиләренә милли рух иңдерергә тырыша. Гаспралы, патша жандармериясе шиген уятмас өчен саклык күрсәтергә мәҗбүр булганга, Г. Исхакый мондый астыртын матбугатны җитәрлек түгел дип таба һәм рухындагы халыкчылык, социаль хокук һәм миллиятчелек принципларыннан илһам алып, «Тәрәкъкый» исемле яшерен гәзит чыгара башлый. Бераздан социаль хокукның татар халкы арасында урнашуын таләп иткән радикаль характердагы бу гәзитне патша хөкүмәте яптырса да, Исхакый өметсезлеккә бирелми, 1902 елда «Хөррият» исемле тагын да радикальрак характердагы, социаль хокук дәгъва итүче яшерен бер журнал чыгара башлый. Мөхәррир бу журналда, изү астында иңрәгән, социаль һәм дини яктан хокуксызлыкка дучар булган сөекле милләтенә хөррият кояшының туачагын хәбәр итә. Нәкъ менә 1904 елда кечкенә бер сылтау белән Русия белән Япония арасында сугыш кабынып китә һәм бөтен дөньяны хәйран калдырган бер вакыйга була. Ул чорда Бөек дәүләтләр сафында

* Бу кульязма әсәре, кызганыч ки, Икенче бөтендөнья сугышы вакытында кайбер кәгазьләре белән бергә югалган.

урын тоткан Русия империторлыгы яңа гына күтәрелә башлаган Япониядән җиңелә. Г. Исхакый 1942 елның 13 февралендә Истанбулда «Төрки мәдәният берлеге» исемле җәмгыятьтә сөйләгән бер лекциясендә бөек Русиянең кечкенә бер Япониягә җиңелү вакыйгасы турында болай ди: «Азияле японнарның урысларны ачы җиңелүгә китерүе, үзләренең дөньяны идарә итү өчен яратылганлыкларына инанган колонизатор аурупалыларның һәм христиан дине белән Аурупа мәдәниятен Көнчыгыш милләтләре арасына җәелдерү өчен Аллаһы тарафыннан сайланганлыкларына иман китергән империалист урысларның акылын алды.» Г. Исхакыйның моннан ярты гасыр элек сөйләгән бу сүзләре бүген дә актуальлеген югалтмаган. Чөнки көнчыгыш дөньясы бүген дә, бер яктан, христианлык акылы, икенче яктан, Совет империалистлары пропагандасы тәэсире астында, Кытайның дөнья тынычлыгы өчен зур куркыныч тудыруына ышана. Югыйсә, чынлыкта Русия үзе дөнья тынычлыгы һәм иминлеге өчен иң зур куркыныч тудыручы булуында дәвам итә.

1905 елда Русия Япония тарафыннан җиңелгәннән соң, коллыкта яшәгән милләтләр арасында иң мәдәни саналган финнәр һәм полякларның кораллы баш күтәрү юлы белән сәяси һәм социаль хокукларын яулап алырга тырышулары күренә. Бу вакытларда бөтен Русия төркиләре һәм, шул исәптән, татарлар да милли мәгариф, матбугат, театр, әдәбият һәм сәяси оешмалар мәйданга китерүдә күптән омтылган кайбер хокукларын яулый башлый. Милли матбугатка рөхсәт бирелгәнне күргән Г. Исхакый, бөтен барлыгы белән «Таң» һәм соңыннан «Таң йолдызы» исемендәге гәзит чыгара башлый. Алар, эчтәлекләрендә халыкчылык, миллиятчелек һәм революционерлык рухы ачык билгеле булмаганлыктан, басылуларын дәвам итә алсалар да, жандармерия Г. Исхакыйның революционерлыгыннан курка һәм аны кулга ала, аннары гәзитләрен дә туктата. 1906 елда кулга алынган Г. Исхакый дусларына «Тавыш» гәзитен чыгару турында күрсәтмә бирә, әмма «Тавыш»ның да Исхакый эше булуын белеп алган хакимият, татар халкын хакимнәргә каршы күтәрүеннән курыкканга, аны Идел-Урал өлкәсеннән ераклаштыра, ягъни гәзитнең чынлыктагы баш редакторын ерак төньякка — Архангельск шәһәренә сөрә. Ташкын йөрәкле революционер Гаяз Исхакый сөргендә бер елдан артык калмый, дуслары ярдәме белән сөргеннән качып, чагыштырмача хөр булган Финляндиядә бераз сулыш ала. Аннан форсат табып, Истанбулга килә һәм мәсләктәш матбагачылар белән бәйләнешкә керә.

Г. Исхакый Истанбулда яшәгән дүрт ай эчендә, 1908 елда игълан ителгән Икенче конституциядән соң Төркиядә мәйданга килгән азатлык хәрәкәтенең юлбашчылары белән берлектә бер журнал чыгарырга омтылса да, нәтиҗәсе күренмәгәнгә, 1909 елның башында ялган паспорт белән ватанына кире кайта һәм гәзитчелек эше белән шөгыльләнә башлый. Петербургта яңа бер журналда эш алып барган вакытта, урыс жандармериясенең яшерен агенты булган бер язучы белән бәрелешкәннән соң, кулга алына һәм яңадан элеккеге сөрген урыны булган Архангельскига җибәрелә. Исхакый Төньяк боз диңгезеннән 40 км гына ераклыктагы Мезен поселогында сөрген җәзасын үткәргәндә 1913 елда Романовлар нәселенең тәхеткә утыруына 300 ел тулу мөнәсәбәте белән амнистия игълан ителә. Г. Исхакый да туган авылы Яуширмәгә кайта, соңыннан татарларның мәдәният һәм сәясәт мәркәзе Казанга килә. Татар яшьләре аның кайтуы хөрмәтенә театрда әсәрләрен сәхнәгә куярга хәзерләнә. Әмма жандармерия революционер Г. Исхакыйның Казанга килүен тыеп, аны кулга алу чараларын күрә. Казандагы татар театрында куелган үз әсәрен тамаша кылганнан соң, Исхакый яшь миллиятче татар зыялылары ярдәмендә чорма аша качып китеп, ул заманның яшь язучысы Ф. Әмирхан фатирында яшеренә һәм кулга алынудан котылып кала. Г. Исхакый, Казанда калуның куркыныч икәнен белгәнгә, Уфага китә. Монда да жандармнар эзәрлекләвенә дучар булгач, Петербургка юнәлә. Монда ул яңадан гәзит чыгару эшенә керешә. 6—7 еллык әсир, сөргенче һәм качак хәятеннән соң да кыю рәвештә гәзит чыгара башлаган Гаяз Исхакый турында Идел буе төрек-татарларының бөек милли шагыйре Габдулла Тукай «Мөхәррирга» исемле шигырен язды. Бу гүзәл шигыре белән Тукай 6 еллык аерылу хәсрәтен һәм язучының матбугат хәятенә кире кайтуы белән бәйле чиксез шатлыгын белдерде. Бу шигырен язганнан соң 2 ай үткәч, Тукай вафат булды. Әнә шулай бөек шагыйрь белән бөек язучы шәхсән танышу мөмкинлегеннән мәхрүм калдылар. Бераздан Г. Исхакыйның яңа гәзитенә дә ябылу куркынычы яный. Әмма көрәшчә бернинди авырлыкларга да бирешмичә, «Ил» исемле бер гәзит чыгарырга тотына.

Патша Русиясе заманында мөселманнардан бары тик Идел буе һәм Кырым татарлары гына мәҗбүри хәрби хезмәткә алына иде. 1914 елда Беренче дөнья

сугышының башлануы белән, хөкүмәт авыр хезмәтләрдә куллану өчен Төркестандагы кардәшләребезне дә тоташтан мобилизацияләп, сугышка җибәрә башлый. Әмма тәртипсез һәм кешелеклелектән мәхрүм шартларда яшәү авырлыгында калган төркестанлылар баш күтәрә һәм бу хәрәкәт хөкүмәт тарафыннан канлы рәвештә бастырыла. Патша хакимиятенең мондый кешелексезлеге Русия мөселманнары арасында тискәре реакция тудыра. Г. Исхакый «Ил» газите битләрендә, Дәүләт Думасында игълан ителгән протест белдерүен тиз арада бастырып чыгара. Патша хөкүмәте бу протестның киң таралуыннан курыкканга, сугыш вакытында игълан ителгән хокуктан файдаланып, газитне яптыра. Ару-талуның, куркуның һәм өметсезлеккә төшүнең ни икәнен дә белмәгән Исхакый, бу юлы «Сүз» исемендә яңа газит чыгара башлый. Тора-бара зурая барган Төркестан баш күтәрү хәрәкәте һәм залим урыс патшалыгы чиновниклары кулланган кырыс чаралар турындагы хәбәрләр «Сүз» газитендә дә шунда ук басыла. Бу үзәк өзгеч хәбәрләр бөтен Русия төркиләрендә патшага каршы нәфрәтне тагын да көчәйтә. Ниһаять, патша хөкүмәтенең бу вәхшилеген анализлау өчен бер тикшерү комиссиясе төзелә. Бу комиссиягә Исхакыйның «Сүз» газите редакциясеннән дә бер кеше катнаша. Шулай итеп, патша хөкүмәтенең вәхшилеге турындагы хәбәрләр «Сүз»дә бер дә киметелмичә басыла һәм моннан соң аны укучылар саны да кинәт артып китә. Әмма газитнең киң күләмдә таралуы һәм шулай итеп, Исхакый шөһрәтенең бөтен Русия төркиләре арасында таралуы урыс гаскәрләренең төньяк фронты әмерчесе генерал Куропаткинның игътибарын җәлеп итә. Газит ябыла. Моннан соң Г. Исхакый патша хөкүмәте дошманнарының бер юлбашчысы итеп кабул ителгәнгә күрә, инде аны Мәскәүдә яшәү мөмкинлегеннән дә мәхрүм итәләр.

1914 елда башланган Беренче дөнья сугышына Русия Айя-Суфия мәчетенә тәре кую, Истанбулны, диңгез бугазларын кулга төшерү хыялы белән керә. Тик 1914 елда алманнарга каршы Танненберг сугышында урыс гаскәрләре, 1915 елда Чанаккалада каһарман төрек гаскәрләренә каршы сугышта инглиз һәм француз гаскәрләре дә җиңелүгә дучар була. Хыяллары чәлпәрәмә килгәнен күргән Антанта дәүләтләре, инглиз һәм француз колонияләрендәге урыс патшалыгы хакимияте астындагы милләтләрнең таләпләренә буйсынырга мәҗбүр була.

Патша Русиясе җиңелә. Ягъни 1917 елның февраль аенда Русиядә демократик революция була. Бу уңайлы форсаттан файдаланырга кирәклеген белгән Исхакый һәм аның иптәшләре эшкә керешә — Мәскәүдә «Ил» газитен яңадан чыгара башлый. Бу уңайлы вакыйгадан файдаланып, 1917 елның май аенда Мәскәүдә гомум Русия мөселманнарының Беренче Корылтае җыела. Г. Исхакый Корылтай президиумына сайлана. Аның «Ил» газите гомум Русия мөселманнарының беренче корылтае матбугат органы була. Кыскасы, Исхакыйның «Ил»е төрек-татарларның милли мохтарият игълан итүләрендә әһәмиятле роль уйный, соңыннан Уфада җыелган Милләт Мәҗлесе белән Милли Идарәнең дә матбугат органы буларак тарихка керә.

Г. Исхакый 1918 елның башларында Мәскәүгә килеп, «Ил» газитен Казанга күчерү эше белән шөгыльләнгәндә, большевиклар Мәскәүдә ныгый һәм «Ил»не конфискацияләп, анда төрек коммунистлары юлбашчысы Мостафа Сөбхи җитәкчелегендә төрекчә «Дөнья» исемле бер газит чыгара башлый. Г. Исхакый революция дошманы рәвешендә хөкемгә тартылырга тиеш булса да, Мәскәүдән качып китә ала.

Качак Г. Исхакый 1919 елда Себернең Кызылҗар шәһәрендә дуслары Фуат Туктар һәм Гомәр Терегулов белән берлектә «Маяк» исемле бер газит чыгарырга керешә. Гражданнар сугышы бөтен мәмләкәт буйлап җәелгәнгә, ул газитнең бары тик 30 саны гына дөнья күрә. Шулай итеп Г. Исхакыйның горбәт хәяте башланды. Ул 1919 елның ахырларында Ерак Көнчыгыш юлы белән башта Аурупага, соңыннан Төркиягә китә. Төркиядә 1925 елдан 1927 елга кадәр «Төрек йорты» журналына мәкаләләр язу белән шөгыльләнә.

Гаяз Исхакый 1927 елда Төркиядән китеп, Берлин һәм Варшавада яшәде. 1928 елдан 1939 елның ахырына кадәр 11 ел буе «Милли юл» журналын чыгарды. «Милли юл» журналы Идел-Урал төрек-татарларының 11 томлык милли көрәш тарихы һәм милли энциклопедиясе буларак урын алды. Бүген барлык галимнәр бу журналны мөһим тарихи чыганак итеп куллана һәм киләчәктә дә шулай кулланачак.

Г. Исхакый 1933 елда Ерак Көнчыгыш илләреннән Кытай, Япония һәм Кореядә төрек-татарлар яшәгән төбәкләрне карап йөрде, соңыннан аларны бер үзәккә бәйләде һәм 1935 елда Маньчжуриянең Мукден шәһәрендә атналык «Милли байрак» газитен нәшер итә башлады. Бу басма Рокыя Мөхәммәдишнең

баш мөхәррирлегендә 1945 елга кадәр өзлексез чыгуын дәвам итеп, мөһаҗирлектә яшәгән татар яшьләрен милли рухта тәрбияләү эшенә зур өлеш кертте. Бу юлларны язучы да, «Милли юл» журналы белән «Милли байрак» газитеннән илһам һәм үрнәк алып, милли азатлык хәрәкәтенә хезмәт итәргә ашыкты.

Икенче дөнья сугышы нәтиҗәләре Г. Исхакый язмышында да тирән эз калдырды. 1945—1952 елларда Истанбулдан аерылмаган Исхакый, журналист сыйфатында файдалы бер хезмәт таба алмаганга, әдәби эшчәнлек белән чикләнергә мәҗбүр булды.

1953 елда Көнбатыш Германиянең Мюнхен шәһәренә китеп, анда «Милли байрак» исемле өч айлык бер журнал чыгара башласа да, каһәр төшкән рак авыруы җанын һәм тәнен кимергәнгә күрә, кире Төркиягә кайтырга мәҗбүр булды. Г. Исхакый 1954 елның 22 июлендә Анкарада яшәгән кызы — хөрмәтле профессор Сәгадәт Чагатайның өендә вафат булды. Гәүдәсе Истанбулга китерелеп, 24 июльдә Әдернәкапы зиратына җирләнде.

Мәрхүм 76 еллык гомеренең 55 елын матбагачы буларак үткәрде һәм шуңа күрә Идел-Урал татар матбугатының атасы дигән исемне алырга лаеклы иде. Ул «Тәрәкъкый», «Хөррият», «Таң», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Ил», «Сүз», «Ил сүзе», «Маяк» һәм «Милли байрак» газитләре белән «Милли байрак» журналларының баш мөхәррире, оештыручысы була. Совет матбугаты озак еллар бу халык дошманы итеп яшь буынга танытырга маташса да, татар-башкорт халкының зур күпчелеге аның сансыз хезмәтләренә зур бәя бирә. Бер гади кеше башкара алмаслык эшләрне авыр шартларда тормышка ашыру бары тик Исхакый кебек бөек затларга гына хас. Бу чынбарлыкны бөтен төрек-татар халкы аңларга һәм аннан үрнәк алырга тиеш.

Кайбер кешеләр юлбашчы булып туа. Инглиз фәлсәфәчесе Кэлил әйтүенчә, милләтләрнең тарихы ул милләт юлбашчыларының тәрҗемәи хәленнән гыйбарәт. Гаяз Исхакый менә шундый кешеләрнең берсе иде.

Казан губернасының Чистай өязе Яушырмә авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән Гаяз Исхакый башлангыч белемен туган авылында ала, соңыннан Чистай һәм Казан мәдрәсәләрендә, учительская школада укый. Шуларны тәмамлагач, туган авылына имам итеп билгеләнә. Әле башлангыч мәктәп елларында ук сәләте сизелеп торган Г. Исхакый гади бер авыл имамы гына булып кала алмый иде. Учительская школада укыганда ук «Шәкертлек» дигән бер яшерен оешма төзеп, ул яхшы оештыручы булачагын исбат итә. Соңыннан, әдиплек һәм матбагачылык эшләре белән беррәттән сәяси эшләргә дә актив катнашырга керешә. Уку елларында төзегән «Шәкертлек»не үстереп, аның программасын тагын да киңәйтеп, «Хөррият» исемле сәяси бер оешма мәйданга китерә һәм патша хөкүмәтенә каршы актив көрәш алып бара башлый. Япониядән җиңелгән Русиядә патша идарәсенә каршы хәрәкәтләр көчәйгәч, Икенче Николай хөррият манифестын игълан итәргә мәҗбүр була. 1905 елның 30 октябрендә Русиядә беренче конституция кабул ителә. 1906 елда шуңа таянып, Русия тарихында беренче тапкыр парламент — Дәүләт думасы барлыкка килә. Русия мең еллык тарихында беренче мәртәбә конституцион идарәне кабул итә. Дума сайлауларына кадәр үк Русиядә башта яшерен, соңыннан ачыктан-ачык бер шәкелдә сәяси партияләр төзелә. Югарыда әйтеп үткәнебезчә, Гаяз Исхакый да «Шәкертлек» исемле яшерен оешмасын киңәйтеп, программасын хәзерләп, «Хөррият» исемле бер сәяси оешма мәйданга китерә. Думага сайлаулар башлангач, Г. Исхакый якын дуслары — татар дин галиме, Оренбурда чыга торган «Вакыт» газите мөхәррире Риза Фәхретдин углы Габдрахман, адвокат Фуат Туктаров, адвокат Шакир Мөхәммәдьяр һәм химик Мәхмүт Алмай белән берлектә «Хөррият» оешмасын тагын да киңәйтеп, социализм рухында «Таңчы» исемле бер партия дә оештыра. Урыс революцион социалистлар партиясенең татар җирлегенә туры килгән статьяларын «Хөррият» партиясе программасына өстәгән мөстәкыйль татар социалистлар партиясе «Таңчылар» хәленә килә. Исхакый җитәкчелегендә төзелгән «Таңчылар» партиясе чынлыкта социалистлар партиясе була. Ләкин бу партия Карл Маркснең интернационализмын, сыйнфый көрәш принципларын һәм террорны кискен бер рәвештә кире кага. «Таңчылар» партиясенең нигезе һәм төп максаты, социаль, экономик һәм сәяси яктан изелгән төрек-татар халкының хокукын даулау һәм социаль мәнфәгатьләрен яклаудан гыйбарәт иде. Фин һәм поляк социалист партияләре Русиядән аерылып, мөстәкыйль дәүләтләр төзү максатына омтыла, ә Исхакыйның «Таңчылар» партиясе Русиядә җөмһүрият төзү һәм ул җөмһүрият эчендә татарларга һәм гомумән бөтен Русия мөселманнарына урыслар белән тигез хокук яулау өчен көрәшкә баса. Татар халкы арасында «Таңчылар» партиясе зур дәрәҗә казана, чөнки ул социаль, экономик

һәм сәяси таләпләре белән халыкны рухи һәм матди яктан алга җибәрү максатын куя.

1906 елда булган сайлаулардан соң Русия мөселманнары Дәүләт думасына 38 депутат сайлауга ирешә. Икенче Думада 45 мөселман депутаты була. Алар аерым төркем төзи. Болардан 14 е Исхакый җитәкчелегендәге «Таңчылар» партиясенә карый. Алар барысыннан да элек җир реформасы уздырылуын алга сөрә һәм эшчеләргә социаль страхование кертелүен таләп итә. Думадагы урыс, поляк, фин һәм украин депутатлары тагын да зуррак таләпләр белдергәнгә, 1907 елда министр Столыпин Икенче Думаны куып тарата һәм депутатларны кулга алдыра. Шул ук елда яңа сайлаулар үткәрелә, әмма бу юлы мөселман депутатлар саны 10 га гына кала. Таңчылар партиясе һәм аның юлбашчысы Г. Исхакый режимга каршы хәрәкәт итүдә һәм революция хәзерләүдә гаепләнә һәм, алда язылганча, ерак төньяктагы Архангельск өлкәсенә сөргенгә җибәрелә.

Г. Исхакый Беренче дөнья сугышында Русиянең җиңелүен тели. Ниһаять, көтелгән көн килеп җитә. 1917 елның февраль аенда демократик революция була. 365 еллык ачы әсирлек чорыннан соң иркен сулыш ала башлаган төрек-татарлар, бу уңайлы хәлдән файдаланып, башта милли-мәдәни, аннан соң милли-сәяси һәм тулы бәйсезлек өчен көрәшләрен көчәйтә.

Февраль революциясеннән соң патша тәхеттән ваз кичә һәм вакытлы хөкүмәт төзелә. Вакытлы хөкүмәт Русиянең төрле районнарында барлыкка китерелгән мөселман комитетларының һәм сәяси партияләрнең лидерлары белән бәйләнешкә керә. 1917 елның 14 маенда Мәскәүдә Русия мөселманнарының Беренче гомуми корылтае җыела. Г. Исхакый ул корылтайның җыелуында зур роль уйнаганга, корылтайга катнашкан 900 кеше тарафыннан президиумга сайлана. Корылтай башланганнан соң, Вакытлы хөкүмәт вәкиле буларак котлау сүзе белән чыккан профессор Котляревский, мөселманнарның мәгариф, социаль проблемаларыннан һәм аграр реформадан бигрәк, дини темаларга һәм Русиянең киләчәктә дә бүленмәс бербөтен буларак калуының мөһимлегенә тукталa. Мәскәү Корылтае президиумы әгъзасы Гаяз Исхакый, Вакытлы хөкүмәт вәкиле Котляревскийның чыгышына җавап сүзендә: «Профессор Котляревский Русия мөселманнарының кайгысы бары тик дини мәсьәләләрдән генә гыйбарәт булып кала дип ышанып, бик нык ялгыша. Русия мөселманнары бу ялгышны төзәтү юлында бер төрле хәрәкәттән дә тайчанмаска, кирәкле чараларны кулланырга тиешләр»,— ди. Мәскәү корылтае 11 көнгә сузыла, карарлар кабул иткәндә Исхакый бик зур активлык күрсәтә.

1917 елның июль аенда Казанда Русия мөселманнарының өч корылтае булып уза: Бөтен Русия мөселманнарының Икенче гомум корылтае, Хәрби Шура корылтае, Дин галимнәре корылтае. Саналып үткән өч корылтай тарафыннан уртак бер карар кабул ителә. Ул карарга нигезләнеп, «Эчке Русия мөселман төрек-татарларның милли-мәдәни мохтарияте» игълан ителә. Г. Исхакый мохтарият игълан ителүдә зур роль уйный һәм бу юлы социализм фикереннән бигрәк Русия эчендә төрек-татарларның милли берлек фикерен яклый. 1917 елда мохтарият игълан ителгәннән соң, Г. Исхакый Русия мөселманнарының үзәк совет әгъзасы булып Петербурга китә һәм анда Вакытлы хөкүмәт әгъзалары белән күрешә. Очрашудагы төп тема Оештыру мәҗлесен хәзерләү һәм шул ук вакытта Уфада Идел-Урал төрек-татарларының милләт мәҗлесенә булачак сайлаулар мәсьәләсен тикшерү була. Очрашулар уңышлы тәмамлана һәм Исхакый аннан Казанга кайта. Казан татарлары милли язучы, мөхәррир һәм сәяси юлбашчыны борынгы төрки йола буенча ипи-тоз белән, бөек каһарманга лаек бер ихтирам һәм ярату белән каршы ала. Казанда милли төрек-татар җөмһүриятенең нигезләре төзелә башлый. Гаяз Исхакый 1905 елда Нижний Новгородта, Ука елгасында, пароход палубасында җыелган мөселманнар корылтаенда «Таңчылар» партиясенең юлбашчысы рәвешендә мөселман иттифакы (партиясе) белән бер фикергә килә алмаган була. Әмма 12 ел үткәч, Исхакый элекке «дошманнары» белән уртак тел табу мөмкинлегенә ирешә һәм шулай итеп, төрек-татар халкы арасында аның дан-шөһрәте тагын да арта.

1917 елның ноябрь аенда Уфада төрек-татарларның Милләт Мәҗлесе җыела. Өч министрлык белән ике комитеттан гыйбарәт Милли Идарә исемле Идел-Урал хөкүмәте төзелә. Әгәр Идел-Урал дәүләте тулысынча мөстәкыйльлеккә ирешсә, Исхакый аның тышкы эшләр министры булачак иде.

Төрек-татар халкы Идел-Урал Милли Идарәсен төзү белән мәшгуль булганда, большевик революциясе кабынып китә һәм Русиядә эчке сугыш башлана. Бер яктан ак урыслар, икенче яктан Ленин җитәкчелегендә тупланган һәм тора-бара көчәйгән коммунистлар Идел-Урал өлкәсен юк итү максаты белән башланган

көрәшләрендә берләшә, ягъни үзара дошман ак урыслар белән Большевиклар Идел-Урал идарәсен юкка чыгару өчен бер фронт кора. Яшь Идел-Урал Милли Идарәсе ике дошман арасында кысылып калуына карамастан, көрәштән ваз кичми. Биш полктан гыйбарәт булган Милли гаскәр инде күптәннән бирле Исхакый тарафыннан алга сөрелгән «Корбансыз бәйрәм булмый» принцибыннан илһам, Алтын Урда тарихыннан үрнәк алып, ике фронтта сугышка керә. Әмма ялгыз башы калганга, өстен дошман көчләре каршысында авыр югалтуларга дучар булып җиңелә. Шулай итеп, Идел-Урал өлкәсе урыс коммунистлары тарафыннан буйсындырыла. Милли Идарәнең, ягъни мохтар Идел-Урал хөкүмәтенең әгъзалары, шул исәптән Исхакый да, урыс большевиклары тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителә. Әмма Исхакый һәм аның берничә иптәше, форсат табып, Ерак Көнчыгыш юлыннан Солых конференциясендә катнашу максаты белән Аурупага китә.

Исхакый, Аурупада берничә ел калганнан соң, Төркиягә килә. Әмма тумыштан ук юлбашчы идеалист көрәшче булган Исхакый, ул заманда Төркиядә эш өчен уңайлы тирәлек таба алмый. Шуңа күрә, читтә таяныч булдыру максаты белән Варшавага китә һәм 1928 елда иптәшләре белән берлектә Идел-Урал бәйсезлек комитетын төзи.

Аның уставының 1 нче маддәсендә: «Комитетның төп максаты — Идел-Урал бәйсезлеген яклап ахыргача көрәшү»,— диелгән. 10 нчы маддәсендә исә: «Төркия җөмһүриятенең яшәвенә һәм бәйсезлегенә каршы булганнар: Идел-Урал, Төркестан, Кырым, Әзербайҗан һәм Төньяк Кавказның бәйсезлек дәгъвасына зарар китерергә тырышучылар, төрки берлеккә каршы тар кабиләчелек хәрәкәтләре оештыручылар, гомуми төркилеккә зыян китерүче оешмаларга әгъза булып торучылар президиум карары белән комитет әгъзалыгыннан чыгарылачак»,— диелә.

Идел-Урал бәйсезлек комитетының Төркестан, Әзербайҗан, Кырым һәм Төньяк Кавказия комитетлары белән тыгыз берлектә җитди эш алып баруы, империалист Совет хөкүмәте тарафдарларының игътибарын артыгы белән җәлеп итте. Мәсәлән, мәрхүм якташым һәм фикердәшем Хәмит Рәшит 1955 елда Истанбулда Исхакыйның якты истәлегенә багышлап чыгарылган китапчыкта: «Мирсәет Солтангалиев хәрәкәте мәйданга чыгарылганнан соң, Казанда басылган «Чаян» журналында урнаштырылган бер мәкаләдә, Мирсәет Солтангалиев тарафыннан төзелгән Туран хөкүмәтендә Гаяз Исхакый тышкы эшләр министры вазифасын алырга хәзерләнде», дип хәбәр ителә. Бу язудан аңлашылганча, Исхакыйның эшләгән эшләре Советлар берлегендә көчле кайтаваз барлыкка китергән.

30 нчы елда Варшавада Идел-Урал, Төркестан, Әзербайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия һәм Көнчыгыш Карелия вәкилләрен эченә алган бер блок барлыкка килде. Польша хөкүмәтенең ярдәме белән төзелгән бу блокка Прометей исеме бирелде. Милләтче-халыкчы юлбашчы Г. Исхакый Идел-Урал бәйсезлек комитетында да, Прометей блогында да бөтен күңелен биреп, 1939 елга кадәр өзлексез тырышып хезмәт итте.

Татар халкының тугрылыклы улы Гаяз Исхакый 1933 елда Ерак Көнчыгыш илләрендә таралган хәлдә яшәгән төрки-татарлар янына бара. Анда Идел-Урал төрек-татарларының милли мәдәният мәркәзен төзи. Аның бу эшләре, һичшиксез, үз нәтиҗәсен бирә. Бу уңышка ачуы килгән ак һәм кызыл урыслар берләшеп, 1934 елның 11 февралендә Токиода җыелган конгрессны тарату, һәм хәтта Гаяз Исхакыйны үтерү максаты белән урыс полковнигы Порутиковның командалыгында хәрәкәт итсәләр дә, япон полициясенең килеп житүе һәм хәзерге көндә Истанбулда яшәүче ике татар хатынының фидакярлеге аркасында гына чигенергә мәҗбүр булалар. Аңлашылганча, Совет хөкүмәте белән мөһаҗир урыс оешмалары идеологик караштан бер-берләренә кан дошманы булса да, урыс булмаган милләтләрнең мәдәни бәйсезлек хәрәкәтенә каршы берләшә иде. Полковник Порутиковның бер үк вакытта Совет агенты да булганлыгы соңыннан аңлашылды. Гаяз Исхакый, Ерак Көнчыгышта яшәгән татарларның милли мәдәният мәркәзен төзегәннән соң, 1936 елда кабат Аурупага кайта.

1933 елда Г. Исхакый, Идел-Урал бәйсезлек комитетының төп принципларын һәм татар халкының кыскача тарихын аңлаткан «Идел-Урал» исемле бер китап яза һәм аны урыс, поляк һәм француз телләренә тәрҗемә иттерә. 1939 елның сентябрь аенда Икенче дөнья сугышы кабынгач, Исхакый Варшавадан китә. Моннан соң бераз вакыт Лондон һәм Парижда яшәп, 1940 елның уртасында Төркиягә килә.

Икенче дөнья сугышының беренче елларында нацистлар аңа үзләре белән эш алып барырга тәкъдим итсәләр дә, Исхакый бу тәкъдимнәрен катгый рәвештә

кире какты. Моның белән бәйле бер вакыйганы искә төшереп үтәргә телим. 1942 елның эссе бер июль көнендә, Исхакый мине Истанбулдагы өенә чакырган иде. Киттем. Анда Анкарадагы Германия илчелегеннән ике кеше бар иде. Гаяз Исхакый мине шаһитлек өчен чакырган булса кирәк. Алманлылар сүз башлады. Алар, Германия гаскәре белән берлектә хәрәкәт итәчәк Идел-Урал легионы төзеләчәген хәбәр итеп, Исхакыйны Бәйсезлек комитеты рәисе буларак, легион төзүдә ярдәм итәргә чакырдылар. Гаяз Исхакый бу тәкъдимгә каршы килеп, «1) Идел-Урал дәүләте өчен хокукый гарантия, 2) Корылачак легион өчен хәрәкәт азатлыгы һәм мөстәкыйль команда составы, 3) Идел-Урал Бәйсезлек комитетына мөстәкыйль милли хөкем органын төзү мөмкинлеге бирелү иң әһәмиятле шартлар булып тора»,— дип, үз тәкъдимнәрен алга сөрде. Алманнар киң хокук таләп иткән бу тәкъдимнәр белән килешә алмый иде һәм шул сәбәпле ике арада бернинди дә аңлашу була алмады. Һәм гомумән Гаяз Исхакый алманнарның җиңелүгә дучар булачакларын әле 1939 елда ук әйткән иде.

1942 елда Германиядә корылган Идел-Урал легионында вазифа алган кайберәүләр әйтүенчә, имеш, Исхакый 1943 елда алманнар белән бергә хезмәттәшлек итәргә теләгән, әмма алманнар бу тәкъдимне кире каккан. Бу бертөрле дә мантыйкый нигезе булмаган бер сүз. Әле 1942 елда, алманнар бөтен фронтларда җиңү арты җиңү яулаган бер вакытта, алар белән эш алып барудан ерак торган Гаяз Исхакый, 1943 елда, алманнар Сталинградта җиңелүгә, көньяк фронтта зур югалтуларга дучар булганнан соң, хезмәттәшлек итү уенда ничек булсын икән?

Г. Исхакый Икенче дөнья сугышында алманнар белән берлектә урысларның да җиңеләчәкләренә инанган иде. Әгәр америкалылар һәм японнар зур тарихи хаталар ясамаган булса, Икенче дөнья сугышы без теләгән рәвештә тәмамланачак иде. Аңа да карамастан, дөньяда һичбер самодержавие режимының мәңгелек булмавы хакында чынбарлыкны онытмаган Исхакый, үзеннән соң килгән буынга васыять итеп, үлеменә өч көн калгач, шушы юлларны язучыга әйтеп торып, Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәгән мәрхүм имам Хәбибрахман Шакирга (Болгарый) бер хат яздырды. Ул хатның эчтәлеге белән биредә сезне дә таныштырабыз.

*Анкара, 1954 ел, 19 июль.*

**Хөрмәтле Хәбибрахман хәзрәт!**

**Мин 26 майдан бирле Анкарада. Бераз вакыт хастаханәдә яттым. Инде кызымда яшим. Аллага мең шөкерләр булсын, кызым һәм киявем мине бик яхшы карыйлар. Алардан бик ризамын. Минем хәлем бер дә яхшы түгел. Аягымның шешләре үземне идарә итәргә комачау итә. Шуңа күрә минем саулыгымның яхшы булуы турындагы хәбәрләргә ышанмагыз. Бер могҗиза булмаса, сулар сулышым бу айда, бәлки дә бу атнада киселәчәк. Мин дә гөнаһлы башымны Алла рәхмәтенә сонначакмын. Мин мөселман ата-анадан тудым һәм мөселманча тәрбия алдым. Кануни караштан мин төркимен. Һичбер төрки кавемгә дошманлык эшләмичә, бөтен гомерем буе үземнең халкым — төрки-татар халкының уңышы һәм бәхете өчен хезмәт иттем. Бу эшләрне эшләгәндә һичбер төрки кавемгә зарар китермәдем. Әгәр минем хаталарым булган икән, кардәшләрем мине гафу итсеннәр, хакларыны халәл итсеннәр. Үз арабыздагы татарлык, башкортлык, мишәрлек һәм нугайлык юлларына кермәдем. Кулымнан килгәнчә, тар кабиләчелектән качтым. Минем фикеремчә, Татарстан белән Башкортстанны бер-берләреннән аеру да һәммәсен җыеп берләштерәчәк Идел-Урал Милли Идарәсен юк итү өчен уйлап чыгарылган Совет шәйтанлыгыннан башка бер нәрсә дә түгел. Минем ышануымча, Совет буйсындыруы астында изаланган 40 миллион төркинең киләчәктә сәяси яктан конфедерация шәкелендә берләшүе, ул да булмаса, уртак мәдәни берлекне югалтмыйча, ягъни уртак мәдәниятккә ия буларак, Аурупа Берлегенә тигез хокукта керүе, Аурупа Берлеге гаиләсендә дәрәҗәле урын алуы иң дөрес юл булачак. Тәңре сезләргә барлыклы тормыш итүне һәм Ватаныбыз Идел-Уралның азат булуын күрүне насыйп итсен, дигән догада калам. Мәхәлләнең бөтен кешеләренә, берсен дә аермыйча, соңгы сәламнәремне җибәрәм.**

**Ихтирам белән** *Гаяз Исхакый.*

**Өстәмә: Бу хатны Галиулла Акыш исемле миллиятче яшь егет язды, чөнки үземдә хат язарлык көч юк. Язылганнарны минем фикерем итеп кабул итегез. Гали Акыш — минем иң ышанычлы ярдәмчем.**

**Сәламнәр белән** *Г. Исхакый.*

Бу хат язылып өч көн үткәннән соң, Гаяз Исхакый мәңгелек дөньяга күчте.

Мәрхүм юлбашчы Г. Исхакыйның бу васыять хаты ничектер совет матбугатына да үтеп кергән һәм табигый ки, үзләренчә ялтыртылган. Мәсәлән, татар совет философы Камил Фасиев 1971 елда Казанда рус телендә басылган «На путях пролетарского интернационализма» исемле хезмәтенең 250 нче битендә болай дип яза: «Гаяз Исхакый 1954 елның 19 июлендә үлем түшәгендә ятканда яздырган бер хаты белән, Гали Акышка, урыс хакимиятендә яшәгән 40 млн. төркине мөстәкыйль сәяси берләштерүне тормышка ашыру вазифасын тапшыра.» Бу җөмләдән аңлашылганча, Совет хөкүмәте һәм аны яклаучылар һәртөрле чаралардан файдаланып, чит илләрдә яшәгән актив миллиятче көрәшчеләрнең шәхси хатларын да кулга төшереп, аларны бозып күрсәтеп, үз максатларында кулланырга тырышкан. Икенче яктан, мондый эшләре белән, Совет хөкүмәте идарәчеләре чит илләрдәге урыс булмаган милләтләрнең азатлык хәрәкәтен дәвам итүләренә кайгыруларын ачык күрсәтә. Чынлап та, Гаяз Исхакый тарафыннан башланган Идел-Урал азатлык хәрәкәте һәм 1953 елда аның да катнашы белән барлыкка килгән «Париж блогы»ның хәрәкәте дәвам итә. 1930 һәм 1939 еллар арасында, Варшавада эшчәнлек күрсәткән «Прометей» фронтының дәвамы булып саналган Париж блогы бик авыр шартларда да кыю көрәшә, урыс булмаган милләтләр өчен үзбилгеләнү хокукының табигый хокук булуы турында бөтен дөньяга хәбәр сала, изге дәгъвадан ваз кичмичә яшәвен дәвам итә.

Әдип, матбугатчы һәм сәясәт көрәшчесе Гаяз Исхакый моннан йөз ел элек туган. Минем бу язмамны да эченә алган аны искә алу китабының басылуы кеше кадерен белү билгесе булачагына инанам. Әйе, Исхакый үз халкы — төрек-татар халкының бәхете һәм үсеше өчен 60 ел буе армый-талмый хезмәт итте һәм тирән бер тарихи эз калдырды. Без, ягъни азат илләрдә яшәгән бәхтиярләр, үз бөекләребезне искә алу һәм аларга багышланган китаплар чыгару мөмкинлегенә иябез... Совет хакимиятчеләре Исхакыйны «буржуаз миллиятче һәм капиталистлар ялчысы» дип телгә ала. Югыйсә, югарыда да әйткәнебезчә, Гаяз Исхакый яшьлегендә социалист иде һәм гомеренең соңына кадәр халыкчы һәм социаль хокукны яклаучы идеалист бер кеше булып калды. Исхакый марксизмны инкяр итүе, сыйнфый көрәшне кабул итмәве һәм урыс мәдәниятенең өстенлеге шовинистик фаразына каршы торуы өчен, урыс империализмын тормышка ашыручы Совет идарәчеләре һәм алар яклылар карашынча, Совет режимының рәхимсез дошманы санала. Бу чынбарлыкны милләтебезнең яшь буыны яхшы белергә тиеш. Бу мөнәсәбәттә, мәрхүм Гаяз Исхакыйны яшь буынга таныту — иң изге бурычыбыз. Шуның белән бергә, Төркестанның бөек юлбашчысы Мостафа Чокай углын, Кырымның бөек улы Җафәр Сәйдәхмәтне, Әзәрбайҗанның мәшһүр лидерлары Мөхәммәт Әмин, Рәсүлзадә, Мирза Бала һәм Ваһап Йортсоярне, Көнчыгыш Төркестанның бөек лидеры Әмир Буграны искә алу һәм алардан үрнәк алу кирәклеген яклау да — изге бурычыбыз.

Һичбер золым мәңгелек булмаган кебек, Совет империализмы да җимереләчәк. Мәсәлән, урыс революциясе баласы, урыс тарихчысы Андрей Амалрик, 1969 елда язган «Советлар Союзы 1984 елга кадәр яши алачакмы?» исемле әсәрендә, урыс императорлыгы бүлгәләнәчәк, дигән фикерне ышандырырлык тарихи дәлилләргә таянып, ачык итеп әйтә. Бөекләребез тыныч ятсын, димәк, Русия империализмы бу йөз елның ахырына таба көчен югалтачак.

Безнең бурыч, бездән алда килгәннәрдән милли хәрәкәт байрагын кабул итеп алганыбыз кебек, бездән соң килгән буынга ул изге байрагыбызны тапшырудан гыйбарәт.

Владимир Гордлевский

# МӨХӘММӘТ ГАЯЗ ИСХАКОВ

Урыс әдәбияты тәэсирендә буын ныгыткан талантлы реалист язучы М. Г. Исхаков 1878 елның 10 февралендә Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылында туа. Атасы авыл имамы була. Малайны яшьли хәреф танырга өйрәтәләр: алтыда ул инде тотлыкмыйча Коръән укый. 1889 елда аны Чистай мәдрәсәсенә бирәләр. Өч елдан ул Казанга, Галләм хәзрәт мәдрәсәсенә күчеп килә. Мәдрәсәне тәмамлагач, Исхаков бер ел чамасы мөгаллимлек кыла, аннары Татар учительләр мәктәбенә укырга керә. Казанда Исхаковка китап җене кагыла: сентименталь романнар авторы, төрек язучысы Вәҗиһи әсәрләре белән мавыга; Жюль Верн романнарын кат-кат укый, шул дәвердә үк Лев Толстойның О. С. Лебедева тарафыннан төрекчәгә тәрҗемә ителгән «Гаилә бәхете» белән таныша; урыс телен бу вакытта ул әле җитәрлек дәрәҗәдә белми. Казанда ул беренче мәртәбә театрга бара һәм Антроповның «Адашкан утлар»ын тамаша кыла.

1897 елда беренче әсәрен яза — «Тәгаллемдә сәгадәт»тә белем алуның бәхет китерүен гәүдәләндерә.

М. Г. Исхаков театр өчен дә яза. Аның беренче пьесасы «Өч хатын берлә тормыш» була. Әсәрне ул болай иҗат итә: Казанда спектакль куюу уе белән янган публицист Заһид Шамил татар (учительләр) мәктәбе укучылары С. Максудов һәм М. Г. Исхаковка пьеса язуны үтенеп мөрәҗәгать итә. Пьесасы өчен сюжетне Исхаков тормыштa булган бер вакыйгадан ала.

Хатын-кызлар көнкүреше һәм рухи халәте белән Исхаков балачагыннан ук таныш. Анасының ахирәт тутакае аларга килгән саен ачы язмышыннан зарлана. Исхаковның анасы, остазбикә буларак, авылда ихтирам ителә, аның белән киңәш-табыш кылырга килгән хатын-кызлар бусагадан бер дә өзелеп тормый. Табын янында алар чәй эчә-эчә күңел бушатканда, самавыр артына поскан малай мыштым гына гәпләргә колак салып утыра.

Халык тормышына тоташып, М. Г. Исхаков халыкның сөйләм телен әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрүгә ирешә һәм «татар әдәби теленең атасы» дигән ат казана.

М. Г. Исхаков хикәяләрендә, романнарында һәм драмаларында татар гаиләсе һәм иҗтимагый тормышындагы кимчелекләрне камчылый, хатын-кыз хәлен, руханилар әһәмиятен һәм бүтән үткен мәсьәләләрне чагылдыра. Әсәрләрендә төп аһәң — җиңелчә яки әче көлү, мыскыл итү.

Мондый алым Исхаковның гәзит мәкаләләрендә аеруча ачык гәүдәләнә. Публицист буларак ул татарлар арасында беренче урынны тота. 1905—1906 елларда социаль рухлы «Таң», «Таң йолдызы» гәзитләрен нәшер итә. Әмма тиздән моның әҗерен татырга туры килә — М. Г. Исхаков тормышында ирекле һәм ирексез каңгырап йөрүләр дәвере башлана. 1913 елның көзендә Архангельск сөргененнән кайтарылгач, ул Петербургта «Ил» гәзитенә нигез сала, анда инде ул кыю рәвештә халык ихтыяҗларын сүрәтли. Социалист халык мәнфәгатьләрен эзлекле яклаучыг әверелә.

Үзенең тануынча, аңа урыс язучыларыннан Тургенев һәм Л. Толстой; чит илнекеләрдән — Кнут Һамсун, Мопассан һәм О. Уайлд күбрәк йогынты ясый.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Инде хәбәр иткәнебезчә, 1994 елның май аенда Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды җыелырга тиеш. Шул уңайдан редакция язучыларга берничә сорау белән мөрәҗәгать итте:

***1. Язучыларыбызның XI съездтан соң үткән биш елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?***

***2. Әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләрдән Сез канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары ни дәрәҗәдә үтәлде?***

***3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?***

***4. Алда торган съездтан Сез нәрсәләр көтәсез?***

***5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?***

Түбәндә редакциягә килгән җавапларны тәкъдим итәбез.

## Миргазиян Юныс:

1. Татар язучыларының ике съезд арасындагы иҗатларында ике зур уңыш шиксез: халкыбызның тарихын яктыртуга керешү һәм бүгенгенең иң актуаль проблемаларына багышланган публицистик әсәрләр. Бу ике хәрәкәт Язучылар берлеге Өлкә комитеты камчысыннан котылганнан соң барлыкка килде. Өметләнәсе килә, тарихны халыкка җиткерү һәм публицистика киләчәктә дә дәвам итәчәк һәм, әгәр бүгенге көндәге кимчелекләрне җиңә алсак, һичшиксез, ике тармакны да зур уңышлар көтә.

Кимчелекләр нидән гыйбарәт? Тарихи әсәрләргә чыганакларны җентекләп, фәнни өйрәнү җитми. Әсәрләрдә «су», хәтта «сабын күбекләре» күп. Моңа кадәр татарларга геноцид оештыручылар язган «тарих»ның үзен, аның эзләрен юкка чыгарып, Хакыйкый Тарихны тергезү һәм пропагандалау буенча гомуми концепция кирәк.

Публицистикабыз шактый зәгыйфь, тешсез, куркак. Аңа тирәнлек, тиешле анализ җитми. Сәбәбе — татар язучылары арасында чын-чыннан мөстәкыйль фикер йөртүчеләр, яшәешне, көнкүрешне социология, социаль психология ысуллары белән коралланып, фәнгә таянып тасвирлаучылар чиктән тыш аз булып чыкты. Алган белем шулай сай булдымы икән, әллә иҗатны фикер белән, философия белән бәйләү татар әдәбиятының традициясендә булмаганлыктанмы? Бу мәсьәләне махсус өйрәнәсе бар.

Тарихи әсәр иҗат итә алган барлык татар язучыларының уңышлары бәхәссез, әмма тарихның мөгезеннән эләктереп тота алган ике язучы мине горурландыра: «Шәҗәрә» иҗат итә алган Нурихан Фәттах һәм Болгар белән Алтын Урда хакыйкатен халкыбызга җиткерә алган әдибебез — Равил Фәхретдинов. Равилнең татар әдәбиятына керткән өлешен күрә һәм аңлый алмаган берләшмәне тәнкыйтьләп тә булмый, чөнки бу кара сакал булып безнең язмышыбызга береккән фаҗига.

Публицистика өлкәсендә нәкъ шул ук хәл. Татар публицистикасын әле шушы көнгә кадәр беркайчан да ирешелмәгән иң югары ноктага, дөнья әдәби-

ятындагы иң мәшһүр публицистлар белән мәйдан тотарлык дәрәҗәгә ирештергән Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов берләшмәбезнең әгъзасы да түгел, аның турында матбугатта да бер җөмлә әйтелмәгән. Ә бит аның иҗаты филология һәм журналистика факультетларында җентекләп өйрәнелергә, Борһанов тәҗрибәсенә таянып киләчәк өчен публицист кадрлар әзерләнергә тиеш иде.

Аерым әсәрләргә карата булган фикерләремне монда әйтмәү яхшырак булыр дип уйлыйм. Ни өчен? Татар әдәбиятында ак тәнкыйтьне кара тәнкыйтьтән аера белү критерие өлгермәгән әле. Шуңа күрә, каләмдәшеңнең иҗатына карата әйтелгән бер кәлимә сүз газаплы рәнҗү, гауга, итәк астыннан ут йөртүләр уята. Бүгенге көнгә кадәр матбугатта күбрәк комплиментар тәнкыйть яшәп килде. Ул әле озак яшәячәк.

2. Язучылар берлегенең эше турында берни әйтә алмыйм. Кемнеңдер кодрәте әдәби басмаларны искиткеч авыр шартларда газета һәм журналлар басылуны, китап чыгаруны саклап кала алды. Менә шушы эш кенә дә зур ихтирамга лаеклы. Матбугатның кимчелекләренә килсәк, бу инде мәңге яшь һәм яшәвен дәвам итәчәк проблема: халтураның талантган көчлерәк булуы һәм һәр очракта халтураның талантны җиңеп чыгуы.

Үткән XI съездның карарлары ничек үтәлгәнен беләсездер. Шул карарларның үтәлешен оештырырга, әдәби процесс белән җитәкчелек итәргә сайланган язучы Мәскәү фетнәләре вакытында актив катнашып вакытын исраф итте. Җитәкченең ярдәмчеләре, урынбасарлары арасында ихтирамга лаеклы шәхесләр дә җитәрлек иде. Ләкин минем утыз елга якын диңгездә күзәтеп йөргәнем бар: әгәр капитан үз вазифасын ярдәмчеләр җилкәсенә ташлый икән, кораб батарга мөмкин...

3. Әдәби фонд бар көчен, эшчәнлеген, тырышлыгын татар язучыларына иҗат йорты салып бирүгә тотарга тиеш. Хөкүмәттән акча сорарга, спонсорлар табарга, язучыларның үзләреннән акча җыярга һәм төзелеш башлангач, һәр язучы күпмедер вакыт төзү эшенә катнашырга тиеш. Татарстан язучыларының иҗат йортлары булса, путевка алышу юлы белән элеккеге СССР җирендәге теләсә кайсы иҗат йортына барып булачак. Татлы хыял бит, әй!

4. Күпне көтмим. Әнә, башкорт язучыларының съезды узды. Үзгәреш булдымы? Бездә дә шулай булачак. Бу ике тугандаш һәм күрше республикаларның галимнәре һәм язучылары арасында бәхәс барса да, берлекнең җитәкчеләре, марионетка курчак шикелле, бер җепкә беркетелгән булалар. Эш менә нәрсәдә. Язучылар берлеге дип аталган оешма — ГУЛАГ лагерьлары, НКВДга, соңрак КГБга ялланып эшләүче шымчылар армиясе белән бер анадан, бер вакытта туган оешма. ГУЛАГны тараттылар, КГБның структурасын үзгәрттеләр. Хәтта партия хакимияте дә таратылды. Бер анадан туган балаларның бары тик берсе — күп кенә республикаларда Язучылар берлеге генә исән калды. Бу оешма, структураль берәмлек буларак, идеология чылбырының сыңар боҗрасы гына иде. Белмим, киләчәктә ничек яшь алыр ул?

5. Иҗат берлеге алдында торган иң мөһим чараларның беренчесе — Берлек урынына законга таянып эш итүче, цивилизацияле илләрдәгечә Пен-клуб оештыру. Пен-клуб эшли башлагач, бүгенге көндә Татарстан хөкүмәте биргән дотацияне йотып торучы идарә аппараты, «Волга» машинасы, миллион артыннан миллион йотып торган кабинет биналары, киңәшмәләр үткәрү, җитәкчеләрнең күрше берлекләргә кунакка йөрүе өчен киткән чыгымнары тулысынча татар язучыларының иҗат мохтаҗлыкларына тотыла башлаячак. Татар язучыларына чит ил әдипләре белән аралашу, чит илләрдә китаплар бастыру мөмкинлеге туачак. Әдәбият өлкәсендә Тукай чорындагы Яңарыш кабат җанланып китәчәк.

Миндә донкихотлык чиктән тыш көчле. Шуңа карамастан, алдан әйтә алам: татар язучыларын басып киткән мең тонналы битарафлык Пен-клуб оештыру мәсьәләсен дә сытып үтерәчәк. Бу турыда мин бик күп уйладым, баш ваттым, мәгълүматләр җыйдым. Тик вакытым, көчем, теләкләрем исраф булачак... Нишлисең — без шундый инде...

*Декабрь, 1993 ел,*
*Вавилон.*

## Мөсәгыйт Хәбибуллин:

1. Большевиклар идеологиясенә еллар буе йөз тоту сәбәпле татар язучылары гына түгел, башка тугандаш халыкларның әдипләре дә, тышауланган аяккуллары чишелүгә, уй вә аң-гамьнәре ирек алуга шактый каушап калдылар.

Йөргән юлын, югалткан кыйбласын эзләгән мосафирдай каңгырып калган иҗат кешеләрен әле дә булса күрергә була. Мәгәр шунысы куанычлы: татар язучылары арасында коммунистик идеология коткысыннан арынучылар ишәйгәннән-ишәя бара. Җәбер-золымга йөз тоткан тоталитар совет режимы җимерелүгә, татар әдипләренең күбесе үз кыйбласын эзләргә ташланды. Әмма безнең арада хәтта бүген дә коммунистларның буш идеологиясенә мөкиббән киткән, шушы яман чирдән арына алмый интеккән, шул сәбәпле бер юл да яза алмый йөдәп йөргән, үткәнне сагынып, тансыклап, сагышланып яшәгән әдипләребез бар әле. Ләкин татар язучылары ошбу яман чирдән кыенлык белән булса да арына баралар, аларның әсәрләрендә милли хис, милли аң, милли горурлык кебек татар халкы өчен изге сыйфатлар һаман күбрәк күренә.

2. XI съезд карарларына кабат кайтып карыйсым килми. Ә менә киләчәк Татарстан язучылары җыелышын күрәсем килә. Мин күрәзәче түгел, алдан ни буласын әйтә алмамдыр, гәрчә Татарстан язучылары оешмасы хакында әйтер фикерләрем булса да. Мәгәр бер нәрсәгә иманым камил: дөнья тыныч вә имин булган хәлдә, җыелыштан соң язучыларыбыз яхшы якка таба үзгәрер.

3. Әдәби фонд, нәкъ менә Советлар Союзы таркалгач, без бахырыгыз аркасында Бөтендөнья әдәби фондына әгъза итеп кабул ителде. Гәрчә моның өчен мине Татарстан Язучылар берлеге идарәсе җыелышыннан куып чыгарыр хәлләр булса да. Мин үз вазыйфамны эшләгән идем инде: бүген Татарстан Әдәби фонды рәсми төстә Бөтендөнья әдәби фондында Рәсәй кебек үк тулы хокуклы әгъза булып тора. Шул сәбәпле нииндидер күләмдә финанслана да. Хәзер татар язучыларына бермә-бер күләмдә арзанрак бәһагә үзе теләгән иҗат йортына барып, иҗат итәргә мөмкинлек бар. Рәсәй әдәби фондына йөз тоткан элеккеге бүтән автономияләр исә Рәсәй кул астында калдылар. Аларны Рәсәй Әдәби фондының бер дә җибәрәсе килми. Һәм җибәрмәс тә. Чөнки Рәсәй дәүләте, аның оешмалары өчен бу нәрсә гайре табигый хәл. Шуннан һәркем үзенә нәтиҗә ясасын.

4. Татар язучыларының булачак җыенын ул кадәр атлыгып көтмим. Әдипне Җыен әсәр язарга утырта алмый. Татар халкының бер язучысы буларак, мин бүген алны-артны белми үз халкым өчен иҗат итәм. Гәрчә хезмәтемә нәширләр чамадан тыш аз түләсәләр дә.

5. Берлек ни ул?! Бер сум акчамы янсә бер төрле уйлап, бер табактан ашарга табынга утырган адәмнәрме? Әллә булмаса, бер фикергә килеп, гел бер төрле итеп, бер темага язучылармы? Миңа калса, исеме җисеменә туры килми ләбаса! Без ул чорны мүкәләп булса да үттек түгелме соң инде!.. Бит һәр әдип үзе бер дөнья, үзе бер кабатланмас шәхес. Ул — илаһи галәмнең рухыннан азык алган варис. Минем исә халыкның мәнфәгатен, рухи вә илаһи дөньясын күпкырлы итеп сурәтләгән яңадан-яңа авторларны күрәсем килә — алмашны. Шөкер кылырлык, соңгы елларда татар халкының күркәм сыйфатларын сурәтләгән әсәрләр туа башлады. Җирлекле алар, рухи яктан байлар, күңләшерлек байлар, чөнки кемгә дә сер түгел: татар язучылары Шәрыкъ вә Аурупа тарихын, мәдәниятен һәм әдәбиятын күптән үзләштереп киләләр. Алар шушы байлыкны гамәли әдәби агышка кертеп, энҗе-мәрҗәннәргә әверелдереп, үз халкына күбрәкне бүләк итәр, дигән өмет бар.

5. Тагын бер теләк мондый:

Миңа калса, бүгенге Татарстан Язучылар берлеген тамырдан үзгәртергә кирәк. Хәзерге Союз аппараты гамәли тереклек итүен үзе үк ирекле рәвештә җыелыш сайлаган варисларга тапшырса — әйбәт булыр иде. Ләкин каршылар булуы бар. Чөнки әле искегә ябышып ятучылар бик күп.

Аннан соң болай эшләргә: Язучылар җыелышында сайланган варислар Җыенны кайчан уздыру хакында сөйләшерләр һәм бер фикергә килеп, бүтән язучыларга белдерерләр. Бөтентатар Язучылары берлеге булырмы ул, Җыенымы, Мәҗлесеме, Оешмасымы, Диванымы — мәгәр ул яңа типтагы беренче җыен булыр. Һәрхәлдә, Җыенны 1994 елның беренче яртысыннан да калмый уздыру хәерлерәк булыр иде.

## Рөстәм Кутуй:

1. Язучы — шәхес буларак та, гражданин буларак та иң бәйсез кешедер, мөгаен. Ләкин, шул ук вакытта, ул җиңел яраланучан һәм социаль яктан бөтенләй сакланмаган да. Соңгы биш ел эчендә менә шул хәл бик ачык күзгә ташлана. Әлбәттә, һәрбер яңа тәртипкә бик тиз җайлашучылар да бар. Һәм мондый

шартларда алар үзләренә шактый гына табыш та эшлиләр. Әмма, минем ышануымча, мондыйлар әдәбиятка файда китерми. Чөнки чын әдәбият өчен мондый «хезмәт күрсәтү», ялагайлану вазыйфасы бөтенләй чит, ят нәрсә.

Чын язучылар бишьеллыклар белән яшәми, «съездан съездга хәтле иҗат» дип хисап бирми. Алар — мәңгелек рухи һәм әхлакый кыйммәтләр өчен тир түгә, шулар хакына иҗат утында яна.

Әгәр дә инде соңгы биш елны алсак, бу елларда болгану һәм өметсез ыгы-зыгы гына көчәйде. Язучы ул профессия түгел бит, ә тормышның сыйфаты ул. Менә шул хакыйкатьне без тирәнтен аңласак һәм үзебезгә иман итеп алсак иде. Шул ук вакытта, бу — башкалардан аерылып тору да дигән сүз, чөнки сүз талант турында бара. Биредә инде суррогат белән алдап булмаска тиеш! Без андый адымнардан кискен рәвештә баш тартырга тиеш. Әмма бездә әле коньюнктура бик көчле. Соңгы биш елда менә шул да нык сизелде.

2. Оештыру эше йомшак булды. Яшьләр картаеп киткәнгә ошый. Эшләгән кыяфәт чыгару — эшләмәүдән дә начаррак. Аннан соң иҗатчы шәхес өчен һәртөрле депутатлыклар җимергеч тәэсир ясый бит ул. Данга, дәрәҗәгә омтылу ахыр чиктә начар нәтиҗәгә илтергә мөмкин.

3. Әдәби фондның киләчәгеп мин дәүләт кайгыртуыннан башка күз алдына да китерә алмыйм. Коммерсантлар ярдәм итәргә ашыкмас алар... Ә акчасыз нинди Әдәби фонд инде ул?! Безне бик нык адаштырдылар шикелле. Хәтта басылып чыккан китапларга хәтле кеше кызыктырырдай матур итеп эшләнмәгән бит. Сатып алучы алырга теләмәгәч, менә шунда чылбыр өзелә инде. Ягъни «язучы — нәшрият — сатучы — табыш» дигән чылбыр өзелә.

4. Шулай да мин нәрсәдер көтәм, нәрсәгәдер ышанам әле. Моның кимчелек икәнен белсәм дә, миндә оптимизм бетмәгән әле. Минемчә, якындагы Съезд иҗат берлегебез аппараты турында бер фикер әйтергә тиеш. Ныклап. Һәм безгә нинди иҗат берлеге кирәк булу турында әйтергә кирәк. Ә ахыр чиктә язучылык нәрсә соң ул? Президиумнарда утыру, хакимлек исе килгән бөтен җиргә ашыгу кайберәүләргә бәлки ошыйдыр да, ләкин бит безгә язу, иҗат турында уйлаучылар, шуның өчен тиешле шартлар тудыручылар ныграк кирәк.

5. Дөнья әдәбиятының бөтен үсеш юлы шуны күрсәтә: бик еш битлек алмаштыруга корылган бу фани дөнья тормышына чын язучы кеше җайлашмаган була, шуңа күрә ул чынлап та бәйсез хәлдә иҗат итәргә тиеш.

## Әхәт Гаффар:

1. Татар язучыларының соңгы елларда матбугатта һәм китапларында нәшер ителгән әсәрләренә канәгатьмен. Бүтәнчә була да алмыйдыр инде ул. Чөнки татар язучылары, кулларына каләм тоттылар исә, фәкать үз халкыбыз, милләтебез мәнфәгатен кайгыртып язды. Әлегәчә мин үз әдипләребезнең: «Дөнья начарайсын, бетсен!» дигән нияттән язганнарын белмим. Халык арасында йөргән чакларда да татар язучыларының абруе зур икәнен ишетеп беләм, шуңа сөенәм.

Ахыр килеп, дөнья татар язучылары шундый бер алама чиккә китереп терәде ки, безнең бәгъзеләребез кулларына каләм алудан гаҗиз калды. Халкыбызга бүген үтә кирәкле уй-фикерләребезне гәҗитләрдән җиткерергә ашыктык. Ә шул арада кайберәүләр үзләренең бер көнлек әсәрләре белән дөнья тутырдылар. Тик бу — безнең уртак бәлабез.

Кыскасы, махы бирмәбез, җәмәгать. Тугры, чиста, көр рухлы, эшчән татар халкы бар икән — аның рухи хәзинә сандыгы буш булмас. Уй-ниятләребез, фикерләребез чишмәсе ургудан туктамас. Югыйсә — фаҗига!

2. Әдәби басмалардан — «Казан утлары» журналы, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» гәҗитләре, аларның кече туганнары «Идел», «Мирас» журналлары, үз мәсләкләре, үз маяклары буенча барып, иман, хөрлек, азатлык фикерләре чәчә. Алар халык рәхмәтенә лаек, халык рухына әҗәтле түгел.

Инде «Язучылар берлеге» дигәндәме? Аны бетерергә, авызын томаларга теләүчеләр ишәйде. Яхшы, шартлатып бикләп куйдык, ди. Соң, иптәшләр, әгәр дә халкыбызның рухы — керсез, шәфкатьле, нурлы рухы бар икән, нәкъ менә шул һәм шушы рухның, шул рух сандыгы йозагының ачкычы саналган Язучылар берлеген ничек һәм нинди оят белән кара бәкегә ыргытмак кирәк?

Ә шушы берлек белән идарә итүчеләргә килгәндә — уйлансыннар. Эшне, эш ысулын заманча итү турында уйларга вакыт җитте. Соңарсалар, аларны һичкем гафу итмәстер.

3. Бүгенге җәмгыятьнең иң яклаучысыз калган кешеләре без — язучылар булып чыктык. Кайбер вакытны төннәрен уйлап ятам: мәйтәм, Президентыбызны каршыбызга утыртасы иде дә, киңәшеп бер зарланып утырасы иде...

Адәм хуры: җир йөзендә дип әйтерлек иң имин, иң бай бер төбәк язучыларының, бөтен дөньядан гарык булып беткәннән соң, җаннарыбызны өстәлләргә чыгарып салып сөйләшердәй бер Иҗат йорты юк бит, ә?!

4. Гаделлек һәм тугрылык. Каһарманлык һәм җиңү. Ахыр килеп, без әйткәнчә булыр, Аллаһы теләсә.

5. Язарга, язарга иде. Их, тугарылып бер язасы иде ул!

Ә чаралар — көн, заман кушканча. Тик, бу аралардагы шикелле, мыштым һәм шыпырт кына йөрсәк, безне халкыбыз гына түгел, ә бәлки Тарихыбыз да гафу итмәс.

## Җәмит Рәхимов:

1. Әлбәттә, ике съезд арасында безнең проза сизелерлек үсте. Байтак кына кызыклы әсәрләр күренде. Кайсыбер роман һәм повестьлар тирәсендә хәтта шактый гына сүзләр дә булып алды. Дискуссия дә булып узды. Ләкин, шулай да, күңел нәрсәдәндер канәгать түгел. Сыйфатның тагын да яхшыруын күрәсе килә. Талымсызлык бетсен иде. Ә бәлки соңгы елларда редакцияләргә әдәби әсәрләр дә күп килми торгандыр. Ул чагында берни дә эшләп булмый шул инде...

2. Ике съезд арасында язучылар даирәсендә оештыру эше булмады диярлек. Язучылар үз язмышлары белән күзгә-күз калдырылды. Бигрәк тә язучыларны социаль яктан яклау турында уйлау җитми.

3. Әдәби фонд, һичшиксез, кирәк. Ләкин аның эшен оештыру турында бик ныклап уйлыйсы бар.

4. Оешканлык булсын һәм заманны аңлап эшләүче җитәкчеләр сайлансын. Гомумән, иҗат берлеге иҗади оешмага, эшлекле оешмага әверелсен иде.

5. Чын әдипләр белән язмаучы «язучылар»ны аеру һәм чын язучылар турында чынлап кайгырту кирәк дип саныйм.



**Равил Әмирхан,**

тарих фәннәре кандидаты

# ФАҖИГАЛЕ ЕЛЛАР АВАЗЫ

Безнең кулыбызда Татарстан китап нәшрияты 1993 елда чыгарган күләмле китап. Ул **«Болгар вә Казан төрекләре»** дип атала һәм бөек мәгърифәтче, галим, дин әһеле, философ **Ризаэтдин бине Фәхретдин** тарафыннан язылган. Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче — Әнвәр әфәнде Хәйри. Халкыбызның борынгы чорлардан алып XX гасырның беренче яртысына кадәр булган рухи тарихын барлау һәм өйрәнү юлында әлеге җыентыкның әһәмияте ифрат зур. Ул бүгенге көндә дә күп кенә җәһәтләрдән кыйммәтле чыганак булып тора.

Китапның эчтәлегенә тирәнтен керүне максат итеп куймыйча, без аның иң әһәмиятле бер состав өлешенә — «Болгар вә Казан төрекләре» бүлегенә генә тукталып китәрбез. Олпат тарихчы, үзе инанганча, Болгар һәм Казан төрекләренең дөньяда гомер сөрүләрен түбәндәге дәверләргә бүлә: **1) мөстәкыйль хәлләрендә гомер сөрүләре; 2) татарларга** (Р. Фәхретдин биредә Бату яуларын, монголларны күздә тота.— **Р. Ә.**) **тоткын булып, аларның хакимлекләре астында калулары; 3) урыслар тарафыннан басып алынып, урыс җәбере һәм золымы астында яшәүләре; 4) миссионерларның хакимлекләренә дучар булулары һәм һәртөрле чирканыч чаралар белән чукындырылулары; 5) коммунистлар кул астында юкка чыгулары.**

Мәкаләбезнең максатына муафикъ рәвештә без төп әһәмиятне шушы биш дәвернең дүртенчесенә, ягъни мөселманнарның көчләп чукындырылуына юнәлтербез. Бу бүлекне тулысынча Риза Фәхретдин вариантында тәкъдим иткәнче вөҗдан иреге мәсьәләсенең аерым якларына кыскача тукталып китү урынлы булыр.

Сүзне халкыбыз тарихына, милләтебез тамырларына турыдан-туры мөнәсәбәте булган Алтын Урда, хәтта ки Чыңгыз хан, аның атаклы «Яса»сына бәйле рәвештә башларбыз. Чөнки кайсы гына җәһәттән алсаң да, халкыбызның борынгы чорын бу факторлардан аерып карап булмый. Моны шәрехләп тору артык урын гына алыр иде. Зәки Вәлидигә сүз бирик: «Ул (Чыңгыз хан.— **Р. Ә.**) үзенең борынгы бабаларының динен алмаштырмады, ләкин һәммә дин әһелләрен бер төсле ихтирам итә... иде». (Ә х м ә д - З ә к и  В ә л и д и. Кыскача рәсемле төрек-татар тарихы. Беренче җөзьэ. Казан, 1915, 45 б.). Бу тарихчы янә болай дигән иде: «Чыңгыз вә аның балалары иске диндә, шаманилыкта тордылар [...], дин әһелләренең һәммәсен дә ихтирам иттеләр, һичбер дин әһелен дине өчен кысмадылар». (Шунда ук, 97—98 б. б.) Чыңгыз хан *(каган, кахан, каан,— ягъни иң олуг*

*хан)* үз динен беркемгә дә көчләп такмаган, бернинди мәзһәбне кысмаган булуы белән шөһрәт алган иң бөек хөкемдарларның берсе. Диннәр тигезлеге аның мәшһүр законнар җыентыгы — «Яса»да үзәк урынны тәшкил итә.

Чыңгыздан соң тәхеткә менгән каганнарның һәрберсе бабаларының юлын тоткан, диндә иркенчелек ягыннан барлык Европа миссионерларын таңга калдырган. Мәсәлән, мәшһүр сәяхәтче һәм миссионер Виллем Рубруквис (1293 елда вафат) Чыңгыз ханның оныгы Мәнгу каган алдында төрле дин әһелләренең бертигез дәрәҗәдә гыйбадәт кылуына шаһит була. Бу фактны күренекле урыс тарихчысы С. М. Соловьев тасвирлавында китерәбез. Тәрҗемәсе болай: «Минорит Рубруквис Мәнгу хан алдында башта несториан христианнары руханилары, аннары мөселман муллалары, соңыннан мәҗүси каһиннары *(жрецлары)* дога кылуын үз күзләре белән күрә. Рубруквис хан әмере буенча өч төрле дин — христиан, ислам һәм мәҗүси мәзһәбе руханилары арасында үткәрелгән кызыклы бәхәсне дә тасвирлый. Рубруквис мәҗүси каһинына каршы бәхәстә христианлыкны химая кыла *(яклый)*, соңыннан хан аны үзенә дәштереп болай ди: **«Без, татарлар, бер Аллага ышанабыз, аның белән яшибез һәм дөньядан үтәбез; ләкин кулга төрле бармаклар бирелгән кебек, Алла кешеләргә дә үзләрен коткару өчен төрле юллар биргән: сезгә Алла Китап иңдергән, ә сез аны саламыйсыз; безгә шаманнар биргән, без алар әйткәнчә эшлибез һәм тыныч яшибез».** (С. М. Соловьев. Сочинения. Кн. II. История России с древнейших времен. Т. 3. М., Мысль, 1988, 145 б.).

Хәзер инде урысның икенче бер олуг тарихчысы Н. М. Карамзинны тыңлап карыйк. Чыңгыз хан варисларының дингә иркенчелек мәсьәләсендәге сәясәтен тасвирлап, ул болай ди: «Гөек каган үз хозурында христиан руханиларын тота һәм аларга үзенең чатыры каршында грек чиркәве ысулынча бар халык алдында гыйбадәт кылырга рөхсәт итә». (Н. М. Карамзин. История государства Российского. Т. IV. М., Наука, 1992, 30 б.) Икенче җирдә ул болай дип өсти: «Аларның Канунына килгәндә, болар Аллага, Галәмне Яратучыга табыналар [...] хәер-хаһлык белән дан тоталар һәм үз Иманнарына дүндермиләр». (Шунда ук, 35 б.) Ягъни башка диннәргә юл куялар һәм үз иманнарын көчләп такмыйлар.

Инде Чыңгыз хан империясенең бер өлеше булып хисапланган Җуҗи олысына килик. Нәкъ менә шунда Чыңгызның оныгы Бату соңрак Алтын Урда дип шөһрәт тапкан дәүләткә нигез сала. Олыс *(улус)* хөкемдары булганлыктан, Бату фәкать «хан» исемен йөртә һәм үзәктәге каганнар: Чыңгыз, Үгдәй, Гөек, Мәнгуларга буйсынып эш итә. Дин-дианәткә мөнәсәбәттә шамани мәзһәбендәге Бату тулысы белән Чыңгыз «Яса»сына таянып гамәл кыла, ягъни диннәргә, нинди булуына карамастан, камил иркенлек бирә.

Мәгълүм булганча, барлык урыс язма чыганакларында Бату хан коточкыч бер юлбасар, кан коючы итеп сурәтләнә. Әлбәттә, монда артык күпертү юк. Бу җиһангир кылыч тарткан җирләрдә (сүз башлыча 1237—1242 еллар турында бара) кан елгалар булып ага, шәһәрләр вәйран ителә, гөрләп торган илләр шыксыз сахрага әйләнә. Әмма дин-иман мәсьәләсендә хәтта бу адәм дә традицион хәер-хаһлыкка тап төшерми. Замандашыбыз Л. Н. Гумилев сүзләрен күздән кичерик: «1240 елда Батый Владимир-Волынскийны «сөңге» белән ала, халкын «рәхимсез төстә кыра», ләкин Богородица чиркәве һәм башкалар исән кала, ә кешеләрнең байтагы, соңыннан мәгълүм булганча, урманга качып өлгерә һәм аннары кире кайта». (Л. Н. Гумилев. Древняя Русь и Великая Степь. Т-во Клышников, Комаров и К. М., 1992, 351 б.) Бирелә кылт итеп мөдһиш Иванның 1552 елның 2 октябрендә Казанны алгач, мәчетләрне җимереп, таш өстендә таш калдырмавы искә килеп төшә.

Әле ул гынамы! Итальян сәяхәтчесе, миссионер Плано Карпини 1246 елда Бату хозурында кунак була һәм «вәхши юлбасар» дип хисапланган ханның барлык диннәргә дә гаҗәп дәрәҗәдә лояль *(уңай)* каравына исе китә. С. М. Соловьев бу фактны түбәндәге юллар белән билгеләп үтә: «Бу юл кую канунга нигезләнә: ханның үз гаиләсендә дә христианнар бар; ул грек мәзһәбендәге христиан руханиларын үз хисабына асрый, алар ханның зур чатыры каршында урнашкан чиркәүдә ачыктан-ачык үзләренчә гыйбадәт кыла». (С. М. Соловьев. Күрсәтелгән хезмәт., Т. 4, 154 б.) Баксаң, яулап алган җирләрендә Бату чиркәү-монастырьларны җимерү түгел, Урда башкаласында үзе чиркәү салдырган икән!

Алтын Урданың беренче ханнары Бату, Сартак, Улакчы вафат булганнан соң, тәхеткә Батуның энесе Бүркә күтәрелә (1258). Бу хан ислам динен кабул итә һәм исемен Бәрәкәгә алмаштыра. Бәрәкә хан үрнәгендә аның хатыны Чәчәк, бер тума энесе Тукай Тимер һәм башка татар идарәчеләр катлавы ислам динен кабул

итә. Хәер, бу вакыйга Алтын Урда өчен искитәрлек яңалык булмый. Мәмләкәт халкының шактый өлеше (мәсәлән, Идел Болгарстаны X йөздән) электән үк ислам динен тотып килә. Ләкин хөкемдарлары һәм идарәче даирәләре (бигрәк тә Үзбәк хан дәверендә) Мөхәммәт Галәйһиссәлам динен кабул иткәч кенә Дәште Кыпчак (Алтын Урда, Жүжи олысы) чын мәгънәсендә ислам мәмләкәтенә әйләнә. Югары катлауның ислам кабул итүе мәмләкәт халкының да киң колачта мөселманлашуына житди этәргеч бирә.

Алтын Урда дәүләтенең рәсми дине ислам булып киткәч, ханнарның вөждан ирекe мәсьәләсендә сәясәте үзгәргәнме соң? Бөтен хикмәт тә шунда шул: диннәр тигезлеге ислам дәверендә дә Чыңгыз гасырыннан килгән кануннар белән гарантияләнгән. Объективлык җәһәтеннән мөселманнарга мәхәббәтенең әсәре дә булмаган олуг урыс тарихчысы Н. М. Карамзинның сүзләренә игътибар итик: «Александр (Невский.— **Р. Ә.**) Бәрәкә ханны Итилдәге Сарай шәһәрендә тапты. Батуның бу варисы сәнгатьне һәм гыйлемнәрне ярата, галим-голямага, рәссамнарга мәрхәмәт кыла иде; үзенең Капчак (Кыпчак) башкаласын яңа биналар белән бизәде. Биредә яшәгән русиялеләргә христианнарча гыйбадәт кылырга шундый хөррият бирде ки, митрополит Кирилл (1261 елда) биредә *Сарская* дип исемләнгән махсус Епархия ачты, соңыннан бу Епархиягә Көньяк Переяславль Епископлыгын китереп куштылар». (Н. М. Карамзин. Күрсәтелгән хезмәт. Т. 4, 1992, 54 б.)

Шушы ук фактны Л. Н. Гумилев болай тасвирлый: 1261 елда Сарайда Александр Невский һәм монгол ханнары Бәрәкә һәм Мәнгу-Тимернең тырышлыгы белән православие епископы чиркәве ачыла. Ул бернинди эзәрлекләүләргә дә дучар ителми: Сарский епископы Русьнең һәм бөек хан сарае каршындагы барлык урыс кешеләренең мәнфәгатьләрен күздә тотучы, яклаучы булып хисаплана». (Л. Н. Гумилев. От Руси к России. Очерки этнической истории. М., Экопрос, 1992, 133 б.)

Моны инде Россия империясе башкаласы Мәскәүдә бөтен мәмләкәт мөселманнары өчен мөфтият оештыру белән генә тиңләргә мөмкиндер.

Шушы ук җәһәттән С. М. Соловьевның да бик әһәмиятле нәтиҗәсен китерү урынлы булыр: «Татарларның төрле диннәргә хәер-хаһлыгының икенче бер нәтиҗәсе шунда, Сарайның үзендә, ханнар башкаласында, урыс митрополитына буйсынган православие епископлыгы кафедрасы оештырыла; 1261 елда Кирилл Сарайга епископ итеп Митрофанны куя; 1279 еллар тирәсенә караган бер хәбәрдә без Сарай епископы Феогностның Царь-градтан өченче мәртәбә урап кайтуын очратабыз. Аны анда патриарх һәм императорга хатлар һәм бүләкләр белән митрополит Кирилл һәм хан Мәнгу-Тимер юллаган була. Әлеге хәбәр Сарай епископының христиан көнчыгышы өчен нинди әһәмияткә ия булуын күрсәтүе белән гыйбрәтле». (С. М. Соловьев. Күрсәтелгән хезмәт. Т. 3., 145 б.) Икенче төрле әйткәндә, Алтын Урда башкаласындагы православие руханилары вөждан ирекe сәясәтенең бөтен нигъмәтләреннән авыз итә.

Урыс чыганакларында Алтын Урда дәвере православиесенең гаҗәеп уңай шартларда яшәвен күрсәткән материалларының иге-чиге юк. Революциягә кадәрге Русия тарихы буенча бик күп китаплар, дәреслекләр иҗат иткән атаклы профессор С. Ф. Платонов та моны кат-кат искәртә. Аерым алганда, ул менә нәрсә ди: «Әмма шуны истә тотарга кирәк, татар изүенең беренче дәверендә дә Русьтагы чиркәви һәм сәяси төзелеш үзгәрешсез калды. Татарлар Русьны үзләренең «олыс»лары, ягъни үз биләмәләре дип атады; ләкин алар бу олыста аның иске тәртипләренә кагылмады. **Урыс иманына һәм урыс руханиларына, гомумән, барлык башка диннәргә, рухи вәкилләренә караган кебек үк, аларга хәер-хаһлык һәм хөрмәт саклады.** (Ассызык безнеке.— **Р. Ә.**) Урыс митрополиты үзенең чиркәү кешеләре белән татарлар файдасына булган салымыннан, башка төр түләү һәм йомыш-йолымнардан азат ителгән иде. Урыс чиркәве ханнардан руханиларның хокукларын тәэмин итә торган махсус уңайлык ярлыклары алып торды». (С. Ф. Платонов. Учебник Русской истории для средней школы. С.-П., 1913, 87 б.) Урыс профессорына дәгъва белдерү, мөгаен, урынсыз булыр иде.

Әмма, безгә калса, татар хакимлеге чорында православиенең оҗмах шартларында яшәве турында иң үтемле фикерне әлеге дә баягы Н. М. Карамзин әйткән. Башта ул Русьнең, урыс кенәзләренең гомумән мөстәкыйль яшәүләрен, үз халкыннан Урда өчен дигән булып күпләп салым җыюларын, бу керемне, ханнарны алдап, үз мәнфәгатьләре өчен файдалануларын икърар итә, хәтта Мәскәүнең үсеп, күтәрелеп китүен дә Алтын Урда хөкемдарларының сәясәте белән бәйли: «Ханнар фәкать *ерактан* гына (биредә һәм алдагы очракларда

курсив Карамзинныкы.— **Р. Ә.**) безнең хакимнәребез булып торырга теләде, гражданлык эшләренә катышмады, кенәзләрдән бары тик көмеш һәм буйсынуны гына таләп иттеләр... *Татар изүе боек кенәз казнасын* кеше саны алу ысулы белән, монарчы билгеле булмаган, хан өчен дигән сылтау белән җыелган, ләкин кенәзләрнең хәйләләре аркасында аларның үз керемена әйләнгән төрле салымнар белән баетты... Мәскәү үзенең бөеклеге белән ханнарга бурычлы». (Н. М. Карамзин. Күрсәтелгән хезмәт. Т. V. М., Наука, 202, 206, 208 б. б.) Аннары тарихчы православие чиркәвенең һәм руханиларының нинди зур өстенлекләр һәм яклау актлары белән файдалануын санап китә. Кайбер икърарлар чыннан да шаккаттыргыч: «Татарның Русия өстеннән хакимлегенең янә бер күренекле нәтиҗәсе — безнең руханиларыбызның күтәрелүе, монахларның һәм чиркәү биләмәләренең ишәюе булды. Ханнарның сәясәте халыкны һәм кенәзләрне кысты, әмма чиркәүгә һәм аның әһелләренә ригая кылды, аларга аерым бер игелек күрсәтеп килде; митрополитларны һәм епископларны иркәләде; аларның көндәм төстә дога кылуларына мәрхәмәт кылды һәм еш кына пастырьларына хөрмәт йөзеннән мәхәллә халкына булган ачуын шәфкатькә алыштырды. Без инде митрополит изге Алексийның Урдага махсус гозер белән барып, илне тынычландырганын күргән идек... Ханнар, үлем белән янап, үзләренең буйсынучыларына керем, күчмә һәм күчмә булмаган мөлкәтләр белән баеый килгән монастырьларны талауны, борчуны тыйдылар». (Шунда ук, 208 б.)

Христиан чиркәвенә, православие әһелләренә, урыс халкының иманына, яшәү һәм гамәл кылуга тулы ирек бирелүнең иң ышанычлы шаһиты шул, Алтын Урда дәүләте ханнары берсе артыннан берсе митрополит исеменә православиене саклау һәм хөрмәтләү буенча ярлыклар тапшыра. Тарихта татар хөкемдарларының урыс чиркәвенә һәм иманына кылган мәрхәмәтләрнең иң биек ноктасы булган Мәнгу Тимер (1269) һәм Үзбәк хан (1313) ярлыклары безнең көннәргә хәтле килеп җиткән. Аларның эчтәлекләренә киң тукталып тормастан, Үзбәк хан ярлыгының бер-ике урыныннан гына өземтә китерәбез. Бу юллар аерым аңлатуларга мохтаҗ түгел. «Аларның дини кануннарына, чиркәүләренә, монастырьларына золым кылмаска, яманламаска; кем дә кем аларның иманын хурласа яки кимсетсә, ул кеше һичничек гафу кылынмас, бәлки яман үлем белән үтерелер». (Карагыз: Н. М. Карамзин. Күрсәтелгән хезмәт. Т. IV. М., Наука, 1992, 274 б.) Ярлыкта тагын мондый кисәтү дә бар: «Кем дә кем чиркәүнекенә яки митрополитныкына кул сузса, аңа Алланың каһәре төшәр, безнең тарафтан олуг җәза бирелер, ул һич тә гафу кылынмас, яман үлемгә дучар ителер». (Шунда ук.) Кыскасы, берәр мөселман христиан диненә тел тидерсә, чиркәү әһелен берәр ничек кыерсытса, җаны җәһәннәм китәргә тиеш була. Моны хәтеребезгә киртләп куйыйк та, сүзебезне дәвам итик.

Әлбәттә, Русия тарихларында мондый мәрхәмәтле ханнарга мәдхияләр күп. Мәсәлән, урысның иң абруйлы энциклопедиясендә түбәндәге юллар бар: «Үзенең элгәреләре үрнәгендә Үзбәк православие әһелләрен эзәрлекләү түгел, бәлки алар файдасына беренче ханнар биргән һәм мәгълүм Мәнгу-Тимер ярлыгы белән расланган барлык җиңеллекләрне саклый». (Энциклопедический словарь Ф. А. Брокгауза и И. А. Ефрона. С.-П., 1902, Т. XXXIVA, 610 б.) С. М. Соловьевны тыңлыйк: «Татарлар электән үк төрле диннәргә юл бирә һәм ислам кабул иткәннән соң да яңа дингә һәвәсләнми. Үзбәк [...] Кафадагы христианнарны үз канаты астына ала, католик монахы Иона Валенсның ясларны һәм Кара диңгез буендагы башка халыкларны христиан итүенә комачауламый». (С. М. Соловьев. Күрсәтелгән хезмәт. Т. 3., 223 б.).

Үзбәк ханның улы Җанибәк турында да шундый ук раслаулар байтак. Шул ук Соловьев болай ди: «...ул христианлыкка бик мәрхәмәтле була һәм аның заманында Урыс җирендә зур җиңеллек хөкем сөрә». (Шунда ук, 254 б.)

Шунысы бик гыйбрәтле: урысның иң мәшһүр тарихчылары барлык Алтын Урда ханнарының православиегә карата олуг мәрхәмәтен кат-кат шәрехлиләр. Ләкин Урыс хөкүмәтенең мөселманнарга, аерым алганда, татарларга карата XVI—XX йөзләрдә үткәрелгән көчләп чукындыру сәясәтенең кешелексез икәнен икърар итү аларның хәтта башларына да килми. Алар уенча, моныеы инде «изге» гамәл, ягъни вәхши халыкларның күңелен православие нуры белән сафландыру, иблискә табынган иманнарын, рухларын пакь итү.

Бәлки православиегә чамадан тыш хәер-хаһлык Алтын Урда чорына, Сарай хөкемдарларына гына хас булгандыр? Бәлки Алтын Урданың берничә җәһәттән варисы — Казан ханлыгында христианнарга карата рәхимсезлек кылынгандыр, әсир төшкән урысларны гына булса да мөселманлыкка чыгарырга омтылышлар ясалгандыр?

Хәер, нигә баш ватарга? Сүзне урыс тарихчыларының үзләренә бирик. М. Г. Худяков: «Казан ханлыгы иҗтимагый хәятының иң якты якларыннан берсе — диннәргә тулы иркенчелек бирү. Бу иркенчелек шәһәр халкының сәүдәгәрлегенә, Идел-Чулман Болгарстаны традицияләренә, шулай ук Сарай идарәсенең дәүләти һәм иҗтимагый төзелешенә камил төстә туры килүенә бәйләнгән. Казанның үзендә христиан храмы — әрмән чиркәве торган; Казандагы әрмән зиратының кабер ташлары бүгенгә кадәр сакланып калган. Башка мәҗүси халыкларга мөселманнар камил хәер-хаһлык кылганнар һәм аларны беркайчан да (астына без сыздык.— Р. Ә.) көчләп мөселман итәргә омтылмаганнар». (М. Г. Худяков. Очерки по истории Казанского ханства. Репринтное воспроизведение. Казань. Фонд ТЯК, 1990, 197 б.)

Очраклы өзекме бу, юкмы? Әлбәттә, юк. Икенче цитата калган шөбһәләрне дә «тузгытып» ташлый. Биредә «иго» дигән төшенчәгә дә шактый ачыклык кертелә: «Хәтта татар изүенең (иго) иң чәчәк аткан дәверендә дә татарларның Русия өстеннән хакимияте салым җыю белән генә чикләнгән; **татарлар бервакытта да урыс дәүләтенең сәяси автономиясенә дә, урыс кенәзләренең хакимлегенә дә, аларның хәрби тәртипләренә дә, диннәренә дә, телләренә дә** (астына без сыздык.— Р. Ә.) тыкшынмаганнар. Казан хөкүмәте Олуг Мөхәммәт заманында Мәскәүнең Казаннан фәкать ясак түләү формасындагы бәйлелеген һәм татар шаһзадәләренең биләмәләр алу хокукын гына дәгъвалаган; бу омтылыш та вакытлар үтү белән юкка чыккан». (Шунда ук, 119 б.)

Алда күзәтелгән өзекләр Алтын Урда һәм Казан хөкүмәтләренең барлык диннәргә, шул исәптән, православиегә дә, уңай шартлар тудыруын, аларны махсус кануннар нигезендә саклавын җитәрлек исбатлый торгандыр.

Инде ошбу мәкаләбезгә рухи этәргеч биргән материалны әйләнешкә кертү вакыты җиткәндер. Сүзне бөек тарихчыбыз Ризаэтдин бине Фәхретдингә бирәбез.

## 4) Миссионерларның хакимлек итүләре, урыс хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның чукындырылуы

**Урыс кавеменең уртача фикерле һәм яхшы әхлаклы, төзек табигатьле булмаганлыгы мәгълүм. Шуңа күрә һәр эшләре чиктән тыш түбән юллардан йөридер. Бу көнгә кадәр боларга шушы ике юл уртасындагы зур юлдан йөрү насыйп булмады. Моннан соң уңышлы булу билгеләре дә күренми. Болар динле булсалар да, чамадан тыш кыйланалар, динсез булсалар да, һәрбер динсезнең өстеннән таптап китәләр.**

**Урыс падишаһларының бу мәмләкәттә булган мөселманнарны чукындыру өчен тырышулары ис китәрлек дәрәҗәдә булды. Бу маҗараны тәфсилләп язу — берничә кисәктән торган китап язу белән бер. Безнең моңа көчебез җитми. Болар шушы дәрәҗәдә тырышып та, бу илдә мөселман токымы югалмавы Аллаһе Тәгаләнең ярдәме булса кирәк.**

**Дөрес, әгәр дә урысларның мөселманнарны чукындырырга тырышулары беркадәр йомшак һәм уртачарак булса иде, урыс халкы бу дәрәҗәдә үрчемәс һәм күбәймәс, ислам халкы да Болгар хөкүмәте вакытына караганда бу мәртәбәдә кимемәс иде. Болар мөселманнарны көчләп чукындыру юлына керде һәм шул сәбәптән ифрат дәрәҗәдә күбәйде. Бу көндә «керәшен» дип йөртелә торган бер халык көчләп чукындырылган мөселманнардан таралган халыклардыр. Боларны Казан алынганнан соң Иван Грозный шулай бик чиркәнеч ясады.**

**Урысларның бу җинаятьләренә мисал итеп бу урында кайбер вакыйгаларны күрсәтү дә зарар булмас. Ләкин болар — диңгездән бер тамчы кебек кенәдер.**

**1. Кенәз Василий үз кулына төшкән мөселман ир һәм хатыннардан ике йөз әсирне милади белән 1536 елда дингә көчләде, риза булмаганнарын үтертте.**

**2. Ярославль шәһәрендә тоткын булып торучы Күчем хан ганләсен һиҗри белән 1048, милади белән 1638 елда көчләп чукындырдылар.**

**3. Ханкирмән (Касыйм.— Р. Ә.) шәһәрендә хан булып торучы Сәет Борһан бине Алып Арслан бине Гали хан бине Күчем ханны һиҗри белән 1065, милади белән 1655 елда, бер нәрсә дә аңламаган сабый вакытында чукындырдылар.**

**4. 1731 елда Казан һәм Нижний мөселманнарын чукындыру өчен «Свияжская богородица-монастырь»да рәсми идарә оештырылды.**

**5. Чукындырылганнарны ислам диненә кире кайтарырга өндәүчеләрдән 47 мөселманны 1867 елның 28 гыйнварында Себердәге Турухан якларына сөргенгә җибәрү белән хөкем иттеләр.**

6. Берәр төрле эш хакында гаепләнүче һәм дә өсләренә түләүләр төшкән мөселманнарны, чукынсалар, гаепләреннән коткару, түләүдән азат итү хакында кануннар игълан кылынды. Чукынучы мөселманнар гаскәрлек хезмәтләреннән азат ителә иде.

7. Бик күп чакта базарда һәм халык күп җыелып торган җирләрдә поплар җыелып торучылар өстенә үзләренең «изге су»ларын бөркиләр иде дә, шуның белән шул җыелган урында, җыенда булган халык христианлык кабул иткән булып хисаплана иде. Моннан соң шул кешеләрнең: «Минем христиан булганым юк, үз динемнән чыкканым юк!» — дигән дәгъвалары ишетелмидер иде.

8. Урысларның талауларыннан, җәфалау һәм газаплауларыннан, үз диннәренә кертер өчен көчләүләреннән йөдәгән мөселманнар бераз булса да тынычлык табу, дөньяларын һәм диннәрен төзәтү һәм саклау өмете белән башкорт сахраларына күчә һәм авыллар корып гомер сөрә башлаганнар иде. Бу эшләре белән мөселманнар шул җирләрдә берләшә, Төркестан һәм Фиргānә мөселманнары белән мөнәсәбәткә керүләре ихтимал, аннары чукындырып булмый башлар, дип фикер йөртеп, Романовлардан Алексей Михайлович һиҗри белән 1059, милади белән 1649 елда христиан булмаган халыкларның башкорт сахраларында торуларын тыеп фәрман игълан итте.

9. 1713 елда: «Җирләрендә православный крестьяннар булган мөселман җир хуҗалары алты ай эчендә православный мәзһәбкә керергә тиешләр, шуңа риза булмаган мөселманнарның җирләре, йортлары һәм бөтен мөлкәтләре көчләп алыначак»,— дигән фәрман чыкты. Бу фәрман 1729 елның 1 мартында, 1743 елның 28 сентябрендә тагын кабатланды.

10. Чукынырга риза булмаган мөселман алпавытлар үзләренең җирләрен һәм мөлкәтләрен сатып яки залогка салып акчалы булып калмасыннар һәм чукынудан котылмасыннар өчен, 1737 елның 21 октябрендә: «Мөселманнарның урысларга җир сатулары тыела»,— дигән фәрман игълан ителде.

11. 1754 елда: «Чукынмаган мөселманнар тарафыннан урысларга сатылган яки залогка салынган җирләрнең документлары һәм килешү кәгазьләре игътибарсыз калачак һәм җирләре көчләп алыначак»,— дигән аерым фәрман игълан ителде.

12. 1749 елда Казанда мөселман балаларын көчләп христиан дине мәктәпләрендә укыту юлына басканнар иде. Ләкин бу дәрәҗәдә хурлыкка һәм җәберләргә мөселманнар түзә алмадылар, «файдасы булса, булмаса, дип, шул вакыттагы хөкүмәткә каты сүзләр белән гаризалар бирделәр. Хәтта бу хәл чит мәмләкәтләргә дә ирешә, зур гына гаугa күтәрелде. Нәтиҗәдә, хөкүмәт мәчетләрне ваттыру һәм җимертү, сабый балаларны христиан динено көчләп кертү һәм мәктәпләрдә көчләп укыту турындагы законын алмаштырырга мәҗбүр булды.

13. Русиядә булган урыс кенәзләре һәм алпавытларының, дворяннарының күбесе крестьяннарыннан яки җир-суларыннан һәм дөньяда торган урыннарыннан аерыласы килмичә чукынган мөселман мирзаларының бер өлеше икәнлекләре мәгълүм. Боларның күбесе үзләренең мөселман вакытларындагы фамилияләрен ташлап, урыс фамилияләре алган булса да, кайсыберләре әүвәлдәге мөселман вакытларындагы фамилияләре белән калган, урыс фамилиясен алмаган. Бу соңгы бүлем җөмләсендә шундый фамилияләр бар: Абдуллин, Абдеев, Апраксин, Ахматов, Астанков, Аксаков, Астругaнов, Ахмедов, Измайлов, Удеевский (Уфа шәһәрендә мәшһүр), Ураков, Урысов, Батурлин, Башкиров, Балашов, Поливанов (Пәһлеван), Богданов, Бикбулатов, Башов, Пашин, Полванов, Татаринов, Татищев, Тимашов, Тимошкин, Чибиш, Чичаков, Черкасов, Дадишев, Дашко, Дәүләттилдиев, Денисов, Родаль, Рузаев, Шаховский, Шулашкин, Шихалеев, Ширинский, Сорокин, Салашников, Сукуров, Годунов (Борис), Котков, Кадушев, Карамзин (тарихчы), Каришев, Карилин, Кантилеев, Калпаковский, Кугушев, Каземберк, Клянчин, Мамин, Мартин (Мортаза исемле мирза балалары), Максудов, Мансуров, Мирзалинкин, Нахимов, Ермолаев, Языков, Янгаличев, Юсупов. Боларның күбесе — зур мөлкәтләргә ия булган алпавытлар, кенәзләр һәм мирзалардыр.

14. Көчләп чукындырылган мөселманнар әһле ислам каршында «керәшеннәр» һәм «мәкруһлар» исемнәре белән йөртеләдер. Урыс хөкүмәте тарафыннан «Новокрещенская контора» ачылганнан соң чукындырылганнар — «мәкруһлар» дип, аннан элек чукындырылганнар «керәшеннәр» дип аталалар. Бу ике төркем арасында аерма зур. Керәшеннәр үзләренең иске төрек телен, кием-салымнарын саклап килсә дә, ислам диненнән һәм мөселманнардан ераклашкан, христианлыкта торуларына артык ощынмый. Әммә «мәкруһлар» үзләрен чын мөселман саный, әгәр дә аз гына форсат тапса, үзләренең мөселманлыкларын күрсәтә. Бу уңайдан күреләчәк авырлыкларга түзәргә дә хәзерләр. Мәкруһлар турында һиҗри белән 1271, милади белән 1855 елның 29 маенда императорның: «Ислам диненнән христи-

ан диненә мөрәҗәгать итмәгән мәкруһлар Казанның духовная консисториясе хөкеменә җибәрелсеннәр, бармасалар, балалары ата-аналарыннан полиция көче белән алынып, чукындырылсыннар, христиан диненчә яшәмәгән мәкруһлар чиркәүләргә яңадан христиан руханилары тарафыннан йөртелсеннәр, әгәр дә бу эшкә риза булмасалар, ата-аналары аерылсын, ирле-хатынлы булып тормасыннар!» — дигән указы игълан ителде.

15. Шушы елларда мәкруһлар урыслашсыннар, чын христиан булсыннар өчен, ялгыз-ялгыз гаиләләрне урыс авылларына таратып утырттылар, урыслар белән аралашырга һәм барлык хәлләре урысларның күз алдында булып торуга мәҗбүр иттеләр.

16. Мәкруһларның ислам динендә көчле һәм ныклы булуларын муллалар һәм мәчетләр тәэсиреннән күреп, урыс хөкүмәте мәчет салу эшләрен христиан руханиларына тапшырды. Болар риза булса — мәчет салуга рөхсәт бирелә, әмма алар яраклы күрмәсә — рөхсәт бирелми торган булды. Бу закон һиҗри белән 1188, милади белән 1774 елда гына үзгәрде. Ләкин бу үзгәртү нигездән түгел, бәлки мәкруһлар тормаган һәм гомумән, христианнарга тәэсир итү куркынычы булмаган урыннарга гына кагыла иде. Әмма христианнардан яки мәкруһлардан бер генә гаилә булса да, ул урында мәчет салуга рөхсәт бирү яки бирмәү христиан руханилары ихтыярында иде. Бу закон Икенче Николайның тәхеттән төшкән көненә кадәр дәвам итте.

17. Кыргыз, казакъ кавемнәрен урыслаштыру һәм христиан итү теләге белән 1223 һиҗри, 1808 милади елда император тарафыннан: «Фәкыйрь кыргыз һәм казакълар үзләренең балаларын Төркестан, Хива, Бохара халыкларына сатарга тиеш түгел. Әмма урысларга саткан очракта ярдәм ителә»,— дигән указ игълан ителде. Шушы указга таянып, сатып алу дигән булып урыслар кыргыз һәм казакъ балаларын урлап һәм талап алып кайту юлына басты һәм һәммәсен чукындырып торды. Шуңлыктан бу көндәге урысларның ерак әбиләре һәм бабалары мөселман булмаганы бик сирәк һәм аз табылыр.

18. Чукындырылу хакында мөселманнарның күргән бәлаләренең иге-чиге юк. Төрмәдә ятучылар, ватаннарыннан сөрелүчеләр, үтерелүчеләрнең исәбен бер Аллаһе Тәгалә генә беләдер. Бу турыда иске һәм зур архивлар түгел, бәлки Уфа шәһәрендәге Диния нәзарәте архивында булган эшләр генә дә гакылларны хәйран калдырырлык дәрәҗәдәдер. Көчләп чукындыру турындагы законнар императрица Екатерина тарафыннан юкка чыгарылган һәм алыштырылган булса да, бу юкка чыгару һәм алыштырулар кәгазьдә генә булып, гамәлдә һаман да үтәлеп торды.

19. Кырым ханы Мораттгәрәй бине Мөбарәктгәрәй тарафыннан Мәскәү кенәзе Федор Алексеевичка һиҗри белән 1093, милади белән 1682 елның рабигыльәүвәлендә, ягъни март аенда язылган хатта шундый җөмләләр бар: «Мәмләкәтегездә булган мөселманнарны көчләп һәм кыстап христиан мәзһәбенә кертәсез икән. Мондый эшләр падишаһлар дәрәҗәсенә лаек түгел. Бу бик яман эш. Бездә һәм дә бәхетле солтан кул астында хисапсыз дәрәҗәдә күп христианнар бар, безнең тарафыбыздан алар турында шундый бер эш булганы юк. Сез мөселманнарны дин мәсьәләсендә кыстамагыз, мөселманнар үз диннәрендә тыныч торсыннар».

20. Кырым ханы Мөхәммәтгәрәй ханның вәзире Сәфәргази Ака тарафыннан Мәскәү кенәзе Алексей Михайлович вәзире исеменә язылган хатта шундый сүзләр бар: «Падишаһыгыз мөселманнарның мәчетләрен һәм мәдрәсәләрен ваттырып, Аллаһе Тәгаләнең сүзләре булган изге Коръәннәрне утка яктырды. Тотсакларны (әсир төшүчеләрне.— Р. Ә.) йолып алырга биреп, кыйнап христиан итәсез. Андый эшләр белән генә христиан күбәймәс. Бездә дә христианнар күп. Ләкин без аларның диннәренә тыкшынмыйбыз. Кешеләрне көчләп христиан һәм көчләп мөселман итү — лаек эш түгел. Ханкирмән солтанын да көчләп христиан иттегез!»

* * *

Әлбәттә, бу мисаллар, Риза Фәхретдин раслаганча, диңгездән бер тамчы кебек кенә. Боларга меңләгән яңаларын өстәргә мөмкин булыр иде. Без тагын иң чирканчыкларыннан гына берничәсенә тукталырбыз. Югыйсә манзара тулы булмаячак. Эш шунда ки, татар-мөселманны көчләп чукындыру 1552 елдан соң гына башланган гамәл түгел. Мәсәлән, 1487 елның язында Иван III Казанны алгач, Гали (Илһам) хан тәхеттән төшерелә, хатыннары, анасы Фатыйма, сеңелләре-энеләре Мәлик-Таһир һәм Ходайкул белән берлектә Русиягә озатыла. Хан гаиләсе гомерлек әсирлеккә хөкем ителә. Гали хан үзе Вологдада, Фатыйма ханбикә һәм шаһзадә Мәлик-Таһир Карголымда үлә. Ләкин төп хикмәт анда түгел.

Төрле елларда Ходайкул — Петр, Мәлик-Таһирның уллары — Василий һәм Федор исемнәре белән чукындырылалар. Христиан рухындагы иманын ныгыту өчен Петр-Ходайкулны Василий III нең сеңлесе Евдокиягә өйләндерәләр. Боларның һәммәсеннән яңа буын урыс кенәзләре үрчи.

1533 елда Мәскәү хөкүмәтенә хыянәт итүдә гаепләнгән Шаһ Галинең йөзләгән иярченнәрен төрмәләргә озаталар, каты газаплыйлар, ач үлемгә хөкем итәләр («үлемгә утырталар», «болар көне-төне үлеп торалар»), христиан булудан баш тартучыларның җанын кыеп, чукындыралар. Псков төрмәсендә генә дә 72 ир-атны буып, 50 хатын-кызны һәм бала-чаганы көчләп христиан итәләр.

Казанның соңгы ханнарының язмышы да аяныч. 3 яшьлек Үтәмеш-Гәрәй 1551 елда әнисе Сөембикә белән Русиягә әсир сыйфатында озатыла. 7 яшендә әнисеннән тартып алына һәм Чудово монастырендә Александр исеме белән чукындырыла. Иманыннан, әнисеннән, ватаныннан аерылган бу бала озак яшәми, 20 яшен дә тутырмыйча вафат була. Соңгы хан Ядкәрне дә шул ук язмыш көтә: 1553 елның февралендә ул Мәскәү елгасы бәкесенә чумдырып чукындырыла һәм Симеон исеме белән «бүләкләнә». Һәр икесе чиркәүдә җирләнә. Монда да бер параллель уздыру соралып тора. 1445 елда Мәскәү кенәзе Василий II Казан хөкемдары Олуг Мөхәммәт ханга әсир төшә. Кенәзне мөселманлыкка дүндерү түгел, шаһзадәләр Касыйм һәм Ягъкуб аны, солых төзегәннән соң, Мәскәүгә кадәр озатып, тәхетенә үк утыртып куялар.

1552 елда Казан алынганнан соң көчләп чукындыру һәм урыслаштыру киң колач белән җәелдерелә. Бер үтә әһәмиятле якны аерым искәртү зарур. Идел буе җирле халыкларына, беренче чиратта, мөселманнарга карата үткәрелгән христианлаштыру сәясәте 1649 елгы Соборное Уложение дигән документта закон төсендә раслана. Әлеге Уложение чукынырга теләүчеләргә уңайлыклар тудыруны күздә тота һәм шул ук вакытта православиегә күчүдән баш тартучыларны кысу һәм эзәрлекләү челтәрен хокукый нигезгә сала. Әмма хикмәт шунда, православие диненә иңдерү «изге» эш саналса да, урыс кешесен ислам диненә дүндерү җинаятькә тиңләштерелгән. Уложение мондый «әшәкелек» өчен үлем җәзасы билгеләгән. Тыңлап карыйк: «Бусурман (ягъни мөселман.— Р. Ә.) берәр урыс кешесен нинди дә булса көчләү яки алдау юлы белән үзенең бусурман иманына дүндерә яки үз бусурман иманы буенча сөннәткә утырта икән, аны эзләп тапканнан соң ж ә з а л а п  ү т е р е р г ә, берниндн шәфкатьсез у т  б е л ә н  к ө й д е р е р г ә» (сирәкләүләр безнеке.— Р. Ә.) (Соборное Уложение 1649 г.; Текст, комментарии. Л., 1987, Гл. XXII, 24 нче маддә.).

Менә бит ул ничек! Урыс хөкүмәтенең 1649 елгы Соборное Уложениесе татарга берәр урысны исламга дүндергән өчен үлем җәзасы билгеләсә, Татар хөкүмәте 1313 елда урыс диненә сүз тидергән өчен генә дә үз мөселманының башын балта астына куйган. Хәер, «вәхши» һәм «кыргый» татарлардан ни көтәсең инде!

Соңгы мисал итеп «хрестоматик» үрнәк сыйфатын алган Аксак Каратун (Лука Канашевич) «каһарманлыгын» искә алыйк. Бу бәндәнең башлангычы белән 1742 елда Казанда һәм Казан өязендә генә дә 516 мәчетнең 418 е җимерелә. Себердә 136 дан 89 ы, Әстерхан тарафларында 40 тан 29 ы харап ителә. (Г. Г а з и з. Татар тарихы. М., 1925, 243 б.)

Ни өчен соң барлык мәчетләрне дә җир белән тигезләмәгәннәр икән, дигән сорау туарга мөмкин. Ярамый. Исән калган мәчетләр мөселманнарны үзләрен көчләп чукындырган хөкүмәткә ант иттерер өчен кирәк. Бөтенләй бетерсәң, мөэмин-мөселманның «ак патша»га итагать итми башлавы бар.

Чукындыру белән урыслаштыру зур сәясәтнең бер-берсенә һәрвакыт үрелеп бара торган ике тармагы ул. Бер генә мисал. Хөкүмәтнең төп максатын мәгърифәт калыбына салып, Русиянең мәгариф министры граф Д. А. Толстой 1870 елда ачыктан-ачык болай дип белдергән иде: «Безнең мәмләкәт кысаларында яшәүче барлык инородецларны мәгърифәтле итүнең ахыр максаты, шөбһәсез, урыслаштыру һәм аларның урыс халкы белән кушылуы булырга тиеш». (Аграр, вопрос и крест. движ. 50—70 гг. XIX в. Ч. Т. М.-Л., 1936, 285 б.) Бу инде милләтләрне халык буларак юк итү дигән сүз.

Хәер, җитеп торыр. Бүгенге укучы томана түгел, нәтиҗәләрне үзе чыгарыр. Шуңа гына игътибарны юнәлтик: менә шушы тарихыбызны дистәләгән еллар буена язарга түгел, хәтта болар турында авыз ачып сүз әйтергә дә ярамады. Нәтиҗәләре мәгълүм.

Хәзер керәшен кардәшләребез юлбашчылары: «Мөселман татарлар нишләп шул чаклы христианлыкны күралмыйлар икән», дип уфтангалап куя. Гафил булмагыз, дуслар. Чын мөселман татарның христианлыкка берниндн дошман-

лыгы юк һәм булуы да мөмкин түгел. Һәркемнең үз иманы. Аның каршында Будда дине дә, яһүд дине дә, Гайса дине дә бертигез. Башка мәзһәбләргә карашы да хәер-хаһлык нигезендә генә. Ләкин эш татар-мөселманны халык, милләт буларак бетерү (денационализация) хакында бара һәм бу телисә нинди дин (христианлыкмы, буддачымы, яһүдме, кришнаитмы — барыбер) байрагы астында эшләнә икән, бу инде икенче мәсьәлә. Моңа бер генә намуслы татар да битараф булып кала алмас! Татарны милләт буларак тарих чүплегенә ташларга маташу моңарчы Будда дине рухында да, яһүд дине рухында да алып барылмады, бәлки православие җирлегендә, чукындыру юлы белән эшләнә килде. Мисаллар эзләп ерак барасы юк, керәшен кордашларыбызның узаманнары үзләре үк: «Без татар түгел, без аерым керәшен милләте», дип лаф оралар түгелме соң? Хәтта Идел Болгарстанындагы дин иркенчелегенә ишарәләп, үзләрен Болгар заманыннан ук христиан булып килүләрен исбатлап маташучылар да очрый. Тукай ничек дигән әле: «Сөйләве яхшы, күңелле, шагыйрәнә ялган ул», дигәнме? «Крещеный», «крещеный татарин». Тәрҗемә кылсаң, «чукындырылган», «чукындырылган татар» килеп чыга. Моны кая куясың ди инде? Аннары урыс та, грузин да, украинлы да чукынган халык, ләкин бит берсе генә дә «крещеный русский», «крещеный грузин», «крещеный украинец» булып йөрми. Димәк, Болгар заманыннан килгән, үзе теләп христианлыкны кабул иткән халык берничек тә «крещеный» титулын күтәреп йөри алмый.

Татар халкының, башкалар кебек үк, милләт буларак сакланып калырга тулы хокукы бар. Һәм ул шуңа омтыла да. Әгәр моны закончалыклы күренеш, табигый халәт итеп кабул итсәк, бернинди аңлашылмаучылыкка урын калмый. Биш гасыр элек үк көчләп чукындыру, телдән-иманнан яздыру һөҗүменә юлыккан татар халкы үз фаҗигале язмышына аек караш ташларга һәм аннан олуг гыйбрәт алырга тиеш.

# ИСКЕРМИДЕР ӘДИПЛӘРНЕҢ СҮЗЕ

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

**Татар әдәбияты классигы Шәриф Камал дип әйтүгә, «Акчарлаклар» повесте, «Хаҗи әфәнде өйләнә» сатирик комедиясе, «Уяну», «Авыл мөгаллиме», «Депутат» кебек хикәяләре искә килеп төшә. Балачактан ук күңелләребезне кузгаткан, хыялларыбызны уйнаткан кызыклы вә гыйбрәтле әсәрләр алар.**

**Шәриф Камал иҗаты — татар әдәбиятының узганы белән бүгенгесе арасындагы ныклы күпер ул. Аның сүзгә кыска, фикергә һәм тасвир чараларына бай әсәрләре, кырыс тормыш сынауларын уңышлы узып, бүген дә яшәүләрен, көрәшүләрен дәвам итәләр.**

**Шәриф Камал үз иҗатындагы хакыйкать вә камиллеккә, Ходай биргән таланты өстенә, гаять бай тормыш юлы, яшәеш тәҗрибәсе, гади хезмәт кешеләренең рухия-халәтен бик яхшы белүе аша ирешә алгандыр, мөгаен.**

**Шәриф Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгильдиев) 1884 елның 27 февралендә элекке Пенза губернасы Инсар өязе (хәзерге Мордва республикасының Рузаевка районы) Пешлә авылында мулла гаиләсендә туа. Мәдрәсәдә укый. Төплерәк белем алу нияте белән Төркиядә һәм Мисырда була. Яшьтән үк үз көнен үзе күрергә өйрәнә, укуны эш белән аралаштырып алып бара. Матди ягы кысынкы булганлыктан, чит илдән кайтып, Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшли.**

**1905 елгы революция вакытында Шәриф Камал Петербургтагы татар мәдрәсәсендә мөгаллим була. Биредә ул «Нур» исемле беренче татар газетен нәшер итүдә катнаша, шунда беренче әсәрләрен бастырып чыгара. 1906 елда аның «Сада» (Аваз) исемле беренче шигырьләр китабы дөнья күрә.**

**Революция җиңелүгә дучар булып, кара еллар башлангач, Шәриф Камал туган авылы Пешләгә кайта һәм мәдрәсәдә мөгаллимлек итә. 1910 елда ул Оренбургка күчеп китә, анда «Шура» журналы һәм «Вакыт» газете редакцияләрендә эшли. Оренбургта язучының активлыгы үсә, каләме үткенәя. Биредә ул күпләгән хикәя һәм «Акчарлаклар» повестен, «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен иҗат итә.**

**1925 елдан башлап Шәриф Камалның тормышы Татарстан белән турыдантуры бәйле. Ул Казанга килеп, башта «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газете редакциясендә бүлек мөдире, аннары Татар мәдәнияте йортында гыйльми секретарь, Татар дәүләт академия театрында әдәбият бүлеге мөдире булып эшли. Гомеренең соңгы елларында ул әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә. Бу чорда күләмле проза һәм драма әсәрләрен яза. Алар арасында «Таң атканда», «Матур туганда» романнары, «Козгыннар оясында», «Таулар», «Томан арты» (Габбас Галин) һәм башка әсәрләре бар.**

**Шәриф Камал татар милләтенең рухи үсешенә зур өлеш керткән олы шәхес. Ул үзенең әдәбият өлкәсендәге олуг хезмәтләре өчен 1940 елда Ленин ордены белән бүләкләнә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек була. 1950 елда исә Казанда Шәриф Камалның музей-йорты ачылды.**

**Быелның февраль аенда классик әдибебез Шәриф Камалның тууына 110 ел тула. Шул уңайдан, заманында матбугатта инде бер дөнья күргән булса да, әдипнең «Депутат» дигән хикәясен журнал укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык. Безгә калса, бу әсәр бүгенге көн вакыйгаларына бик тә аваздаш.**

# DEPUTAT

Ul inde kitərgə xəzerlənə ide.

Өc kөn aldan вernicə çөmlədən qiвarət kenə bik qaj-nar вer «notьq» kisəgc də əzerləp qujdь.

«Millətneŋ tələklərеn çirenə çitkery julьnda çan fida вulsьn! Alarnь вuldьru өcen вer tamcь qanьm kipkənce içtihad ity iŋ məqədəs vazifam dip iqtiqad qьlam. Xəzergе məs'ələ—təqlim qomumi məs'ələse—millətneŋ xəjatь вelən tiŋ! Əgər вu məs'ələ millət tələgənсə xəl itelməsə, anьŋ xəjat və şomьna kytərə almaslьq zur zərвa, anьŋ vəkillərenə zur xəqarət вulacaq. Ul xəldə вezgə deputat ismen kytərydə məqnə qalmьj, вezgə zillət * və xurlьq qьna вulacaq. Ul xəldə вez deputatlьqnь da taşlajacaqвьz!»

Menə şul notьqnь ul vokzalda, ikence zvonok вirelgəc, yzen ozatьrqa təşkən xalьqqa qarap vagon ploşcadkasьnnan səjlərgə niət itkən ide.

Ul soŋqь kənnərdə өjləngən sajьn avьz ecennən өkrenləp вu notьqnь təkrar qьlьp ala ide. Cөnki şoma həm „выразительный" сьqarьrqa isəpli ide...

**Xatьnь cittən anьŋ вolaj avьz ecennən səjləngənen kyrgəndə ni səjləgənen soraşьp anь xafalarqa вazmьj ide. Tirən genə sulьş alьp yz yzenə:**

**— I i i xodajьm... Juqqa leputat jasamaqannarđьr şul...—dip kөsenep quja ide.**

Təəssef ki deputat əfəndegə, şulaj tьrьşьp, tьrьşьp xəzerləgən notьqьn səjlərgə turь kilməde; cөnki anь ozatьrqa vokzalqa aqaj-enedən kem də сьqmaqan ide...

---

* Zillət—tyвənlek.

man saqalьn qarmaştьrьp tərəzəgə qarьj. Pojezd şөp kenə вara inde... Tərəzə arqьlь cəcelep kitkən aq воlьt tөsle qajnaşьp artqa тава aqьp torqan parovoz tөtennөre arasьnnan telegram вaqanalarь qara şyldilər keвek jalt ta jolt kyrenep qalalar... Qaj caqьnda, çir astьnnan işetelgən tөsle genə-çil вelən вylenep-вylenep parovoz sьzqьrtqan tavьş ta işetelgəli... Urtalьq kyk kykrəgən tөsle jomşaq qьna haman tavьşlьj, haman gөrli, həm də kөjləp gөrli: «вez kitəвez qajlarqa, ii, вez kitəвez qajlarqa!..» di. Bu tavьş вu taqmaqlar вaşqa vaqьtta deputat əfəndenen joqьsьn kitersələr də xəzer ni өcender uңajsьzlьj, ecen poşьra idelər. Gyjə вajaqь aljapqьclь өc tatar qocaqlaşьp вiep anь mьsqьllap şul taqmaqlarnь əjtə idelər... Tьşta kic вula ide inde. Qarşьda qьna tege jəşrək marça deputat əfəndene вer də kyrməgən tөslө вer də iltifatsьz əllə ni ujlap irennəren jalьj, jalьj utьra, вalasь əllə nindi kəqəzlər вelən ujnap mataşa. Alarqa da deputat əfəndenen nişləpter ece poşa ide...

Ul ujlьj başladь:

«Bezdə deputat вulqanьnnan вulmaqan men artьq. Beznen mөselman xalqь qьzьq qьna ujlьj. Gazetalarda: «mөselman deputatlarьmьz» «mөselman fraksiəmez!» digən вulьp haman tal cəjnilər... Gyjə, sin alarnьn satьp alqan qollarь! «Duma acьla» imeş, «вeznen deputatlarьвьz əle də çiьlmaqan» imeş! Azmь son, kesenen xezmətlərе вulьp kicygə, vaqtьna çitə almьj. Alar şunь əle qьcqьruqa, əle gazetalarqa jazarqa!.. Anda вarasьn, gazetalarь taqьn: «fələn deputat rec sөjləgən! Fələn deputat fələn komisiəgə sajlanqan! Fələn deputat fraksiəgə rəislek itə...» dip jaza вaşlьjlar... Cittə qalasьn dyrt, вiş keşe—isemnərenne вөten tatar kyneldən вelə. Gyjə вөtenese: «ul nik rec sөjləmi! ul nik komisiəgə sajlanmьj?» dip kyzgə tөrtep toralar...

Ikence zvonok вireldә—platformada, fәqәt anь ozatьrqa 'tәşkәn yzeneŋ balalь xatьnь da, asrav qьz вar: alardan вeraz cittәrәk, aljapqьclь өc tatar tәmәke tartьp tora idelәr. Alar әlвәttә deputat ozatьrqa kilgәn keşelәr tygel, vokzaldaqь cşcelәr ide.

Alaj da deputat әfәndeneŋ sөjlise kilә ide.

— Barьвer inde, xәzerlәngәn—hic вulmasa şul өc keşe işetep qalsьn...—dip ujladь da notьqьn sөjli başladь:

— «Millәtneŋ telәklәren çirenә kitery»—dip kenә әjtkәn ide, tegelәr monь xatьnь вelәn sөjli dip ujlap, вer dә iltifat itmice salqьn qan вelәn genә вorьlьp platformanьŋ ikence вaşьna taвa kittelәr... Deputat tegelәrneŋ tupaslьqlarьna uŋajsьzlansa da aptьrap qalmadь.

Xatьnьna qarap:

— Әjje... Telәgәnen вir, jaxşь qьna qara... әjje вalanь dim! Suьqqa cьqarma; jәtkerә вaşlьj annan soŋ... Ul вalalar өcen вik zararlь... işetәseŋ? Әnә Işmoratnьŋ qьzь şulaj jәtkerә-jәtkerә dөnjadan da kitte...

— Әfәnde, eckә keregez—pojezd quzqala xәzer,—dide konduktor.

— Jә, xuş... Isәn qalьqьz inde Xәdicәkәj...

Deputat vagonqa kergәc tә urnьna utьrmьjcь вuj-dan-вujqa вer ike mәrtәвә jөrenep әjlәnde... Keşe az. Ike marça qarcьqь cәj вelәn әvәrә вulalar: вerse, qulьn qaltьratьp-qaltьratьp, вaqьr cәjnektәn sьjьq qьna cәj qoja, ikencese vaq qьna almalar kisep cьnajaqlarqa salьp mataşa... Jaltьravьq itekle вer taza qьna qart urьs tәrәzәgә qarap вarmaqlarь вelәn saqalьn qarmaştьrьp tora... Вer matur qьna marça yzeneŋ dyrt, вiş jәşlek вalasьn ujnatьp şөqellәnә...

Deputat әfәnde yzeneŋ urnьna utьrdь. Tege qart ha-

Ə'urьsnьŋ alaj tygel. Milykof jəisə Maqlakof rec səjli, anь hər kem вelə. Qaniqin jəisə Sutaqin вer də səjləmilər ikən—alarnь kem вelə. Bəlsə, вelsə avlьnьŋ puвь da volostnoj pisere вelə... Juq, сьnlap ta вezdə deputatlьq вik qьzьqsьz eş...»

Bu şulaj ujlap utьrqanda tege jaltьravьq itekle qart monьŋ janьna kilep utьrdь.

— Knəz, sez Məskəvgə?—dide.

— Juq Məskəvdən arь...

— Səvdə вelən olвəttə?

— Juq... Min dumaqa, xalьq vəkile min, jəqni clen gosudarstvennьj duma.

Şulaj digəc tege ciвər marça qiьq qьna itterep moŋar вer qarap aldь.

Qart вeraz qəçəplənep:

— Şulaj digen! Seznen məselmannardan da dumada clen вar digen!

Bu arada marça da syzgə qatьştь:

— Əlвəttə вar. Alarnьŋ yzlərenə ajrьm fraksiələre də вar şikelle.—Deputatqa qarap:—Dəres вit?—dide.

— Əjje, əjje, əjje, ajrьm, Məselman fraksiəse, вik dəres əjtəsez.

— Soŋ sez anda nişlisez?—dide qart.

— Zakonnar təziвez.

Qart вik qəçəplənep:

— Joqni nicek zakonnar təzisez?!—dide.

— Əjje, zakonnarnь qarьjвьz, tikşerəвez.

Şulaj digəc qart вeraz tьnьclandь.

— Şulaj dip əjt! Juqsa patşadan вaşqa zakon сьqarьrqa, zakon təzergə kemneŋ eşe вar!.. Anь patşa qьna сьqara ala!—dip qujdь.

Qart şulaj digəc səjkemle marça deputat əfəndegə qarap kələmserəde, вu da aŋar qarşь azraq jьlmajdь,

həm yze zismice yk tegenen kyzlərenə də tup-turь qarap aldь.

Bu vaqьtta kic вajtaq ytkən ide.

Qart yz urnьna kitte.

Pojezd tuqtaqan ide. Deputat əfəndenen əllə nişləp kynle kytərelep stansaqa təşep вeraz jərergə isəpləde. Ul вufet aldьnda qьsqa qьna tuqtaqannan son вeraz jərenep vagonqa kersə—tege səjkemle kyrşese, art вujda joqlaqan вalasьn qocaqlap citkə genə suzьlьp jatqan ide. Deputat əfənde cьqqanьna da вeraz yken-de: cənki kyrşese вelən вeraz gəpləşep utьrьrqa isə-вe вar ide. Ləkin irtəgə də kən вar ikənlege xətrenə təşkəc tьnьc kynel вelən genə urnьna suzьlьp jattь.

Ul manqasь cьqqan qьna вalasь, qara şəl jaвьnqan tənənək kenə xatьnь ul aljaŋqьclь əc tatar xəzer əllə qajda toman ecendə qalqan idelər.

Ul xəzer gazetalarnь həm də kitkəndə səjlərgə xə-zerləgən notьqьn da təmam onьtqan ide. Nicekter no-tьqnьn sonqь cəmləse xətrenə təşte də qьcqьrьp kələp çiвərə jazdь. Ləkin keşe işeter dip jaxşьsьnmьjcь kəl-kesen tьjьp əkren genə yz yzenə:

— Deputatlьq вit ul, вer ujlaqanda вer də zararlь nərsə tygel,—dide.

Ul вajtaq vaqьt joqlamьj jattь. Kyz aldьndaqь kileş-le pricjoska Peterвurgnь Nevski uramь вelən genə ty-gel, xətta pereuloklarь вelən yk xəterlətə, kyz aldьna kiterə ide.


Ber vaqьt ul inde jartьlap joqlaqan ide. Bik tatlь itep kierelde də, ьnqьraşьp qьna teş arasьnnan:

— Əjje şul, kem вelgəngə вer də zararlь es tygel ul...—dide.

1910

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

# БӘХЕТ КОШЫ КАЯ КУНА?



Оҗмах кошын күрү һәркемгә дә насыйп түгел, ләкин кем дә кем күрә — ул инде, һичшиксез, бәхетле була... диелә татар риваятьләрендә. Мин үзем күрәзәче түгел, әмма рәссам Ринат Насыйровның учындагы тормыш сызыкларына ул үткән бөтен юллар, борылышлар да язылган, ул — оҗмах кошына тап булган шәхес, дип уйлыйм. Үзен сәнгатьтә, шигъриятә, архитектурада тапкан, шундый кызыклы язмышка дучар кеше инде ул.

Ринат Насыйров белән мин күптәннән таныш. Кыю фикерләве аркасында күпләрне аптырашта калдыручы кабатланмас шәхес, танылган архитектор ул. Шунысы гаҗәп: тыгысыз холыклы булуга карамастан, ул зур урыннар биләп, башта проектлау буенча баш архитектор, аннары Чаллының баш архитекторы һәм Татарстанның Госстрой рәисе булып ничек эшләде микән? Иҗат кешесе буларак, ул өстән төшерелгән күрсәтмәләрне бик өнәп бетерми, үз мәсләгенә каршы килгәнне бөтенләй дә кабул итми иде. Ул эшкә кайнарланып тотынган җирдә, һичшиксез, бәхәс куба, түрәләр аның көтелмәгән яңалык уйлап чыгарасын алдан белеп, «утны» сүндерергә әзер торалар, һәм аны «чәчәк атучы» совет чынбарлыгы сукмагына төшерү өчен күп көч куялар иде.

Сиксәненче еллар азагында Ринат Насыйров бөтенләй яңа яктан ачылып китте. Ул сәнгатьтә хөкем сөргән рәсми агымга бөтенләй капма-каршы мәсләк белән рәссам-авангардист булып мәйданга калыкты. Аның әсәрләре кыюлыгы белән аерылып тора иде. Әгәр архитектор дигән рәсми статусы күләгәләп тормаса, аның бу иҗат юнәлеше әллә кайчан инде күпләрне җәлеп иткән булыр иде.

«Арсенал» галереясында без аның әсәрләрен беренче мәртәбә күреп шаккаттык. Хәер, аның «билгесезлек» кимәлендә йөрүе болай гына иде, рәссам буларак, безнең илдә генә түгел, хәтта чит илдә дә танылып өлгергән икән бит ул.

Ринат Сәхиулла улы Насыйров-Насыйри Башкортостанның Авыргазы районы, Толбазы авылында 1942 елны дөньяга килә. Татар мәктәбендә укып белем ала. Аның Фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнашкан әтисе урта хәлле җир кешесе була. Әнисе исә мәктәптә балалар укыта. Ринат үзенең 105 яшькә җиткән дәү әнисен яхшы хәтерли. Ул үләннәрнең «телен белә», авылдашларын һәртөрле чирдән дәвалый торган була. Ә бабасы — тирә-якта билгеле хаҗи — мөселманнарның изге бишеге — Мәккәгә барып хаҗ кылган изге затлардан.

Иҗат әһелләренең, гадәттә, рухи тамырлары балачак дөньясына барып тоташа. Ягымлы, дини мөнәсәбәт хөкем сөргән шамаилле йорт, табигать белән янәшә, бер сулышта яшәгән ата-ананың, әби-бабаңның җиһан нурыннан

алган итагатьле тәрбиясенең шифалы йогынтысы — иҗади киләчәккә шулар бәрәкәтле нигез булып ятмый дисеңме!

Татар әдәби һәм мәдәни хәятына күпләр Башкортостаннан килә. Алар — Уфа губернасы татарлары. Большевиклар дәверендә милләтнең төшүзәгеннән ясалма чикләр белән бүленсә дә, рухи җепләр өзелми, төп тамырның сулкылдавын тоеп тора. Тормыш тәҗрибәсе алып, язмышың, иртәме-соңмы, барыбер, үз ярларына кайтып төшә икән... Ринат Насыйров белән дә шулай булды. Үсмер чагы турында ул болай сөйли: «мәктәпне бетердем, башка түбәтәй, өскә куртка кидем дә, фанер чемодан тотып, Свердловск шәһәренә, политехника институтына укырга керергә дип киттем. Акчам, чама белән, ун көнгә җитәрлек иде». Ә нигә Свердловскига? Чөнки Урал төбәгендә илгә билгеле зур белем учаклары урнашкан. Ринат архитектура факультетына имтиханнар бирә. Ни дисәң дә бу факультетта, кем әйтмешли, «физик»лар белән «лирик»ларның тәңгәл берлегенә бөтен мөмкинлекләр бар: техник белем алу өстенә, тагын рәсем, нәгышле сәнгать һәм архитектура фәннәре дә күп урынны алып тора. Ә Ринатның бәләкәйдән үк сурәт ясарга хирыслыгы бар, үзенең беренче укытучысы итеп ул район театры рәссамы Галиевне саный. «Бөтен буш вакытымны аның эргәсендә үткәрә идем»,— ди ул.

Свердлау каласы мәһабәтлеге белән аны таң калдыра. Бер катлы тәбәнәк авылга күнеккән егеткә биек колонналы, «сталинчыл» рухта төзелгән биниһая эре биналар бик көчле тәэсир итә. Биш катлы һәм шул биеклектәге колонналары белән гаҗәеп зур Урал политехника институты бинасын күргәч, егетнең кулыннан дыңгырдап фанер чемоданы төшеп китә. Әмма аңа шәһәр күренешләре белән артык хозурланырга вакыт калмый: көнне төнгә ялгап ул имтиханнарга хәзерләнә башлый.

Сәламәт җирлектә чыныгып үскән авыл егете ала алмаган биеклекләр була димени! Менә ул, бөтен киртәләрне дә уңышлы үтеп, архитектура факультеты студенты булуга ирешә (1959 ел).

Урал гидрометереологик үзәк проектын эшләү һәм шуны диплом эше итеп кую аның иҗат язмышында олы вакыйга була. Алынган темасы катлаулы, мондый бина төзү технологиясе эшләнмәгән. Шуңа күрә ул Мәскәүгә, Киевка барып шушыңа охшашлы төзелешләрне өйрәнеп тәҗрибә туплый. Объектның бик мөһим-җитди булуын искә алып, студентның проектына академик үзе кул куя. Диплом эше менә дигән итеп яклана, Ринат Насыйровның эше шәһәр төзелеше советында хупланып кабул ителә. Шулай итеп, иҗади хыяллар белән янган егет заманына күрә шактый кыерсытылган архитектура өлкәсен үзенең кыйбласы итеп сайлый. Уңышлы яклаудан соң аңа киң юл ачыла: Свердловскиның өлкән архитекторы урынын да тәкъдим итәләр. Әмма егетне туган яклары тарта. Уфага кайтып, ул проектлау буенча баш архитектор булып эшкә урнаша. Озак та үтми, архитекторлар союзына әгъза итеп алына. Инде хәзер Башкортостанда иҗатын җәелдереп җибәрергә, үсәргә бөтен мөмкинлекләр дә бар, эшлә генә. Ләкин шул чорның астыртын сәясәте аңа да китереп суга: теләгән максатыңны гамәлгә ашырып, шәп яшисең килә икән, син паспортыңа «нәни» генә үзгәреш кертергә тиешсең. Милләтне алыштыру, башкорт булып язылу хакында югары оешмаларда да аңа тәкъдим итәләр. Ринат гариза яза, милләтен алыштырырга түгел, ә аспирантурага керергә. Мәскәүдә ул бер ел укыганнан соң күптәннән яратып йөргән якташ кызы Светланага өйләнә.

Ринат Насыйров яшьтән үк Казанны күрергә хыялланган була. Мәктәптә укыган елларында Тукай, Такташ кебек классиклар әсәрләре аша ул татарның мәркәзе — борынгы, серле Казанны яратып өлгерә. Шушы һәртөрле милли сөремнәрдән азат башкалада яшисе, иҗат итәсе килү теләге көнделендә уянган икән — гаҗәпмени, Ринат архитектор Үзбәк Алпаровка күңелендәге ачып хат юллый һәм, көттермичә, Казаннан җавап-чакыру ала. 1969 елда ул тәвәккәлләп Казанга ыргыла.

«Гасыр төзелеше» — КамАЗ Ринат Насыйровның язмышын котелмәгән юллар чатына китереп чыгара. 1973 елдан ул — Чаллы шәһәренең баш архитекторы. Дөресен әйткәндә, монда инде архитекторларга иҗади эшкә мөмкинлек калмаган, шәһәр гигант йокы урыны итеп, шул чорның стандарт үрнәгендә, Мәскәүдән үк алдан проектлаштырылып куелган. Ләкин әзер кысаларда гына яшәргә күнекмәгән, тынгысыз Ринат Насыйров иҗади акылын бер хәрәкәтсез тота алмый. Илнең иң югары иерархиясендә расланган проектны үзгәртергә берәүнең дә кодрәте житмәсен дә белә. Әмма бик теләгән очракта мәйданнарга һәйкәл-монументлар куеп, фонтаннар ясатып, шәһәрне «җылытырга», кешелекле тойгылар уята торган сәнгать ансамбльләре төзетергә була бит!



*Балачак хыяллары*

Шулай итеп, баш архитектор Мәскәүдә яшәүче скульптор, заманның бик кызыклы шәхесе — Илдар Хановны чакыртып китерә. Мексиканың бөек художнигы Давид Сикейросның укучысы буларак, Илдар Хановка нәкъ менә Чаллыда үзенең монументаль сәнгатен киң колач белән җәелдереп җибәрергә мөмкинлек туа.

Баш архитектор белән скульптор арасында иҗади дуслык тиз урнаша. Берсе — урын сайлый, әсәрнең күләмзурлыгын чамалый, икенчесе булачак скульптураны образлы итеп күзаллый, кәгазьгә төшерә.

Мин Ринат Насыйров белән быел Чаллы мәйданнарында йөреп чыктым, кайчандыр шушы ике шәхеснең кулгакул тотынышып, рухи бергәлектә ясаган скульптура әсәрләрен тамаша кылдым. Кайчандыр «буржуаз зәвык» белән төзелгән бу сәнгать әсәрләре минем өчен үзе бер ачыш иде. Әйтерсең лә бу һәйкәлләр күк катларыннан төшерелгән дә, үз тирәсенә шәфкатьле нур чәчеп, шәһәр кешеләрен һәртөрле явызлыктан саклаучы калкан булып үрә басканнар.

Чаллыга килгән бер кешенең игътибарын җәлеп итә торган скульптура әсәре бар. Сугышта үлгәннәр хөрмәтенә куелган бу һәйкәл заманында хакими даирәләр югарылыгында шактый кайнар бәхәсләр кузгата. Казаннан да, Мәскәүдән дә бер-бер артлы комиссияләр килә, һәйкәлне шартлатырга кирәк, дигән фикерләр дә калкып ала. Ринат Насыйровны партиядән чыгару белән яный башлыйлар. Җитмеш ел буена партия каһарманнарына табыну, догматик зәвык белән тәрбияләнгән, аң-белем дәрәҗәсе ягыннан да тар карашлы бәндәләр белән көрәштән «яныпа» чыккан Ринат Насыйровның чәче көмеш көл төсенә керә.

Ә сәер монумент караган саен яңа яклары белән ачыла, фәлсәфи уйларга этәрә. Бәлки ул — Җир-Ана символыдыр... Чиксезлектә очып баручы хатынкыз — тормышка мәңгелек тере сулыш бирүче, аның белән бергә яугир балалары... Кешеләрнең йөз-кыяфәтләре бозылган, яшәү мәгънәсен аңлау юлында алар әле камиллеккә ирешмәгән, шунлыктан интегүче гариппәр... Җир-Ана шушы рухи җитлекмәгән балаларын канат астына алып яктылыкка, яхшылыкка таба очып бара. Скульптураның асыл мәгънәсе әнә шундый.

Бу монумент җитмешенче еллар идеологларын куркыта, һәр көнне тукып, аңга сеңдерергә тырышкан идеалларын кимсетә-мыскыллый. Ярый әле ул чорның кайбер шәһәр башлыклары киңрәк фикерле, дөньяда барган үзгәрешләрдән әзме-күпме сабак алырга күнегеп килә. Чит илдән килгән белгечләрнең дә бу монументны мактап китүләре үз йогынтысын эшли. Ләкин Ринат Насыйровның югары кабинетлар-

да туктаусыз аңлатма бирүе, яңа төр сәнгатьне аңлатырга теләп үз-үзен аямыйча йөрүе эзсез калмый, ул йөрәген тотып егыла. Шактый озак вакытларга тормыш агышыннан аерылып, түшәмнең өметсез аклыгына карап ятарга туры килә.

Аны остазы булып өлгергән Илдар Ханов хәтәр үлем тырнагы астыннан йолып ала. Шәрык медицинасына нигезләнгән катгый тәртип-күнегүләр ясап Ринат Насыйров аякка баса. Дөньяга ул гүя рухи яктан да икенче кабат туа. Мең еллык Һинд фәлсәфәсен өйрәнеп, ул тормышында яңа борылыш ясый, үзалдына галәми максат куеп, шуңа ирешү юлында моңарчы күрелмәгән ихтыяр көченә ия була.

1990 елда ул бөтен эш урыннарына кул селтәп, тулысынча иректә иҗатка бирелә. Архитектор буларак, үз фикердәшләре белән бергә иске Чаллы төбәгендә бик югары катлы итеп түгел, ә коттедж тибындагы йортлар төзетүне гамәлгә ашыралар.

Ринат Насыйров Чаллыда оешкан Махариши университетында лекцияләр укый башлый. Идеал шәһәрләр, вед архитектурасы кануннары буенча, табигать белән тәңгәл ярашып, табигый әйберләр генә кулланып, кояш тәэсирен искә алып төзелергә тиеш. Насыйров үз укучыларына тормышны, әйләнә-тирәне әнә шулай чиксез галәмнең аерылгысыз бер өлеше нисбәтендә карап өйрәтә. Ринат Насыйров вед белеменә үзенең авыру стадиясен җиңеп үтү юлында, акыл-аңнан өстен булган яңа, серле дөньяларны үлеп-терелү мизгелендә ача.

Ул — бәхет кошын күргән шәхес. Үзенең картиналарында ул җиһан киңлегенә таралган төрле дөньяларны тасвир итә. Аның әсәрләре Европаның затлы илләрендә күргәзмәләргә куела, хәзер аны вед белеменең үзәге — Һиндстан һәм Азиянең башка илләре көтә.

Ринат Насыйров сәнгатьтә яңа дөньялар ачарлык акыл кодрәтенә ничек ирешкән соң? Оста, рәссам, кабатланмас бу иҗат әһеленең гомер китабына иелик тә, яңа битеннән укый башлыйк әле.

* * *

Аның әле без күзәткән тәрҗемәи хәле янәшәсеннән икенче гомер җебе сызылып бара. Башта сизелер-сизелмәс кенә үзенең чалымын сиздергән бу юл эчке «мин»не калку итеп, отыры күтәрә барып, шәхес буларак, Ринат әфәнде Насыйровны галәми-космик аң-акыл кодрәтенә ия булырлык дәрәҗәгә илтеп җиткерә. Архитектор чагында җиңә алмаган ясссылыкны ул рухи ирегән тойган рәссам буларак җиңүгә ирешә.

«Кайчан рәсем ясый башладың?» — дип сорагач, ул миңа болай дип җавап бирде: «Үземне белә башлаганнан бирле. Табигатьне ярата идем. Авыл кырыенда бик матур өч күл бар иде. Һәр татар өендәге кебек, безгә дә сәнгать җиле кагылган иде. Әбием, әнием, сеңелем палас, келәм тукыйлар иде. Әтием җәнлек рәсемнәре ясарга бик ярата иде. Энекәшем дә рәссам-график. Мине рәссам итәр өчен табигать үзе тырышты».

Насыйровның үсмер чагында ясаган бер картинасы сакланып калган. Зәңгәр күк, биек агачлар белән каймаланган күл. Илаһи тынлык. Бу тынлык мәңгелек белән бәйләнгән. Табигать, рәссам уенча, дөнья яралышының тере үзәге.

Студент елларында тыелган әдәбият уку Ринатның карашын баета, дөньяны фәлсәфи тирәнлектә аңлауга китерә. Мавыгып китеп, ул үзе дә поэзия хәятенә омтыла, шигырьләр яза башлый.



*Мадонна*

Ринат Насыйровның «Агыйдел» дип аталган беренче зур картинасы 1965 елда Уфада, республика күргәзмәсендә күрсәтелә. В. Чюрленисның атаклы «Мәңгелек яңгырау» әсәре рухында эшләнгән бу картина Татарстанда берничек тә кабул ителә алмас иде. Бурдюк кебек авангард остасы яшәгән, аның тәэсирендә яңа омтылышлы рәссамнар төркеме баш калкыткан Баш-

кортостанда сәнгатьнең һәртөрле агышына караш ул кадәр үк каты булмый.

Таир Сәлахов рекомендациясе белән Ринат Насыйров 1983 елда СССР художниклар берлегенә әгъза булып керә. Шуннан соң аның әсәрләре төрле күргәзмәләргә куела башлый. Хәтердә калырдае Дюссельдорфта була. Аның график рәсемнәре һәм эскизлары танылган немец рәссамы Юкер остаханәсендә күрсәтелә. Зур белгечләр тарафыннан югары бәяләнә. Сәнгать белгече, коллекционер Вальтер Лоссен аның ике картинасын сатып ала, рәссамның иҗаты хакында зур сүзләр әйтә, мондый фантастик чынбарлык алымы белән дөньяда ике генә рәссам эш итә, аның берсе Парижда иде, икенчесе — Казанда икән, бу безнең өчен көтелмәгән ачыш, ди.

Нинди рәссам ул Ринат Насыйров? Аның иҗаты кайнар бәхәсләр уятырга мөмкин, ә инде «социалистик чынбарлык» сәнгате рухында тәрбияләнгәннәр бөтенләй дә кабул итмәскә мөмкин. Насыйровның иҗатын нинди дә булса стиль кысаларына сыйдыру мөмкин түгел, гәрчә аны чит ил белгече, фантастик чынбарлык алымына кертсә дә, мин үзем, шәхсән, аның фәлсәфи (медитатив) экспрессионизм стилендә эшли дип әйтер идем. Аңа яңалыкка омтылу хас. Архитектура ягыннан бертөрле, типик кысаларда биналар төзетү белән шөгыльләнгән Насыйров, социалистик реализм киртәләреннән чыгып, сәнгатьтә үз юлын даулаган рәссамнар рәтенә килеп баса. Мондый диссидентлар плеядасына бары тик абстракт, экспрессионистик яисә бүтән төрле яңа алымнар белән эш иткән рәссамнар гына керә ала.

Ринат Насыйров рәссам-авангардист булып Чаллыда формалаша. Казан һәм Мәскәү биеклегеннән күзәтеп торган идеология бурзайларының үткен карашыннан ерак булганга күрә, Чаллыда һәртөрле экспериментлар өчен шартлар чагыштырмача уңай була. Яңа шәһәр төзелешендә үзгә мөмкинлекләр ачыла. Минем уйлавымча, нәкъ менә скульптур образлар белән эш итү кеше уй-фикерен, интеллектын бер төшкә туплау ягыннан, рәссамның дөньяга, сәнгатькә фәлсәфи карашын үстерү өчен иң шәп мәктәпләрнең берсе. Өч яклы яссылык художникның кодрәтен бергә туплый һәм аны әйләнәтирәгә чәчә. Ринат Насыйров бу кодрәтне ике яссылыклы киндергә күчерә. Аның интеллектуаль фантазиясе мизгеллек илһамга гына буйсынмый, ә озын-озак вакытлы танып белү юлына чыга. Борынгы Шәрыкның философлары югары акыл тавына омтылган бу юлга Ринат Насыйров үз язмышының борылышлары аша килә. Аның беренче укытучысы — Илдар Ханов. Хәзергесе — Махариши Махеш-йога — бөтен дөньяга танылган дин белгече, философ, җәмәгать эшлеклесе. Аның белән Насыйров Голландиядә таныша. Һәм ул аңардан фәлсәфә фәннәре үзәге — вед университеты проектын ясарга заказ ала.

Чиксез күк астында нинди генә уйлар килми кеше башына. Яңа кояш табарга хыялланган, «кеше ни өчен туган, ни өчен яши?» дигән мәңгелек сорау белән изаланган Ринатның уй-гамьгә чишмәсе балачак дөньясына барып тоташа. Аннары... клиник үлем кичерү, әнә шул үлеп терелү мизгелендә ул җанның икегә аерылганын, дөньяның сул ягын күрә. Ак һәм карадан торган ике бүленеш. Теге дөнья чагылышында да ул бизмәннең бер ягында яманлык, икенче ягында яхшылык тантана итүенә төшенә. Бу капма-каршылык һәрчак булачак, Дон-Кихот сыман, җил тегермәннәре белән көрәшүнең һич тә хаҗәте юк, моңа көченне, хәтта гомереңне бирү — акылсызлык, чөнки бу көрәштә җиңүче була алмый, дип югары көчләр менә шушы хакыйкатьне төшендерәләр аңа. Күбрәк яхшылык кылсаң, гаделлек артыр. Ринат Насыйров үзе ачкан сурәтле дөньялар аша кеше җанын матурлауны — яхшылыкны арттыру юлын сайлый.



*Сихерчегә сәяхәт*

Борынгы философларның хезмәтләрен өйрәнеп, бигрәк тә Сент-Экзюперинең «Цитадель»ен укыгач, ул серле

дөньяны ачуга якыная, Хатхи-йогадан Рамачарака һәм Вивекананда Раджа-йога өйрәтүләреннән соң ул үзе сайлаган юлга олы ышаныч белән чыга. Ринатның хатыны, фикердәше, иҗади эзләнүләрдә рухи ярдәмчесе, кайбер әсәрләрне бергәләп эшләүдә таянычы — Светлана ханым да һичбер икеләнүсез шушы кыйбланы сайлый. Светлана — әнисе ягыннан Башкортостанда элек-электән билгеле татар укытучылары Тәбризләр нәселеннән. Менә шулай ир белән хатын, ике бала үстереп, иҗатташ булып, рухи бергәлектә белем-акыл дөньясыннан янәшә атлыйлар. Иҗатта бу — ир һәм хатынның бергәлеге, илаһи чиста күңелнең башлангычы. Ринат Насыйровның шушы башлангыч сурәтләнгән ике картинасы бар: Инь — «Ачык капка», Янь — «Мәңге тере», моны галәми-фәлсәфи яссылыктан торып аңларга кирәк.

Без Ринат Насыйровның иҗатын сәнгатьнең образы һәм символы булган Хакыйкатькә күтәрелү юлында дүрт чорга аерып карый алабыз.

Беренчесе — 1965—70 еллар. Рәссам бу чорда дөньяны чынбарлыктагыча образлар аша күзаллый, монда һәртөрле шартлылык, абстракт чалымнар шәйләнә генә. Аның «Мәңгелек», «Ай кызы», «Пейзаж» һәм башка күп кенә рәсемнәре шуны раслый. Бу аның Башкортостанда яшәгән, иҗат иткән чорына туры килә. Ә инде Чаллыда үткән шактый катлаулы еллар (1978—84) аның сыналу дәвере. Сәнгатьнең дә, тормышның да асыл мәгънәсенә төшенеп, чынны ялганнан аеру чоры аның әсәрләрендә тышкы ялтыраудан, төче матурлыктан әкренләп котыла барып (андый әсәрләре: «Энергия», «Карина», «Бишче диско», «Гаилә» һ. б.), кискен контрастлардан ул инде нечкә нюансларга күчә башлый. Ә инде өченче этап (1884—1990) — «Көч», «Тәэсир», «Гармония») дип аталган триптих язылудан башланадыр, мөгаен.



*Эдельвейс*

Җиһан ничек яратыла, галәм нәрсә ул, дөньяларның бер-берсенә тәэсире ничек — рәссам буларак, Ринат Насыйровның сюжет нигезендә шушындый сораулар ята. Аның эволюциясе төсләр ярдәмендә сәнгать «телен» камилләштерүдә генә түгел, ә фикри үсеш югарылыгына җитүдә чагыла. Рәссамның иҗатын чорларга бүлеп карарга була. Иҗат әһеле һәм шәхес буларак камилләшә барган саен, аның әсәрләре дә тирән мәгънәле, югары кимәлгә ирешә бара.

Ринат Насыйровның әсәрләре хакында фикер йөртү шактый катлаулы, аларны күрергә, күңел күзең аша үткәрергә кирәк. Чөнки аның картиналары тасвирлап бирә торган сюжетка корылмаганнар. Аның картиналарында фон-җирлек гадәти түгел, галәми яссылык булып, тере агым, хәрәкәт тудыра. Төсләр, чатнап таркалалар да,

яктылыкны төрле рельефларда кабул итеп, бер-берсе белән кисешеп уйный, яссылыкны колачлап хәрәкәткә китерәләр. Безне чолгап алган гамәли дөнья Ринат Насыйров әсәрләрендә Рерихча монументаль формалар ала. Гүя рәссам читтән торып, үзе дә сокланып күзәтә, анда үзе тудырган модель-элпә төтенсез рәшә эчендә коена, һәр сызыгын йөрәге аша үткәреп, сурәтнең эченә кереп бетә. Бу яссылык энергия дулкыннары аша үз сүрүенә алып, дөнья әйләнешенә бөтереп алып кереп китә.

Киндернең рәссам-оста буяу белән салган һәр күзәнәгендә биокыр тибрәнеше, яссылык хәрәкәте ачык сизелеп торган әсәр — «Мадонна» 1987 елда ясалган. Анда, рәссамның кискен бер хәрәкәте белән, контрастлы түгәрәкләр һәм сызыклар аша көч-кодрәт тупланышы бирелгән һәм алар бердәм космик хәрәкәткә кушылып китә. Мадонна пәйда була, төрле сызыклар ташкыны арасыннан аның түгәрәк йөзен шәйлисең, кара чәчләр шарлавыгы, иңнәре һәм галәм тирәнлегендә яралган планеталар кебек түгәрәк имиләре күренә. Бу — бөтен тереклек иясенең бар итүче изге Әнкә, галәм Мадоннасы. Аның сабыйларының берсе — Җир-планета.

Ринат Насыйровның иҗади өченче этабы — галәм һәм кеше арасындагы бәйләнешне, акыл һәм гөман, тән һәм җан, матдә һәм аң арасындагы бәйләнешне эзләү чоры. Тумыштан ук кешене чолгап алган кануннар кысасыннан чыгып, һәртөрле хорафатлардан арынып, ирекле фикерләү офыгына нинди сикереш ясаганын аңлау өчен рәссамның күргәзмә залларына куелган әсәрләрен тамаша кылырга кирәк. Аларда үзгә, кабатланмаган төсләр яңгырашы.

Рәссам үзе иҗат гомерен өч дәвергә бүлеп караса да, минем фикеремчә, 1991 елдан казна эшен ташлап, хатыны Светлана белән бергә ирекле иҗатка күчүе аның дүртенче чорын билгели. Бу чорда Ринат Насыйров халыкара масштабка чыга, Европада танылып өлгерә. Анда имтиханны уңышлы үтә, хәзер инде рухи яктан шактый югары баскычта торган Шәрыкны «яулыйсы» кала. Рәссамның бу этабын эзотерик дип атарга мөмкин. Космосның серләренә төшенә барып, үз күңеле тирәнлегендә галәмнең чагылышын аң-фикер аша сурәтле образларга күчереп, рәссам аны киндергә төшерә.

Ринат Насыйровның «Серле теләк» дип исемләнгән әсәре өч эштән тора: «Тынычлык». «Моң». «Минем стихиям». Соңгы картина үзәгендә — кояш, җәядән атылган ук һәм якты түгәрәккә таба омтылган өчпочмак. Тормыш көче, иҗади илһам биргән бу хәрәкәт һәм омтылышта рәссамның эчке асылы гәүдәләнә. Әмма рәссам үзенең эчке «мин»ен галәм белән бәйләнештә ачарга омтылып кына калмый, ул заманның бәгыренә кагылган идеяне алга куеп, кешелекнең киләчәге өчен борчу-гамен дә белдерә. «Символ» (1992) дигән картинада без лалә сурәтле агач ботаклары арасында кыңгыраулар күрәбез. Алардан як-якка түгәрәк дулкыннар тарала. Лалә — төрки дөньясы белән бәйле, яңадан туу символы. Лалә, әйтерсең лә икегә аерылып, биеккә омтыла, әмма аның омтылышын, үсешен аска төшеп баручы кыңгыраулар рәте туктата. «Символ»да төрки-христиан бәйләнешләрын чагылдырган тарихи мәгънә бар. Бу әсәр халыклар арасында золым-фаҗигаләрнең кабынып китәргә мөмкинлеген кисәтә.

Тукай-Кырлайдагы скульптур композициягә бөек шагыйребезнең: «Югары ашсаң, канатың ач, вакыт җитте бүген»,— дигән алдан күреп әйтелгән хикмәтле сүзләре чокып язылган. Менә ул: җирдән күтәрелергә җыенган сыман үсмер егет, кулына күк гөмбәзен күтәргән, ә анда әллә инде болытлар, әллә инде бер-берсе белән чуалышкан әкияти образлар... Гүя Тукай образы аша бөтен бер татар халкы үзенең фаҗигале тәкъдире өстеннән калка, канатларны җәеп, җанны киереп, киләчәк язмыш кочагына талпынырга, бәхет-кош булырга чакыра.

Бу скульптураның авторлары — Ринат Насыйров, бертуган Илдар һәм Илгиз Хановлар.

Аның остаханәсе үзе яшәгән күпкатлы йортның чардагында урнашкан. Монда син табигать манзаралары чолганышында каласың. Серле дөньялар, галәми киңлек, сүз белән аңлатып бирүдән өстен сәер күренешләр, гарәп хәрефләренең илаһи тәэсире, борынгы Шәрык фәлсәфәсенең тылсымлы билгеләргә сыйган кодрәте... Әйе, Ринат Насыйров әсәрләрен күрергә, алар белән бергә-бер калып, аң белән, җан белән кабул итәрлек халәткә килергә кирәк. Шул чакта картиналардан синең күңелеңә гаделе мизгел, акыл яктылыгы күчәр.

Рәссамга бу мәлдә канатлар үсеп чыга һәм ул җирдән күк катларына күтәрелә. Шул мәлдә галәми Акыл иясе аның баш түбәсенә учын куя...

## ИСӘНМЕ, ИСПАНИЯ!

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге Республика делегациясе гыйнвар аеның соңгы ункөнлегендә Испаниягә эш визиты белән барды. Делегация составына хөкүмәт әгъзалары, зур предприятиеләр, банк һәм фирмалар җитәкчеләре, журналистлар кертелгән иде.

Визит көннәрендә сәяси эшлеклеләр, промышленность һәм финанс даирәләре вәкилләре белән эшлекле очрашулар булды. Испаниянең төп банклары, сәүдә-промышленность палатасы белән икътисадый, финанс-фәнни техник хезмәттәшлек турындагы килешүләргә кул куелды.

## Ф. МӨХӘММӘТШИН — СОГУД ГАРӘБСТАНЫНДА

Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин гыйнвар азагында кайбер республикаларның җитәкчеләре һәм күренекле мөселман дине эшлеклеләре делегациясе составында король Фахд Бен Абдель-Азиз чакыруы буенча дүрт көнлек визит белән Согуд Гарәбстанында булды. Делегация составында Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры Р. Галиев тә бар иде.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ УКРАИНАДА

15 гыйнварда Татарстан Республикасы Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров җитәкчелегендәге хөкүмәт делегациясе Украина башкаласы Киевта булды. Анда ике республика арасында сәүдә, фән, техника, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге үзара файдалы хезмәттәшлек турындагы шартнамәгә кул куелды.

## ТӨРЕК МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ

24 гыйнварда Казанның Г. Ибраһимов проспектындагы 85 А йортта Төрек мәдәнияте үзәге ачылды. Тантанага «Төрек дөньясы araштырмалары» вакыфы башканы, Истанбул университеты профессоры Туран Язган, Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә Вәлиева, Татарстанның халык язучысы Әмирхан ага Еники, Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, шәһәр һәм район хакимиятләре вәкилләре, галимнәр, укытучылар, журналистлар килгән иде.

## «КАНАТЛЫ БАРС» КОНКУРСЫ ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ АТЫЙ

Билгеле булганча, Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы узган ел «Канатлы барс» дигән исем астында иҗади конкурс игълан иткән иде. Конкурсның максаты — Татарстан Республикасының суверенитетын ныгытуга, халыкара мәйданда аның абруен күтәрүгә, демократик-хокукый дәүләтнең оешуын, республикадагы халыклар дуслыгын һәм икътисадый реформаның барышын күрсәтүгә булышлык итү иде.

Иҗади бәйгедә республикабызның танылган бик күп язучылары һәм журналистлары катнашты. Матбугатта чыккан язмаларны, эфирда яңгыраган тапшыруларны — конкурска тәкъдим ителгән материалларны карап чыкканнан соң, жюри, беренче бүләкне бирәүгә дә бирмәскә, дигән нәтиҗәгә килде.

Икенче акчалата бүләккә язучылар Марсель Галиев һәм Рашат Низамиев язмалары лаек дип табылды.

Өченче бүләкнең хуҗалары — Владимир Белосков, Марсель Зарипов, Мидхәт Миншин, Венера Якупова. Кызыксындыру бүләгенә әдип һәм журналистлардан Алмаз Алиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Флүс Латыйфи, Ринат Якуш, Мөхәммәт Мәһдиев, Илдар Низамов ия булдылар. Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга хезмәт иткән күп кенә язмалары өчен Тәлгать Бариевка иҗади бәйгенең махсус бүләге бирелде.

## «ФЛАМИНГО» БӘЙГЕСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Чаллыда озак еллар дәвамында игелекле эшләр башкарган Социалистик Хезмәт Герое Равил Низаметдиновның улы — «Фламинго» кече предприятиесенең генераль директоры Фәнис Низаметдинов, әтисе васыятен үтәп, «Фламинго», ягъни «Кызыл каз» иҗади бәйгесен ачып җибәргән иде. Күптән түгел генә аңа йомгак ясалды. Балаларны, яшүсмерләрне иң яхшы әсәрләре белән куандырганы өчен, жюри «Фламинго»ның беренче бүләген «Самира — чәчәк исеме» һәм «Кеп-кечкенә бака» дигән нәсер-хикәяләре өчен язучы Ркаил Зәйдуллага бирергә булды. Икенче бүләккә «Чикерткә» дигән лирик хикәясе өчен Мөдәррис Әгъләмов лаек булды. Өченче бүләк ихлас-самими шигырьләр бәйләме өчен шагыйрә Резидә Вәлиева өлешенә тиде.

## ТАНЫШТЫРУ КИТАБЫ

Татарстан газета-журналлар нәшриятында 10 мең данә тираж белән «Кем ул кем?» («Кто есть кто?») дигән китап басылып чыкты. Анда җөмһүриятебездәге күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр һәм язучылар, сәясәтчеләр һәм эшкуарлар турында, фоторәсемнәре белән, өч йөзгә якын белешмә бирелгән. Китапта урын алган танылган шәхесләр арасында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, тышкы икътисадый элемтәләр министры Шәүкәт Арсланов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрафҗанов, «Казанэнергокоммаш» берләшмәсенең генераль директоры Рөстәм Шакиров, Республиканың газета-журналлар нәшрияте директоры Дилбәр Хәйруллина һ. б. бар.

## «ДЕЛОВЫЕ ЛЮДИ» — ТАТАРСТАН ТУРЫНДА

«Деловые люди» журналының Татарстанга багышланган махсус саны чыкты. Анда республикабызның икътисадый потенциалын, базар мөнәсәбәтләренә күчүнең барышын, эшмәкәрлекнең гамәлгә керүен күрсәтүгә урын бирелгән.

Журналның авторлары арасында республикабыз Президенты М. Шәймиев, Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары Ф. Хәмидуллин, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Ф. Сибагатуллин, тышкы икътисадый элемтәләр министры Ш. Арсланов, язучы Туфан Миңнуллин һ. б. бар.

Журнал 100 мең данә тираж белән рус һәм инглиз телләрендә басылган.

Басманың спонсоры — Җөмһүриятебезнең Баулы районында туып үскән күренекле эшмәкәр Әнис Мөхәммәтшин җитәкләгән «Анис» фирмасы.

## ОЛУГ ЯЗУЧЫ ЮБИЛЕЕ

Күренекле әдип, проза остасы, фронтовик язучы Рафаил Төхфәтуллинга 70 яшь тулу уңае белән Әлмәт татар дәүләт драма театры бинасында зур иҗат кичәсе уздырылды.

Кичәне Әлмәт язучылар оешмасының җитәкчесе Рәзим Вәлиуллин ачты һәм алып барды. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев юбилярны Татарстан язучылары исеменнән кайнар котлады, адрес тапшырды. Татарстан Республикасының халык язучысы Гариф Ахунов юбилярның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача кереш сүз сөйләде. Шагыйрә Клара Булатова Рафаил Төхфәтуллинга багышланган балладасын укыды.

Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Сарман, Азнакай хакимиятләренең җитәкчеләре, «Татнефть» производство берләшмәсе, «Татнефтегазстрой», «Татнефтеремстрой», радиоприбор заводы, Зәй технологик транс-дылар.

## ШАГЫЙРЬГӘ ХАЛЫК ХӨРМӘТЕ

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Татарстан комсомолының М. Җәлил премиясе лауреаты, Татарстан халык депутаты Равил Фәйзуллинның тууына 50 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булып үтте. Шагыйрьне котларга республикабызның иҗат берлекләре рәисләре, Мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов җитәкчелегендә газета-журналлар мөхәррирләре, шагыйрьнең авылдашлары, райондашлары, сабакташлары һәм хезмәттәшләре килгән иде.

Тантанада Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә Вәлиева, Татарстан Премьер-министры урынбасары Илгиз Хәйруллин, Республика Фәннәр Академиясе президенты Мансур Хәсәнов катнашты.

## ШАГЫЙРЬ ТУГАН КӨНДӘ

Моннан төгәл 13 ел элек, 1981 елның гыйнварында Мамадыш районының «Чулпан» колхозында шушы төбәкнең Тулбай авылында туып-үскән күренекле шагыйрь Шәйхи Маннур исемендәге махсус премия булдырылган иде. Ул ел саен олуг әдипнең туган көнендә — 15 гыйнварда бер төркем хезмәт алдынгыларына һәм балалар өчен яхшы әсәрләр иҗат итүче язучыларга бирелеп килә.

Быел Ш. Маннур исемендәге мактаулы бүләккә ирешкән механизаторлардан Мәҗит Шакиров, Рәшит Шәрәфиев, Миңнехаҗи Даутов, алдынгы терлекчеләрдән Нәзимә Җиһаншина, Суфия Миннеханова лаек булды. Язучылардан исә Мамадышта яшәүче Вәкил Ахунҗановка, Казаннан Рәниф Шәрипов белән Ләбиб Леронга шулай ук акчалата бүләкләр һәм Почет дипломнары тапшырылды.

Яңа лауреатларны котларга Казаннан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Зиннур Мансуров, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, Ш. Маннурның иҗат мирасы комиссиясе сәркатибе Шаһинур Мостафин, Мамадыш районы хакимиятеннән Револь Гыйззәтуллин, Фаяз Габдрахманов, Маннур Газизов иптәшләр килгән иде.

## ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ МУЗЕЕ ОЕША

Әтнә районының Комыргуҗа урта мәктәбендә күренекле галим-мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани музеен оештыру буенча эш башланды. Укучылар хәзер бөек якташлары тормышына бәйле экспонатлар җыю белән мәшгульләр. Алар галимнең өченче буын оныгы Суфия ханым Мостафина белән очрашып, кызыклы истәлекләр язып алганнар.

## ЯЗУЧЫЛАР САФЫНА

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 24 декабрьдә булган чираттагы утырышында каләмдәшләребез сафына бер төркем талантлы әдипләр, шагыйрьләр кабул ителде. Алар арасында Казаннан Наил Касыймов, Индус Сирматов, Заһид Фәйзи, Түбән Камадан Таһир Нәбиуллин, Мизхәт Хәбибуллин, Хатыйп Касыймов, Кырымнан Диләвер Осман һәм Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрьләрдән Халисә Мөдәррисова, Рәшит Гатауллин, Рим Идиятуллин бар. Шулай итеп, Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалар итеп, беренче мәртәбә, күрше республикада яшәүче милләттәшләребез алынды. Хәерле сәгатьтә булсын!

## ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫ КЛУБЫ

Мәскәүдә Бөтендөнья татар зыялылары клубы ачылды. Аны нигезләүчеләр — Халыкара коммерция үзәге президенты Рәшит Ахунов, Мәскәү дәүләт университеты профессоры Зөфәр Фәтхетдинов, Россия Югары суды рәисе урынбасары Ренат Смаков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Россия телевидениесе рәисе урынбасары Рифат Сабитов, танылган кинорежиссер Булат Мансуров, биотехнология институты директоры, профессор Раиф Васыйлов, бөтен дөньяга мәгълүм академик Роберт Нигъмәтуллин.

Клубның максаты: татар халкын һәм Татарстанны киң таныту, татар мәдәнияте үсешенә ярдәм итү.

Күптән түгел әлеге клубны ачу тантанасы булды. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килгән ике йөздән артык татар зыялысы катнашты. Алар арасында галимнәр, язучылар, сәнгать эшлеклеләре дә бар иде. Тантанада кызыклы очрашулар, фикер алышулар булды, максатлар билгеләнде. Соңыннан алар Мәскәү, Казан, Уфа шәһәрләре сәнгать осталары катнашында зур концерт карадылар.

## ПОЛКОВНИК ЖУРНАЛ ЧЫГАРА

Кыргызстанның Бишкек шәһәрендә яшәүче полковник Хәйдәр Габдрахманов (тумышы белән ул Мамадыш районындагы Ямаш авылыннан) «Өмет» исемле журнал нәшер итә башлады.

Әлеге хәрби эшлекленең «Борынгы һәм бүгенге татарлар» дигән китабы да биредә яшәүче милләттәшләребез арасында зур кызыксыну уятты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият һәм сәнгатьне үстерүдәге хезмәтләре өчен, шагыйрә, «Мәгариф» журналының бүлек мөхәррире Шәрифуллина Эльмира Мөхәммәт кызына «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Полиграфиядә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен, Татарстан газета-журнал нәшрияты директоры Дилбәр Талип кызы Хәйруллина, Татарстан Президентының 1994 ел 17 гыйнвар указы нигезендә, Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.

## САЙРА, САНДУГАЧ!

24 гыйнварда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы, Г. Тукай бүләге лауреаты Әлфия Афзалованың сәхнә эшчәнлегенә 40 ел тулуга багышланган иҗат кичәсе булды.

Мәшһүр җырчыбызга Татарстан Республикасының Мактау грамотасын мәдәният министры урынбасары И. Тарханов тапшырды. Ә. Афзалованы балалары, якташлары, сәхнәдәшләре һәм дуслары котлады. Тамашачылар халкыбызның сөекле сандугачына көчле алкышлар белән аның моңына, иҗатына мәхәббәтләрен һәм тирән ихтирамнарын белдерделәр.

Кичәдә Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм Премьер-министр М. Сабиров катнашты.

## Тышлыктагы сурәтләр

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Р. Насыйровның «Ачык капкалар» исемле рәсеме.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь Әхмәт Рәшит.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосурәте

# ЯҢА КИТАПЛАР

**«Алтын Урда тарихыннан».** («Из истории Золотой Орды».)
Сәет-Галиев исемендәге Фонд һәм Татарстан рәссамнарының матди ярдәме белән чыгарылган. Казан. 1993.




Халкыбызның ерак үткәне булган Алтын Урда чорына караган хезмәтләр бездә юк дәрәҗәсендә аз иде. Алтын Урданың үткән ел уздырылган 750 еллык бәйрәм тантанасы мондый хезмәтләр туугa бер этәргеч булды. Тарих катламнары арасында күмелеп калган дәреслекне, халкыбызның гаҗәеп бай тарихлы үткән юлын күзалларга ярдәм итәрдәй тагын бер яңа җыентык — «Алтын Урда тарихыннан» дип исемләнгән китап дөнья күрде. Бу җыентык татар халкының күренекле улы — сәнгать белгече Фоат Вәлиевнең тууына 70 ел тулуга багышланган конференция материалларын үз эченә туплаган. Әлеге хезмәт белән танышып чыкканнан соң Алтын Урда тарихының чит ил галимнәре тарафыннан да зур кызыксыну белән өйрәнелгәнен күрәсең. Мондый уртак хезмәттәшлек халкыбызның ерак тарихын бөтен тулылыгы, дәреслеге белән аңларга ярдәм итәчәк.

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН. **«Гомерем дулкыннары».** *Шигырьләр.* — Казан: Татар. Кит. нәшр., 1993.



Кадыйр Сибгатуллинның Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган бу китабын укып чыкканнан соң шагыйрь кичергән хисләр белән укучы арасындагы аваздашлыкка тап буласың, күңеленнең иң яшерен почмагында гына сакланып килгән күп кенә сорауларга җавап табасың, шагыйрь үзе әйткәнчә, «хисләргә хисләр өсти алырлык» төсмерләргә юлыгасың.

Бу җыентыкка авторның төрле елларда иҗат иткән иң яхшы әсәрләре тупланган. Гомумән, китап аша шагыйрьнең бөтен иҗат юлын шактый тулы күзалларга мөмкин.

Тиражы — 1500 данә.

Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог